# Казан утлары

4. 1997





**Шигырь бәйрәме — халык бәйрәме**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**4**

**(894)**

**1997**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Г. АФЗАЛ. Ир йөрәге — сандугачлы урман. *Шигырьләр* ..... 3
К. МИҢЛЕБАЕВ. Бакый. *Роман* ..... 9
И. ГЫЙЛӘҖЕВ. Туган ил хисе. *Шигырьләр* ..... 63
З. ХӘКИМ. Гөнаһ. *Роман* ..... 69
Н. САФИНА. Язда шундый садә мәл бар ... *Шигырьләр* ..... 116
М. ВӘЛИ. Иртәнге пароход. *Новелла* ..... 120

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Проза турында сөйләшү ..... 133

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫ

С. ШӘМСИ. Куликово кыры сабаклары ..... 139

ФӘРИТ ГЫЙЛЬМИНЕҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Истә, һаман да истә ..... 161
Ф. ГЫЙЛЬМИ. Кунак кызы. Хикәя ..... 163

ХӘТЕР

Р. ШӘРӘФИЕВ. Уятмакчы булсаң ..... 168

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

М. ЮНЫС. Югалган кыйбланы табу ..... 181

УКУЧЫ СҮЗЕ

Л. ЗАКИР. Ни өчен Россия Аляскадан колак каккан? ..... 185

Котлыйбыз ..... 187
Безнең календарь ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа К. МИННИБАЕВА «Баки»; продолжение романа З. ХАКИМА «Грех»; новелла М. ВАЛИ «Утренний пароход»; стихи Г. АФЗАЛА, И. ГИЛЯЗОВА, Н. САФИНОЙ.
«Литературная критика»: разговор о современной прозе.
«К истории народа»: статьи С. ШАМСИ «Уроки Куликово поля», Р. ШАРАФИЕВА «Если хочешь разбудить... память».
«К 50-летию писателя Фарита Гильми»: статья А. ГИЛЯЗОВА, рассказ Ф. ГИЛЬМИ «Гостья».
«Новое произведение»: М. ЮНУС рецензирует рассказ А. Халима «Кыбла».
Слово читателя.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»:
«Солнечное утро» — фоторепродукция из картины художника Фаиля Зиязова; поэт Рафаэль Газизов.

## IN OUR ISSUE

'Prose and Poetry': the end of K. Minibaev's novel 'Bakii', the sequel of Z. Khakim's novel «Sin», M. Vali's short story 'Morning steamer'; the verses of G. Aphzal, I. Gilyazov, N. Saphina.
'Literary criticism': the talk about modern prose.
'To the history of nation': S. Shamsi's article 'Lessons of Kulikovo sield', R. Sharaphiev's article 'If you want to wake a memory'.
'Commemorating the 50 th anniversary of Pharit Gilmi': A. Gilyazov's article; Ph. Gilmi's sfory 'The Guest'.
'New works of Literature': M. Yunus's review of A. Khalim's story 'Kibla'.
Reader's word.
Our calendar.
In our covers: Phail Ziyazov's picture reproduction 'Sunny morning'; the well-known poet Raphail Gazizov.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев, Тәүфикъ Әйди**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 28.02.97 ел. Басарга кул куелды 2.04.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12 645. Заказ Н-81.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1997 ел.



# Гамил Афзал

## ИР ЙӨРӘГЕ — САНДУГАЧЛЫ УРМАН

### Ир йөрәге

*Ибраһим Сәлаховка*

Тамырлардан канны куа торган
Насос кына диләр йөрәкне.
Ир йөрәге — сандугачлы урман,
Ак каенлы, уйчан тирәкле.

Әкият сыман серле кара урман,
Кер дә адаш борма юл белән,
Бар тереклек ямен сөя торган,
Күңелдәге серле кыл белән.

Каян килә икән Идел-Йортка,
Халыкка һәм илгә тугрылык,
Күз дә йоммый, кереп янган утка,
Җиңеп чыга торган горурлык!

Дулап торган дулкыннарда йөзеп,
Бөркет булып оча иректә,
Ялган, кара кысаларны өзеп,
Ир йөрәге бозны эретә.

Җан җылысыз баракларда туңып,
Егыла-тора алга омтыла,
Алмаз кылыч тоткан батыр булып,
Яна, көя көрәш утында.

Йөрәк яна тәмуг кебек дөрләп,
Бәйрәм итә, җиңә, шатлана,
Җиңелә һәм өзгәләнә йөрәк,
Бәгыреннән аның кан тама.

Икейөзле хаиннардан көлә,
Күзен алмый кылыч йөзеннән,
Сүзен яклап, биек дарга менә,
Кире кайтмый әйткән сүзеннән.

Бер вакытны аңа «мат» диелә,
Буйсынудан башка юл булмый.
Соңгы чикне күреп баш иелә,
Баш иелә, йөрәк кол булмый.

Шулай туган утта янмый торган,
Суда батмый торган дөреслек.
Шундый йөрәк сызып үткән юлдан
Иң биек үрләргә ирештек.

Ир йөрәге — сандугачлы урман,
Шаулый-гөрли иртә-кич белән,
Бар тереклек ямен сөя торган,
Һәм яшәтә торган көч белән.

## Фикердәш

Әллә кайда, эт олаккан җирдә
Яшәп ята синең фикердәш,
Шул егетне тап та, бергә-бергә,
Яманлыкны сүгеп чөкердәш!

Бар ул бәхет, якты нурлы кыйбла,
Вәсвәсәдән җаның бушаныр,
Нидер көтеп яткан кырыс дөнья
Изге пәйгамбәргә ышаныр.

Әйдә, кардәш, алгарак бас әле,
Манкорт түрәләрдән курыкма,
Бу урамга кайтыр дөнья яме,
Изге бәйрәм килә бу йортка.

Хәер-дога көтеп, иңрәп яткан
Каберләргә карап боекма,
Идел бозы кебек шаулап аккан
Ата-баба данын онытма!

## Кеше булыгыз

Ач пәйгамбәр килер, ачы сүз әйтер:
— Кеше булыгыз, оланнар,
Дөрес сүз генә тынны киңәйтер,
Дөрес күңелдә иман бар.

Ач пәйгамбәр килер, ачы сүз сөйләр:
— Дөрес яшәгез, оланнар,

Дөрес күңелдә иман бар, диләр,
Бозык күңелдә елан бар...

* * *

Чичәннәр сирәк булган,
Кешенең җанын аңларга
Тәҗрибә кирәк булган.

Чичәннәр юмарт булган,
Ил агалары янында
Кадерле кунак булган.

Чичәннәр зирәк булган,
Дөньяны танып белергә
Акыллар кирәк булган:

«Адәм баласы усал,
Усалга афәт килер.

Яхшылык эшлә дә, суга сал,
Халык белмәсә балык белер.»

## Язмышлар кайнаган төбәк

Яхшыга битараф, яманга битараф,
Үзеңнең вак кайгың үзәктә.
Йөрисең ни кырып, йөрисең ни карап,
Язмышлар кайнаган төбәктә!

Болай итсәм, яхшы булыр кебек —
Иртәгәгә план корасың.
Ятсаң-торсаң, нәрсә булыр, диеп,
Киләчәктән куркып торасың.

Аягүрә басып алкышладың,
Киләчәккә карап киләсең.
Кайсы патша ничек ялгышканын
Йөз ел үткәч кенә беләсең.

Йокымсырап ята күксел дала,
Башын чайкый-чайкый үсә үлән.
Патшалар да китә, халык кала
Йөз төрле кайгысы белән.

## Авыл картлары

— Минем малай самолетлар ясый...
— Минем малай нефте чыгара...
Кибет алдындагы бүрәнәдә
Сөйләшәләр картлар үзара.

Вәкарь белән, тамак кыра-кыра,
Сакал белән сакал сөйләшә:
— Минем кызым акча санап тора.
— Минем малай медаль өләшә.

Сары сакал сөйли кырын басып,
Сыңар кулын куеп бөергә:
— Минем малай яңа шахта ачып,
Потлап алтын көри Себердә...

## Ничек яшәрсез сез?

Бу төркемгә карап уйга талам:
Бәхет, шатлык өчен тугансыз,
Ничек яшәрсез сез, газиз балам,
Әхлаксыз, намуссыз, имансыз?

Сулар ага, олан, еллар ага,
Типсә — тимер өзәр егет сез,
Ничек яшәрсез сез бу дөньяда,
Намуссыз, имансыз, өметсез?

* * *

Кайгылар килә башыңа,
Борчулы йөзләр чалыш.
Иң кыйбат нәрсә — машина,
Иң очсыз нәрсә — намус.

Баеган, бөлгән җирләргә
Моңаеп карап торам.
Иң «бөек» нәрсә — дәрәҗә,
Иң очсыз нәрсә — иман...

## Бергәлек

Мажик-урыс белән нужа күрдек,
Якты киләчәккә ышандык,
Тракторга утырып басу сөрдек,
Бәйрәмнәрдә ашка-суга йөрдек —
Каян килсен безгә дошманлык!

Кемгә тормыш авыр, кемгә җиңел,
Милләтенә аерып тормадык.
Кара эчле политиклар түгел,
Мәкер чәчеп, ялган урмадык.

Бәйрәмдә дә, матәмдә дә бергә,
Солдат булып йөрдек бер сафта.
Хуҗа булып туган-үскән җиргә,
Гөрләп яшә икән бу чакта!

Түрәләрдән шелтә, медаль алдык,
Урыс, татар, чуваш — бертигез.
Илке-салкы йөреп җыкка калдык,
Бәрәкәтсез булды бу нигез.

Әллә кемнәр хокук, власть даулый,
Тырный-тырный йөрәк ярасын.
Башын чайкый-чайкый урман шаулый,
Кайсы юллар белән барасы?

## Урал даласы

Көньяк Урал, дулкын-дулкын дала,
Ерак таулар сырты күгелҗем.
Ярты җаным өзелеп шунда кала,
Бер ядкаре булып гомернең.

Күккә ашкан биек таулар иле
Хәвефле дә кебек, серле дә,
Офыклардан искән дала җиле
Итәгенә килеп сөрлегә.

Таштан-ташка сикереп сулар ага,
Тын күлләре уйчан камышлы.
Тирән серләр моңын сөйгән дала,
Кемнәр язды синең язмышны?

## Уяну

Күзеңне тырнап ачтың да,
Уянасың, милләт,
Сине кемнәр адаштырды,
Сөймәгән кыз димләп?

Итәк кисеп, терсәк ямап,
Озак юандың син,
Почет тактасына карап,
Юкка куандың син.

...Динең бетсен, телең бетсен,
Милли йөзең бетсен,
Атказанган ишәк булып,
Сөенеп яшә, мескен!

Гомерлек юлдашың булсын
Кәйлә белән көрәк!..
Заем, налог белән буды
Кызыл күзле өрәк.

Күзеңне тырнап ачтың да,
Уянасың, милләт,

Әйдә, инде алга барыйк,
Илне буйлап-иңләп!

* * *

Безнең җаннар тыныч түгел,
Тыныч булмасын да.
Ничек тыныч булсын күңел
Мәхшәр уртасында!

Нинди дәһшәт көтеп ята
Илләр чормасында —
Бүген ниләр булыр, дисең,
Иртән торасың да...

## Уртаклык

Кояш уртак, агым сулар уртак,
Ай да уртак айлы кичләрдә.
Барыр юлларыңда туктап-туктап,
Уйланасың: инде нишләргә?

Кая барсаң таламаслар микән,
Сөямәсләр кәкре каенга?
Таң атканда кайгырасың иртән,
Кояш батса — тагын кайгыда.

## Авыр туфрак

Күңелләр шомланган урыннар,
Малайлар киртәгә менгәннәр.
Картларның түшендә орденнар,
Картларның түшендә медальләр.

Бер явыз бәндәне җирлиләр.
Әзерләп куйганнар ансын-монсын.
Алай да, болай да димиләр.
— Авыр туфрагы җиңел булсын...

## Халык

Аңгыра һәм надан халык була —
Мескен кыяфәттән танып була,
Селкеп алып, утка салып була,
Яклап калып була.

Шул халыкны күккә чөеп була,
Җиргә салып, комдай төеп була,
Аркасыннан сыйпап, сөеп була,
Герой диеп була.



# Кыям Миңлебаев

## БАКЫЙ

РОМАН

### VIII баб

### «Йөзем»

*«Нәкышь бит ул тукыма шикелле:
әгәр дә син берәр төсне үз урынына,
тиешле урынга куймасаң,
ул төс аннан ертылып чыга, аерыла».*

Бакый Урманче,
1978 ел, 28 гыйнвар.

*«Монда эш бар, хезмәт куелган
моңа... Кем язды икән моны?»*

Бакый Урманче,
«Йөзем» картинасын
язганнан соң егерме
ел үткәч.

Ташкентта халыкара сәнгать бәйрәме — фестиваль үткәрделәр. Кунаклар төрле илләрдән агылды. Поезд белән килүчеләр дә хәтсез иде, тик инде самолет белән тагын да күбрәк килделәр. Сабый балалар кунакларның һәркайсына җете-кызыл розалар сузды, житү кызлар исә милли ризыклардан авыз итүен, ширбәтне татып каравын үтенде. Атна буена бөтен шәһәр, алай гынамы соң, бөтен Үзбәкстан гөр килде. Сәнгать осталарының чыгышын халык хәйран калып тамаша кылды. Артистларга җирле халыкның игътибарыннан да артык берни кирәкми, тәмам күңелләре күтәрелеп, очынып йөрделәр.

Дәрвиш Урманче сәнгать бәйрәме узганын ишетмәде түгел, ишетте болай үзе, әмма аны берәр тамашага чакыручы да булмады, үзе дә әрсезләнеп йөрмәде. Кунакларга ул көпә-көндез Нәваи урамында юлыкты. Дөресрәге, үз эше белән тиз-тиз атлап барган чакны кемнәрнеңдер французча сөйләшкәне ишетелде — колагына таныш музыка булып яңгырап килеп бәрелде. Сәнгатькәр шунда гына башын күтәреп карады.

---

Ахыры. Башы журналның февраль-март саннарында.

Әһә, актан киенгән егерме-егерме бишләр тирәсендәге, зифа буйлы, сылу гәүдәле, ачык йөзле, төз борынлы, зур авызлы француженка икән. Әллә профессиональ гадәт, әллә Габделбакыйның үзенә генә хас сыйфат иде инде, мәгәр җилкәнле көймә шикелле иттереп югары калкындырып өелгән сары чәчле, үзе балкып-елмаеп килүче, изүләре-иңнәре ачык, озын торыклары шәрә әлеге артистканы күргәч тә, аның ике ягындагы юлдашларын бөтенләй абайламады да. Француз теленең аһәңеннән, артистканың кыяфәтеннән тәмам сихерләнде, күзе тонды абзыкайның. Аны-моны уйлап өлгергәнче, сәнгатькәр, чал башын иеп:

— Je suis bien aise de vous voir a notre ville[1],— дигәнен сизми дә калды.

Тегеләр үз телләрендә сүз кушкан чал чәчле, мәһабәт кыяфәтле «абориген»ның каршысына ук килеп туктадылар. Әлеге артистка үзен иркенрәк тота иде, энҗедәй тешләрен күрсәтеп елмайды да:

— Parlez — vous franscais?[2] — дип кызыксынды.

Шуннан сөйләшеп киттеләр, Габделбакый үзенең Ренуарларга һөнәрдәш булуын аңлатты, исем-фамилиясен әйтте һәм, әлеге танышлыктан файдаланып, француз гүзәлкәенең сурәтен язарга теләге барлыгын белдерде. Моны ишеткәч, артистка башын болгап, алтынсу чәчен тузгытып, озын керфекләрен сирпеп, яңадан көлеп җибәрде. Рәхәтләнеп көлеп туйганнан соң рәссамга төбәп карады да чытлыкланыбрак:

— Comment vous avais des premlez?[3] — дип сорап куйды.

Рәссамның остаханәсе ерак түгел иде, кунакларны шундук алып та кайтты. Аларга үзенең хөҗрәсендә нәкышь әсәрләрен дә күрсәтте, бишалты портретны исә дивар буена тезеп куйды.

Хатынының, апасының тагын шундый ук олы яшьтәге кешеләрнең сурәтләрен күргәч, артистканың йөзенә сәерсенү чыкты, бу рәссам карткорының гына портретын яза ахрысы, дип уйлап алды да шундук, әдәп-фәлән саклап тормастан:

— Vous aimez ne jamais pas?[4] — диде, күзләрен уйнаткалап алды.

Рәссам аңа инсафлы гына итеп:

— Je suis vieux et laid[5],— дип җавап кайтарды. Үзе ул арада мольбертына бер кысага тарттырган киндерен җайлаштырудан туктамады. Карандаш, күмер, пастель яисә акварель белән сурәтен ясарга тотынсаң, затлы кунакның чынлап торып рәнҗүе-үпкәләве ихтимал иде. Майлы буяу белән яза ул аның сурәтен, һич тә бүтәнчә түгел.

Чибәркәйне мольберт белән янәшә утырткач, гүя хәзер генә күреп алгандай, аның юлдаш кызларына диваннан урын тәкъдим итте, икесенең дә кулларына саллы-саллы альбомнар тоттырды. Шуннан соң инде рәссам онытылып китеп эшкә керешге. Ашык-пошык эшләүне җене сөймәсә дә, бу юлы кызу тотарга туры килде. Артистка тыныч кына бер минут та утыра алмады, сөйләшүдән, башын артка ташлап көлүдән туктамады. Озын-озак уйлап торырга вакыты булмаганга, рәссам аны шулай чәчен туздырып башын артка ташлаган, көләч йөзле итеп киндергә төшерде.

Үзенең сурәтен күргәч, артистка бик тә инде канәгать булды. Башын артка ташлап, мәгърур кыяфәт алып, юлдашларына:

— Beate il y a eternel[6] — диде.

Кунакларын озаткач, рәссам ял итәргә утырмады, кулына яңадан кыл-каләмен алды, үзенең тиз арада язып ташлаган киндеренә читтән торып, кырыс күз белән карады. Портрет гәрчә натураның күңеленә хуш килсә дә, кимчелекләре тулып ята иде. Шуңа автор үзе һич тә канәгать

---

[1] Сезне үз шәһәремдә күрүемә бик шатмын (фр.).
[2] Сез французча сөйләшәсезмени?
[3] Моны ничек исбатлый аласыз?
[4] Әллә сезнең бер дә гашыйк булганыгыз юкмы?
[5] Үзем ямьсез, үзем карт.
[6] Гүзәллек картаймый, ул мәңгелек!

була алмады. Артистканың кыяфәте болай, җыйнап алганда, чыккан да сыман, тик инде аерым-аерым, детальләп, төпченебрәк караганда, күзендә дә, авызында да, муенында да, күкрәгендә дә җитешмәгән җирләре күп иде әле.

Чир китә, гадәт китми, диләр бит. Габделбакыйның гадәте — һәр яңа эшенә атналар-айлар буе бәя бирү, кимчелек-дефектларын таба тору, аларны ашыкмыйча гына кимету дә бетерү. Әлеге портретны карамаган көне булмагандыр. Шунысы рас, караган саен күңел түрендәге ризасызлык арткканнан-арта барды.

Көннәрдән бер көнне рәссам портретны әлеге хәлендә камиллеккә җиткерә алмаячагын абайлады. Моның сәбәбен дә аңлады сыман. Ихтимал, артистканың чамадан тыш чибәр булуына кызыгып та алданып, яшьтән үк өйрәнгән һәм Соловкида чагында күренекле тоткыннар белән һәр көнне сөйләшеп йөрү нәтиҗәсендә ныгыткан французча гәпләшүгә алданып та кызыгып, натураның чын матурлыгын чагылдырырга омтылгангадыр? Ихтимал, картаюы җиткәндер? Әллә югыйсә гомере буена фотографик төгәллекне бирергә генә омтылган булдыксыз бер буяучы гынадыр? Һай, абзыкаем, мондый сәнгать-фотографияң белән кемне генә сөендерерсең икән?..

Портретны өр-яңадан, сәнгатьчә иттереп язарга кирәктер. Юк шул менә, тора-торып язуның нәтиҗәсе беркайчан да юньле булмый аның. Әүвәл карандаш белән яисә күмер белән ясап карарга кирәк иде. Француженканы француз ватманына. Кәгазьнең менә шунысын алабыз аның, ярты табак өлешенә портретны күчерәбез, һәйбәтләп кенә, алла бирсә. Карандашның менә монысын алабыз, «Кохинор»ын, аның да арада бер йомшагын...

Габделбакый француз артисткасының сурәтен җиде мәртәбә карандаш белән, ике-өч тапкыр пастель белән күчереп ясады. Ул арада натура аның күз алдында торгандай, аермачык шәйләде, чибәр йөзенең һәр чалымын күңеленә тирәнгә сеңдереп өлгерде. Хәзер инде асыл затның бер генә йөз сызыгы да билгесез түгел, һәммәсе билгеле, таныш, гаҗәеп озын керфекләренең дә ясалма икәнлегенә бернинди шик тә калмады; бер шикелле нәзакәтлелек булып кабул ителгән елмаюдагы ясалмалык, кылтыйлану да сер булудан туктаган иде инде. Мәгәр портрет чыкмады да чыкмады, авторның күңеленә ятардай кыяфәткә килмичә газаплады. Атна буена гына түгел, ай буена әлеге эшеннән аерыла алмады, әмма аңа карап кына сурәттәге ясалмалык һич тә кимемәде-бетмәде. Юк, фотография үк түгел инде бу түгелен, әмма сәнгатькәр портрет ясаудагы үзенең сыналган ысулын таба гына алмый бит, үзенең кулы-почеркы ярылып ятардай табигыйлеккә-гадилеккә ирешә генә алмый лабаса! Нишләптер менә җан өреп булмый гына бит үзенә, каһәрем-зәһәрем...

Ай буена рәссам башка хатын-кыз белән күрешмәде-аралашмады, берәүне дә сагынмады-уйламады. Хыялында фәкать артистканың тешләре мәрҗән шикелле тезелеп киткән авызының җәелүе, озын керфекле зур соры күзләренең сихерле елмаюы, колагында исә яшь, дәртле, һичшиксез бәхетле чибәркәйнең бәгырьләргә үтеп керердәй сүзләре: «Гүзәллек-матурлык картаймый, ул мәңгелек!..»

Һе, мадмуазель, картлык шул синнән-миннән һич сорап тормый, албасты шикелле, өстеңә ябырыла да куя. Мин дә бит синең шикелле үк яшь идем, әйе, бар иде безнең дә яшь чаклар, чибәр чаклар — саламнан тәртә ясап, чикерткә җиккән чаклар!..

Әллә син Мәхсинә туганыйны гомер-гомергә шушындый чал чәчле булгандыр дисеңме? Әллә син минем Сара бәгырьнең яшь чагы, сөлектәй сылу вә гүзәл чагы, дәртле чагы бер дә булмагандыр дисеңме? Юк, мадмуазель, бик нык ялгышасың! Алар да синең кебек яшь иде, һәркайсы чибәр иде!..

Хәер, син үзең дә мәңге бакый гүзәллек алиһәсе булып яши алмассың, әле синең үзеңә дә килер ул картлык. Сизми дә калырсың, килер, бер дә

көттермәс... Алыптай авыз кырыйларына менә шушы-ы-ындый сырлар сызылыр... Күз төпләрең менә бола-а-ай җыерчыкланыр... Муен тирәләреңә менә мо-о-ондый буразналар ятар... Кыяфәтеңә аеруча бер күркәмлек, сиңа аңлаешлырак булсын дип әйткәндә — грация биреп торучы күкрәк шәрифләрең, французча итеп әйткәндә — бюстың менә шушыла-а-ай итеп сәлперәп төшәр...

Сәнгатькәр үзенең натурасы белән сөйләшкән-аңлашкан арада, үзе дә сизмәстән, портретның сангина белән эшләнгән вариантына сызыклар сызгалады: алтынсу купшы чәченә көмеш бөртекләр өстәде, ясалма керфекләрен икеләтә кыскартты, зур соры күзләрен чак кына кысынкырак иттерде, авызын бераз гына ямьшәйтә төште, бит алмаларыннан буразналар уздырды, муенын нечкәртте, җыерчыклар белән тутырды, мәгърур артистканың бюсты калкулыгын җуйды — сәлпәрәеп-салынып төште...

Вариантлары ишле булгач, рәссам бер дә кызганып тормады, үзалдына хәтсез чибәр француженка белән сөйләшә-сөйләшә, аңарга вәгазь укый-укый, гыйбрәтле-хикмәтле сүзләрне тукый-тукый, француз ватманына пастель белән сызгалады, бозгалады, читкәрәк китеп караганнан соң кабат буяштырды. Шулай кыландыра торгач, беркадәрле күңеле булды шикелле. Әгәр дә кәсептәшләре, нигә болай эшләдең, дип сорасалар, Габделбакый ни әйтерен тиз генә таба алмас иде. Чыннан да, чибәрләрнең чибәре, япь-яшь артистканың үзеннән олыларга мыскыллабрак каравы сәбәпче булды микән, әллә инде гүзәллек алиһәсенең сурәтенә җан өрә алмаганга үз-үзенә үчләшүе булды микән? Ничек булса булды, әмма автор бүгенге көндә япь-яшь мадмуазельне... алтмыш яшьлек мадам, карчык иттереп сурәтләде дә куйды.

Ул көнне сәнгатькәр үз эшенең ниндирәк нәтиҗә биргәнен тәгаенлианыклый алмады. Фәкать үзенең гасабилануын басты да яшьлектән үч алды... Тукта-тукта, бу рәвешле кыландыру чынлап та яшьлектән үч алу була түгелме соң? Яшьләрнең бөтен бер буыныннан үзеңнең картаюыңның каруын кайтару була түгелме соң? Алай эшләргә хакың бармы синең? Юктыр, алай ук түгелдер, син, абзыкай, бераз арттырасыңдыр, күпертеп-кабартып кына җибәрәсеңдер... Син бит өлкәннәргә ыржаеп караучы, аларны чутка алмаучы бер гүзәллек алиһәсен фәкать олыгайтып күрсәттең. Нибары шуның гына картайгач нинди булачагын тасвирладың. Картаю нәрсә ул? Башың белән уйлап карасаң, картаю дигән нәрсәнең табигать законнарына буйсыну икәнлеген искәрерсең. Димәк ки, табигатькә бертөрле дә хилафлык кылмыйсың. Шулай булгач, табигать кануннарына каршы бармагач, нишләп әле яшьлектән үч алу дигән миһербансызлыкны уйлап чыгардың? Сафсата бу, абзыкай! Бүтән берни түгел. Хәер, һич тә хафаланырлык урын да юк: кеше күзенә күрсәтерлек рәвешкә китереп ясый алганың да юк. Моның ише эскизлар бит синдә меңләгән нөсхә булырдыр. Менә шулай иттереп йөзкәен аска каратып каплап куй да кайтып ят ялгызак фатирыңа...

Ташкентны болай үзе элек-электән әйбәт белә иде рәссам. Анда барганы да бар, танышлары да юк түгел иде Габделбакыйның. Әмма инде үзен сәнгать институтына эшкә чакыргач, шунда күченеп, шәһәрнең үзәгендәге Нәваи урамына килеп төпләнгәч, эшләре бөтенләй җайга салынды. Фатиры бик иркен булуга да карамастан, форсатны ычкындырмады — рәссамнар оешмасыннан янә дә ипле генә якты бер бүлмә алып, аны көне-сәгате белән остаханә иттерде. Үзе белән алып килгән киндерләрен, картон-кәгазьләрен, буяу-мазарларын шунда ташыды. Бүлмәнең нәкъ уртасына өр-яңа мольбертын да җайлап куйды, эшләрлек итеп көйләп җибәрде.

Рәссамны гомер буена язмыш-тормыш иркәләмәде. Әмма авыр-кыен шартларда да эшеннән туктамады ул. Озак эшләми торсаң, нинди генә һөнәр иясе булсаң да, кулың ияләшкән эш тә онытыла. Шуңа ул, сабый

чакта мичне җыен кош-корт, мал-туар рәсеме белән бизәүдән туктый белмәгән рәссам, олыгайган саен вакытын отышлырак уздырырга тырышты. Йә ул үзе хәстәрләгән картон-кәгазьне алып, шуңа күзенә кереп торган берәр күренешне төшерә. Яисә шунда берәрсенең сурәтен ясап ташлый. Акварельне кулай күрмәсә, йә инде үз янында булмаса, карандаш яисә күмер белән сызгаларга керешә. Меңләгән эскизлары — әнә шулай вакытның кадерен белү, бер генә сәгатьне дә бушка уздырмау, әрәм үткәрмәү нәтиҗәсе.

Әле менә хәзер дә, мольбертын урнаштыру белән, җәһәт кенә бер чәчәк рәсеме төшерелгән эскизын алып, шуңарга карый-карый, акварель белән күзгә натюрморт ясарга ябышты. Сәгатьләр буе гынамы соң, көннәр буе эшләп тә ул ару-талуның нәрсә икәнен дә белмәде.

Хәер, Ташкентта яши башлагач та, Габделбакыйның дус-ишләре бик тиз арада бермә-бер ишәеп-күбәеп китә: элек үзе белән бер елларны Мәскәүдә укыган һәм шунда аралашкан олуг галим дә, музыкантлар вә артистлар да һәм, әлбәттә инде, рәссам халкының яше-карты аның бусагасын таптый. Яшьрәкләр белән дә, өлкәннәр белән дә сөйләшер сүзе бар аксакалның. Күңел түрендә яткан һәм беркемгә дә чишәргә ярамаган серләре булган кебек, бүгеннән ачылып сөйләрдәйләре генә дә җитәрлек, хәттин ашкан, хәтер капчыгының бавын чак-чак кына бушаткан очракта да айлар-еллар буена сөйләп бетерерлек түгел иде.

Хикмәт аның үз гомерендә күпне күргән һәм төрле телдә хәтсез күп укыган булуында гына түгел, бәлки әле тагын хәтерс искиткеч әйбәт булып, әңгәмә вакытында хәтер капчыгыннан иң урынлы, иң кызыклы хәлләрне тартып чыгару һәм гаҗәеп кызык, мавыктыргыч иттереп сөйли белү сәләтендә дә иде. Һәй, сөйләп җибәрсә фарсының бер шаһы кичергән маҗараларны, гаптәшләре тәмам хәйран калып, дөньяларын онытып тыңлыйлар. Маҗаралары гыйбрәтле булуы бер хәл инде, шуны бит әле тәмләп кенә, фарсының үз сүзләрен кыстыргалап, мавыгып-онытылып сөйли белергә дә кирәк.

Гадәттә рәссам халкы хәмер эчүнең кимен куймый. Бу хәл бигрәк тә остаханәләргә ныклы тамыр җибәргән. Фәкать Урманче остаханәсендә берәүгә дә салып утырулар насыйп булмады. Картлач безнең шәһәрдә яңа кеше, әле җүнләп аякка басып өлгергәне дә юк, үзебез шешә кыстырып барыйк әле, диючеләр дә булгалады, булды. Мәгәр хуҗа аларның берсенә дә шешә ачарга рөхсәт бирмәде.

— Безгә бит, дустым, ансыз да күңелле. Без бит эш кешеләре, баш авырттырып, баш тәзәтеп маташулар безгә хәрәм,— диде, сүзендә нык торды.

Нинди генә шартларда да эшләү сәләтен җуймау-югалтмау, мөгаен, шуннан да килгәндер? Габделбакый үз гомерендә хәмергә алданмады. Табиблар аз-маз эчкәләргә киңәш биргәч кенә, сихәте булсын дип кенә, бер-ике рюмка коньякны түмен белеп кенә эчте, яки берәр төрле затлырак шәраб белән сыйланып утырды.

Иҗади эшләрен җайга салгач кына, дәртләнеп эшләп торганда гына, көннәрдән бер көнне иртә таңнан дуслары килеп керде. Хәл-әхвәл сорашканнан соң:

— Бакый әкә, без сине үзебез белән алып китәргә килдек,— диләр.— Әйдә бер сәяхәт кылып кайтыйк, булмаса.

— Юк, егетләр, эшем күп. Алай трай тибеп йөрергә һичбер төрле вакытым юк.

— Бүген бит ял көне, синең дәресең юк. Бүген синең коллегаларың барысы да табигать кочагына чума.

— Әйтмәгез дә, үгетләмәгез дә, егетләр,— дип котылмакчы булып азаплана сәнгатькәр.

Әмма тегеләр дә бирешергә уйламыйлар: яхшылык белән алдыра алмагач, усаллашып карыйлар:

— Бу хәтле кире беткән кеше булырсың икән! Синең бит әле, Бакый әкә, бездәге ямьлелекне юньләп күргәнең дә юк. Чын матурлыкны, чын Үзбәкстанны күрсәтергә исәп иттек үзеңә. Әйдә, киреләнеп маташма. Юл кешесенең юлда булганы хәерле.

— Һе! Мин сезгә иярә алырмын микән соң, егетләр? Минем бит аяк шәрифләренең рәте китебрәк тора.

— Без сине җәяү чабарга чакырмыйбыз, машина белән килдек. Машинаның да ниндие әле — «вездеход». Теләсәң нинди юлдан бара аласың. Берәр чибәркәйне күрсәң, юлсыз-нисез генә дә куып җитәрсең,— диешteләр, гөр килеп көлештеләр.

Көлүен Габделбакый да көлде, әмма тыйнаклык күрсәтү йөзеннән, әдәпле генә:

— Кая инде ул безнең эше карт-корыга яшь-җилкенчәк артыннан чабулар!..— дигән булды.

— Ичмаса, анда күз күрер, дияр идең. Без бит синең дәртле-дәрманлы иҗат иясе икәнеңне беләбез.

— Анысы шулаен шулай да, сездәй каһарманнар белән узыша алмамдыр инде, диюем...

Бүген әле юньләп эшенә кереп китә алганы юк, институтка да йөгерәсе түгел — якшәмбе көн иде. Тәвәккәлләде сәнгатькәр. Хәер, елына берике генә көн эшсез үткәргәндә дә хәрәм булмас инде анысы, дөнья җимерелмәс, күкләр ишелеп төшмәс.

Сәфәр чыгарга тәвәккәлләде тәвәккәлләвен, тик әле машинага чыгып утыргач та, җаны тынгы белмәде, әрәм китәчәк көн өчен үзен-үзе битәрләде. Совхозга барып җиткәнче шулай булды: табигатьнең яме күзенә күренмәде, әңгәмәгә юньләп катнашмады. Киң арык аркылы салынган күперне кичеп, авылга килеп кергәч кенә, бераз җанланган сымак булды, монда ниндирәк адәмнәр яши икән, дигән шикелле, тирә-ягына күз салгалады.

Машина таштан өелгән, йөзем куаклары сарып алган мәһабәт күксел бина алдына килеп туктау белән, эчтән каратут чырайлы, алыптай таза гәүдәле, ир урталары бер үзбәк чыкты, болдырдан егетләрчә төште дә, ике кулын җәеп, болар янына килә башлады.

— Хуш киләсез, кадерле кунаклар, кардәшләр, хуш киләсез! — диде.

Савхоз директоры белән күрешкәч, хәл-әхвәл сорашкач, аңа ияреп идарәгә юлландылар. Хуҗа аларны озынча өстәл тирәли уннап урындык куелган киң вә иркен бер бүлмәгә алып керде. Кунаклар утырышкан арада каяндыр олы табак белән йөзем, графин белән шәраб, җамаяклар китереп куйдылар. Башка вакыт һич тә иртә таңнан эчмәс иде сәнгатькәр, тик инде бүген барыбер эше казага калган иде, үзе генә карышып маташкан очракта кәефе тагын да ныграк кырылачак, агай-энедән, яшьләрдән отыры аерылачак, хуҗа алдында акланып торасы булачак иде. Шуларны уйлап, беткән баш беткән, диде дә һич каршылык күрсәтмәде — яртылаш кына салып биргән җамаякны авызына китерде. Шәрабның төсе дә искиткеч саф, исе дә исертерлек иде. Габделбакый ашыкмыйча гына татып карады. Аннары башын чайкап:

— Хәйран калырлык икән шәрабыгыз, әфәндем,— диде.

Хуҗаның моңа бик тә күңеле булды. Хәер, ул үзенең шәрабын яхшы белә иде, тик инде аксакалдан ягымлы сүз ишетү сөенеч өстенә сөенеч иде.

— Һе-һе-һе!.. Йөзем диңгезендә йөзәбез бит, Бакый әкә, йөзем диңгезендә. Бу әле бер тамчысы гына. Егерме ике төрле йөзем үстерәбез. Әнә берәвеннән авыз итегез,— диде, табакны аксакалга табарак шудырды.

Габделбакый, авыз итеп карауга:

— Чынлап та хәйран-тамаша икән ләбаса! — дип соклануын белдермичә булдыра алмады.

— Шула-а-ай, Бакый әкә, рас әйтәсең. Бу сорт үзе дә бит алеппо дип атала. Аның тагын шассла дигән алсуы да була булуын, тик анысы бу арада, соңгы вакытларда дигәнем, сирәгрәк очрый.

— Ишеткәнем бар алеппо дигән сортны, бар. Шәрабын да шуннан ясадыгызмы?

Кунакның күп нәрсәне белеп бетермәвенә, сөйләргә җай чыгуына хуҗа үзе сөенгән шикелле тоелды, сабыр гына аңлатып бирү ягын карады:

— Шәрабка аеруча кулай сортлар башка анысы: калабрес, изабела, суперави, мускат-франтинян... Елның-елында иренмичә хөрмәт күрсәтәсең икән, йөзем бит ул йөз ел гомер итә — өстәлеңдә шифалы шәраб була, сихәте үзеңә килә, нигъмәте янә дә өстәлә. Осталарыбыз җитәрлек хәзер, алтын куллы егетләр... Махы бирмиләр!

Сүзгә кунакларның берсе катнашыр булды:

— Башкаларны мактавың ярый анысы, әмма арада бер оста үзең инде, Иркән. Бу төбәктә йөземне синең хәтле танучы, нинди туфракта кайсы сорт әйбәтрәк үскәнне белүче бөтенләй дә юк бугай әле,— диде.

Хуҗаның күңеленә хуш килсә дә, кунакның хуплау сүзләрен ул җавапсыз калдырмады:

— Әнә яшьләр җитешә. Быел безгә дүрт егет практикага килгән иде. Институттан. Махсус шуңа ничә ел укыталар үзләрен. Алар белән алыша алмабыз, ахры...— дигән булды.

Урманченың кәефе хушланган иде, һич тә әңгәмәгә катнашмыйча, сүзсез генә утырасы килмәде:

— Болай бит ул, дустым. Ходай бирмәгән булса, институт бетереп кенә бирәү дә юньле һөнәргә ирешә алмый. Еш кына бит, Иркән, вуз бетергәннән соң нәкъ менә синдәй каһарман янына килеп, синең академиядә уку вә өйрәнү гаять зарур була. Синең академияңдә тәҗрибә-белем алгач кына, буразнага төшә, кулыннан эш килә башлый,— диде.

Директор кояшта янган беләгендәге сәгатькә күз салды да:

— Җылы-матур сүзләрегезгә мең рәхмәт. Идарәдә озаклап юанмабыз. Кояш ныгытып кыздыра башлаганчы кузгалырбыз. Йөзем бакчаларын карап әйләнербез, йөзем җыючылар белән гәпләшеп алырбыз,— диде, рәхәтләнеп җәелеп утырган кунакларны ашыктыра башлады.

Габделбакый аңа көләч йөз белән:

— Кунак хуҗаның ишәге, Иркән дустым, син кушкан җиргә барабыз, куш кына,— дип җавап кайтарды.

Идарәдән чыккач та аяз көнне кояшта ялтырап яткан асфальт юлдан алай артык озак бармадылар, басу юлы белән уңга бордырып алдылар. Юл такыр булгач, машина тизлеген киметмәде дә шикелле. Менә үргә менделәр, иңкү җиргә төштеләр. Аз-маз дыңгырдап алса да, кунакларны селкеткәләсә дә, тигез юлдан элдертте генә.

Басу юлы аткан ук сыман турыга сузылган иде. Юлның бер ягында чөгендер басуы, икенче ягында кукуруз кыры җәелгән. Бодайны урып-җыеп бетерү белән, җирен парга сөрә дә башлаганнар. Чөгендер алучылар янында директор машинаны туктаткалады, төшеп сөйләшкәләде.

Җаен туры китереп юлчылар:

— Совхозың йөзем совхозы бугай, Иркән, чөгендер белән кукуруз сиңа нигә кирәк булды соң? Шикәр заводы ачарга исәбең юктыр бит?! — дип кызыксындылар.

Директор җитди кыяфәт белән:

— Хуҗалыкта аның барысына да урын табыла. Чөгендер генә үстермибез, әле без тәмәке дә үстерәбез. Әнә, күрәсезме сул кулдагы басуны? Анда егерме гектар тәмәке үсеп утыра. Безгә ул зур табыш китерә. Быел аның яңгыры да нәкъ безгә кирәгенчә яуды, сөенеп бетә алмыйбыз,— диде.

Кунаклар шул якка борылып карадылар. Анда урман шикелле куе булып киң яфраклы, карасу-яшел тәмәке үсеп утыра иде. Аның күршесендәге нәни генә үсентеләрне күреп:

— Тегесе нәрсә? Бигрәк инде аралары сирәк,— диештеләр.

— Анысын былтыр көз генә утырттык. Алма бакчасы булачак. Үсеп киткәч, бер-беренә якыная әле алар. Аннан алдагы елларда абрикос, шафталы агачларының үсентеләрен утырткан идек, алары быел матур гына тернәкләнеп өлгерде бугай инде...

Шулай сайрашып бара торгач, юл буеннан ук башланган зур бер бакчага якынлаштылар. Хуҗа ягымлы булса да җитди кыяфәт белән:

— Менә безнең совхозның төп тераге, иң зур байлыгы шушы инде. Әйдәгез, рәхим итегез, кардәшләр,— диде.

— Хәзинәң зур икән, ай-һай! — диеште кунаклар.

Машина иләмсез киң җил капкага борылды. Барысы да җиргә төштеләр. Рәссам юл килеп бераз оеган аякларын яздырып алды да:

— Бисмиллаһи рахман иррахим,— дип, йөзем бакчасына аяк атлады. Бу вакытны ул нәкъ шушында аңа дан вә шөһрәт китерәчәк, бөтен иҗатында йөзек кашы булып балкыячак, гүзәл нәкышь әсәрен — «Йөзем» картинасын язармын, дип башына да китерми иде әле.

Йөзем бакчасының буен буйларлык кына, инен иңләрлек кенә түгел иде. Гаҗәеп киң вә иркен басуга моннан биш-ун ел элек үсентеләр утырткан булганнар, хәзер инде бакча тәмам җитлеккән, ничәнче ел инде йөзем уңышы бирә.

Көн аяз булганга кул яссуыдай киң вә челтәрле яшел яфрак араларыннан йөзем тәлгәшләре нурланып күренә. Бакчага аяк басу белән, директор кунакларына:

— Кардәшләрем, авыз итсәгез лә, үзегез сайлап алсагыз ла,— диде.

Урманче яшел яфраклар астында авыз суларын китерерлек булып, җитү кызлар түшедәй тырпаеп-калкып торган тулы гына бер тәлгәшне оста гына өзеп алды. Йөзем чыннан да тәмле иде, татлы иде. Авызы буш булмаганга, олы кунак үзенең соклануын баш чайкап белдерде. Хуҗаның йөзе балкып китте.

— Әйдәгез, узыгыз, кардәшләрем, йөзем җыючылар белән гәпләшегез, ничек эшләгәннәрен үз күзегез белән күрегез,— диде.

Казык башларына тарттырылган тимерчыбыкны сарып алган йөзем ботаклары, йөземнең киң яшел яфраклары артыннан җыючы хатыннарның башлары гына күренә. Кайсының башында яулык, кайсысында эшләпә.

Кунаклар ерактан ук аларны сәламләп:

— Алла куәт бирсен! Сәламәтмесез! Аманмысыз! — диештеләр.

Габделбакый исә йөземче хатыннарга:

— Эшегез бигрәк күркәм икән, берәр көнгә мине дә арагызга алмассыз микән? — дип сүз кушты.

Аның сүзләренә бер шаяны:

— Синдәй мут кешегә берәр көн генә җитмәстер, без күбәү бит,— дип җавап кайтарды.

Барысы да рәхәтләнеп көлештеләр. Җор кешене хупламый хәлләре юк иде. Сәнгатькәр аларга сокланып туя алмады: күр инде син аларны, үзләре шаярып та сөйләшәләр, ә менә эштән һич туктый белмәсләр, кай арада кәрзиннәрен тутырып та өлгертәләр!

Сөйләшә-көлешә, биниһая баллы йөземнән авыз итә-итә, рәт араларында озаклап йөри торгач, сәнгатькәрнең күзенә үтә җиңел-житез гәүдәле яшь кенә бер кыз бала чалынды. Шул чагында абзыең башкаларны тәмам онытты, күрмәс булды, сылу кыздан күзен ала алмас булды. Һай ул җитезлеге-өлгерлеге, һай ул йөзкәенең елмаю-балкулары, һай ул кояшта янган беләк-кулларының йөзем тәлгәшләрен кәрзиненә салгандагы матурлыгы, һай ул зифа буеның бөгелү-сыгылулары, һай ул төп-төз аякларының ипле генә йөрүләре!..

Шул сылуны күрү белән, сәнгатькәрнең хыялында могҗизалы бер күренеш пәйда булды, шундук аның чал башында «Наполеон планнары» туды, уй-фикере яшен тизлегендә йөрде.

Ул аны кояшка чыгарып, нурландырып-балкытып язачак. Бөтен сылулыгын, бөтен яшәү дәртен буй-сынына туплаячак. Иңенә кәрзин күтәртеп зифалыгын отыры калкуландырачак, муенын, беләкләрен бераз каратутрак итеп, кояшка янган матурлыгын, йөзкәенең көләч-шат икәнлеген табиги шартларда күрсәтәчәк. Алгы планга аны бастырып, калку итеп бирү өчен йөзем куакларын карсаграк итәчәк. Алай иткәндә бит аның иптәшләрен дә алырга мөмкин булачак, ә бу инде абзыкай, табигатькә тагын да ныграк якынаю дигән сүз. Әһә, янә дә бер деталь өстәү зарур булыр. Аны бит, абзыкай, Брюллов бабаң да тикмәгә кертмәгән. Белгән, Карл, бик белгән. Шәп деталь булачак картинада, шәп!

Тик менә ничек итеп сүз кушасы булыр икән әлеге кыз балага? Бигрәк яшь нәрсә бит, бигрәк яшь... Өркетеп куюың бар... Әле бит аның буе зифа булып формалашып килсә дә, тәмам өлгереп җитмәгәнлеген сукыр да күрерлек... Бер уйлаганда, бөтенләй кул тимәгән асыл зат курку-өркүнең нәрсә икәнен дә белмәскә тиеш тә бит...

Әллә югыйсә тәвәккәлләргә микән? Сәмаркандтагы кебек, ә? Юк, ярамастыр. Анда бит сөйләшү-вәгъдәләшү икәүдән-икәү барды. Ходай кушып, Шаирә остаханәгә килде. Һай, бусын да чакырып булса, Карл бабайдан уздырып мөселман кызының табигать биргән бөтен гүзәллеген-байлыгын киндердә гәүдәләндерер иде дә бит!.. Ничек итеп дәшмәк кирәк? Бердән, бик яшь. Икенчедән, үзе генә түгел. Өченчедән, авыл җире: яман атым таралмагае, дип сагаеп калачак. Нәрсә эшләргә? Һәрхәлдә, тора салып сүз кушудан юньле нәрсә чыкмас. Натураң үзенең табигый халәтендә булырга тиеш. Югыйсә портрет, һичшиксез, ясалма килеп чыгачак. Аның кыйммәте Буа базарында да тишек бер тиен...

Туктале, абзыкай, ашыкма әле син алай. Ашка пешмәгәең. Әүвәл син өлкәннәрнең сурәтен язып күрсәт. Көчеңне-сәләтеңне жәлләмә. Үзбәк агае икән, ул инде, әлбәттә, үзбәк диярлек булсын. Хезмәт кешесенең эчке гүзәллеген тап син аның, өлгерлеген-җитезлеген чагылдыр, уңганлыгын-булганлыгын тамашачыга тулаем күрсәт! Шул чагында иң сылу, иң назлы затның да илаһи сәләтенә, кодрәтенә ышануы, соклануы ихтимал. Кызлар синең эшләгән эшеңә сокландымы, кызыктымы, сагаю дигән нәрсәне исеннән үк чыгара, башы-аягы белән үзеңә гашыйк була. Шул чагында син аны бор да борыныңа тык. Әйе, абзыкай, кызыктыру мәслихәт хатыннарны-кызларны, кызыктыру, гашыйк итү...

Кайтканда Габделбакыйны танырлык та булмый: үзе дәртле, үзе балкый, үзе гел көлә дә шаяра. Юлдашлары моның серен аңламыйлар, картлачның кәефен күтәрдек әле, дип сөенәләр. Совхоз директоры исә моны үзенең шәрабыннан дип юрый. Әмма сәнгатькәр үзенең сереңхыялын бирәүгә дә чишми. Яшь-яшь кызның сурәтен язып, олы бер картина иҗат итәсем килә, дип ычкындырса, юлдашлары шундук, картыбыз гашыйк булган, дип көләчәкләр. Хуҗаларның да сагаюы бик ихтимал. Андый чакны эшкә гел комачаулык итәчәкләр. Хәйләсез берни кыра алмассың, Габделбакый абзыкай. Бөтен зирәклегеңне-тәҗрибәңне җигәргә тиешсең. Сиңа алар үзләре теләктәшлек күрсәтсен. Алар сиңа үзләре эш өчен кирәкле шартлар тудырсын. Алар сиңа үзләре кыз баланы кояшка чыгарып бастырсын. Шунда булырсың егет.

Сүзне ерактан башлады рәссам. Кайтыр алдыннан юл аягы сыптавы белән сыйланып утырган чагында совхозның хәлләрен сораштыргандай булды:

— Сездә табигать искиткеч гүзәл икән, дустым. Уңышны да матур гына, соңгармыйча җыеп алырсыз, иншалла. Тик менә бу чаклы байлык ходай кушуы белән генә барлыкка килмәгәндер ич? Әнә шунысын әйтеп бетермисең, Иркән. Хезмәт алдынгылары бардыр бит совхозыңда? Син безгә әнә шуларны сөйлә.

Ярата иде совхоз директоры үзенең эшен. Ярата иде хезмәткә җанытәне белән бирелгән эшчәннәрне. Гаиләдә үз балаларының холкынфигылен белгән кебек, Иркән дә һәр эшчәннең күркәм сыйфатын белә

иде, шуларны хәзер бик иркенләп-тәмләп, бәйнә-бәйнә сөйләп утырды.

Кунаклар аның сөйләгәнен күңел биреп тыңладылар. Габделбакый исә:

— Инде хуш, дустым Иркән, совхозында шундый да асыл кешеләр бар икән, нишләп аларның сурәтләрен шушында, әйтик менә бу диварга элеп куймаска? Ул агайларның сурәтләре бит синең яшьләреңне һәрдаим тәрбияләр иде. Аннары идарәңә ямь дә өстәр иде бит әле,— дип сүзне үз уңаена борды.

— Рас әйтәсең, Бакый әкә. Сүз дә юктыр, ямь өстенә ямь булачак. Әле мин үзем дә сиңа сүз кушарга, кылың тартып карарга уйлап тора идем. Хәзер инде аяк терәп сөйләшәм. Ясарсыңмы уңган эшчәннәремнең сурәтләрен?

— Ничә кеше булыр синдә алар?

— Өлкән яшьтәгеләре бишәү.

— Һәй, Иркән дустым, алты итәбез аны! Җиде итү бигрәк хәерле булыр. Җидегән йолдыз шикелле. Иң элек синең үзеңнең портретны язам, Аллаһы боерган булса. Аннары картларыңа чират җитәр.

— Минем сурәтне ясау килешеп бетмәс бит, Бакый әкә. Минем сурәтне монда куярга да ярамас — үзем көн-төн шушында.

— Анысы өчен бер дә борчылма, дустым. Портретыңны шундый иттереп һәйбәт киндергә майлы буяу белән язсаммы, бөтен дөньяга йөртерләр үзеңне, бер генә күргәзмәдән дә калдырмаслар. Даның тагын да ныграк үсеп китәр.

Кунаклар аның сүзен җупләп:

— Афәрин! Бик мәгъкуль! — диештеләр. Үзләре аксакалның тәвәккәлләп сүз башлавына, үгезне мөгезеннән эләктерергә яратуына хәйран калып утырдылар.

— Үзең уйлап кара инде, Иркән дустым. Үзбәк халкының синдәй күркәм йөзле, пәһлеван гәүдәле, уңган-булган егетләренең дә сурәтен ясамасам, аннары мин нигә ярыйм инде? Бернигә дә ярамыйм. Миңа һәрдаим ачык чырай күрсәтүче тугандаш үзбәк халкына мәхәббәтем юк дигән кебегрәк килеп чыга лабаса!

Идарәдә утыручылар барысы беравыздан:

— Бакый әкә, яратканың безгә мәгълүм,— диештеләр.

Сәнгатькәр үзе дә мондый чакны тыйнаклык саклап тормаска булды:

— Со-о-оң! Рас әйтәсез! Бәхәссез ич инде бу, дусларым! — дип пичәт сукты.

Хуҗа азмы-күпме уйланып утырганнан соң:

— Алайса болай килешәбез, Бакый әкә. Иң әүвәл син өлкәннәрнең, михнәт каһарманнарының сурәтләрен ясыйсың. Алардан узу миңа килешеп бетмәс. Иң ахырдан үзем өчен генә минем дә сурәтне өстисең. Ул арада совхоздагы эшләр дә түгәрәкләнә язар, вакытым да бушрак булырдыр сыман...— дигән тәкъдим ясады.

Габделбакый, нәкъ шуны гына уйлап торгандай, җавабын да кайтарды:

— Инде дә! Бирсен ходай! Корьәндә бит, дусларым, болай диелгән: «Йөдхиле мән йошазз фии рәхмәтии вә эзалиминә әаддә ләһем азәбен әлиимә».

Сәнгатькәрнең илаһи матур тавыш-мәкам белән Коръән аятен укыганы идарәдәгеләргә ошаса да, әлбәттә, алар берни аңлый алмадылар. Габделбакый үз бәһасен белеп кенә:

— Безнеңчә болайрак булыр ул,— дип төшендереп тә бирде: — Теләгән кешесене рәхмәтенә кергезер, Аңа, ягъни Аллаһы тәгаләгә, каршылык күрсәтүче залимнәргә — каты газабын бирер.

Хуҗа үзе дә, кунаклар да Урманченың рәссам гына яисә күңелле гәптәш кенә булмыйча, бәлки галим дәрәҗәсендә укымышлы зат булуына сокланып туя алмадылар.

— Тик миңа, Иркән дустым, мәркәздән синең гөлбакчаңа килү өчен берәр төрле транспорт кирәк булыр бит. Шуның хәстәрен күрсәң, янә дә бер егетлегең булыр иде.

— Иртәгә үк машина җибәрәм. Урамыңны гына әйтерсең дә...

— Иртәгә үк кирәкмәс әле. Чөнки институтта дәресләрем бар. Ә менә берсекөнгә иртән килсә машинаң, биниһая әйбәт булыр иде.

— Алып килер, Бакый әкә, алып килер. Кичен өеңә илтеп куяр. Җаның теләсә, кунарга да урын табарбыз. Җаның теләгән хәтле бездә яшәрсең.

— Һе-һе-һе! — диештеләр кунаклар. — Җылырак куенлы берәрсенә урнаштырсаң, Ташкент ягына әйләнеп тә карамас әкәбез.

Гәрчә әлеге шаяру күңелләрен тәмам эретеп җибәрсә дә, каршы җавабы әзер иде Габделбакыйның:

— Кая инде ул безгә, каткан тезгә, майлы калач, җылы түшәк!.. — дигән булды.

Ниятләгән картинасын язар өчен алынасы фонга-табигатькәияләшү, аңа детальләрне сайлау-караштыру кирәклеген истә тотып, рәссам әлеге портретларны бер генә җирдә язарга карар кылды.

Иң әүвәл тәбәнәгрәк буйлы, базык гәүдәле үзбәк агаеның сурәтен язып ташлады. Аннары мәһабәт буйлы, арыграк гәүдәле картны язарга тотынды, аның кулына китмән тоттырып, башыннан алып аягына чаклы язды. Монысын инде портрет кына диярлек түгел, бу инде хезмәт кешесен эш вакытында күрсәтү, үзбәк халкына дан җырлау иде, мактанырлык-горурланырлык иде. Хезмәт даирәсен шулчаклы да оста чагылдыруына сокланмаган кеше калмады. Йөзем җыючы хатыннар да килеп карады. Теге сылукай да аларга ияреп килде. Үзенә яхшы таныш картны күреп таныгач, елмаймыйча булдыра алмады, ә инде китәр алдыннан, берәүдән дә тартынып тормыйча, мәһабәт кыяфәтле, ай сыман балкыган рәссамга озаклап төбәп карап торды, йөзенә елмаю чыкты.

Әнә шул елмаю мәсьәләне хәл итеп ташлады. Рәссам:

— Синең дә сурәтеңне языйммы? — дип аңа турыдан-туры сүз кушты.

Сылукай башта югалып калды, ни әйтерен белмәде. Аннары инде, исенә килеп:

— Мин бит Рахман әкә шикелле михнәт каһарманы түгел, — дип каршы төште.

— Бер дә курыкма, синең кулыңа авыр китмән бирмәмен, йөзем җыя торган бәләкәй кәрзинеңне тотарсың. Син әле моннан да матуррак чыгарсың, иншалла. Үзең яшь, үзең сылу, үзең чибәр.

Йөзем җыючы хатыннарның авызлары ерылды:

— Күр инде син аны! Без бит аны карт-коры сурәтен төшерергә маһир бер молла дип торабыз. Ә ул әнә кыз баланың чибәрлеген дә шәйләп өлгергән, сурәтен дә ясамакчы. Ризалашма, Вәлидә, ризалашма! — диештеләр.

Вәлидә исә бераз гына уйланып-тынып торды да ниндидер бер яшьлек үҗәтлеге белән, чибәр затларга хас була торган табигый бер горурлык белән мәгърур елмайды:

— Хәзер үк ясыйсыңмы? — дип сорады. Кыяфәте мәгърур күренсә дә, эчке шикләнүе, билгесезлек алдында каушап калуы нәфис тавышында чагылды.

— Юк, гөлкәем, хәзер үк түгел. Иртәгә мин яңа киндер алып килермен, Аллаһы боерган булса, иртәгә иртән башларбыз. Сиңа бер генә үтенечем: теге атнада кигән алсу күлмәгеңне киеп килә алмассыңмы?

Моны ишетеп, хатыннар тагын шаулашып та гөрләшеп алдылар:

— Күлмәген дә күреп өлгергән! — диештеләр.

Җор теллесе:

— Әллә ул аны гел күлмәксез үк күргәндер, — дип, чыркылдап алды.

Сүз уйнатуга китсә, Габделбакый сезнең барыгызны да авызына каратачак бит, бер дә аптырап тормады:

— Гүзәллекне күреп соклана алмагач, матурым, ул инде рәссам булмас, бүтән кәсеп иясе булыр. Сез бит һәммәгез дә чибәрләр. Ходай тәгалә сезгә матурлыкны-уңганлыкны кызганмый биргән. Хезмәтегез дә күркәм. Ә инде алсу кулмәк дигәндә, аны рәссамнар гына ятатмый, аны бит кояш үзе дә ярата — бөтен нурларын шул тарафка юнәлдерә.

Каршы әйтүчесе, моннан да үткенрәк сүз таба алучысы булмады. Хатыннар фәкать ашыгып-кабаланып:

— Эшебез кала, әйдәгез. Моны тыңлап кич җиткәнен дә сизмәссең. Авызына шайтан төкергәндер моның,— диештеләр дә, кулына китмәнен тоткан хәлендә мәңгелеккә аяк атлаган сабыр гына холыклы, уңганбулган авылдашларына тагын бер мәртәбә күз салып, таралышу ягын карадылар.

Кайту юлында Габделбакый идарәгә сугылды. Директор анда юк иде, хәзер килә, диделәр. Аксакал аны көтәргә ниятләде. Гадәтенчә, вакытны бушка уздырмас өчен генә, рәсем альбомын алып, карандаш белән генә совхоз хисапчысының кыяфәтен кәгазьгә төшерә башлады. Эш белән мавыгып киткәнлектән, директорның шау-гөр килеп идарәгә кергәнен дә абайламый калды. Холкы шундый сәнгатькәрнең: яраткан эшенә чумдымы, гүя дөньядан ваз кичә, күзенә ак та, кара да күренми.

Директор, бүлмәгә килеп кергәч тә, рәссамны күреп елмайды, сәламләде, алай гына бер эш тә кыра алмагач, авыр гәүдәсе белән моның янындагы урындыкка ларсылдап утырды.

— Саумы, дим, Бакый әкә! Нәрсә мәтәштереп утырасың?

Рәссам аның ягына битараф караш ташлады, аннары шундук яңадан хисапчыга төбәлде. Эше беткәнгә тәмам инангач кына, хуҗага елмаеп кулын сузды.

Директор аны олылап, ике куллап күреште дә:

— Йә, нихәл, Бакый әкә, эшләрең иплө барамы?—дип кызыксынды.

Рәссам гәрчә үз эшенең кыйммәтен яхшы белсә дә, әдәплелек йөзеннән бүтәннәргә илтифатлы булырга тырыша иде.

— Минем эш барды ни дә бармады ни. Хикмәт анда түгел, Иркән дустым. Хикмәт синең басудагы эшләрең ничегрәк баруында. Йә, ничек, чөгендерне алып бетерделәрме? Йөземне һәммә җирдә тиң җыяларлармы?—дип гүләп алды.

— Көннәр бүгенге шикелле аяз торса, атна-ун көн эчендә төгәлләргә исәп тә бит... Әлегә бик иплө бара кебек. Йөземне бик пөхтә җыялар, бакчадан ташый баралар, аны әрҗәләргә матурлап кына салып, шәһәрләргә озата торалар.

— Ташыйлар дигәннән, гел шулай ат белән ташытасыңмы?—дип кызыксынды.— Ишәктер, понидыр юкмы хуҗалыгыңда?—дип тә өстәде.

— Барын бар да бит ишәк дигән мәхлүкләр, тик аларны ике тәгәрмәчле арбага җигеп, күпме генә салырсың икән? Ат арбасына син җаның теләгәнчә төйи аласың.

— Шулаен шулай да, Иркән дустым, иртәгә син миңа әнә шундый озын колаклы бер мәхлүкне юнәтсәң, янә дә бер егетлегеңнән булыр иде.

— Ишәккә атланып бакчаларны әйләнергәмени исәп?

— Юк шул менә. Бу гомердә атланылгандыр инде, җитәр. Ишәк миңа синең йөзем бакчаңда зуррак картина язганда композиция кору өчен кирәк. Әгәр сиңа авыр булмаса...

— Нәрсәсе авыр булсын ди аның! Ишәк кенә түгел, дөясен-филен дә табабыз аның, хаҗәте булса. Иртәгәдән бер ишәкне синең карамакка тапшырырлар. Анда да әле килбәтлерәген, колагы озынрагын.

Бер-берсенне аңлап эш итүгә ни җитә? Әңгәмәдән икесе дә канәгать калдылар, дустанә саубуллаштылар. Ә инде иртәгесен идарәгә якынлашканда озын колаклы шундый мәхлүкне күргәч, сәнгатькәрнең түгәрәк йөзенә елмаю җәелде. Шофер егет хайванның ни сәбәпле идарә янындагы мәһабәт тирәккә бәйләп куелганын белми иде, гудогын кычкыртып сәлам бирде. Ләкин теге ичмасам сыңар колагын да селкетмәде, башын иеп тора бирде.

Директорның монда юклыгын белгәч, рәссам машинадан төшеп тормады — иртә таннан авырткан аягын артык бимазаламау ягын карады. Шулай да бер шакмакны туп урынына тибеп уйнаучы малайларны үз янына дәшеп алды да икесенә берьюлы мөрәҗәгать итеп:

— Ишәкне сез алып килгәнсездер инде? — дип сорады.— Хатыннарны тыңламый бит ул, кызларны да тыңламый, сездәй егетләрне генә тыңласа тыңлый. Хәзер сез аны ике тәгәрмәчле җинел арбага җигеп килегез. Монда килеп тормасагыз да була, туры йөзем басуына утырып барыгыз. Шунда иркенләп йөзем ашарсыз,— диде.

Малайлар көлештеләр:

— Йөзем безнең үз бакчабызда да бар,— диештеләр.

— Һәй, берни белмисез икән. Совхозныкы тәмлерәк була бит ул. Иң эреләре, иң баллылары шунда үсә. Миңа ышанмасагыз, әнә Хаммат әкәгездән сорагыз.

Шофер егет аның сүзен җүпләп елмайды, ияк какты, аннары җилдереп алып китте.

Ишәкне рәссам кояшлы мәйданның алдына ук бастырды.

Аны читкәрәк китеп, төрле яктан карап чыкты да үзенә кулайрак позицияне эзләп тапты. Әйе, ишәк моннан әйбәтрәк күренәчәк иде. Бичара хайванны күпме генә рәнҗетмәсеннәр, мәсхәрәләмәсеннәр, ул тынычлыгын җуймый, башын аска иеп сабыр гына басып тора бирә. Нәкъ әнә шул сабырлыгы кирәк тә инде рәссамга. Бастырып куйган җирендә көннең-көн буе торсын, кузгалмасын, кымшанмасын.

Арбага рәссам йөзем тулы кәрзиннәр куйды, аларны ул матур-килешле итеп үз кулы белән урнаштырды; читкә китеп карады да кайсын кая кабат күчереп куйгалады. Нәрсәдер җитешмәгән төсле тоелгач, җиргә дә өч-дүрт кәрзин утыртты.

Картинада урын алачак һәр детальнең-нәрсәнең контурын һәйбәтләп күмер белән сызгалап чыккач кына, рәссам үзәк урынны алып торачак сылу кызны дәшәргә барды. Тәвәккәлләвен тәвәккәлләсә дә, күңелендә әле нindидер шик тамыр җәеп ята иде: килерме, кирәкле позада тора белерме, зирек тәртәле булып, кырт кына борылып ун минуттан ук китеп бармасмы? Картинада аның гүзәллеген гәүдәләндерү насыйп булырмы?

Чибәркәйне ияртеп килгәндә рәссам артына борылып карамады. Ишәге янына җитеп, экспозицияне җайлап урнаштырырга тотынгач кына, як-ягына карангалагач кына, күзе шар булды. Йөзем җыючы өлкән яшьтәге ике хатын аларга якын ук килеп, нинди хикмәтле хәлләр буласыны күзләрен терәп көтәләр иде. Гаҗәпләнүен яшерми-нитми, сәнгатькәр ярыйсы ук кырыс тавыш белән:

— Сез нишләп йөрисез әле? Сезне чакырмадым бит! — дип ярып салды.

Тегеләр дә әллә ни әдәп саклап тормадылар:

— Сабый әле ул синең шикелле мут адәм белән икәүдән-икәү генә ялгыз башкаен калдырырга,— дип җавап кайтардылар.— Кыз баланың күңелен алгысытырга син ниләр генә сайрамассың, телеңә шайтан төкергән,— дип тә өстәделәр.

Вәлиднең йөзендә ризасызлык билгеләре күреп, сәнгатькәрнең коты алынды: гасабиланып тәртәгә типмәгәе, гомерем буена язарга хыяллангән картинамны пыран-заран китермәгәе, дип шөбһәләнде, коты алынды. Ничек тә уртак тел табарга тырышып, елмайгандай итте:

— Вакытыгыз әрәм китә, димәсәгез, бергә-бергә күңеллерәк булыр, сез миңа һич тә комачауламыйсыз,— дигән булды.

Кыз баланың кояшта янып торган каратут беләгенә ичмасам нәни генә орынырга бик теләсә дә, түзде, һич кагылмады. Һай, каһәрем-зәһәрем, каян гына сарылгак булдылар әле болар, дип эчтән генә үрсәләнде. Вәлидәгә кәрзинен алырга кушты. Үзе читкәрәк китеп, экспозицияне тулаем күздән кичерде. Юк, болай кәрзин бөтенләй күренмәү генә түгел, чибәркәй үзе дә юньләп күренмәс. Кәрзинне беләгенә кияргә

киңәш бирде. Әмма әле һаман табигый бер халәт, кабатланмый торган илаһи мизгел табылып җитмәгән иде.

— Апалары, сез минем янгарак, мондарак килегез әле,— дип, теге хатыннарны кыздан аерды. Тупас кагылмады.

Вәлидә үзе генә калгач, әсәрне тулаем кузаллау җиңеләя төшкәндәй тоелды. Мәгәр күңелдәге ризасызлык, үрсәләнү бетеп җитмәгән иде әле. Менә хәзер аның янына барып, биленә йомшак кына кагылып ничегрәк торырга икәнен үзең күрсәтсәң, җиту кыз эчке бер табигый хискә буйсынып, назга эрер иде дә бөтен күркәмлеге, сылу-гүзәллеге ачылыр, тәмам балкып китәр иде.

— Матурым, син кәрзинеңне иңбашыңа алып, бераз уңгарак авыша төшсәң иде. Юк-юк, үскәнем, кәрзинеңне сул иңбашыңа алгач, икенче якка, уңга авышырга туры килә. Менә шулайрак, нәкъ шулай! Икенче иңбашыңа алып, җиңелрәк тотарга тырышып кара әле. Кәрзинең һавада асылынып торгандай булсын...

Рәссам кулына кыл-каләмен алып, алдан хәстәрләгән буяуларына иелде, әмере ничек үтәлгәнне күзәтеп тормады. Ә инде башын күтәргән иде, бигуш булып егылып китә язды. Вәлидә кәрзин тоткан уң кулын югары күтәргән, беләкләренең нәфислеге ачылган, муены матур булып күренеп тора, буе зифа, аяклары биегән сыман җиргә тияр-тимәс, гомумән, кояшта йөзе генә балкымый, бөтен барлыгы, бөтен гәүдәсе балкып яна.

Шуннан соң инде Габделбакыйның күзенә бүтән һични күренмәде: ул, дөньясын онытып, әлеге кояшлы мизгелне тизрәк эләктереп калырга, киндеренә төшерергә — мәңгеләштерергә керешге. Көннең чалт аяз икәнен күрсәтим дисәң, син инде һич тә кояшны язу белән мавыкма, аның нәрсәләрдә чагылуын ышандырырлык итеп тасвирла. Анда да әле һәр әйберне тиң итәргә, кояш нурында балкытырга тырышма, арада берен сайлап ал да, кояш нурларын бер конуска җыйган кебек, әнә шуңа тупла-юнәлдер. Бер үк зурлыктагы, бер үк төстәге ике вазаны куеп, аларга нинди генә яшелчә-җимеш салсаң да, нинди генә чәчәкләр куйсаң да — юньле тын табигать килеп чыкмаячак. Бер-беренә тиң роза, пион, хризантема яки башка төрле чәчәкләрне бергә җыеп кую гына букет дигән сүз түгел әле; син аларны биш, җиде, тугыз итәсеңме — барыбер юньле эффект бирмәячәк; әгәр дә букетың көлеп торсын дисең икән — чәчәкләрнең берсе эрерәк-зуррак булып, башкалардан аерылып торырга, калганнары аның янында фон гына булырга тиешле. Әсәрендә рәссам нәкъ әнә шундый юлны сайлаячак: гүзәлкәй иң үзәктә булу бер хәл, кояш нурлары да аны аеруча нык яктырткан итеп тасвирлаячак.

Рәссам Вәлидәнең күзләренә бераз көләчлек өстәде, тагын да карасурак иттерде. Ике бит алмасын тагын да түгәрәгрәк ясап кояшка ныграк охшашлык бирде. Борын яфракларына бераз кырыслык өстәмәкче булган иде дә, тыелып калды, дөресрәге шундый да килешле төз борынны кечтеки генә үзгәртергә дә кулы бармады. Аның каруы авызын җыйнакландыра төште, ике дә уйламады. Шуннан инде ияге дә эрерәк килеп чыкты. Мәгәр моның белән генә эш бетми, сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткерим дисәң, натураның муенына, иңнәренә, түшенә аеруча нык игътибар итәргә кирәк була. Тициан картлач та, Франсиско Гойя да, Огюст Ренуар да хатын-кызның матурлыгын күрсәтүдә моңа зур урын биргәннәр. Һәм бу табигый бер хәлдер, мөгаен. Күр инде сылукайның муены нинди зифа икәнлеген, күр син аның яңа-яңа тулып килгән нәфис алмаларын. Күр иңенең, кәрзин күтәргәч тә, гүзәллекне югалтмавын... Беләкләре сыеграк икән дә бит сыеклыгын, тик аларны пропорциягә якынлаштыру кыен булмаячак. Хәтта бераз гына арттыра төшсәң дә, зарар итмәстер. Менә шулайрак иттерәбез чибәркәйнең беләкләрен. Ә инде кулын, бармакларын аермачык язып тормабыз, картинада моның хаҗәте юк. Ә менә аякларын биегәндәге шикелле итәбез, Каворадже әсәрләрендәге төсле булсын әле. Үзбәк гүзәлен болай кояшта балкытып,

йөзем тулы кәрзин күтәртеп, табигатьнең аерылмас бер баласы иттереп, нәкъ менә шулай яланаяк килеш күрсәтү берәүнен дә башына килмәгәндер, төшләренә дә кермәгәндер әле. Балкып торыр минем Вәлидәм, үзбәк рәссамнарының ачуын китереп классикага тартым булыр, ә киндер үзе импрессионизм рухында язылганга бүгенге тамашачының күңеленә, әлбәттә, хуш килер...

Вәлидәгә монсу-ямансу булмасын өчен, йөзем җыеп ятучы хатыннарның да сурәтләрен төшерергә туры килер. Дөресрәге, силуэтларын гына. Югыйсә картинаң тип-тигез роза чәчкәләреннән җыелган букет сыман килеп чыкмагае... Әһә, ул хатыннарны аз-маз калкурак итеп күрсәтим дисәң, йөзем куакларын карсаграк итәсең бар икән. Тукта, моның Вәлидәгә зыяны-фәләне тимәсме? Әһә, тими икән. Алай гына да түгел, кояшта балкып-нурланып торган сылу кызның фигурасын тагы да калкурак иттереп күрсәтәчәк әле. Нәкъ шул кирәк тә инде рәссамга, нәкъ шул...

Офыкның киңлеген ничегрәк күрсәтү отышлырак булыр икән, ә? Зәңгәрсу итсәң, картинаңны чамадан тыш гадиләштерәчәк. Алсу итсәң? Кояш та шул якта лабаса... Юк, алай иткәндә, реализмнан кушаяклап качу булыр иде, әсәрнең табигыйлеге югалыр иде. Вәлидәнең илаһи гүзәллегенә хилафлык килер иде... Нишләргә икән соң? Нәрсә генә эшләргә икән инде?..

Ни хәтле генә тәҗрибә туплаган рәссам булмасын, Габделбакый һәр яңа әсәренә унҗиде яшьлек кыз, берәүнең дә кулы тимәгән гыйффәтле туташ итеп карый торган иде. Ничек итеп туташның эчке дөньясына үтеп керергә? Ничек итеп күңелкәен үзенә җәлеп итәргә? Ничекләр тегенең көен көйләп, гашыйк иттереп, куенына барып керергә дә һәйбәтләп кәефен-күңелен күрергә икән инде? Булдыра алырмы Бакыйҗан, хур булмасмы, адәм мәсхәрәсенә калмасмы? Гүя ул курка-курка гына кул сала, шикләнеп-шөбһәләнеп кенә якын бара, шул чагында йөрәге читлегеннән бәреп чыгарга ыргылган кош сыман талпына-чарпалана...

Әһә, Эврика! Тапты! Офыкны бит ул картинаның буеннан-буена тоташ бер тасма рәвешендә сузмаячак. Җене сөйми әнә шул тасмаларны бүтән рәссамнар язган картиналарда да... Күк белән җир берсе икенчесеннән алай кискен рәвештә аерылып торырга тиеш түгел. Габделбакый офыкны әсәрдә, гомумән, теге яки бу роль уйный алырлык дәрәҗәдән мәхрүм итәчәк, ягъни өлешчә генә калдырачак — офыкның шактый кадәресенә... тут агачлары, җимеш агачлары утыртачак! Ул чагында Вәлидә үзе дә әллә кайлардан килгән пәри кызы сыйфатында түгел, бәлки әле тәгаен шушы җирлектә, йөзем бакчасында уңыш җыючы алтын куллы уңган кыз кыяфәтендә тамашачы алдында пәйда булачак. Муафикъ андый хәл, бик тә инде менә муафикъ!

Әмма ләкин агачларны алай ук еракта аермачык язу ярамас. Ә менә аларның табигыйлегенә басым ясау нияте белән бирегәрәк, берәр груша агачы да утыртып кую мәгъкуль булырдыр сыман. Тукта, ни гомердән бирле башын аска салындырып, күзен йомып, сабыр гына басып торучы ишәк бичарага зыяны тимәсме? Агачның төбен, ишәкнең тоякларын төрле биеклектә аласың икән, һич тә зыяны тимәячәк. Әле киресенчә, картинаның уң кулдагы өлешенә нагрузка җитми иде, бушабрак калгандай тәэсир итә иде. Менә болайрак аңа нагрузка да өстәлә, куе яшел деталь дә бирелә. Җанлылык өстим дигәндә, груша агачының артына да берәр күркәмрәк деталь өстәү ягын кайгыртмыйк микән әле? Йөзем җыючы хатын сурәте ничегрәк булыр, килешерме? Юк, килешеп бетмәстер... Аннары бит әсәрнең сульяк өлешендә дә хатыннар җитәрлек. Без монда һәйбәтләп кенә бер җайдакны китереп кертик. Монда табан килә торган иттерик үзен, хәрәкәттә бирик, читтән генә әсәргә килеп кергән сымаграк тәэсир калдырсын...

Картинаның кыл үзәгендә бердәнбер Вәлидә фигурасы урын алып торырга тиешле. Мәгәр, мәгәр... Аның артында фон тоташы белән

язылган булуына да карамастан, алдында берни күренми бит әле... Бәйләнчек сәнгать белгечләренә азык калдырмыйк әле, бирәр нәрсә өстик. Һәй, абзыкай, бакчада үсеп утырган байлыкны иң-иң алгы планга чыгарып сурәтли алмассыңмыни? Булдырырсың син аны, иншалла... Менә шулай, кәрзиннәрне тәртипсез рәвештә, асимметрик итеп тезгәч, аларга түбәләмә йөзем тәлгәшләре дә тутыргач... менә шулай, менә шулай... матур гына килеп чыга икән үзе! Һай, дөнья... Әнә шул тигезлетигезсез детальләр гүя тамашачының күзен буалар — сәнгатькә генә хас илаһи бер гармония китереп чыгаралар. Хәзер инде Вәлидәнең сурәте соклангыч бер гармонияле рәвештә кереп кенә утыра. Гүя ул фани дөньяда туып-үскән кыз бала да түгел, гүя ул кояшта туган да алтын нурлар канатында йөзем бакчасына килеп төшкән, гүя ул үзе белән нурлы яктылык алып килгән, гүя ул яланаяк көенчә йөзем бакчасының эссе туфрагына, җылы чирәменә дә басып йөрми, очып кына, биеп кенә йөри... Кояшлы көндә гүя Кояш кызы биеп йөри, ә иңендә кешеләргә, тамашачыларның барчасына кәрзин тулы иң тәмле, иң татлы, иң баллы җимеш, дөньяда бер сихәтле кучтәнәч-сый күтәреп килә... Гүя ул үзе дә Кояш нурында үтәли күренә торган, тәмам өлгереп-пешеп җиткән йөзем җимеше...

«Йөзем» картинасы үзенең камиллеге вә гүзәллеге белән бөтен дөнья сынлы сәнгатендә зур урын биләгән мәшһүр әсәрләргә тиңләшерлек дәрәҗәдә килеп чыкты. Рәссам, кояшны кайсы яктан һәм ничегрәк бирергә икән инде, дип баш вата торгач, контражур белән язарга ниятләде, ягъни яктылыкны картинаның түреннән, арткы планнан бирде. Кичке эңгер иңеп килгән бер мизгел. Йөземчеләр йөзем җыялар. Урта бер җирдәге җиту кыз сурәте, аның кызыл күлмәкле, эшләп үскән сылу гәүдәсе тирә-юньдәге бар нәрсәне Кояш кебек бер фокуска тартып, җыеп тора. Иңенә бәләкәй генә кәрзин белән йөзем күтәргән, көләч йөзле ул кыз менә-менә биеп китәрдер төсле... Бу чаклы да шатлыклы, мажор картинага чынлап та сокланырлык шул: гүя бөтен әсәр тулаем бер йөземдәй кояш яктысында үтәдән-үтә күренә һәм гаҗәеп ямьле вә садә күренеш булып нурланып-балкып тора...

Тик менә Вәлидәне үземнеке дип хыяллану гына өметсез тәмамланыр микәнни? Ә бит өметләнгән иде, өмете бөтенләй үк юк түгел иде. Кая олактылар соң әле җан сакчылары? Әһә, минем арттан төшкәннәр икән, авызларын ачып киндергә текәлгәннәр. Әйдә, карап калыгыз, мөртәтләр, күргәнегез-күрмәгәнегез шул булсын. Бүген үк шәһәргә алып китәм дә, үкенеп бетә алмассыз әле мине ни рәвешле рәнҗеткәнегез өчен... Әллә боларның дөньяларын онытып картинаны караштыруларыннан файдаланып калыргамы югыйсә?

Форсатны ычкындырмаска ниятләп, рәссам угры адымнары белән арба янына килде, арбадагы кәрзиннәрне иплерәк урнаштырган булып, Вәлидәгә сүз кушты:

— Вакыт табып, остаханәмә килсәң, әйбәтрәк итеп эшләр идем, сурәтеңне махсус язып, үзеңә бүләк итәр идем,— диде һәм ник әйткәненә үкенде.

— Күр син аның мутлыгын, әй! Яшь әле ул синең хәрәмханәңә барырга, синең түшәгеңә ятарга, сабый гына әле ул! — дигән кинаяле сүзләрне колак төбендә үк ишетеп, сәнгатькәр — җир ярылса, җир тишегенә төшеп китәргә әзер булды, артына борылып карамаса да, теге бәдбәхетләрнең тагылып килүен абайлады.

Нәрсә дигән сүз инде бу, ә? Сихерләнеп, онытылып картинаны караган сыман тоелган иделәр бит, югыйсә! Хәзер инде аларны аера алмассың, дип уйлаган иде, ялгышкан булып чыга. Димәк, кызыгып карарлык берни майтара алмагансың. Димәк, йөзем җыючы хатыннар үз бакчаларында йөзем җыйганны тасвирлавыңны да ошатмадылар. Димәк, гади тамашачы күңеленә синең әсәрең бөтенләй үтеп керә алмаячак. Их, абзыкай, абзыкай, шушы яшеңә җитеп тә юньле әсәр иҗат итә алмагач...

Нәрсә белән генә алдырырга уйлыйсыңдыр, кай жирең белән алма шикелле яшь һәм чибәр кызларны каратырга өметләнәсеңдер... Чыкмады синнән юньле рәссам, абзыкай, чыкмады... Гомер эчендә бер адәм рәтле картина язу бәхетенә ирештемме, дигән идең, анысы да барып чыкмады...

Өметсезлеккә бирелсәң әгәр, күңел төшенкелеге өстенә бер ябырылса әгәр, тиз генә котылырмын димә. Таныш-белешләре белән аралашмады Габделбакый, беркая чыгып йөрмәде, шактый вакыт кыл-каләмен кулына да алмады. Тик инде бер дә эшсез тора белмәгәнгә генә карандаш белән эскизлар сызгалаштырды, кулына балчык алып, күптәнге хыялына — Тукайның сынын әвәләргә тотынды. Ни хикмәттер, хәсрәттән башы чыкмаган, фани дөньядан бик яшьли китеп барган, әмма кыска гына шул гомерендә дә искиткеч әйбәт вә камил әсәрләрен безгә мирас итеп калдырган шагыйрьнең пластик образын табу мәшәкате, иҗади эзләнүләр белән мавыгып китү нәтиҗәсендә бераз онытыла, кайгылы-кара уйлардан акрынлап арына башлаган сыман булды.

Совхозда эшләр тәмамлаганнан соң, көзге күрексез көннәрнең берендә сәнгатькәрнең остаханәсенә, ишекне шакымый-нитми генә ачып, Вәлидә үзе килеп керде. Әмма аны чакырган рәссам — әллә бүтән төрле мәшәкатькә баш-аягы белән чумганга, әллә йөземчегә күңеле сүрелгәнгә, әллә инде сафлыгыннан мәхрүм итү-рәнҗетүне гөнаһ булыр дип санаганга — сылу кызның сурәтен язудан ваз кичте, гомумән, кыз балага кагылмаска — якын бармаска булды, ачык чырай күрсәтмәде. Бичара кыз, нидер өметләнеп, беравык кына торды да, балчык изүдән һич туктый белмәгән әкәҗаннан йөз чөереп, мыштым гына урамга чыгып сызды, гарьлегеннән елый-елый кайтып китте.

Ике-өч елдан соң күргәзмәдә илаһи бер гүзәллеккә өртелгән зур күләмле киндердә үзен күреп, Вәлидәбез егылып китә язар әле. Ә инде исенә килгәч, кояш тулы картинадан күзен һич кенә дә ала алмыйча, соклanудан тәмам гаҗиз булыр әле.

Аннары күргәзмәдән тиз-тиз чыгып, рәхмәтен әйтергә дип, сәнгатькәрне эзләп янә остаханәсенә юнәлер. Анда таба алмагач, Рәссамнар оешмасын эзләп китәр.

— Кайда ул Бакый әкә? Нигә аны миннән яшерәсез? Әллә юкса авырып ятамы? Мин аны барыбер күрергә тиеш, рәхмәтемне әйтергә тиеш! — дияр сылу җиту кыз.

Чал чәчле бер үзбәк агае, аның башыннан аталарча сыйпап:

— Бездән китте шул инде аксакалыбыз, — дип төшендереп бирер. — Хәзер инде ул яшидер үз якларында, рәхәт сөрәдер туган иләндә...

> Бетте сабырым, юнәлдем үргә.
> Юл өстендә кичтем төрле жирдән,
> Биек түбәләргә
> Ләкин... житмәдем[1].

## IX баб

### «Печән базары»

*«Суга басып язып булмый...»*
Бакый Урманче,
*1975 ел, 26 май,*
*«Печән базары»*
*картинасын язганда.*

---

[1] Б. Урманче шигыре.

Гәрчә Тукай белән Урманче милли мәдәниятнең үзәге булган Казан каласына икесе дә 1907 елның көзендә күченеп килсәләр дә, алар ул вакытны, әлбәттә, аралаша алмыйлар: берсе — танылган шагыйрь, икенчесе — «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең шәкерте. Гәрчә булачак сәнгатькәребез халык шагыйренең китапларын биһуш булып укыса да, автор янына барып, танышып йөрергә һич тә җөрьәт итми әле: бик яшь була; ә инде бераз исәя төшкәч, бик барыр иде — өлгерми кала... Халык шагыйрен соңгы юлга озатучы меңләгән кеше арасында, әлбәттә, Габделбакый да була һәм гүя ул аңардан халыкка гомер буена тугрылыклы хезмәт итәргә дигән васыятен, олуг эстафетаны кабул итеп алып кала...

Тукайның портретын, мөгаен, гомерендә дә исеннән чыгармагандыр сәнгатькәр. Шуны мәрмәрдә чүкеп кую, шуны башкарып чыгу бер заман хыял булудан ашып китә — яшәвенең максатына әверелә. Һәрхәлдә, Ташкентның Сәнгать институтында укыткан дәвердә шуның дәртенә-хәстәренә бик ныклап керешә. Ихтимал, әнә шул хыялы-дәрте сынчыны янә үз иленә кайтаргандыр да әле...

Очлап чыккач — һәркем хәйран кала.

Шагыйрьнең йөз еллыгына кабат ясый.

— И, Казан, нурлы Казан!.. — дия-дия ясадым да бу вариантны. Нәкъ шундый, Казанга кайтып, дөньяга шатланып караган заманы, рухи күтәренкелек заманы! Ә беренчесен ясаганда бит, дустым: «Бетте көч...» — дип җырлаган идем...

Тукайның күпме шигырен, — әкият һәм поэмаларын әйткән дә юк инде, — мин бит кече яшьтән рәсем итеп күрә идем, һәрбересен картина буларак кабул итә идем. Әнә шул күргәннәремне иң әүвәл карандаш белән кәгазьгә дә төшергәләдем. Ул заманнарда, гомумән, карандаш белән генә эш итә идем әле, махсус белемем дә юграк иде... Бөек Тукай иҗат иткән «урман сарыгын» да тасвирларга тырышып караганымны әле дә хәтерлим. Шактый көчсез, җансыз була торган иде ул рәсемнәр...

Менә бу әйберләрне үзем бик яратам. Бу инде үзенә бер урман поэмасы. Шигърият бар монда. Табигатькә мәҗнүнчә гашыйклык бар. Җан ияләре монда — барчасы урман халкы. Гомерләрен шул урманда үткәргәч, алар бит, дустым, бөтен гәүдә төзелешләре белән дә, әлбәттә, агачларга нисбәтән булырга тиешләр. Котылгысыз зарурилык бу. Шунсыз ул җан ияләре һич кенә дә куе урман эчендә яши алмас иделәр...

Юк, явыз җан иясе түгел шүрәле минем күзаллавымча. Бер генә бөҗәкне дә рәнҗетмәс: әнә, чикерткәсе дә кәлтәсе рәхәтләнә аның өстендә! Хәтта әле куркак куян да әлләни читләшми. Тик инде шүрәленең килеш-килбәте, урман кош-кортын гәрчә өркетмәсә дә, адәм баласының котын алырлык, һуштан яздырырлык. Табигате-холкы белән дә һич инде менә хуш килердәй түгел адәм баласының күңеленә...

Менә монысы төсле вариант. Менә әле монда егетне калдырып торам хәзергә. Чөнки аңа буяу салсам — бәхәс китә буяулар арасында... Бу әйбәт буяулар белән ясалган: Англия һәм Голландия буяулары, тушы да Кытай тушы... Менә шулай төс кенә белгертсәң, гармония өчен җитә дә. Тоташ буяп чыксаң — баса аннары буяу... Бик бизәкле итеп эшләргә тырышам инде мин... Халык әкиятенә тартым. Халык әкияте дә бит матур була. Татарның чигешенә, тамбур чигешенә тартым. Буямый калдырам шүрәлене. Болай кычкырганы отышлырак бирелә: бушлыкка ул һаман кычкыра да кычкыра...

Назим белән шулай күрешеп сөйләшкән чакларында Габделбакый ара-тирә тегенең самими фикер йөртүенә соклангандай була:

— И-и-и, мсье поиет, синең фикерләвең мине хәйран калдыра!.. Җаның-рухиятең белән тәмам сәнгатькәр, коеп куйган сәнгать белгече икәнсең ләбаса!

— Арттырыбрак җибәрәсез, Бакый ага, сез бигрәк юмарт инде. Сәнгать белгечләре бит алар махсус белем алган затлар...

— Һәй, Назимҗан, шуны да белмисеңмени, аларның күпчелеге укып надан калган бит! Килә дә инде синең остаханәңә арада бер укымышлысы, текәлә синең әле генә язып тәмамлаган киндереңә — и китә тезеп, китә тезеп шаблон сүзләрне, түзеп кенә тор!

— Белгеч сүзе үзенчә бәя инде югыйсә, тик нигәдер ачуыгыз килә икән...

— Ниткән белгеч сүзе булсын ди ул, китаптан укыган сүзләр тезмәсе! Ниткән белгеч ди ул, үз фикере булмагач, булган очракта да аңлаешлы итеп, адәм рәтле әйтеп бирә алмагач!..

Шунда Назим сүзнең җаен икенчерәк юнәлешкә борып җибәрү ягын карый:

— Кәефегез кай тирәдәрәк соң, Бакый ага? Аяк шәрәфләрегез ничегрәк, бик борчымыймы?

— Аякмы? Аяк бер килеш инде... Ул бит тегендә аксап барсаң да, аксамый барсаң да барыбер. Менә минем анда аксап барырга исәп. Тик исем генә китми ул аяк авыртканга...

— Эш кешесен бик борчымаса да ярар иде дә бит...

— Менә күрәсеңме, Назимҗан дустым? Мин хәзер әле туп-туры сызам сызыкны болай. Утырып эшләгәндә мин бит аякның бар икәнен дә, юк икәнен дә сизмим! Аякны төзәтәм дип, йөрәкне эштән чыгарсаң — аннары аякның гел кирәге дә калмас...

Аксакалның сөйләшкән арада да кыл-каләмен кулыннан төшермәве, берсен куеп, икенчесен алуы, үзенә генә мәгълүм күренешне гәүдәләндерүгә егеттә соклану хисе уята иде.

— Бакый ага, табигатьнең серләрен белергә күп кеше омтыла булыр?

— Һәр рәссам иң әүвәл нәкъ әнә шуңарга омтыла, дустым. Ул аны тумыштан белгән сыман кыланып карый, ә рәсем ясый башлагач — берни килеп чыкмавына үзе үк инана.

— Һай, хаталанмыйсыз микән, Бакый ага? Үзенең эшләгән эшләренә тәнкыйть күзе белән карый алучы рәссам, гомумән, җир йөзендә дә юктыр ул.

— Бар, дустым, бар! Саф-таза гакыл иясе булган кеше үзенә һәрчак таләпчән килә. Иҗатчы икән инде — бигрәк тә. Еш кына болай да була бит әле: син үзең эшләгән эшеңнең кимчелеген бүтәннәрдән элегрәк шәйлисең. Күпме көч сарыф итеп тә, камиллеккә ирешә алмавыңны абайлыйсың...

— Сүзегезне бүләм, бигайбә, андый чакта, автор үзе житешмәгән якларын күрә икән, аңа төзәтүгә дә берни тормыйдыр?

— Алай гына түгел шул менә! Син уйлаганча, ансат кына төзәтеп, кимчелегеннән арындырып булмый шул менә! Хәлеңнән килмәгәнгә җен ачуларың чыга, әмма ләкин төзәтә алмыйсың.

— Нишләп? Сез автор ич!

— Нишләпме? Тыңла алайса, мсье поиет. Авторның бүген иҗат иткән әсәре — ул аның сәнгать баскычларына бүген менгән дәрәҗәсе. Кичә түбәнрәк баскычта булып, начаррак, калышрак картина язган булса, бүген ул бер баскычка югарырак күтәрелә һәм әйбәтрәк картина яза. Аның иҗади түшәме әнә шул. Аннан да югары китә алмый, сикерә алмый. Үзе күргән кимчелекләрне бүген үк төзәтеп, әсәрне камиллек дәрәҗәсенә җиткерергә аның хәленнән килми. Шуңа ул яңа эшен күргәзмәгә куярга ашыкмый.

— Коллегаларына күрсәтә инде, ә?

— Аларга күрсәтә. Һәм бик игътибар белән аларның сүзләренә колак сала. Күрерләрме әлеге үзе белеп торган кимчелекләрен, әллә үткәреп җибәрерләрме? Ниндирәк киңәшләр әйтерләр? Үзләре дә рәссамнар бит...

— Бакый ага! Сезнең художникларда ничегрәк соң, дөресен әйтү гадәте бармы? Чын-чынлап киңәш-табыш итү, диюем. Ягъни мәсәлән, көнчелек галәмәте генә хөкем сөрмиме?

— Сөалең четерекле бит, дустым, шуны сизәсеңме, хәйран четерекле.

— Йә, йә?

— Көнчелек галәмәте, хөсетлек син әйткәнчә үк хөкем итә алмый, иҗат дөньясын томалый алмый. Мәсьәлә болайрак бит: гадәттә сабакташлар, тиңдәшләр бер-береннән көнләшә. Ярыйсы ук нык таралган ул хиссият. Әнә шуның аркасында иске дуслар низаглаша, аралары бозыла. Әмма бу хәл һәр иҗат кешесенә дә хас түгел. Чын сәнгатькәр икенче берәүнең дә уңышына сөенергә тиеш.

— Бигрәк тә олуг уңышына.

— Дөр-р-ре-е-ес! Үз өлкәсендә эшләүче бүтән иҗатчының, син әйткәнчә, олуг уңышын күрмәүче яисә инде күрмәмешкә салышучы — беткән кеше. Нинди генә дәрәҗәле урында утырса да, аңардан милли сәнгатькә инде бертөрле дә файда килмәячәк.

— Һәм шигъриятькә дә, Бакый ага.

— Анда да шул ук хәл. Даһилыкка дәгъва кылучылар сезнең агай-эне арасында ишлерәк тә әле ул! Үзенә вә сөеклесенә,— әлбәттә, алиһә инде ул,— ошарлык тезмә юлларны яза алган шагыйрь, гадәттә, үзен инде тәмам җитлеккәнгә исәпли. Янәсе, шигърияттә ул инде балигъ булган, Тукай белән үзен тиң тота, башкалар белән сөйләшәсе дә юк, аларына ул югарыдан карый.

— Кызым, сиңа әйтәм — киленем, син тыңла, диюегез түгелдер бит?

— Һич юк, дустым, юкка хафаланма. Үз тирәмдәге кешеләргә мин болай турыдан ярдырам, тел яшерү гадәтем юк. Үзен даһига санаучы шагыйрьләр хакында сүзем. Укыйсың инде яңа шигырь китабын, кулыңа алып — шунда ук авторның ни рәвешле көчәнеп язуы, тырыша-тырмаша азапланып шигырь ясавы, рифмага сүзләрне күсәк белән дөмбәсли-дөмбәсли куып кертүе бер чакырымнан кычкырып тора. Үзеңне даһига санау гына җитми шул. Тукайның һәр шигырендә ярылып яткан гадилеккә ирешү, ай-һай ла! — бик җиңел нәрсә түгел.

— Тукайга анысы берәүнең дә җитә алганы юк әле.

— Шунда шул бөтен хикмәт тә. Күпләр гомер буе шигырь язып та, шигъриятнең серләрен белү бәхетенә ирешә алмыйча, дөнья куялар, бичаралар... Әмма иң олуг аяныч шунда ки, болар минем балаларым, алар озын гомерле булырлар, дигән өметләре дә акланмый: иҗат җимешләренең халык күңелендә сакланмаганын, аларны беркем укымаганын, берәүгә дә кирәге булмаганын үзләре үк күреп үләләр. Миңа калса, картларның берәм-берәм китә баруында түгел фаҗига, анысы аның табигый хәл; иң олуг фаҗига — олы яшькә җитеп, хыялларының чәлпәрәмә килүедер, ягъни үзенең гомерен, һөнәрен, иманын дәвам иттерергә тиешле иҗади балаларын гүргә иңдерүдер. Чөнки андый хәл — гайре табигый!

— Бакый ага, сүзегезне бүлдерәм, бигайбә. Миңа язучылар мохитында шундый гайре табигый хәлнең шаһиты булырга туры килде бит, һич онытасым юк. Әле генә сез иҗади балаларын югалтучы шагыйрьне телгә алдыгыз. Ә мин әйткәне — чын хәл. Искиткеч зур әдибебезнең студент улы кышкы каникулда иптәш малайлары белән бергә Львовка китә, анда төн уртасында газ шартлап, болар барысы да һәлак булалар. Шул егетне күмгән чагында әнисе, әлбәттә, сыгылып төште. Ә менә әтисе нык торды, сер бирмәде. Ләкин үзенең өстенә каравы да авыр иде, үзәкләреңне өзәрлек иде.

— Авызың тулы кан булса да кеше алдында төкермә, диләр бит. Егет кеше икән әдибең!

— Ләкин егет кешебезнең куе матур чәчендә аңарчы бер генә тотам ак булып, йөзенә-килбәтенә ямь биреп торса, шул фаҗигадән соң тоташы белән агарды да куйды...

— Андый зур фаҗигане беребез дә җиңел генә үткәреп җибәрә алмыйбыз шул, дустым, алмыйбыз.

— Мин сезне әңгәмәдән читкә алып киттем шикелле, гафу кылгайсыз, картым.

— Инде килик Сәйдәш кавеменә. Музыкантларның эшләре ансатрак: алар без белгән алфавитны да, өстәвенә әле нота әлифбасын да беләләр. Хәер, күбесе әнә шуңа юанып, әрсезләнеп, әллә ни баш ватмыйча гына яшәү ягын карыйлар — тапталып беткән күрексез көйләрне әз-мәз генә сипләштергәләп «яңа» көйләр чыгарып маташалар. Андый ансат юл белән «иҗат ителгән» җырларның эфирда яңгыравы да, сәхнәдән башкарылуы да бик ихтимал. Тик инде халык күңеленә үтеп керүләре һич мөмкин түгел. Чөнки сәнгатьнең серләрен белмичә генә язылган көйләрне халык кабул итми.

— Авторларын да санга сукмый.

— Дөре-е-ес! Халык үзе Сәйдәш алдында баш ия, аны даһига саный, ул чыгарган көйләргә мөкиббән китә.

— Исегездән чыгармагыз, картым, Сәйдәш берәү генә шул ул, андый талант ияләре мең елга бер генә туа.

— Алай килмә син, мсье поиет, бу мәсьәләгә! Даһи булып тумаган очракта да, талантлы сәнгатькәрләребез бөтенләй үк юк түгел. Халык әнә шул талант ияләренең бөтен күңелләрен салып, дөньяларын онытып, иҗат газапларын кичерә-кичерә, елый-елый, чиләнеп-каударланып сәнгатьнең серләренә тирәнгә үтеп керүен таләп итә, шуңа өметләнә, көтә. Әнә шулай иҗат ителгән әсәрләрне генә ихластан кабул итә.

— Бакый ага, композиторларга бит, алай язма, болай яз, дип акыл өйрәтүчеләр дә бар. Сез аларны кая куясыз?

— Һе! Соңгы сүзне түрәләр дә, тәлинкә тотучылар да әйтми, иң соңгы бәяне еллар үткәч халык үзе бирә! Менә ни сәбәпле фәкать халыкчан рухта язылган, милли моң тулы әсәрләр генә озын гомерле булучан.

— Рәсем сәнгатендә һәм шулай бит инде ул, Бакый ага, иеме?

— Инде дә! Рәсем-уем өлкәсендә шулай ук һәр ялтыраган алтын түгел, дустым. Еш кына тырышуларың гел әрәм китә.

— Үз кимчелекләрегезне күрә алгач, сез бик бәхетле кеше инде. Бу нәрсә иҗат кешеләренә, гомумән, хас түгел шикелле.

— Эшләгән чагында күзеңә бүлтәеп кереп тора бит ул, дустым, аны һич күрмичә кала алмыйсың. Кайвакыт бик тәмле ягым төшкән була. Мазок инде ул безнең рәссамнар телендә, буяуны ягып кую. Аны инде бик тә яратасың. Рәхәт булып китә. Эшли-эшли карыйсың — ул күршеләренә зарар китерә, бүлтәеп чыгып тора. Шуны кырып ташларга һич кулың бармый гына бит! Яратасың! Шуннан инде сукрана-сукрана гына: — «Һәйт!» — дисең. Кулдан шырпы тартып алган чагында авырта бит кул, монда да нәкъ шуның кебек... Әмма файдасы бар, зур файдасы.

Шулчакны Назим җайлап кына аксакалга сүз кушар булды:

— Бакый ага, Низаминың бер өзеген-хикәятен үзебезчә бирергә иде исәбем. Шуңа фатиха рәвешендә әйтеп җибәрмәссез микән «гаскәр башы» дигәнне бер сүз белән генә? Ике сүз алсам, ритмга каза килә.

Сәнгатькәр аның әйтеп бетергәнен көтте дә, нәкъ шуны гына уйлап торган шикелле, бер генә секунд та уйланып тормастан:

— Бар андый сүз бездә, бар. Элекләре бит бездә хәзергечә «воевода» димиләр иде, «салар» диләр иде. Менә сиңа бер генә сүз, тот та яз шулай! — дип үзенең фатихасын-әмерен бирде.

Назим тәмам хәйран калды. Шулай да өр-яңа соравын кыстырып өлгерде:

— Бакый ага, икенче бер әсәрдә французларның «альков» дигән сүзе бар. Ничегрәк алыйм икән шуны?

Сәнгатькәр гүя көннең-көн буена бүтән берни эшләмәгән, фәкать әлеге сүзнең тарихын һәм төрле телләрдәге вариациясен генә өйрәнгән, шундук бераз дорфарак тон белән әйтә куйды:

— Нишләп син французчаны аласың әле? Үзебезнең сүзне ал син — «әлкеббә» диген!

— Бәй! Бармыни бездә андый сүз?

— Инде дә! Син соң французлар ул сүзне каян алганнар дисең? Гарәптән алганнар, анда «әлкеббә» йөри.

Шактый вакыт башын чайкап торырга мәҗбүр булды Назим.

Гадәттә кеше дигәнең бар нәрсәне табигать күренешләре белән чагыштырса, Габделбакый һәр күргәнен скульптурага яисә майлы буяу белән язган картинага тиңли.

Төсләр — аның өчен иң ачык һәм аңлаешлы, дустанә һәм кулай чарадыр. Шунсыз шигырь дә юк, моң да юк. Гәрчә үзе сөйләргә бик яратса да, шигырь язса, матур итеп җырласа да, әңгәмә корып җибәрергә оста булса да, сүзнең кадерен белсә дә, ни хикмәттер, буяу төсләрен барча нәрсәдән дә өстенрәк күрә. Аңа калса, буяу — сүздән көчлерәк, куәтлерәк, илаһи көдрәткә ия: буяу белән теләсәң нинди фикерне, хисне, хәтта әле тезмә юллар белән, хәтта әле нота-көй белән әйтеп биреп булмастаен да әйтергә мөмкин, алай гына да түгел, йөрәктәге серләреңне, күңелдәге хисләреңне әйтүе бигрәк ансат.

Ихтимал, Ходайның һәр бирмеш көнендә буяулар һәм кыл-каләм белән эш итүе дә әнә шуннан киләдер, бик ихтимал. Югыйсә иртә таңнан эшкә тотынмас иде. Бер генә көнен дә әрәм-шәрәм итмәскә тырышмас иде. Хәер, көннең ямен дә сәнгатькәр фәкать буяу төсләренең аермачык күренү-күренмәвеннән чыгып кына бәяли. Әйтик, әбиләр чуагы, көн аяз. Габделбакый авырып «ята», дөресрәге — остаханәсендә эшләп утыра, чыгып-нитеп йөрми, ә үзенең тәмам җаны әрни:

— Мин монда утырам утыруын рәхәтләнеп... Тик, әнә, көне бит! Кояш нуры йөземә орынган саен менә монда да орына, — дип, йөрәгенә сугып ала.

Көн яктысында буяуларның тылсымына сихерләнеп эшли дә эшли сәнгатькәр, ал-ял белми. Инде буяуны төсмерләү мөмкинлеге тәмам бетеп, ахшам якынлашкач, ак белән кара бүтән төсләрне үз эченә йотып-сеңдереп бетергәч, әйләнә-тирәдә фәкать үзләре генә торып калгач — аның өчен көннең яме китә, гомумән, көн бетә.

Аксакал сәнгатькәрнең юбилей күргәзмәсенә тамашачылар өзлексез рәвештә агылып торды. Бүтән һичбер төрле күргәзмәгә йөрмәүчеләр бу юлы килде, читтә калмады. Тәбрик сүзе әйтеп, кулын кысучыларның исәбе-саны булмады. Иң зур күпчелекне, әлбәттә, шагыйрьләр һәм әдипләр тәшкил итте.

Сәнгатькәрнең юбилее уңае белән Сынлы сәнгать музееның югарыгы катында зур күргәзмә ачылганны ишеткәч, иренең елын зурдан кубып уздырырга йөргән тол хатын ничек итсә итте, әмма көн үзәгендә мәшәкатьләрдән арынып, күргәзмәгә килде. Табигатьне тасвирлаган картиналар янында үзенең портретын күреп хәйран калды ханым. Юбилярның бу портретны иң күркәм әсәрләре белән бергә элүе гаҗәпсендермәде аны. Юк. Фәкать чирек гасыр эчендә үзенең шактый олыгаеп өлгерүенә, ягъни майлы буяу белән гаять җылы тоннарда киндергә төшерелгән теге вакыттагы сурәтеннән бик нык аерылып торуына сәерсенде. И-и-и, гомер-гомер...

Мәһабәт гәүдәле, түм-түгәрәк йөзле, матур тавышлы сәнгатькәр белән конструктор ханым башкаладан кайткан чагында поездда очрашып танышкан иделәр. Бер купега туры килделәр. Чал чәчле абзыйның кыяфәте гаҗәеп яшь иде әле. Әүвәл урысча сөйләшеп алдылар: поезд китәргә ике-өч минут каларак атылып килеп кергән ханым үзе шулай исәнләште, сүз башлады. Тик бераздан соң гына абзый кеше:

— Гафу кылгайсыз, мәгәр сез бит безнең кеше булырга охшыйсыз, — дип татарча сүз кушты.

— Әллә урысчам аксыймы? Шуна әйтүегезме?

— Юк шул, ханым. Урысча артыграк дөрес сөйлисез. Урысның бит аның үзендә беркадәр ваемсызлык була сөйләшүендә, аларча әйтсәк — небрежность. Ә сездә ул юк, сез ничек тә дөресрәк сөйләргә тырышасыз.

— Коллективта гел урысча аралашырга күнегелгән инде... Минем татарчам алай шәптән түгел бит, сөйләшергә дә оялам.

— Зарар юк, туташ. Ана телендә генә рәхәтләнеп сөйләшеп кайтыйк әле. Туташ дип дөрес әйтәмме, кияүдә түгелме әле?

— Минем инде биш яшьлек улым бар...

— Сөбханалла, сөбханалла!.. Бигрәк яшь күренәсез.

— Рәхмәт! Комплиментлар әйтә беләсез икән. Сез бик интересный собеседник. Тавышыгыз да матур. Не артист случайно?

— Юк шул, ханым, артист ук булырга Ходай язмагандыр, сынлы сәнгать тирәсендә чуалам шунда...

Төне буе бәләкәй генә өстәлнең ике ягында сөйләшеп кайттылар. Яшь ханымның авиация заводында эшләгәнен белгәч, Габделбакый үзенең остаханәсе шунда якын гына икәнен әйтте, ничек итеп керергә икәнен — иң кыска юлны өйрәтте, сурәтен ясарга нияте барын сиздерде.

Сөйләшүен сөйләштеләр, һич кимен куймадылар болай, әмма Казанга кайтып җиткәндә сәнгатькәрнең гәптәшен гүя күз ачып күз йомганчы алмаштырдылар да куйдылар. Күзгә каршында өстен-башын рәтләгәннән соң ханым инде юлдашы ягына әйләнеп тә карамады — тәрәзәгә капланды. Ыспай гына ире белән бәп-бәләкәй улын күргәч, юлдашы белән юньләп-рәтләп саубуллашып та тормады — сумкаларын алды да чыгып чапты.

Үзенең әдәпсез кыланышына чибәр ханым икенче көнне генә «отчет бирде». Заводка якынлашканда чал чәчле сәнгатькәрне уйлап куйды:

— Ба-а-а, саубуллашмадым да... Нәрсә подумает минем турыда? Көтми инде ул мине, раз не обещала. Ә мин вот назло — тотам да барам мастерскоена!..

Остаханәгә көтмәгәндә-уйламаганда барып кергәч, сәнгатькәрнең үзен дә, ике-өч кунагын да һушсыз калдырган иде ул. Фигурасы да, кыяфәте дә, киенү-ясануы да һәркемнең исләрен китәрерлек иде шул. Зифа буй дисеңме, яшькелт күз, бераз калкурак почык борын, дәртле иреннәр, битендәге алмаюы дисеңме, сарыга буяткан, очып китәргә торган кыска чәч дисеңме...

Остаханә хуҗасы илаһи затка төбәлде дә телсез калды. Фәкать бераздан соң гына һушына килеп:

— Мәрхабә, ханым, хуш киләсез...— дигәне дә әллә кайлардан, мәгарәдән ишетелгән шикелле генә булды.

Аның кунаклары ул арада исләрен-һушларын җыеп өлгереп, тизрәк чыгып сызу ягын карыйлар...

Татлы мизгелләр... Рәссам аның портретын да шул чагында язган иде. Шәрәлеген әлләни күрсәтмичәрәк, гүя җиңелчә пәрдәгә төрендереп, тәненең нәфислегенә, күкрәгенең калкулыгына ир-ат халкы сокланырлык, хатын-кызлар кызыгырлык-көнләшерлек итеп, чак-чак кына чагылдырып язган иде.

Чирек гасыр гомер эчендә ханым шактый ук олыгаеп өлгерде, эшендә дә уңышлар-дан казанып, конструкторлар бюросының җитәкчесе булып алды, ахыргы елларын тыныч кына, коллективы белән тату гына эшләп калды. Тик менә яшьлеге-нәфислеге әкренләп сүндесүрелде...

Әнә хәзер үзенең ни дәрәҗәдә чибәр булганлыгын портретына карап кына исенә төшерә бугай. Зур диварга, тәрәзәгә каршы эленгән алиһәнең сурәтенә гүя кояш үзе соклана, әледән-әле аның гүзәллегенә

күз салгалый, озаклап китмичәрәк тора... Хәер, тамашачылар да битарафлык күрсәтмиләр шикелле. Әнә ич, пәрдә үтәли бөтен гүзәллеген күрергә теләгән шикелле, якын ук барып карыйлар.

Ханым үзе, кешеләргә бик үк сиздермәскә тырышып, каршы якка тәрәзә буена барып баса да... Шунда аның яшьлеге, чибәрлеге, бәхетле чаклары күз алдыннан агыла да агыла... Шундый гамьсез чакларын кайтара алса әгәр, бүгенге көндә ирешкән данын-дәрәҗәсен жәлләмәс иде. Бакый абыйсы да аның янында булыр иде...

Халкыбызның бөек шагыйре Габделла Тукай иҗат иткән «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы тәэсирендә олуг талант иясе Бакый Урманче шул ук теманы сынлы сәнгать телендә гаҗәеп зур осталык белән, һәркем аңларлык итеп тасвирлап күрсәтә.

«Печән базары» картинасы — үзе бер дөнья. Искиткеч киңлек монда; һәркем үзенчә йөри:

Берсе алдый, шунда берсе алдана...

Картинада һәркайсы үз тормышы, үз шөгыле белән яши: сәүдә итә, сатулаша, товар ташый; кәләпүшче кызлар исә үзләре каеган кәләпүшләрне төенгә төйнәп, ул төеннәрне баш түбәләренә куеп, кибеткә китерә; икенче берәүләр кибетчеләргә ризык илтә; әнә тегеләре читеккәвешне әрҗә-әрҗә олауларга төяп Усиягә озата; урам чатында — Рәсәйнең жандармы кукраеп басып тора; авыл гибады әнә тарантаста баручы бер байга мөкиббән киткән; көфер почмагы әһелләре-агайлары узып баручы курсисткалардан көлеп рәхәтләнә — алары тагын үзенә бер дөнья!

Тукайлар заманындагы татар дөньясын үз күзе белән күреп калган сәнгатькәр аны импрессионистлар рухында гәүдәләндерә. Тик шулай да, Манелардачыга, фигураларны өсте-өстенә өйми. Һава күп монда, бушлык зур, һәм әнә шул хәл киндерне, монда сурәтләнгән күренешне мәһабәт кенә бер картинага әверелдерә. Бернинди катып калган нәрсә юк монда — барчасы хәрәкәттә!

— Мин моны Тукайлар, Әмирханнар яшәгән, Идрисулла хәзрәт малае Мөхәммәтбакый «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып йөргән дәвер дип алам. Гүзәл дөнья. Бу үзе бер дөнья. Шунда һәркайсының үз шөгыле, үз дөньясы бар. Әллә син боларны, шулай гына, үзләре килеп кергән, дисеңме? Мин бервакытта да, болай булырга тиеш, тегеләй булырга тиеш, дип кенә язмыйм. Миңа башта әле таянырлык фактик материал булсын. Шуннан соң инде, үзем тәмам ышангач, эшкә керешәм. Суга басып язып булмый... Тарихи нигезең дөрес булган очракта гына максатыңа ирешү ихтималы бар. Анда да әле ихтималы гына бар. Чынлап торып максатыңа ирешү өчен күп көч куярга, иҗади эзләнүләр аша узарга, тау хәтле вариантлар ясап карарга туры килә. Ә инде күңелеңдә ышаныч беркетмичә, бернәрсә язып булмый — бигрәк тә тарихи нәрсәләрне... Тукай үзе ничек ди бит:

Бер заман бардым Печән базарына, —
Шунда мин таптым азык язарыма.
Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.
Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.
Һәр заманны монда хәлләр шул икән,
Һәркем үз хәле белән мәшгуль икән...

## X баб

### Сагыш

*«Үзебезнең әдәбият һәм сәнгать әһелләрен мәрмәргә, ташка, агачка уеп ясау эшләре минем кул белән эшләнергә тиешле иде. Сәнгать кешесе буларак, аларның портретларын киләчәк буыннарга ясап калдыру минем изге бурычым иде».*

Бакый Урманче,
*1982 ел.*

Габделбакыйның озак еллардан соң кабат Казанга кайтуының кызыклы тарихы бар.

Башкалабыз Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгатенең декадасын уздыруга иң әүвәл сугышка хәтле әзерләнәләр. Сугыш аркасында тоткарланган сәнгать тантанасын 1957 елга тәгаенлиләр. Партия өлкә комитетының идеология сәркатибенә җитәкчелек эшләрен йөклиләр.

Әдәбияттан мәгълүматы була сәркатибнең. Язучылар оешмасының рәсми җитәкчеләрен дә, китапларын үзе яратып укый торган олуг әдипләрне дә үз янына җыеп, бер генә сөйләшә — барысы да җайга салына.

Ә менә сәнгать дигәннәре... Ай-һай, чуалтканбыз икән без аны. Ярый, башкалага барып, сынлы сәнгатьнең күргәзмәсен дә күрсәтерсең, ди. Композиторлар иҗатын ни рәвешле күрсәтәсең? Симфония, концертларны да оркестрдан уйнатырсың. Ә менә филармониянең бер генә дә рәте юк икән бит. Күбесе профессиональ булудан ерак тора, үзешчәннәр дәрәҗәсендә. Ичмасам бер юньле-башлы костюмнары гына да юк икән...

Филармония хакында уйлана калгач, сәнгать әһелләрен җыеп сөйләшергә ниятли сәркатиб. Шунда бер композитор куркып тормый:

— Хәзер бит милли киемнәрне юньләп белүчебез дә юк. Элекләре бит безнең Урманче шикелле художникларыбыз булган. Менә ул талант, шәхес... Костюмнарны да яхшы белә иде,— дип ычкындыра.

Академия театрының режиссеры да бу фикерне хуплап чыга. Җитәкче кешегә җитә кала. Рәссамның язмышы белән кызыксына башлый, аның кайдалыгын ачыклау эшен ярдәмчеләренә тапшыра.

Бакый Урманче ул чакны Ташкентның сәнгать институтында укыта торган була. Көтмәгәндә-уйламаганда моны Үзбәкстан компартиясенең Үзәк Комитетына чакыралар. Идеология сәркатибе хәйран олылап каршы ала, үзе белән янәшә утыртып, хәл-әхвәлен сораштыра, тыныч кына тыңлап утыра.

Әмма Урманче хәтле Урманчены алай гына алдый алмассың. Академияне ул Соловкиларда узган. Сәркатип аны һич тә сөйләгәнен тыңлап утырыр өчен генә, хәл-әхвәлен белер өчен генә чакырмаган, ниндидер бер мөгез чыгарыргадыр әле исәбе. Тыныч кына тыңлап утырыр-утырыр да берзаман, әкәҗан, үзбәк халкына синең кирәгең калмады, егерме дүрт сәгать эчендә үкчәңне ялтырат, дияр. Шул булыр дөньяви бәян.

Сагаеп-шигәеп кенә торганда, сәркатип гәптәшенең күзенә туры карап, бөтенләй көтелмәгән сүзне башлап җибәрә:

— Әкәҗан, төрки халыкларның сәнгатен-мәдәниятен үстерүгә күп көч саласыз. Казагыстандагы хезмәтегез дә миңа мәгълүм. Үзебезнең сәнгать вузындагы укытуыгызны әйткән дә юк. Һәрчак мактыйлар үзегезне. Мин туләем хәбәрдар анысыннан. Эрудит дигән, аяклы энциклопедия дигән данытыз-кушаматыгыз да бар икән. Сез безгә искиткеч кирәкле кеше,— дип оеткы салып куя да әйтәсе килгән фикерен әйтә.— Инде менә Татарстан обкомыннан чылтыраттылар. Сезнең аларга да кирәгегез бар икән. Бездә скульптурадан укытсагыз, анда костюмнар художнигы сыйфатында файдаланмакчылар, декадага әзерләнәләр икән...

Габделбакыйның уй-фикерләре гаҗәеп тиз йөри бит аның.

— Һич була торган хәл түгел. Күпме тырышуларымның кадерен белмәделәр, илдән сөрделәр...— дип тәмам күтәрелеп бәрелә.

Тик инде партия җитәкчесе дә төшеп калганнардан түгел:

— Шәхес культы корбаны булгансыз, анысын яхшы аңлыйм. Хәзер бит эшләр үзгәрде, шәхес культы аркасында ясалган хаталарны төзәтәбез, дөньяны башкача алып барырга исәп,— ди.

— Гөнаһсыз-гаепсез көенә күпме кыен ашаттылар миңа андагы җитәкчеләр! Хәзер имин генә эшләп ятам, яшь талантларны үземнең һөнәремә, скульптурага өйрәтәм. Бөтенләй ВХУТЕМАСтагыча куйдым укыту эшен. Үзем бит мин берьюлы ике факультет бетердем: берсе — нәкышь, икенчесе — әлеге дә баягы сынчылык һөнәре, скульптура...

Партия җитәкчесе дилбегәне үз кулыннан ычкындырырга уйламый да:

— Үзбәк халкы сезнең хезмәтегезгә хәйран зур бәя бирә. Без сезне бервакытта да пенсиягә җибәрергә уйламыйбыз, эшләрсез әле, эшләрсез. Киресенчә, профессор итеп күтәрүебез ихтимал. Шул ук вакытта кардәш халыкны да онытырга ярамый. Без татарларга бу очракта ярдәм итәргә тиешбез, ярдәм кулы сузыйк без аларга,— ди, әнә кайсы яктан суктыра бит.

Үзәк Комитетның сәркатибе сүзен тыңламыйча ярамый, аны аяк астына салып таптасаң, аннары үкенеч хәлгә төшәреңне бел дә тор. Аңлый моны Габделбакый, башына тай типмәгән. Ризалаша.

Кардәш халыкка ярдәм итү нияте белән генә җибәрелгән Габделбакыйның, туган якларга кайткач, күңелләре бөтенләйгә үзгәрде. Дәртләнеп эшли торгач, ярыйсы гына ыспай, бик тә инде килешле киемнәр тегәргә эскизлар ясады. Күргәзмә-конкурс ише нәрсә оештырганнар иде, шунда Урманче эскизлары җиңеп чыкты. Иң милли, иң матур дигән бәя алды алар. Кая ул анда Варшавскийларга! Аларның төшләренә дә кермәгән детальләр белән баетты Габделбакый үзенең эскизларын.

Декаданың гаҗәеп тантаналы шартларда узуы да, башкалада чуалган арада өенә кайтып, гаилә җылысын тату да нык тәэсир итте, ахры: Декаданы тәмамлап, кесәгә ярыйсы гына малны салгач, рәссамның күңеленә әллә нинди нәрсә була бит, әй! Кайчандыр милләтчелектә гаепләнеп сөрелгән Казаннан бу юлы үз теләге белән, үз аягы белән китә бит, китә...

Нәкъ шушы мизгелне көткән шикелле, өлкә комитеты сәркатибе дә:

— Нәрсә, китәргә чабатаңны киенеп куйдыңмы инде? — дип төрттерде.

— Шулайрак иде ният, шулайрак иде...

— Әллә, мин әйтәм, берьюлы ике-өч җирдә яшәүдән туктап, Казанга кайтып ныклабрак төпләнәсеңме? Не мальчишка же! Алтмышның өстенә бастың. Һәйбәт фатир бирербез үзеңә, гаиләңне монда алдырырсың. Аннары инде звание, пенсия, выставка ише нәрсәләр — һәммәсе бездән. Аларын үз өстемә алам. Әле дәртең бар, ныгытып эшләрсең.

Уйга калды Урманчең. Уйланырлык иде шул. Егерме-утыз ел буена ошбу тарафларга якын килергә, шәһәргә атлап басарга тыелган иде бит... Менә хәзер бөтен республиканың идеология башында торучы зат үзе дәшеп-чакырып тора, кайткан тәкъдирдә вәгъдәсен һич боза торган адәм түгел. Егет кеше. Фатирын да җайлар, күргәзмәсен дә, исем-дәрәҗәсен дә кайгыртмый калмас. Ә соң халыкка барлык әсәрләреңне җыеп-барлап дигәндәй күрсәтүдән дә татлырак нәрсә бар микән ошбу фани дөньяда? Кардәш халык, дип әйтә дә бит Ташкентта утыручы сәркатип... Юк шул менә, бер дә кардәш-фәлән түгел. Ялгыша ул акыллы, инсафлы адәм баласы, нык ялгыша. Габделбакыйның җан атып торган үз халкы, газиз татар халкы ла...

Гәптәшенең тынып калуына бер дә сәерсенмәде җитәкче иптәш: аңлады аның кичерешен-халәтен. Әйе, үзебез үк нинди талант иясен туган туфрактан, яратып эшләгән эшеннән умырып, йолкып алганбыз да җыен уголовниклар янына зинданга ташлаганбыз... Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчуриннар кебек үк, бу бичара да бинахак дөнья газабына дучар ителгән шул, ачысын-төчесен чүмечләп чөмергән, мескенкәй... Бөтен иҗатын чәлпәрәмә китереп, үзен базга түндергәнбез дә, хәзер инде мин кәнфитләнеп утырам. Әйбәт кеше, янәсе... Этлекне үзем эшләмәгәнмен, бүтәннәр эшләгән, миңа кадәр шушы ук креслода утыручылар. Хәер, аларның үзләрен дә әллә кайларга олактырганнар. Исемлектә исем-фамилияләре генә торып калган. Үзләре исә шәхес буларак җилгәбушлыкка очкан... Ә менә бу абзыйның артыннан эзе калган. Соловкига озатуын озатканбыз, тик аның иҗатын себереп түгү хәлебездән килмәгән. Сәнгатькәр шул абзыең, тегенди-мондый гына кеше түгел.

— Бәй, елап утырам икән ләбаса... Ни, иптәш кем... син инде картлачның кыланышын гаепкә алма...

— Нинди сүз?! Ирләрчә сөйләшеп-серләшеп утырабыз бит. Минем тәкъдим таш стенага барып бәрелмәде, ир-егетнең бәгырькәенә үтеп керде дигән сүз.

— Әйе, дустым, таш диварга тимәде әйткән сүзең, минем чит җирләрдә интегеп, үзебезчә итеп әйтсәк, ягада каңгырап йөргән чакларда катып-чиләнеп беткән, җәрәхәт өстенә җәрәхәт өстәлгән, миһербан-шәфкать ише нәрсәне гел онытып бетергән бәгырьәкемне эретерлек булды синең әлеге сүзләрең.

Бар әле Бакый Урманченең сөенечле күз яшьләре түгәсе. Янә дә егерме алты елдан соң, үз гомерендә беренче альбомын кулына алгач, Сөембикәнең скульптурасын мәңгеләштергәнне күргәч, тынып каласылары, нәкъ әле әйткәнчә:

— Бәй, елап утырам икән ләбаса...— дип әйтеп әйтәселәре алда әле... Бар әле, бар...

Ә хәзергә Урманче тиз-тиз генә фикер йөртә: әһә, фатир була, дип ычкындырды, моңа чытырдап ябышырга кирәк, хатыным белән улымны кайтарам, дип каргана-каргана, фатирның олырагын, юньлерәген эләктереп калырга кирәк, ел саен сорап ала торган нәрсә түгел, әйе, берьюлы остаханәне дә көйләп булса...

— Икенче яшьлек, дисең дә бит, иптәш кем... алай ук булмас инде булуын. Мәгәр скульптурага ныгытып тотынырга ният юк түгел. Үзебезнең мәдәният әһелләренең портретларын гранитта яки мәрмәрдә иҗат итәсем килә. Әйтик, Дәрдмәнд, Тукай, Әмирхан, Җәлил... Сез...

Моны ишеткәч, сәркатип ихлас күңелдән гөлдерәп көлеп җибәрде.

— Юк, сине Казанга кайтарырга теләвем үземнең портретны ясатырга хыялланудан түгел. Бүтәннәренә каршы килмим, благословляю...

— Фатиха бирәсең, димәк?

— Әйе, аларына фатиха бирәм. Үземә — юк.

— Син бер нәрсәне исеңдә тот, иптәш кем... Урманче фәкать җаны теләгән шәрабны эчә, җаны теләгән затны коча вә янә дә җаны хуплаган, якын күргән шәхесләрнең генә портретларын киндергә яза, мәрмәргә уя. Боерган булса, мәһабәт кыяфәтегез мәрмәрдән уеп ясалыр да музей залының түрендә булыр, бизәп торыр!

— Бераз читкәрәк киттек. Әлегә бер генә мәсьәләне хәл итик без. Күченәсеңме Казанга?

— Бүген рәтле-башлы фатир булган хәлдә, иртәгә күченәм үзебезнең Казанга. Бөтенләйгә, гомерлеккә күченәм!

Бу сүзләрне ишеткәч, сәркатип биш-алты телефонының берсенә үрелеп чылтыратты да кемгәдер нидер әйтте, хәзер үк килеп җитәргә әмер бирде.

Шәһәр Советы рәисе килеп кергәч, сәркатип мәһабәт кыяфәтен тәмам балкытып:

— Декадабызның хәйран матур узуына менә шушы абзый гаепле. Бүген без синең белән икәүләшеп аңа һәйбәтрәк яңа йорттан шәп кенә фатир сайлап бирик. Өчне-дүртне күрсәтик тә, үзенең күңеленә хуш килердәен үзе сайлап алсын,— диде.

Сәркатипнең ике сөйләргә яратмаганын белгәнгә, карышып тормады шәһәр башлыгы, ризалыгын белдерде.

— Әйдәгез соң, машинам түбәндә көтә,— диде.

Моңа каршы хуҗа үзе:

— Юк, агай-эне, минем машинага утырып барабыз. Шундый зур талант иясенең исендә калырлык булсын. Обком машинасына утырып үзенә квартира карап йөргәнне оныкларына сөйләрлек булсын,— дип каршы төште.

Кара «Волга» белән алар иң әүвәл Себер трактына чыктылар. Анда әле кичә-бүген диярлек кенә пөхтәләп эшләп бетергән, җете кызыл кирпечтән өелгән биш катлы зур йорт каршысына җитеп туктадылар. Мәһабәт иде йорт, сокланырлык иде. Тик менә шау-шуны бик үк өнәп бетермәүче рәссам гына:

— Сүз дә юк, хәйран матур иттереп коргансыз бу йортны! Тамаша булган бу. Авырсынмасагыз, башкаларын да карыйк, күз салыйк инде,— диде.

Сәркатип бер дә үгетләмәде, фәкать машинасына кереп утыргач кына, саллы гәүдәсен артка борып:

— Зәрә генә ризалык бирмәдең, абзыкай. Нинди капризлы әдип фәләнов булып ул да шушы йорттан сорап алды. Иң престижный йорт бу. Тагын да бар барын престижныйлар. Хәзер үзең дә күрерсең,— дип гөлдерәп алды.

Ул чагында Ленин районын шәһәр белән тоташтыра торган икенче күпер юк иде әле, бөтен шәһәрне үтеп Производство урамына чыктылар. Сулда бәп-бәләкәй коттеджлар, уңда исә урам чатын кочып торган өч кенә катлы, ак кирпечтән өелгән җыйнак кына йорт.

Урманче әлеге йортны күрү белән ошатты. Ә инде икенче катка менеп, киң коридорлы, өч бүлмәле квартираны караганнан соң, рухланып китеп:

— Дустым! Син хәйран укымышлы зат, Гетенең Фаусты кычкырып әйткән сүзләрне хәтерлисең булыр,— диюгә, сәркатип тә сынатмады:

— Остановись, мгновенье, ты прекрасно! дигән бугай, хәтерем алдамаса.

— Әйе, дөп-дөрес. Мизгел, тукта, син гүзәлсең, дигән. Яшем белән мин Фаустка тиң булсам кирәк. Әгәр дә егетлек күрсәтеп мөһер сугасыз икән,без фәкыйрегез ошбу бельетажга урнашырга бик разый. Инде бер очтан якын тирәдә остаханә, безнең халык теленә кереп киткәнчә әйтсәк, мастерская да җайласагыз, аннары дөньям тәмам түгәрәкләнә.

— Ачык чырай күрсәткәч, ямаулык соравың белән, абзыкай, син чеп-чи үзебезнең кеше икәнеңне күрсәттең. Җыен казакъ, үзбәк арасында яшәсәң дә, әлләни бозылмагансың, татар булып калгансың икән әле, бик шәкер.

— Канда бит ул, иптәш кем, геннар белән килгән.

— Алайса болай. Действительно, урамы тыныч, магистральдән ерак. Моны сайлап бик дөрес эшлисең. Бүген үк моны оформить итегез, ачкычларын кулына тоттырыгыз...

Шәһәр Советы рәисе әлләни күп сөйләмәсә дә, бу юлы:

— Йортны фәкать ун көннән генә тапшырасылары...— диебрәк каршы төшеп карады да соң, сәркатипнең талканы коры булды:

— Ну и что же, атна-ун көннән йортны тулаем тапшырасыз, ачкычны бүген бирерсең. Бүген үк! Үз кулың белән! Ә иртәгә мастерской карап

сайларсыз. Анысына, шәт, обком секретареның кияү егете сыйфатында йөгереп йөрүе кирәкмәстер. Так что, минем миссия выполнена.

— Рәхмәтемне биш фарыз намаз укыган саен кабатлармын, һич иренмәм! — дип сәнгатькәр нык иттереп сәркатипнең кулын кысты. Чит кеше алдында, әлбәттә, мәрмәрдән портрет уячагын кабатлап тормады.

Икенче көнне шул ук районда, Соцгородта бер катлы карсаграк кына таш йорттан остаханә дә алгач, ул остаханәнең бер ачкычын әлеге йортның икенче яртысында яшәүче уңган егеткә тоттырып, атна-ун көн эчендә киштәдер-фәләндер әмәлләргә кушкач, картның тәмам дөньясы түгәрәкләнде.

Казанга кайтып урнашканнан соң да әле Урманче җыен вак-төяк эшләрен һәммәсен әлеге алтын куллы егеттән эшләткәләде. Габделбакыйның былбыл булып сайраганын, башкарган эше өчен күкләргә чөеп мактаганын теге тыңлап тора-тора да, кулын селтәп:

— Ярар анысы. Корал эшләр, ир мактаныр. Хакын түләп сөйлә син. Бу эшнең тияре биш тәңкә буладыр,— дип мәсьәләгә ачыклык кертә торган булды.

Габделбакый гәрчә кесәдән акча чыгарырга яисә берәр зыялыга картинасын бүләк итәргә бик яратмаса да, югары материя хакында акыллы сүзләр әйтеп кенә бу останы юмалап булмасын шундук аңлады. Инде бер сөмсере коелгач, шуннан соң бу денсезгә көмеш сүзләрен әрәм итүдән туктады.

Биргән вәгъдәсендә нык тора Габделбакый: татар мәдәниятендә иң тирән эз калдырган даһиларның сурәтләрен мәрмәргә уеп ясый. Бере артыннан бере Тукай, Әмирхан, Җәлилләрнең җанлы образларын гәүдәләндерә. Кызык бит дөнья! Алты дистәсен тутырган Урманченың Казанга кайтуын хуплаган, үләргә кайта инде, дип фикер йөрткән, типсә тимер өзәрлек рәссамнар аның дәртләнеп эшкә тотынуын, заказны турыдан-туры министрлыктан алуын, иҗади оешмага әйләнеп тә карамавын абайлагач, акрынлап читләшә башлыйлар. Җитмәсә бит әле җөмһүрияттә аңа каршы торырлык уемчы-скульптор да юк. Шуннан идарә әһелләре әкренләп тегеңәргә этлек эшләргә тотыналар.

Иҗат кешесе өчен синең хезмәтеңне халык алдына чыгартмаудан да зуррак хурлык юктыр, мөгаен. Урманчега нәкъ әнә шундый җәзаны кулланалар. Зуррак күргәзмә-фәлән оеша башлады исә, түрәләр моның күзен дә ачырмыйлар:

— Синең бу үзбәкләрең белән адәм мәсхәрәсенә каласыбыз килми. Син бит гомумән дә татар рәссамы түгел. Менә бу ичмасам татар, диярлек бер генә картинаң да юк ич,— дип теңкәсенә тияләр.

Шуннан бу «Зур Идел» күргәзмәсенә Галимҗан Ибраһимов портретын тәкъдим итә. Инде монысына үзбәк яисә казакъ дип бәйләнә алмыйлар. Эшләнешенә янә дә сүз тидермиләр. Рәссам белән договор төзеп, әсәрне сатып алырга вәгъдә итәләр, аванс түлиләр. Бүтән әсәрләр белән бергә безнең Галимҗан да Самарага китеп бара.

Әмма үз өендә үз кулы белән суя алмаган түрә — кеше өендә икенче берәүләр кулы белән сую җаен таба. Имин генә яшәп яткан җирендә рәссамга дәрәҗәле комиссия исеменнән рәсми документ килеп төшә: Галимҗан Ибраһимов портреты күргәзмәнең таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел икән, шул сәбәпле яраксыз табылган... Урманчега бирелгән авансны кайтарырга карар кылынган...

Моның ишерәк хәлләр елның-елында кабатлана тора. Олуг талант иясен ничек тә кимсетергә, мәсхәрә итәргә көчләрен һич кызганмыйлар.

Әле ярый, милли сәнгатьнең кадерен вә кыйммәтен белүче әдипләр бар бу дөньяда, язучылар бар. Әнә шулар олуг талант иясен изәргәсытарга ирек бирмиләр, аны бердәнбер татар рәссамы, халыкның үткәнен-бүгенгесен өйрәнгән, чын-чынлап тоя торган бердәнбер зыялы рәссамыбыз, дип күтәреп чыгалар, аны сынлы сәнгать өлкәсендә Тукай белән Сәйдәшкә тиңлиләр, матбугатта мәкаләләр белән чыгалар.

Әнә шул тырышлык аркасында җитмеш яше тулган елны Бакый Урманче Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек табыла.

Бинибая дәртле ир-ат буларак, Габделбакый, әлбәттә, хатынсыз гына яши алмый. Өч бүлмәле фатир алганда нияте бик-бик изге була: тиз арада тиз көндә гаиләсен алдыра да тынычлап кына, картларча гына яши соң. Әүвәл телефоннан хәбәр бирә, әзерләнергә куша, аннары аларны алып кайтырга дип үзе китә. Әмма Сара ханым Казанга барам дип атлыгып тормый. Гомер буе Мәскәүдә яшәгән кеше икенче бер шәһәргә күченүне үзе өчен хурлык саный. Аннары ул бит әле музыкант, башкаланың мәшһүр концерт залларын ташлап китәсе, үзенең мохитыннан аерыласы һич тә килми. Янә көн күрү, таләпчән Бакыйны тәрбия кылып тору аның өчен инде кызыгын югалткан: дөресен генә әйткәндә, алтынчы дистәсен тутырып ятканда аңа ир дигән затның электәге мәгънәсе югалган, суынып өлгергән була. Хатын-хатын дигән өметләре өзелгәч, рәссам тагын да ялгызак тормышта яшәргә дучар ителә. Башны ташка орып булмый, үз көнеңне үзең күрергә туры килә.

Урманче гомерендә дә иҗади ярыш дигән нәрсәне белмичә яши. Рәссам буларак үзенең көче нидә икәнне дә, кимчелеге нәрсәдә икәнне дә электән белә. Әйтик, композиция коруда замандашларыннан тиңе юк. Һәр картинасында кеше фигуралары нәкъ кирәгенчә генә һәм нәкъ үз урыннарында. Алар һич тә бер-берсен кабатламас. Бу яктан алганда, сәнгатькәр берьюлы камиллеккә дә, гадилеккә дә ирешә. Аның әсәрләрендәге композицияне һич үзгәртү мөмкин түгел. Ә бит күп кенә рәссамнар еш кына, халыкчанлык төшенчәсен ялгыш аңлап, картиналарына бинибая күп кеше фигурасы тутыралар: ул персонажларның күбесе бер үк позада булып, бер-берсен кабатлый; шуңа аларны тегеләй үзгәртсәң дә, болай үзгәртсәң дә, әсәргә бернинди зыян яки файда килми. Ә син Урманче әсәрләрендәге берәр фигурага кагылдың исә — мәгънә югала. Аннары яшьлегендә импрессионистларның иҗатын өйрәнеп рухланган Урманче төсләрне искиткеч оста сайлый. Зур күләмле картиналарында да һичбер бүлтәеп чыгып торган, ятышсыз бизәк күрмәссең. Һәркайсы үз урынында. Һәркайсы табигый яңгыраш алган. Менә ни сәбәпле аның әсәрләрен халык яратып карый.

Һәй, шул да булдымы сүз?! Каян күрсен-карасын икән халык үзенең чын-чынлап милли хиссиятен җуймаган-югалтмаган рәссамының иҗат җимешләрен? Әллә кайчан язылган, сәнгать белгечләре хуплаган, музей сатып алган картиналары — «Сепаратор янында» (1927), «Кичү» (1928), «Сары күлмәкле кыз» (1929) — экспозициядә юк, запасникларда саклана булыр... Яшь чагында иҗат итеп калдырган газизкәйләрен музейда табып, сокланып туя алмый сәнгатькәр. Ул тыйнак кына утыручы мөлаем йөзле җитү кызның сине үзенә дәшкән сыман туры каравы да нәкъ искечә, эшләпәсенә яки иңнәрен каплаган комачтай кызыл яулыгына да, сары матур күлмәгенә белән ак алъяпкычына да берни булмаган. Төсләр нәкъ утыз ел элгәре салынганча сакланган... Сепаратор янындагысы бераз олырак кыяфәтле. Хәер, болар инде икесе дә әш кешеләре икәнлеге әллә каян күренә. Кичү янындагылар гына төрлесе төрле кавемнән: үзебезнең милли хәлфәбез белән гаять иркен сөйләшеп торучы ак күлмәкле, ялан баш, аягына заманча туфли кигән туташ та бар монда; көймәдә утыручы бүтән милләт вәкилләре дә бар; ак яулык япкан, озын итәкле сары күлмәк кигән, сул кулына каен тырыс тоткан, уңы белән кәкре аяклы малайны җитәкләп көймәгә якынлашучы бистә хатыны да бар... Һай, төсләре дә соң! Буяуны бигрәкләр мул иттереп салган икән шул. Ничәмә-ничә кеше фигурасы булып, бер-берсен һич кабатламыйлар, ни деталь буларак, ни төс ягыннан комачаулык китермиләр. Бигрәк яратып язган икән гади халыкны. Рәхәтләнеп карарлык бит болар. Халыкныкын халыктан яшереп яткызу егетлек түгел.

Әкренләп Урманче әлеге әсәрләрен экспозициягә чыгарту әмәлен күрә, җаен таба. Халыкның игътибар белән каравын күрү аңа әйтеп бетергесез ләззәт һәм куәт бирә. Димәк, халкы аны, Идрис хәзрәт малаен, нәкышь остасы дип кабул итә. Бу жанрда башлаган эшләрне генә тәмамлыйсы да яңаларына тотынмыйча, планнарны читкә куеп, хәзергә алардан йөз чөереп, уем-скульптурада үзеннең кем икәнеңне күрсәтергә кирәк. Аннары чәйнәсеннәр шунда Урманче урынына Урванче дип. Мәрмәр уеп бөек Тукайның рухи байлыгын ачып бирүне юк-бар эшкә саныйлар булыр, югыйсә останың алган гонорарын алай күпсенмәсләр иде. Берсенең дә хәленнән килә торган эш түгел бит, берсенең дә... Иртә таңнан алып караңгы төшкәнчегә кадәр эшләүчеләр бардыр анысы, тик менә халык күңеленә ятышлы гүзәл әсәрләр иҗат кылучысы гына юк. Һәм тиз арада булмас та. Аның өчен Габделбакый Урманче булырга кирәк шул...

Бөек рәссамнарның автопортрет язганы яхшы мәгълүм татар рәссамына. Ул да бит үзенең иҗатына гашыйк, шәхес буларак үзенең бәясен бик белеп эш йөртә. Ул да автопортретын язар. Юк, Тицианнар юлын кабатламас, майлы буяу белән язмас. Музей бизәп торырлык, «Кичү»ләр янына куярлык скульптура портретын иҗат итәрдер. Әйе, нәкъ үзе. Сергей Коненков сыман, мәрмәргә уеп ясар менә үзенең мәһабәт-күркәле сурәтен. Хәер, мәшһүр скульптор Коненков беренче мәртәбә үзенең сурәтен кырык яшендә (дөресрәге, академик итеп сайланган елында, кырык икедә) мәрмәргә уеп ясый, икенчесен нәкъ сиксән тулган елны иҗат итә. Халык аның әнә шул киң сакаллы кыяфәтенә карап кына фикер йөртә булыр, шунысын гына кабул итте бугай...

Ә менә мукшы даһие Степан Эрьзянең яшь чагында бетоннан коеп катырган автопортреты гына мәгълүм. Агачтан, мәрмәрдән соңрак искиткеч гүзәл сәнгать әсәрләре иҗат иткән шәхес кабат-кабат үзенең сурәтен ясамагандыр, дип ышанасы килми. Ихтимал, автопортрет дип атамагандыр гына...

Кара әле, идея бит бу! Урманче карт даһи мукшының тыйнаклыгын кабатлаудан һич курыкмады. Охшаганмы, охшамаганмы, дип авыз чайкап азапланмасыннар. Махсус бераз читләштерер, гел үзенә охшатып ясамас...

Чынлап та, каты агачтан гаҗәеп зур осталык белән уеп ясалган татар картының сурәтен бик сирәк кеше автопортрет дип кабул итә. Чөнки автор әлеге сурәттә үзенең йөз чалымнарын чак кына үзгәртеп бирә: маңгае бераз түгәрәгрәк тә калкурак; кашлары тагын да салынкырак, күзләре уйчанрак та моңсурак; колаклары кечерәгрәк; борыны гүя бөркет борыны; сакал-мыегы да шактый нык аерма-үзгәреш кертә. Шул ук вакытта бу — автопортрет. Хикмәт аның яңагына таянган кулында гына да түгел. Габделбакыйның гомер буена авыр эштән тайчанмаган, кан тамырлары беленеп торган саллы кулын хәтерләтүдә түгел. Хикмәт монда әлеге замандашы сурәтендә Урманченың үзенең эчке дөньясы — бөтен күңел байлыгы, рухани каршылыклары, газаплы кичерешләре, уйлану-сагышланулары — тулаем чагылуда. «Сагыш» дип атавы да әнә шул халәттән килә булса кирәк. Әмма автопортреттан аерылып та тора: монда бер шәхеснең уйлануы гына түгел, юк, монда кешелек дөньясының бүгенге хәлен һәм киләчәген кайгырту, газаплы җаның, олуг гуманистның сагышлануы чагыла. Әнә ни сәбәпле татар скульпторының әлеге хезмәтен мәшһүр француз скульпторы Роденның «Фикер иясе» дигән хезмәтенә тиңлисе килә. Һәрхәлдә, халкыбыз сәнгатендә аңарчы да («Сагыш» әсәре 1968 елны тәмамланган), аннан соң да мондый гүзәл әсәрнең иҗат ителгәне юк әле.

...Иркәне ул урамда очрата. Ашыга-ашыга Рәссамнар оешмасына, утырышка барган чакны асфальт тротуардан кәс-кәс атлап баручы зифа буйлы туташның билдән түбән чәч толымына илтифат итә. Ак күлмәк

фонында хәйран матур булып күренә ул чәч толымы. Аннары аның калынлыгын әйтәсеңме, күз тимәсен!

Рәссам ул туташны, троллейбус тукталышына барадыр, дип фараз кылган иде, әмма кыз анда туктамады. Аның артыннан барыргамы, бармаскамы, дип баш ватып кына торганда, троллейбус килеп туктады, картлач, миңгерәүләнгән шикелле, кереп утырды. Троллейбус кузгалып киткәч кенә, акылына килде.

И Хода, нишләдем соң әле мин? Бу чаклы да килешле натураны тагы кайчан табасың инде? Иртәгә, дип җавап бирде икенче бер эчке тавыш. Ләкин иртәгәге көнгә калдырырга ярамавын яхшы белә иде аксакал. Аның үз гомерендә бихисап булды үкенечкә әйләнгән «иртәгәләр». Һич килешә торган эш түгел. Хәзер үк төшәсе дә кирегә китәсе. Әллә ни ара түгел, каршысына гына барып чыгар менә. Качмас әле идарәләре...

Ләкин бу эшнең акылсызлык икәненә ышанды аксакал. Троллейбустан ялт кына төшеп, таяк таянган көе хәлдән килгәнчә кирегә йөгерде. Күзен ак күлмәкле туташлардан алмады, тик арада озын вә калын толымлысы гына булмады. Берсе әнә эшләпә кигән, олырак яшьтәге ханым. Икенчесе әнә, яшьрәге, кыска җитен чәчен тузгытып, почык борынын күккә чөеп килә. Тегесе юк кына бит, каһәрем-зәһәрем! Шул арада җир тишегенә кереп китте диярсең... Кулдан ычкындырган асыл затны күрергә өметләнеп килә торгач, рәссам әле бая гына утырып киткән тукталышка җитүен дә сизми калды. Шуннан ары аяк та атламаска акылы җитте хәер.

Икенче көнне ул, барча эшен ташлап, кичәге урынга чапты. Әмма шушы яшенә җитеп, былтыр кысты, былтыр, дип зар җылаган шүрәле кебек, кичәге көнне күрә алмый гаҗиз булды. Ни чаклы гына гарьләнмәсен, нинди сүзләр белән генә үзен битәрләмәсен, тик шулай да Урманче алай тиз бирешә торганнардан түгел иде. Янә килде троллейбус тукталышына, янә эзләде. Әмма эзләгәнен тапмыйча туктамады.

Көн алай ук аяз түгел иде. Шуңа туташ җете-кызыл кофта, кара итәк кигән иде. Әмма аның чәч толымы кызыл фонда да ымсындырырлык матур булып ята иде. Аксакал аңа бәрелә-сугыла кадалмады, өркетмәгәем дип, беравык артыннан атлады. Кайсы яктан сүз кушу җайлырак булыр икән, дип хәйлә корып кына барганда, туташ ялт кына кибеткә кереп китте. Рәссам аңа иярде. Кибет эчендә кыз фотография товарлары бүлегенә узды. Рәссам да шул якка атлады. Туташның пленка алырга икән исәбе. Әмма сатучы:

— Кайсысын аласыз? — дип сорагач, югалып калган сыман тоелды.

Шунда инде рәссам агаебыз үзенең бик үк төшеп калганнардан түгел икәнен күрсәтте:

— Киңәш бирергә җөрьәт иткәнем өчен гафу кылгайсыз, туташ, сезгә әнә тегесе кулайрак булырдыр,— дип сүз кушты.

Якында ук шундый да мөлаем тавыш ишетеп, кыз борылып карады. Сөбханалла! Буй-сыны, өсте-башы, озын толымлы чәче генә түгел, кыяфәте дә сокланырлык икән ләбаса: буялмаган-нитмәгән куе кара каш, сөрмә-фәлән тартмаган озын керфекләр; зәп-зәңгәр күз, төп-төз борын, уймактай җыйнак авыз...

— Рәхмәт! — диде туташ коры гына һәм нәкъ чал чәчле абзый кушкан пленканы сорап алды.

Рәссам юк-бар белән кызыксынган булып:

— Фотография белән мавыгасызмыни? Бар иде безнең дә андый чаклар. Япониядән килгән гаҗәеп зур линзалы фотоаппарат сатып алгач, ай буена берни эшләмәгәнемне хәтерлим...— дип сайрады.

Туташ аны шундук үз итте, ачылып китеп елмайды:

— Ахирәтем кызыктырып әле быел гына алдырды. Юньләп төшерә дә белмим, өйрәнчек кенә,— диде.

— Нәрсә, «ФЭД»-мазар алдыгызмы?

— Сез бигрәк инде! Кыйммәт ич ул!

— Өйрәнгәндә анның ниндие дә ярый. Тәмам өйрәнеп житкәннән соң җыенырсыз әле...
— Дәртем сүрелмәсә аңарчыга кадәр.
— Сүрелүен сүрелмәс. Тик менә килеш-килбәтегезгә карап торам-торам да портретыгызны ясарга кызыгып куям.
— Сез портретлар ясаучы фотографмыни?
— Юк шул. Рәссам гына. Профессионал рәссам. Сезнең бу чибәрлегегез фотода бик статично чыга булыр. Ә мин гүзәллегегезне төрле төсләрдә, майлы буяу белән бирер идем. Фото, әлбәттә, әйбәт нәрсә, тик ул гүзәллек алдында көчсез.
— Мин риза. Әле тагын бер сәгатьтән артык буш вакытым да бар.
Өч бүлмәле иркен квартирада туташ аптырабрак калды. Кая карама — сурәт, картина, скульптура, китап. Бүтән берни юк диярлек.
— Ничә кеше яшисез соң монда? — дип сораганын да сизми калды.
— Әлегә үзем генә, туташ. Ялгыз башым...
— Үзегез генә? Өч бүлмәле квартирадамы? Ә без бер генә бүлмәдә өчәүләшеп яшибез: әнием, мин, сеңелем.
— Әлегә үзем генә. Иншалла, табылыр әле ия минем хөҗрәгә дә.
Рәссам үзе язган сурәтләрдә һәркемнең туп-туры каравын бик үк өнәп бетерми иде. Төгәллек, психологик үзенчәлек дия-дия, кызыклырак композицияне бөтенләй исеннән үк чыгарып җибәрә икән бит! Шуңа бу юлы мавыктыргач ысул эзләде. Туташның калын вә озын толымын беренче чиратта алырга кирәк; кашын-күзен дә, авыз-борынын да күрсәтәсе иде бит...
Алай да утыртып карады биек артлы урындыкка, болай да карады, әмма үзе һич риза булмады. Ахырдан урындык сыртына башын салдырып, ян беләнрәк алырга уйлады, чәчен җилкә аша чыгарып салырга кушты. Читтән караганда, килешле генә кыяфәт чыгасы, тулаем бер күренеш хасил буласы иде. Аксакал аңа шулай киңәшләр биреп, читтән генә күзәтүен белде. Һич якын бармады.
Әүвәл күмер белән картонга ясады рәссам портретны. Чибәркәйнең кашына-күзенә, бигрәк тә чәченә юнәлдерде игътибарны. Күмер белән кара чәчне бирүе әллә ни кыенга килмәде шикелле. Берсен бетергәннән соң икенчесенә кереште. Натураны шул хәлендә үк утырган килеш, тик инде бу юлы тоташы белән сызгалап чыкты һәм шуның нәтиҗәсендә гомуми күренешне күз алдына китерә алырдай вариант хәстәрләде. Башка вариантлар ясап маташмады аксакал, болай да портретның әйбәт килеп чыгасына иманы камил иде. Чәчне куншы итеп бирәчәк, иң-иң төп отышы шул булачак, йөзен дә килештерер сыман, позасы да кабатланып теңкәгә тигән поза түгел.
Туташны табуына, көне-сәгате белән эшне ипле генә башлап җибәрүенә сөенеп бетә алмады аксакал.
Икенче килүенә подрамникка тарттырган киндерне әзерләп тә куйган иде инде. Туташ бүген отыры чибәрләнеп киткәндер сыман тоелды. Максат нәрсә генә эшләтми диген Хода бәндәсен. Сөбханалла, күзем тия күрмәсен дип, кызыгып карамаска да тырышты аксакал, артык теленә дә салынмады. Тиз-тиз эшкә тотынып, карандаш белән контурларын сызгалады, шундук кыл-каләмен кулына алды. Ләкин үзенең бүгенге кырыслыгы натурага да күчкәнен абайлап, акрынлап ике арага бәллүр күпер сала башлады. Теләсә кемнең кәефен күтәрергә сәләтле аксакалның тәэсирендә туташның чырае йомшарды, йөзендә табигый елмаю пәйда булды.
Һәр килүендә кыз бу өйдә торган саен үзен иркенрәк тота, ияләшә барды, сәнгатькәрнең каршы алганда нурланып-балкып, иситкеч мөлаем тавыш белән:
— Килдеңме, Иркәҗан? Әйбәт кенәме? — дип теленә салына-салына, уң кулы белән кочып алуын, битен пәп иттерүен, аркасыннан сыйпавын

бер дә чит итмәде. Өй эчендә иркенләп йөреп, Урманче иҗат иткән әсәрләр белән дә танышып өлгерде.

Әкренләп эшли торгач, портрет адәм рәтле бер төскә керде шикелле. Янә бер-ике сеанска түзсә, аннары... Нәрсә — аннары? Килеп йөрүдән туктыймы? Аксакалның дөньясы бер читеннән кителеп төшә икән ич! Юк, үз-үзеңне андый хәлгә дучар итәргә ярамый. Һич тә! Берәр юлын табарга кирәк. Ничек тә җибәрмәскә кирәк. Ярый, кармак салып карыйк, булмаса!

Бүген рәссам эшләгән эшен сырты белән әйләндереп куймады, мольбертында ук калдырды. Үзе шуңа карый-карый, буягычын буяудан-майдан арындырды, аны пөхтәләп җыеп куйгач, буяуларын каплаштырды. Аннары портретка текәлгән көе балкып китте, үз-үзеннән канәгать елмайды:

— Булган бит бу, Иркәҗан! Һи, янә дә ике-өч сеанстан, боерган булса, тәмам халыкара күргәзмәгә җибәрерлек картина булып җитештерәбез аны! Парижда да, Мадридта та күрсеннәр безнең Идел буенда үскән гүзәлне!.. Каяле, яннарыма килеп кара әле, соклан әле үзеңнең нинди йөзек кашы икәнлегеңә!

Кыз бер читтән үзенең майлы буяу белән язган, фотографияләренә охшап җитмәсә дә, искиткеч мөлаем килеп чыккан, гүя нурлар чәчеп торган сурәтенә томырылып карап тора иде. Беренче күрүе бит, бүгенгә хәтле гел яшереп килде.

— Әйдә, Иркәҗан, күр үзеңнең сәнгатьтәге илаһи гүзәллегеңне! Менә шушы ноктадан кара син аны, күзең йомып кара. Кил Иркәҗан, утыр алдыма, бер дә тартынма!

Туташ бер талпынуда аның янына ук килде, елмаеп остага карады. Аксакал, бөтен түгәрәк йөзкәен балкытып елмая-елмая, сул кулы белән генә биленнән эләктереп, алдына утыртты. Менә булды. Менә ияләштерде. Билкәенә бер кул салгач, болай гына калдырмас, тәмам үзенеке итәр әле ул аны, Аллаһы боерса...

Аксакал нидер сөйләде, ул сүзләрнең ягымлы, назлы сүзләр булуы да бик ихтимал, әмма җитү кыз аларның берсен дә ишетмәде. Ул башын артка ташлап, йөзен рәссамга табан борды, томырылып бер генә карады да күзен йомды. Аның әлеге күз карашында: «Ни сөйлисең син? Нигә сүзең әрәм итәсең? Минем тышкы сурәтемне, шундый зур осталык белән ясагансың икән, син инде, абзыкай, күңелемне дә күрә бел! Менә ич мин...» — дигән самими фикер ярылып ята иде.

Рәссам артык кыстатып тормады, сабыр гына иелеп, дымлы ялкынлы иреннәргә кадалды. Кызның тыны кысыла башлагач кына, ычкындырып, зәңгәр күзләрен төбәп бер генә өздереп карады да, кызның башын чак кына күтәрә төшеп, күзләрен, бит алмаларын, муенын шашып-шашып үбәргә ябышты. Кыз оеганнан-ойый барып, талгын рәхәткә, ләззәткә бирелде, ир-атның дәртле иркенә тулаем буйсынды.

Кыз инде эшнең кая табан барганын, шуннан соң ниләр буласын аермачык белә иде — бүген дөньяга килмәгән, ир-атның бер дәрләп кабынгач ул утны ничек итеп сүндерү гадәте аңарга яхшы таныш иде. Тик әле моңарчы аның күңелен күрүчеләр, дискотека-мазар ише җирдә генә кабынып китеп, дәртләрен сүндерүче Радик, Валерка, Ильяс ише җыен малай-шалай гына булды. Ә бу бит чын ир кеше, олы кеше, тәҗрибәгә бай булып, Иркәнең үзен дә сөю-сөешү сәнгатенә өйрәтә алырдыр. Әнә шундый кызыксыну һәммәсен дә хәл итте. Болай утырган көе үбешкәнче, рәхәтләнеп түшәктә яткан көе үбешәселәре, дөньясын онытып сөешәселәре килде. Һәм чәч толымын саллы кулы белән аралаган агайга ул үзе башлап сүз кушты:

— Сез миңа бүген түрдәге бүлмәгезне дә күрсәтәсездер бит? Югыйсә, күпмедән бирле өегезгә килеп йөрим, ә үзегез кайда йоклаганыгызны һич күрсәтмисез, — диде.

Иркә үзе идәнгә сикереп төште, әмма шундук башы әйләнеп китеп, рәссамның беләгенә ябышты. Аның беләгендә көч вә дәрман шәйләп, сөенеп куйды.

Ир-ат аны:

— Әйдәле, Иркәҗан, үзем шушылай кочаклап дуадак ятагыма алып барыйм әле үзеңне...— дип теленә салынып, көрәктәй кулы белән билдән шактый түбән алган хәлендә, таягын да, яшен дә онытып, алга әйдәде.

Эчке бүлмәгә үткәч, тәрәзәгә каршы түр почмактагы хәйран саллы агач карават янына алып килде:

— Йә, хәзер инде, Иркәҗан, үзең хуҗабикә эшлисе эшләрне башкарырсың,— дип, туташны алгарак этәрде.

Иркә житез генә иелеп көрән төстәге солдат одеалын җыештырып куйды, бердәнбер мендәрне кабартты, корама юрганны караватның аргы ягынарак тибәрде һәм сүсәргүе җиткән ак җәймәне ике өлгер учы белән ике якка сыпырып җибәрде.

Аның житезлегенә һәм дә булганлыгына сокланып ир-ат ишек яңагына сөялеп тора бирде. Фәкать урын-җирнең әзер икәнен күргәч кенә, елмаеп-балкып:

— Кил, Иркәҗан... чишендерим үзеңне,— дип чакырды.

— Бакый абый, мин чак кына юынып килим... Озакламам... Урыныгыз җайлы икән, бик кызыктым, шунда җан бирергә дә риза.

— Минем дә синең өчен җаным фида!

Туташ юыну бүлмәсенә кереп, өстен чишенде, ваннага аяк басып, душ астына керде, су краннарын боргалый башлады. Нинди хәл бу? Торбаның берсеннән ни җылы, ни суык су ага, икенчесеннән боздай салкын су ага иде. Чишенгәнче карарга акылы җитмәде, хәзер инде бөтенләй юынмыйча да ярамый. Бр-р-р, салкын ич бу!

Әнә шул кечтеки генә хәл, салкын душта юыну туташны бөтенләй үзгәртте дә җибәрде.

Тукта, ничек килеп эләкте соң әле Иркә мондый суыкка? Җитмәсә үзе бит картның куенына керергә атлыгып тора. Көче-дәрте бар кебек тә соң, шушы салкын душы сыман гына булса, нинди сөенеч, нинди юаныч алырсың икән, ә?! Бу бит сиңа Ильяс та, Радик та түгел. Бу бит инде чәче агарып беткән, аксап-туксап, таякка таянып йөри торган бер карт! Ярый да бит ир-ат вазифасын башкара алса! Бер дә атлыгып тормый шикелле иде бит, үзем әрсезләндем бит әле... Әгәр дә аның теләге булмаса? Яки аның теләге булып та, җегәре булмаса? Аннан да яманрагы — дәрткәхискә бирелгән бер мизгелдә җан тәслим кылса, ни хәл итәрсең? Кеше үтергән дип, төрмәгә илтеп тыксалар үзеңне!.. Аннан соң бит бер генә ир-ат янына да бара алмаячаксың, шул суына барган тәнне, шәрә тәнеңә ишелеп төшкәч, синең өстеңдә тәмам бозга әйләнгән тәнне гомер буйларыңа оныта алмаячаксың!.. Шушы салкын су кебек, тәнеңне куырсамы?!

Туташ, ваннада басып торган килеш, сүсәреп-искереп беткән, ярыйсы ук керләнеп өлгергән озын яшел сөлгене кулына алды, әмма шулчак тәненең кибеп өлгергәнен шәйләде. Кире элеп азапланмады сөлгене, шунда бер почмакка томырды. Ашык-пошык кына өстенә киеп алды да, башын-чәчен тарамыйча ук, аягына босоножкасын элеп, ишеккә атылды.

 Япь-яшь асыл зат белән сөешүне-ләззәтләнүне өмет итеп, күз алдына китереп яткан сәнгатькәр, ишекнең шапылдап ябылганын ишетү белән, дерт итеп китте, үзе шундук моның асылын аңлады тагы. Озак ятты Габделбакый караватта, аның чал башыннан төрле маҗаралар агылды. Барыннан да битәр шунысы гаҗәп, ул моңа бер дә шаккатмады, нәгъраә ормады, ул моңа фәкать гарьләнде генә. Шундый лазем асыл затның сурәтен языйм дип ничаклы вакытын сарыф итте, анысы барып чыкканнан соң кавышуга өмет баглады — сандугачтай сайрады, гайрәтләнеп-егетләнеп карады, нәзакәтле асыл затның куе вә озын

чәчләренә күмеләчәгенә тәмам инанып, буйдак караватына сузылды. Әмма чибәркәй нишләптер кире уйлады, тәртәгә типте, булды дигәндә борып куйды...

Озак ятты Габделбакый караватта, уйланырга аның вакыты да баштин ашкан, җае да чыгып кына тора иде... Олуг акыл иясе буларак, ул, уйлана торгач, үзенең инде гомеркәе узган икәнне дә, шәхси көнкүрештә һичбер кемгә кирәге юк икәнен дә, үзенең ялгыз башы көн күрергә дучар ителгәнен дә икърар итәргә тәгаен мәҗбүр булды. Ялгызлыктан качу юлын, җанны саклап калу юлын эзләү-табу зарур иде.

Иҗат кешесе нинди әсәрен язу-ясауга нинди вакыйга-нәрсәнең сәбәпче булганын тәгаен генә һичбер вакыт әйтеп бирә алмас иде. Кайчагында ул сәбәпләрнең күбәү булуы да бик ихтимал. Тик инде әлеге уйланулар, дуадак ятагында яткан чактагы уйланулар «Сагыш» образын иҗат итүгә бер этәргеч булгандыр, дип фикер йөртергә урын бар.

### Көз

Тиздән инде җәй узып, көз дә җитәр.
Юкәләрнең яфраклары саргаешып, коелып китәр.
Саргаешып, боегып җиргә төшәр —
Куырылган яфрак тулыр бакча эче.
Җылы урын, коры урын эзләп һаман,
Көне буе өйдә калыр карт Урманче.
Мич башы юк. Ямьшек диван, телевизор —
Боегып шунда утырыр карт Урманче...[1]

## XI баб

### «Сөембикә»

*«Без бит бер дә тарих язмыйбыз.*
*Тарихны язарга кирәк иде...»*
Бакый Урманче,
*1989 ел, 23 февраль.*

*«Ул туган туфрак дигән нәрсә...*
*Сәнгать өчен аның әһәмияте бик зур!»*
Бакый Урманче,
*1978 ел, 17 май.*

«Сөембикә»не Назим әле сәнгатькәрнең ерактагы остаханәсенә беренче мәртәбә аяк баскач та күрде. Хәер, почмактагы ул бүкәнне күреп кенә, моннан нәрсә килеп чыгасын чит кешегә әйтүе читен иде әле. Аксакал үзе:

— Милли каһарманыбыз Сөембикәнең сурәтен уярга исәп, боерган булса,— дип хәйран зур ышаныч белән, һәркемне ышандырырлык итеп әйтте.

Мәктәп елларында да, университетта уку дәверендә дә агачның авырлыгын үз җилкәсендә,— елга портында баржалар бушатканда да, урмандагы агачларны вагонга төярлек хәлгә китергәндә дә,— шактый ник татыган Назим моңа һич тә ышанырга теләмәде; һәрхәлдә, шушы гапгади, шоп-шома бүкәннән, юкә бүкәненнән, берәр нәрсә ясап булырын күз алдына китерә алмады. Тегенди-мондый нәрсә генә түгел, сәнгать әсәре бит әле җитмәсә!..

---

[1] Б. Урманче шигыре.

Гүя аның шиген көчәйтү өчен, юри әйткән шикелле иттереп, сәнгатькәр:

— Хәйран чибәр булган икән, дип язалар бит ханбикәбезне. Һәр адәми зат бер күрүдә гашыйк була икән үзенә,— дип тә өстәде. Гәптәшенең йөзендә шик-шөбһәне шәйләп: — Мөхәммәдьярны беләсең инде, шигърияткә бөтен гомерен багышлаган шәхес. Шул бер күрүдә үк Сөембикәгә үлеп гашыйк булган, аңа багышлап искиткеч тирән хиссиятле матур-матур шигырьләр иҗат иткән,— диде.

— Бакый ага, сезне фәкать сынлы сәнгать өлкәсендә генә түгел, бәлки бөтен мәдәният өлкәсендә остаз дип, аксакал дип тану лазем. Ләкин...

Аксакал егетләр өлгерлеге белән:

— Ләкин Сөембикәнең сурәтен чыгара алмыйсың, хәлеңнән килми, төс түгел, димәкчесеңме? — дип бүлдерде.

Үпкәләмәве күренеп тора: йөзендә елмаю. Фәкать элек-электән әңгәмә корырга яраткан аксакал менә хәзер, шушы минутта да иркенләп гәп куертып җибәрүгә һич каршы түгел иде. Гәрчә моны күреп торса да, шагыйрь үзенең күңел түрендәге шиген әйтмичә кала алмады:

— Сезнең сәләтегезгә иманым камил, Бакый ага. Тик бу очракта бит сүз шушы бүкән турында бара. Моннан берәр юньле нәрсә чыгарына шикләнәм мин.

Рәхәтләнеп көлде соң Урманче:

— Синең мөселманлыгыңда мәнем шигем бар, дип сүз көрәштерергә ярата идек без мәдрәсәдә укыган чагында. Дустым, эшли башлаганчы һәммә нәрсә дә нәкъ әлеге бүкән төсле күрексез була бит. Хикмәт синең скульптур портретны нәрсәдән ясарга ниятләвеңдә. Мәрмәр итеп күрәсең икән — олы бер таш булыр ул. Үзе мәрмәр ул, дустым, үзе таш. Син аның тирәсендә биеп йөрергә мәҗбүрсең, чөнки син аны урыныннан да кузгата алмыйсың. Әнә минем хәйран ныклы биек урындыкларым бар, күрше ясап биргән иде. Бушлай түгел, әлбәттә. Син аны гомереңдә бушлай эшләтә алмыйсың. Базар бәясен яхшы белә ул малай.

— Мин аны олы кеше дип торам...

— Олы инде, олы, үзенең малайлары бар. Болай гына әйтүем, үз итеп кенә. Мин сине дә әле шулай атыйм.

— Миңа бара ул, Бакый ага.

— Әнә шул биек урындыкка биш-алты егет китереп куя да, эшләп бетергәнче шунда утыра ул таш. Ул сиңа хезмәт күрсәтми, син үзең аның тирәсендә бөтерелеп йөрергә, хезмәт күрсәтергә мәҗбүрсең.

— Һөнәрегез кыен инде, әйтәсе дә түгел.

— Каләм тибрәтеп көн күрүчеләр кәгазьдән гайре нәрсәне белмәсәләр, безнең халык барысына да җитешә: эскизын катыргыга, шул ук кәгазьгә сызгалый; картинасын киндергә язарга ярата; фанер яки тактаны да читкә какмый — буяуны гына кабул итә күрсен. Ә инде скульптурага килгәндә, шулай ук төрле материалны сынап карый. Әмма бер сере бар ул һөнәрнең, дустым, бер хикмәте бар. Әгәр дә мәгәр син алдан ук материалын дөрес билгеләмисең, дөрес тапмыйсың икән, күпме генә тырышсаң да, нинди генә сәләткә ия булсаң да, берни кора алмаячаксың. Юкка чиләнмәс өчен, уңай нәтиҗәгә ирешү өчен, иң әүвәлесе, образны теге яки бу материалда күзаллау зарур, күрә белү бик әһәмиятле. Аннары инде — бая әйткән материал сайлау...

Әңгәмәне куертып җибәрү өчен генә, егет тә:

— Без күргән һәйкәлләр гадәттә бронза була бугай? — дип үз сүзен кыстырды.

Аксакалның түгәрәк йөзенә бертөрле мәрхәмәтле, игелекле, рәхәт елмаю җәелде:

— Һи, дустым, һәйкәлне бакырга койганчы күп төрле процесс уза әле. Образны һәйбәтләп күз алдына китергәч, һөнәр иясе ул сынның эскизын ясый. Аннары балчыктан бәләкәй генә иттереп сынның үзен ясарга керешә. Мәрмәр каты бит ул, аңа чүкеп ясаганыңны гомердә дә үзгәртә

алмыйсың, башыңны ташка бәрсәң дә. Шуңа күрә әүвәлге вариантларны,— бер генә буламы, ике-өчме, әллә ишлерәкме,— балчыктан әвәләү хәерле. Эшнең бисмилласы шул була, дустым. Аны җаның теләгәнчә үзгәртә-үзгәртә әкренләп үзеңә кирәкле хәлгә китереп житкерәсең. Шуннан инде материалны тәгаенлисең, хәстәрлисең дә макетның зуррагын әвәлисең. Анысы нәкъ син күзаллаган образ зурлыгында булырга тиеш. Күңеленә ошап житмәгән жирләрен әле монда да төзәтү мөмкинлеге бар. Камиллеккә ирешүеңә инде тәмам инанганнан соң гына, аллага тапшырып, эшкә тотынасың...

— Мәшәкатьле икән эшегез... Шигырь язу кебек үк...

— Шула-а-ай, дустым, рас әйтәсең. Нәкъ шигырь язгандагы шикелле. Андый мәшәкатьле, ифрат авыр булмаса, ихтимал, иҗат ләззәте дә килмәс иде.

Гәрчә зур игътибар белән тыңласа да, Назим әле барысын да ачыклап бетермәгән иде. Шуңа:

— Бакый ага, алай зурдан кубу һәйкәл салганда гына буламы, әллә югыйсә мәрмәрдән, агачтан портрет ясаганда да сораламы?— дип кызыксынды.

Аксакал бик рәхәтләнеп аңлатуын дәвам иттерде:

— Мәрмәрдән берәр шәхеснең сурәтен чокып ясар өчен, әле генә әйткәннәрнең һәммәсен кулың белән, шушы катып-бирчәеп беткән бармакларың белән эшләү мәҗбүри. Әллә син Тукай, Әмирхан, Ямашевлар җиңел генә эшләнгәндер дисеңме? Ю-у-ук, дустым, ашыкма — ашка пешәрсең. Андый портретларның һәркайсына, бик беләсең килсә, ким дигәндә биш-ун еллык хезмәт салынган. Образны ничек күрәсең бит, әнә шунда хикмәт.

Әңгәмәне үзенә кирәкле сукмакка төшерү җаен тапты шикелле Назим:

— Агач белән эш иткәндә ничегрәк инде?— дип, сабыйларда гына очрый торган самими карашын остага төбәде.

Әмма аксакалның логикасы көчле, фикер сөрелеше ачык иде, шуңа ул һич тә юлдан язмыйча, абынмыйча-сөрлекмичә сөйләвен белде:

— Материал сайлаган чагында еш кына агачка юлыгалар. Коненков хәтле Коненков ара-тирә агачтан уйгалаган. Әлбәттә инде, аның материалга мохтаҗлыгы булмаган: бронзадан да койган; цементтан катырып, өстеннән алтын йөгерткән чаклары да булган; мәрмәрне дә хәйран оста чүки белгән — сөйләп кенә бетерерлек түгел инде ул. Әмма, дустым, шунысын искә ал: иң яраткан, әүлиягә санаган шагыйренең образын агачтан уеп ясаган.

Гәптәше утырган җирендә кыбырсый башлады:

— Кемне яраткан соң ул, Бакый ага? Пушкиннымы?— дип сорап куйды.

Аксакалның алай тиз генә бирешергә исәбе юк иде:

— Белмәдең, мсье поиет, белмәдең. Минус бу сиңа, минус,— диде, рәхәтләнеп балкыды.

— Алайса Некрасовныдыр әле?

— Юк, дустым, тагын минус.

— Урысларда шагыйрьләр күп бит ул, барысын да әйттермәгез инде.

— Есенинны, Сергей Есенинны. И һәм шундый матур килеп чыккан, сокланып үләрсең инде менә!..

— Сез дә үзегез әүлиягә санаган затның портретын агачтан ясарга уйладыгыз инде алайса?

Аксакал моңа туры җавап бирмәде: алай итүне вакланууга санагандыр, күрәсең, үзенең фикерен бер дә кабатламый-нитми генә дәвам иттерде:

— Сөембикәнең образын хәзер инде аерымачык күзаллыйм. Гаять үзенчәлекле булырга тора әле ул портрет. Ходай насыйп итсә...— Габделбакый сул кулы белән ярыйсы ук сыегайган чәчен сыпыргалады.— Балчык белән матавыкланмаска бу юлы ниятем. Кәгазьдә эскизларым җитәрлек.

Моны ишеткәч, гәптәше янә дә аптырауга калды, гаҗиз булды.

— Бакый ага, әле генә балчык-балчык дип, без бәләкәй чакта төрле хайван сурәтләре ясаган материалның кыйммәтен үстердегез-үстердегез дә... инде аңардан үзегез үк баш тартасызмы? — дип ярып салды.

Аксакал бик рәхәтләнеп бер кеткелдәп алды, шуннан соң гына төшендереп бирде:

— Син дөрес аңлагансың, балчыкның кыйммәте бик зур, аның файдасыннан гомумән баш тартырга уйламыйм. Һич юк! Әмма һәр эшкә иҗади килү зарур, дустым. Бу очракта миңа илаһи бер образны тудыру өчен эскизлар ярдәм итәчәк. Мин шуларга таянмак булдым. Хәер, сөйләвен сөйлим дә бит әле, нәрсә килеп чыгасын хәзердән үк әйтүе кыен. Ник дигәндә, үзем өчен дә яңа алым; табыш дисеңме син аны, ачыш дисеңме — барыбер...

— Сезнең тәҗрибә белән дә чыкмаса, аннары башка һөнәр ияләре нәрсә дияргә тиеш инде?

— Алай димә, дустым. Бу очракта без фәкыйрегез гап-гади өйрәнчек хәлендәдер. Ошбу ысул безнең өчен яңа дөньядыр. Кеше бит үз һөнәренә гомере буе өйрәнә... Беләсеңме, Пәйгамбәр хәдисләрендә нинди бар? Кешенең иң ләззәтле вә хәләл ашы үз кәсебе белән тапкан ризыктыр. Кешенең баласы да үз кәсебеннән хисапланадыр. Шулай, дустым, урлашуга караганда, агач уеп тапкан ризыгым — мең артык.

Шушы сөйләшүдән соң Назимга әлеге хезмәтнең озын-озак дәвам итүенә дә, гап-гади агачның акрынлап кеше сурәтенә керүенә дә, ниһаять, Сынлы сәнгать музеена куярлык кыяфәткә килүенә дә шаһит булырга язды, насыйп булды. Берәр атнадан ук әлеге букәннең ишек төбендәге почмактан түргә күчүен шәйләде. Үзгәрешне дә сизде: моңарчы әле каерысыннан арынган булса да юкәнең коңгырт-сары элпәсе чистартылмаган килеш, ничектер карасуланып торыр иде, хәзер инде оста аның бер ягын ачкан, шуңа ул ягының өске өлеше ап-ак төскә кергән иде. (Юкә бит ул искиткеч ак булучан.) Ләкин әлегә бертөрле дә пычак-пәке эзе күренмәде. Бер ягының шактый өлеше агартылудан узмаган — и вәссәлам. Тагын бер баруында беленер-беленмәс кенә карандаш эзләрен шәйләде. Әмма бу эзләрдән фәкать вак-вак яфраклы агачны яки гөлне генә күз алдына китерерлек иде. Үзе түгәрәк тә түгел, бераз озынчарак, овалрак, үзе нишләптер челтәр-челтәр итеп сызылган. Пычак-пәке эзе әлегә күренми. Юк, чыкмас моннан юньле нәрсә, чыкмас. Олы кешене рәнҗетмәскә тырышып кына:

— Әллә шадра итәсез инде алиһәгезне? — дигән булды.

— Нәрсәдән чыгып шундый фикергә килдең икән? — дип, оста сагая калды.

Назимның җавабы әзер иде:

— Йөзен шома итмисез бугай, менә бит карандаш белән ничек итеп сырлап чыккансыз.

Аксакал рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Әмма аның холкында гәптәшенә тупас бәрелү гадәте булмаганга, йомшак кына тавышы белән:

— Син аны әйтәсең икән... Ул бит әле тышкы кыяфәтенең дә контурлары гына, дустым. Бу аның япмасы булачак, боерган булса. Аның киемнәрен гаять затлы итәргә әле исәп. Портретның ничегрәк килеп чыгасын әйтүе кыен әлегә. Тик мин аны байтактан бирле күреп киләм инде, анысы хак, образы күңелем түрендә. Хәйран кадерле шәхес ул минем өчен. Белмим, хыялымдагы образны биреп җиткерә алырмынмы, юкмы — анысын әйтүе кыен. Бәлкем әле, материал бөтенләй икенче төрле ысул белән эшләүне таләп итәр... — диде, уйга калды.

Икенче баруында Назим инде пәке эзләрен дә шәйләде. Оста бик зур саклык белән генә карандаш эзеннән юкәне ача башлаган. Әһә, бу тирәдә киңрәк икән, маңгае буласыдыр, аска таба челтәр әкренләп тарая бара, иягедер... Моның борынын нәрсәдән ясарга уйлый икән соң автор? Әллә юкәнең үзеннән үк чыгарырга микән исәбе? Юктыр, алай булмас, икенче

бер материалдан ясардыр. Күзләрен әүвәл карандаш белән, аннары пәке белән сызгалар инде, анысына аптырап тормас. Ә менә авыз-борынга монда материал җитмәс. Юкәдән ясарга уйласа да, ябыштырып куяр, ябыштырмый хәле юк...

Бу юлы бәйләнмәде егет, башын чайкау белән чикләнде. Чыкмастыр моннан алиһә сурәте, чыкмастыр...

Тагын бер килүендә эшнең алга китүен күреп гаҗәпләнде. Әнә ничек икән ул! Оста димәсәң оста! Агачның түгәрәклеген әнә бит ни рәвешле файдаланган диген син: маңгае агачның бөтен киңлеген биләгән, кашлары карлыгач канатыдай сузылып та сызылып киткән; күз кабаклары эчкәрәк уелган, шулай да табигый төс алып сизелеп тора; шуннан инде борыны үзеннән-үзе калкынып калган. Бит алмалары әле бөтенләй эшләнмәгән, яңаклары уелмаган, авыз-борын тирәләре әлегә тупас, бернинди нәфислек юк үзендә. Һи, казанын ясаган кеше колагын чыгара инде аның, аптырап ятмый.

Янә бер баруында алиһәнең күлмәк якалары үзенә күрә челтәр кыяфәте алып бертөрле затлылык өстәгән иде.

Аннары маңгай өстендәге челтәр тышына түгәрәкләр, чәчәкләр-яфраклар ясалгач, баш киемен күзалларга мөмкинлек туды. Ичмаса моның бизәк икәне күренеп тора, ә менә йөзе-кыяфәте?.. Ничек кенә чыгара алыр икән?..

Әмма аксакал Сөембикә портретын эшләп бетерергә ашыкмады. Әнә шушы тупас хәлендә шактый вакыт ташлап торды, кагылмады. Әүвәл Тукайга һәйкәл коясы бар иде. Шул эш аның вакытын алып кына калмады, нервыларын ашады, таякка ныграк таянырга мәҗбүр итте.

Тукай көннәреннән соң Урманченың үзенең 80 еллык юбилеена хәстәрлек эшләре башланып китте. Ай-һай, мәшәкате күп булды да соң бу әзерлекнең! Күргәзмәне тантана узасы җирдә — Актерлар йортында гына ясарга карар кылынган. Зуррак картиналарын куйса — нибары тугыз-ун әсәренә урын табылачак. Юрганыңа карап аягыңны сузмый хәлең юк. Шуңа күрә күләм ягыннан кечерәгрәк әсәрләрне күрсәтү мәгъкуль булырдыр. Акварельләренең берсенең генә дә кысасы-пыяласы юк. Нишләргә?

Андый чакны, әзер әйберләре дә өйдә торып калганда, кая инде ул башлаган эшләрне тәмамлау кайгысы!

Шул рәвешле «Сөембикә» портреты башлаган көе торып торды, сынчы аңа айлар буе кагылырга вакыт тапмады. Хәер, ул аны читкә дә алып куймады, ә инде әсәр синең күз алдыңда икән, синең аны күрми хәлең юк; ә инде күзеңә чагылган нәрсә миеңә дә үтеп керсә, һичшиксез, уйланырга мәҗбүр итә. Аксакал үзенә бинһаяхаклы таләпчән килде, артык уемнар ясаудан сакланды...

Алиһәнең бүгенге кыяфәте, бөтен чибәрлеге, гүзәллеге, йөзенең нәфислеге бөтенләй котмәгәндә, әллә кайлардан эчтән килеп чыкты шикелле. Кайчагында шулай син бик өнәп бетермәгән һәм юньләп аралашмаган кеше белән иркенләп бер сөйләшәсең дә... кинәт тегенең күңеле, эчке байлыгы тулаем ачыла, синең алдыңда шәхес яңадан тугандай була. Монда да нәкъ шундый хәл, бүтәнчә әйтә дә алмас иде Назим. Бу чаклы камиллеккә үзенең күз алдында ирешүче сәнгаткәргә егет олылап вә сокланып карады.

— Тәки җиңеп чыктыгыз бит, Бакый ага! Әле кайчан гына, булмый, булмый, дип үз туксанымны тукыган идем, хәзер инде биреләм, сез җиңдегез. Искиткеч бер чибәр зат икәненә, дөресрәге, булганына тәмам ышандырдыгыз. «Тәнкәен ак...» дигән шигъри юллар бигрәк туры килә инде алиһәгә!..

Аксакалның холкы гаҗәп бит: эшләп бетердем, дигәннән соң да әле читкә китеп-китеп каравын, затлы күлмәк якаларын тагын да килешлерәк итү исәбе белән янә бер-ике уем ясавын шактый вакыт дәвам иттерде. Күзен «Сөембикә»дән алмый гына, үзенең фикерен әйтергә дә җай тапты:

— Дәрдмәнд ул шигырен Нәваига ияреп язган бугай... Ничек дигән бит, ничек дигән! — Башын арткарак ташлап, тамак кырып алды да гаҗәеп саф һәм көр тавыш белән:

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында мин яраткан;
Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан! —

дип рухланып шигырь укыды. Каян хәтеренә төшерде диген син аны. Гомере буе шуны гына уйлап йөргән сыман...

Гәптәшенең телсез калуын күреп, рәхәтләнеп бер елмайды да, бармагын югары чөеп:

— Дәрдмәнднең бу шигыренә мин икенче бер әсәремне багышладым. Тушь белән генә ясасам да, хәйран матур нию килеп чыкты сыман... Әле син аларга килеп җитмәгәнсең, ню белән бер мавыгып алды абзаң, алды, — диде. — Иншалла, каталогына керердер әле.

— Исән булсак, альбомга кертәбез аны, альбомга!..

Бу юлы сәнгатькәр дәшмәде — аны уйлар өермәсе бөтереп алган иде.

Икенче атна азагында Назим телефоннан чылтыраткач, аксакал:

— Минем тирәдә бит грипп шикеллерәк бер нәрсә йөри, син инде иртәгә килмәссең, дустым, — диде.

Аннан соң хәл белешеп чылтыраткач:

— Әү, җаный! Безнең бит эшебез тукталып тора. Әйдә кил, сөйләшәсе сүзләр дә бар, — дип элеп алды.

Остаханәгә барып кергәч, Назим һушсыз калып егыла язды. Озын өстәлдә бөтен залны бизәп торучы Сөембикә портретын танырлык түгел — автор аны куе-сарыга буяп чыккан иде. Кайчагында шулай хатын-кызлар чәчен буяп, сөрмә тартып кыяфәтен үзгәртебрәк җибәрә дә күргән бер кешене хәвефкә төшерә. Андый чакны һәркем, чама белми кылансаң, таный да алмаслар әле үзеңне, дип уйлый, тегене эчтән генә битәрли. Алиһә дә һич танырлык түгел иде. Әллә нишләп киткән, каратут йөзлегә әйләнгән. Бигрәк килешми икән үзенә мондый төс...

Назимның ачылып калган авызыннан:

— Тагын нишләттегез инде, Бакый ага?! — дигән әрнүле авазы ургылып чыкты.

Мөтәлчек атып уйнаган малай-шалай, мин менә бола-а-ай иттереп атына беләм әле, дип масайгандай, аксакал үзе көлде генә:

— Болай дөресрәк булыр, дустым, — диде. — Инде хәзер «тәнкәен ак» дип бәйләнә алмыйсың. Кипкәннән соң игә килә әле ул, килә, син алай ук хафаланма, — дип тә өстәде.

Иртәгә ничек буласын Назимның тәҗрибәсез күзе генә күреп житкермәгән икән. Алиһәнең йөзкәе тора-бара табигый тән төсенә керде, тагын да матурланып, тәмам нурланып китте. Күргәзмәгә куйгач, аңарга сокланмаган кеше калмады.

Бу әсәр рәссамның иҗат байлыгын чагылдырачак сәнгать альбомын да бизәргә тиеш иде. Аксакал үзе:

— Әлбәттә, шулай! Бу мәсьәләдә ике төрле фикер булуы мөмкин түгел, һич мөмкин түгел! — дип кистереп әйтте.

Альбомга керәсе нәкышь, уем-скульптура һәм графика әсәрләре арасыннан иң камилләрен сайлап алганнан соң да әле күләмнең икеләтә артып киткәне мәгълүм булды. Китап нәшриятына кәгазьне мыскаллап кына җибәрәләр — планга фәлән басма табак булып кергән икән, син инде аны үлсәң дә арттыра алмыйсың. Әүвәл юкә иләк белән иләделәр. Алай гына барып чыкмагач, кулга җиз иләк алдылар, ягъни иң камил дигәннәре арасыннан да бик-бик сайлап кына тәкъдим итәргә булдылар. Нәшриятта җиз иләктән үткән әсәрләрне бик мәгькуль күрделәр. Тик

минә партия өлкә комитетында гына терәлеп калды... Анда кайсыбер әсәрләрне беренче сәнгать альбомында күрергә теләмәделәр. Иң әүвәл «Сөембикә» портретын. Юкә иләктән дә, җиз иләктән дә үткән «Сөембикә»не...

Әлеге хезмәтенә карата сәнгатькәрнең нинди фикердә торганын яхшы белгәнгә күрә, Назим «Сөембикә»не төшереп калдырырга һич тә риза булмады. Шуннан «түп йортта»:

— Ичмаса националистический дух булмасын, исемен үзгәртсен! — диделәр.

Милли каһарманның кайсының исемен үзгәртәсең ди инде: Батыршаныңмы, Пугачевныңмы, Җәлилнеңме? Ханбикәнең болай да кабер ташына берни язылмаган бугай әле...

Ничә еллар буена иҗат иткән әсәрен альбомнан төшереп калдырырга маташуларын ишеткәч, аксакал күзләрен алартып егеткә текәлде:

— Кем ул? Син әйт миңа, шундый камил әсәремә кайсы дошман каршы килә? — дип бәйләнде.— Нигә син тел яшерәсең әле, әйт үземә?!

Бичара егет ике ут арасында калды. Ничек тел яшермәсен дә ничек итеп, өлкә комитеты сәркатибе, дип турысын әйтсен? Алай дисә, аксакал шундук телефон трубкасына ябышачак, тавыш кубачак. Аның нәтиҗәсе нинди булачагы билгеле — альбом бөтенләй чыкмый калачак...

Нәшрият хуҗалары шунда егетлек күрсәттеләр, әле ярый! Альбом чыккалаганчы кем бар да кем юк, өлкә комитеты сәркатибе үз урынында калган тәкъдирдә дә гел шуны гына уйлап утырмас, әллә бәлкем, онытып та куяр әле, дип, тәвәккәлләделәр бит, рәхмәт төшкерләре.

Назим кичке якта, артык соңга калмыйча гына, аксакалга чылтыратты. Чыбыкның аргы башыннан:

— Әү, җаный! — дигән күңелгә якын тавыш яңгырады.

— Кәеф-шәрифләрегез ярыймы, Бакый ага? Иртәгә эшли алырбызмы?

— Кил, дустым, кил, эшләрбез.

— Авырмагыз гына.

— Авырырга Урманченың вакыты юк.

Назим килгәндә рәссам гүя иртәнге сменаны эшләп бетергән дә, тәмам хәлдән таеп, бераз ял итәргә утырган иде. Әмма чынбарлыкта алай түгел дә түгел: сөйләгән арада да, йотлыгып тыңлаган арада да аксакал бүген эшләргә алынган эштән һич күзен алмас, ара-тирә сүздән туктап, ныклабрак текәлер, уйланыр иде.

Әле дә менә утырган килеш буяулары ягына борылды.

— Шушыларны әзерләп бетерим, дим, күргәзмәгә...

— Изге эшкә тотынгансыз. Триптихсыз нинди күргәзмә ди инде ул?

— Әйе, дустым, рас әйтәсең. «Татарстан» безнең күргәзмәбезнең түрендә торырга тиеш. Иншалла, шулай булыр да. Тик менә килеп җитмәгәнрәк җирләре күзгә бәрелә башлады. Өчесен дә янәшә куйгач, калкыды да чыкты. Шулардан арындырырга исәп.

Менә сәнгатькәр кыл-каләменә бик талымлап кына буяу элде, аны әзер торкан килеш, дивар буена өчесе рәттән бастырып куелган биек-биек картиналарга җентекләп кенә күз салды да шуннан соң гына уртадагысына бер-ике сызык сызды, ничегрәк килеп чыкты икән, дип, башын арткарак ташлап, күзен бераз кыса төшеп, бик төпченеп-текәлеп карады.

— Менә шулайрак булырдыр бу, дустым! — дип беркадәр канәгатьләнү хисе белдерде.

Татарстанның бөтен төбәкләрен, барлык байлыкларын миниатюрада чагылдырган триптих карап туймаслык килеп чыккан иде. Үзәкне тәшкил итүче киндернең дә нәкъ үзәгендә башкалабызның символын күрсәтүче гүзәл Сөембикә манарасы, аның әйләнә-тирәсендә биек-биек таш пулатлар... Картиналарның өчесен бердәй илнең бөек дәрьясы Идел аркылыга кисеп чыга, әмма ул һич тә ямьсез-шыксыз булып тормый, киресенчә,

үзенең киңлеге, мул суының сыеграк кына зәңгәрлеге, яшел утраулары, йөк ташучы баржа һәм танкерлары белән, аккошлар сыман йөзеп барган ак пароходлары белән бөтен триптихка ямь биреп тора. Алгы планда — Тау ягы, аз-маз гына урманы да бар болай үзе, тик әлләни алай мактанырлык түгел, Марииле урманнарына житми. Анда-санда авыллар, колхоз-совхоз фермалары, хәтта әле нәселле сыерлар көтүе дә тасвирланган. Авыл яки шәһәрләрне рәттән төзү белән мавыкмаган рәссам, бәлки унган хезмәт кешеләренең жир өстендә иген игеп, мал-туар асрап, ә инде жир астыннан кара алтын чыгарып яшәвенә басым ясаган. Чыннан да, картиналарның өчесенең дә өске өлешен алтын басулар алып тора, үзәктәгесендә — комбайннар белән уракка төшкәннәр. Кремль янында ук Иделгә бәләкәйрәк кенә Казансу кушыла, агым буйлап түбәнрәк исә киң булып җәелгән, мул сулы, Иделгә тиң Кама-Чулман дәрьясы кушыла. Анысы, нәкъ табигатьтәге шикелле, урала-урала, кыр-басуларны камый-камый, еракларга сузыла. Үзәктәге картинаның югарыгы өлешендә исә — нефть вышкалары...

— Шәп килеп чыккан, Бакый ага, Третьяковкага куярлык булган бу! Бөтен республиканы берьюлы күрерлек иткәнсез бит. Үзе бер дөнья. Төсләр ягыннан алганда, шул тикле гармония, салмак көчеш, кычкырып торырдай берәр кечтеки генә деталь дә юк бит,— дип куйды Назим.

Аксакалның йөзе нурланып-балкып китте. Әйе, хезмәтен бу бәйләнчек тә кабул итә, димәк.

— Төсләрнең бирелешеннән чыгып караганда, рас әйтәсең, дустым, симфония килеп чыккан. Импрессионизм инде, артыгы кирәкми.

— Шушындый да гүзәл киндерләр яза алган рәссам үзен һич курыкмыйча нәкышь остасы дип атарга тиеш. Монда бит татар халкына хас моң ярылып ята, халыкның моңы чагыла.

Яман сүз ишетмәгәем дип төкләрен тырпайтып өлгергән аксакал кирегә сукалау ягын карады:

— Юк, мин скульптор, дустым, нәкышьче түгел, түгел! — диде.

Егетнең дә бирешергә исәбе юк иде:

— Һич килешәсе килми, Бакый ага, андый фикерегез белән. Сез коеп куйган нәкышьче. Хәрәкәтне кем шушылай оста бирә алыр икән: сыерлар утлап йөри, берсенең дә позасын кабатламагансыз; йөк машинасы үкереп үргә менеп килә; яр буендагы кызыл калай түбәле дебаркадердан ак пароход Идел киңлегенә кереп китеп бара; вертолетыгыз оча да оча инде, һавада асылынып тора алмый; иген үскән басуларны ярып, әнә, поезд чаба; комбайннарны да хәрәкәттә күрсәтәсез — өлгергән игеннәр алтынсу булса, комбайннардан соң тырпаешып калган камылларның төсе үзгәрә, коңгыртлана... Әйе-әйе, сез коеп куйган нәкышьче! Ким дә түгел, артык та түгел!

Көлемсерәп куйды Урманче һәм гадәтенчә әлеге хәлгә дә үзенең мисалы әзер икәнен янә бер мәртәбә исбатлады:

— Болай бит ул, дустым. Син беләсеңдер инде... Хужа Насретдин базарга сыер алып чыккан. Сатарга. Берәү килеп сораган, казың кыйбатмы, дип, икенчесе... Өенә кайткач, әйтә икән Хужа хатынына: без сыер дип йөргән нәрсә каз булган икән, дип... Мин дә Хужа Насретдин бит...

Рәхәтләнеп бер көлештеләр соң. Бу юлы икесе дә көлде.

Уртак тел тапканнан соң, гадәттәгечә, икәүләшеп җиңнәр сызганып, илһамланып эшкә ябыштылар.

Менә бер заман аксакал боеграк кына тавыш белән:

— Назимҗан, мин бик кычкырмыйча гына җырлап җибәрсәм, каршы килмәссеңме? Эшеңне калдырмаммы? — дип куйды.

— Бик рәхәтләнеп тыңлыйм, Бакый ага, баритон тавышыгызны,— дигән җавап алгач, сәнгатькәр әүвәл җиренә җиткереп тамак кырды, аннары бик үк кычкырмыйча гына сузып җырлап җибәрде:

Кук кугәрченләрнең дә лә сөтен саудым
Кызыл пәрәннекләр дә лә ясарга;
И дускайларым ла, безләргә язсын иде
Бер өстәлдин ашлар да ла ашарга.
Чаба-юрта киләдер лә кук юрга,
Ташлашмаек, туганкайлар, күп елга!..

Шактый эшләп арыгач, берара ял итеп алырга ниятләгәч, Назимның да теле ачылды:

— Бакый ага, без теге, денем өчен түгел, көнем өчен, дигәндәй, һаман дөнья куа-куа артыграк вакланып китмибез микән?

— Син аны нәрсәдән чыгып әйтәсең әле, дустым?

— Бу арада Николай Рерих язмалары кулыма төште. Ул бит, гел икенче планетада яшәгән кешедәй, гаҗәеп тирән фикер йөртә икән...

— Хуш, ничегрәк инде? Без дә белик әле.

— Каты бәгырьле булудан сакланырга өнди. Киң күңелле, йомшак холыклы булуны алга сөрә.

— Һе! Шунсыз бит ул Рерих та була алмас иде. Гап-гади нәкышьче булыр иде. Талантлы, әмма гади рәссам. Чөнки ул күргәннәрен генә рәсемгә төшерер иде, үзенең кыйбласы булмас иде. Бүген портрет, иртәгә пейзаж, аннан ары автопортрет. Әнә шул фикер иясе булу аны бөек максатка этәрә. Ул һәр әсәрен үзенең кыйбласына буйсындыра — кешелек җәмгыятен караңгыдан яктыга алып чыгу максатына юнәлдерә. Ә каты бәгырьлеме-юкмы адәми зат — анысы бер Алла тәкъдире.

Урманченың 85 еллыгына атап гаять олы күргәзмә әзерләнә. Күргәзмә залларының икенче һәм өченче катларын бирергә вәгъдә итәләр.

Хәйран мәшәкатьле эш инде ул күргәзмә үткәрү. Бигрәк тә аңа әзерләнү. Картиналарның күбесе әлегә рамсыз. Аны кем ясатырга тиеш? Рәссам үзе. Графика әсәрләрен дә Актерлар йортындагыча стендка кнопка белән генә беркетеп куя алмыйсың. Акварельгә әле рам гына да җитми, һәркайсын пыяла артына яшерергә туры килә. Югыйсә кояш яктысында уңып, атна-ун көн эчендә эштән чыга.

Багет-рамнар сатып алуны уйламады да Урманче. Якын тирәдәге заводта балта осталары да барлыгын ачыклап, завод җитәкчеләренең берсе үзебезнең кеше икәнен тәгаенләп, шуңа мөрәҗәгать итте. Аксакалның сүзенә илтифат белән карап, әлеге җитәкче, аңа нindирәк рамнар ясарга икәнен ачыклау нияте белән, осталарның бригадирын моның өенә җибәрде. Шунда рәссам үзенә кирәкле әйберне нindирәк агачтан ничегрәк итеп ясарга икәнен өйрәтте, үлчәүләрен әйтеп яздырды. Җитәкче кешенең әмере белән, шулай иттереп, аксакалга бушлай гына рамнар ясап китерделәр.

Җае туры килгәндә, зарланудан башы чыкмый иде Урманченың. Аны якын күреп, өенә килеп йөргән әдипләр, композиторлар, сәхнә осталары аның фәкыйрьлеген күз алларына да китерә алмыйлар. Мәдәният министрлыгына, башка җитәкче органнарга әледән-әле гозерләрен аңлаталар, милли сәнгатебезнең аксакалын ничек тә әлеге бөлгенлектән коткару чарасын уйлап табарга, һич югы пенсия түләүне җайга салырга әллә нинди «акыллы» киңәшләр бирәләр. Ә инде түрәләр, ашаган белми, тураган белә, дигән әйтемгә таянып, әлеге хәлгә ачыклык кертkәч, һәр айны рәссамның кереме ярыйсы ук саллы булу сәбәпле генә пенсия түләнмәвен чишкәч, фактларга да ышанмыйлар, үпкәләп кул гына селтиләр.

Күргәзмә гөрләп үтте. Йөзләрчә, меңнәрчә кеше килеп карады, үзебезнең шундый зур талантлы милли рәссамыбыз булуына сөенеп бетә алмады.

Альбомның «сигнальный» дип аталган сынамыш нөсхәсе кулына килеп кергәч тә, Назим, кош тоткандай, тизрәк Урманче янына очты.

Габделбакый Урманче үзенең әсәрләрен мәңгеләштергән беренче альбомны күреп сабый балалардай сөенде. Түргә узып, кәнәфигә иплəп кенə урнашты да караштыра башлады.

— Матур булган бит бу, дустым! — дип сөйләнә-сөйләнә карады альбомны. Соклануын яшермәде, сөенүе чиксез иде. Бер мәлне кинәт кенә сүздән туктап, тынып калды. Назим сагайды. Әллә юкса берәр кимчелек таптымы, нинди дә булса хата киткәнме? Ярый әле, тынлык озакка сузылмады. Бер заман аксакал:

— Күр инде... елап утырам икән ләбаса мин...— дип акрын гына тавыш белән әйтеп куйды. Аның күзләреннән яшь бәреп чыккан иде. Тез өстенә җәеп салган, ике кулы белән дә ныклап тоткан өр-яңа, типография буявы исләре бөркеп торган альбомның ачык битләрендә Казанның соңгы ханбикәсе — чибәр Сөембикә сурәте иде...

Үзенең күптәнге хыялын гамәлгә ашыргач, ягъни шушы яшенә җитеп кадер-хөрмәт күрмәгән аксакалның кулына гаять матур булып чыккан альбомны тапшырып, карт рәссамның ни чаклы сөенгәнен үз күзе белән күргәч, Назим инде тыныч күңел белән өенә кайтып китте.

Берәр сәгатьтән килеп кергән шәкерте Мирза үзенең остазын кәнәфигә җәелеп утырган хәлендә күреп, хәйран калды, бусагадан ук биргән сәламен кабатлап тормады, аксакалга ике кулын сузып күрешкән чагында ук:

— Бакый абый, нигә эшсез утырасың әле, ни булды сиңа? — дип сорап куйды.— Авырмыйсыңдыр бит? — дип кызыксынды.

Остазының кулында гомер-гомергә карандаш, күмер, акбур, кылкаләм, пәке, өтерге белән чүкеч күрергә ияләшкән шәкерт, әлбәттә, көпә-көндез аның эшсез утырганын шәйләп, чын-чынлап хафалана калды.

Әмма аксакалның кәефе әйбәт, түгәрәк йөзе балкый, тавышы гайрәтле вә көр иде:

— Нигә, дустым? Әллә син мине сиксән алты ел буена гел инде менә йөзем үстерү белән чикләнергә тиеш, дисеңме? Юк инде, Мирзаҗан, хаталанасың, дустым. Урманченың да үз гомерендә бер генә мәртәбә булса да әлеге йөземне татып карарга хакы бар! Менә бүген нәкъ шундый көн килде! Җан рәхәте вә ләззәтләр кичерәмен,— диде дә әле типография буявының исе дә бетмәгән альбомын сузды.

Аны олылап-хөрмәтләп кулына ала-ала ук, Мирзаның тәмам авызы ерылды:

— Моны, ничек диим, Бакый абый, типографиядән җибәрделәрме? Калинин шәһәрендә эшләнә, дигәнең хәтеремдә, өй адресың белән үзеңә җибәргәннәр инде, алай булгач...

Аксакал һаваланыбрак җавап бирде:

— Беркем дә эзләп маташмаган минем адресны. Һәркем үз эше белән, план тутыру белән мәшгуль... Назим китерде миңа моны. Аның эше бит. Аңа җибәргәннәр, тикшерү өчен. Брак-фәлән юкмы дип. Бу әле беренче карлыгач кына...

Кулына алып актара башлауга, Мирзаның да йөзенә елмаю җәелде:

— Брак-мазар ише нәрсә бер дә күренми әле монда... Ай-һай, оста ясаганнар... «Печән базары» беразтоныграк чыккан сыманрак тоела да, калганнарына буяуны кызганмаганнар, мул салганнар... Бу юкәләр... «Кичү»! «Сара ханым», «Сак-Сок» бәете соң!.. Скульптураларың бик ачык басылган икән, Бакый абый. Мөхсинә апа... Галимҗан абзый...

Аксакал түземсезләнеп:

— Мөхсинә, Мөхсинә! Менә җитәрсең әле син Урманченың шедеврына, шунда ни диярсең икән?..— диде, аны кызулады.

Мирзаның берешәсе килмәде бер дә:

— Монда кергәннәр барысы да шедевр инде, Бакый абый! — дип күңелен үстереп җибәрде.— Халык боларның барысын да шедевр буларак кабул итәчәк! — дип тә өстәде.

Аксакал моңа сүз әйтмәде, фәкать дустанә җупләде генә:

— Иншалла, кабул итә күрсен. Шуны уйлап утырдым әле, Мирзаҗан, син килгәндә: мин әйтәм, инде шул кадәрле һәйбәт эшләнгән альбомым да булды, шуны кулына алып, халкым кабул күрсә, инде үлсәм дә үкенечле түгел.

Шәкерте башын күтәрде, матур итеп елмайды:

— Анысына ашыкма син, Бакый абый. Әле эшлисе эшләрең олы тау чаклы. Болай тырышып эшләгән типография кешеләренә биш-ун акварель җибәрер идем мин, синең урыныңда булсам...— дип акрын гына үзенең киңәшен бирде һәм көтелмәгәндә тупас җавап ишетте:

— Син, әлбәттә, җибәрер идең, шушындый альбомың дөнья күрсә. Мин берни җибәрмим. Алар фәкать үзләренең изге вазифаларын намус белән үтәгәннәр — и вәссәлам... Алданрак, алданрак кирәк иде лә...— Аксакалның йөзенә әрнү-ачыну бәреп чыкты.

Мирза, картны күңелсез уйлардан чыгарырга теләп:

— Таптым, таптым, Бакый абый! Син Сөембикәңне әйтәсең икән. Чыннан да шедевр инде бу, һич сүз әйтерлек түгел! — дип раслады.

Аксакал альбомны аның кулыннан ачык килеш үзенә алды:

— Кая, карыйм әле шуны тагын бер... Менә, дустым Мирзаҗан, карап туймыйм бит, карап кына туя алмыйм!

— Бакый абый, син бит аны альбомга кертмиләр дип бик нык дулаган идең...

— Назимҗан үзе ничектер җайлаган инде. Рәхмәт аңа! Тешләгән җиреннән өзеп алырга ярата торган егет...

Аксакалның үпкә-әрнүләре кайткан иде инде. Мирза аның шунысына сөенде.

— Урманченың Академиясенә юкка гына тарымаганмын икән. Бер көн эчендә генә дә күпме сабак алдым,— дигән булды, елмайган-көлгән булды.

Рәссам каршы килмәде: үзен мактаганны күтәрә иде ул, бер дә авырсынмый иде. Шулай да сүзсез калмады, сабырланып калган тавыш белән:

— Тормыш Академиясе өйрәтә ул зирәклеккә, хәйләкәрлеккә. Урманче картның үзен дә өйрәткәли тора,— дип вәгазенә нокта куйды.

Кичтән ятып йокларга өйрәнгән сәнгатькәр бүген нишләптер тиз генә йоклап китә алмыйча газапланды. Аптырагач-йөдәгәч, бу арада яратып укый торган китабын кулына алды. Риза Фәхретдин, рәхмәт төшкере, Мөхәммәт пәйгамбәрнең фикер-хәдисләрен бергә туплап, 1911 елны Оренбурда аерым китап итеп чыгарган икән. Кыйммәте шунда ки, үзе үк шәрехләп тә бирә. Һәркем дә, синең кебек, гарәпчәне су урынына эчми ләбаса. Шундый чакны ярап куя олуг галимнең шәрехләвеаңлатмасы.

Укый торгач, туктап калды сәнгатькәр, уйланырга мәҗбүр булды. Бу бит миңа, кыек атып, туры тидерә:

«Адәмиләрдә булган яман сыйфат: малы бетүдән куркылган саранлык вә гадәттән тыш куркаклык».

Гарәпчәсен генә укып китмәкче иде, тукта, алай ук түгелдер, бәлкем, дип, шикләнеп, шәрехләвенә күз салды. Каян белгән, диген син аны! Хәер, белмәсә, пәйгамбәр дә булмас иде ул...

Укып бара торгач, сәнгатькәр янә бер, үзенә бигрәк тәңгәл килердәй хәдискә юлыкты:

«Гүзәл холыклы кеше, шул гүзәл холкы сәбәпле, нәфел ураза һәм дә кичләрдә гыйбадәт берлә шөгыльләнүчеләр дәрәҗәсенә күтәрелә алыр».

— Инде дә мәгъкуль хәдис икән! Уразаның без инде аның фарызын тотарга да авырыксынабыз. Шул, такы-токы, вакытлы-вакытсыз ашауэчү белән, ураза шикеллерәк, дип үзебезне тынычландырабыз. Намазына да бушый алмыйбыз. Эш-эш дия-дия, гомеребез үткәнне дә сизми калабыз... Бердәнбер өметебез — әнә шул хезмәтебез белән һәркемгә сөенеч

китерүгә инанудыр, холкыбызның күркәмлеге вә гүзәллеге белән җәннәткә керүдер... Бирсен Ходай!

Тик минә үзенең иҗатын кабул итәме халык, әллә кайбер әсәрен генә мәгъкуль күреп, иҗатын тулаем кабул итмиме — анысы Габделбакый өчен гомер буена сер булып, табышмак булып кала килде. Ярый да бит гомер буе ал-ял белмичә эшләнгән эшләреңне халкың яратса, кабул итсә...

### Иҗат[1]

Ардым тәмам вак-төяк хафадан,
Бер эш өчен тартыш, казгану, җәфадан.
Баш орып сора, ялварып үтен!
Бүген телефон, телефон,
Иртәгә — ишек шаку.
Саклап бусага төбен,
Баскычлардан тибен.
Шулай үтә эшсез сыкранып,
Бит җыртып көнең.
Теләнеп, казганып үткәч,
Дәртең сүнеп, беткәч көчең,
Ясарлык кодрәт калмый.
Әмма эшләр идең армый-талмый,
Иртән кояш белән торып.
Көнозын гайрәт белән ясап, корып
Үткәрсәң көнеңне,
Йоклап батырларча тыныч төнеңне,
Соранып йөрмәсәң,
Теләнмәсәң, келәнмәсәң!

## XII баб

### «Соңгы яфраклар»

*«Фаҗига бит тормышта болай да күп.*
*Сәнгать рухландырырга, дәртләндерергә тиеш... Күзгә мотивлар дип атыйк без бу әсәрләрне — музыкаль бит һәркайсы».*
Бакый Урманче,
1978 ел, 14 октябрь.

*«Ничек алырга... тагы бер гомер?!»*
Бакый Урманче,
*1978 ел, 04 март.*

Чит җирләрдә, үзебезчә итеп әйтсәк, ягада каңгырып йөргән чакларымны сөйләгән идем шикелле. Игътибар иттең микән, дустым, юк микән, «халык дошманы» дигән тамга салынганнан соң без фәкыйрегезгә бит Джугашвили-Сталин вафат булганчыга кадәр, ягъни егерме-утыз ел дәвамында туган илкәенә кайтырга ярамады. Мәркәзне әйткән дә юк инде аны — гүпчем аяк басарга да ярамады. Чит-ят җирләрдә үзбәк яисә казакъ булмаганым өчен генә иҗатыма тиешле бәяне дә бирмәделәр, үземә лаеклы хөрмәтне дә күрсәтмәделәр. Син татар художнигы, дигән ярлык миңа кара сакалдай тагылып йөрде...

---

[1] Б. Урманче шигыре.

Әмма, дустым, әйтсәм, ышанмассың: әлеге дә баягы милли рәнҗетелүнең арада бер зәһәрен, каһкаһәле мәсхәрәне үзем туган-үскән илгә кайткач күтәрергә язган икән... Әйе, каршылыклы булды минем Казанга кабат кайтуларым. Сират күперен кичүгә тиң булды, олуг фаҗига булды утыз ел буена зимагурлыкта, ягада каңгырып йөргәннән соң, дәрвишлеккә инде тәмам ияләшеп-күнегеп беткәннән соң, янә үз илемә кайтуларым...

Егерменче елларда — яшьлегемдә мин бит, дустым, фәкать үз халкыма хезмәт итү дәрте белән яшәдем. Инде минем әзерлегемә килгәндә, бик сирәк кешегә эләгә торган ВХУТЕМАСта берьюлы ике факультетта укып, ныклы белем алып кайткан идем. Мәшрикъ вә Мәгърибләрнең әдәбиятын вә сәнгатен һәйбәтләп өйрәнеп, аларның телләрен үзләштереп, ничәмә-ничә телдә мәгълүмат туплардай, укый алырдай дәрәҗәгә ирешеп кайткан идем.

Татар халкына сынлы сәнгать өлкәсендә хезмәт күрсәтердәй, беренче буразнаны сызып калдырырдай затлар, дөрес, булмаган ук түгел, булган. Димәк, миңа кадәр дә файда китерердәй кешеләребез булган. Әйтик, Санкт-Петербургтагы Штиглицның Сәнгать училищесын Мирзаҗан ага Бакиев белән Касыйм абзый Дәүләткилдиев — икесе дә Октябрь революциясенә чаклы ук тәмамлыйлар. Мирзаҗан ага уем-сынчы оста була, гомерен Ленинградта, ягъни Санкт-Петербургта уздыра; Касыйм абзый исә — нәкышьче, Уфада яшәгән. Ләкин бу осталар, махсус белемле булуга да карамастан, татарның сынлы сәнгате үсешенә әллә ни йогынты ясый алмаганнар шикелле. Ихтимал, икәвенә дә хөрмәт вә игътибар житенкерәмәгәндер, шул сәбәпле бер читтә бөтенләй күренмичә калганнардыр. Ихтимал, иҗатлары әллә ни дәртле булмагандыр. Әмма бер нәрсә бәхәссез — бу икәү татарның сынлы сәнгатен дөрләтеп җибәрә алмаган. Әгәр дә алар зур шәхесләр буларак танылып өлгерсә, беренче буразнаны сызып калдырса, ул чагында, дустым, миңа бераз ансатрак булган булыр иде. Ә бит монда, татарың яшәгән мәркәздә үзебезнең кешеләр укый алмый интегә, читтә калырга мәҗбүр иде. Минем иң нык гайрәтемне чигергән нәрсә әнә шул булды. Шуннан тотындым мин азмы-күпме рәсемгә кулы яткан авыл малайларын сәнгать дөньясына колакларыннан өстерәп китерергә. Мин инде боларга рәсем сәнгатенең бисмилласын өйрәттем, җиренә җиткереп, һич иренмичә өйрәттем, бер дә инде менә вакыт белән исәпләшеп тормадым, аларга чын мәгънәсендә остаз булдым; балчык изү, скульптура-уем эшләрен башлап җибәрдем; үзем исә татар халкының тормышын-көнкүрешен зур-зур киндерләрдә тасвирладым. Мактанып әйтә, дип уйлама, дустым, акны карадан аера алганга гына әйтүем: аларны бит әле бүген дә бөтен дөньяга мәшһүр Н. Фешин, П. Беньковтай классикларның картиналары белән бер дә курыкмыйча янәшә куярлык. Бәс, шулай икән, мин бит шул заманда ук үзебезнең сынлы сәнгатебезне гаять зур баскычка-дәрәҗәгә күтәрдем дигән сүз. Инде үзең уйлап кара, татар халкына хезмәт итмичә, мин соң кемгә хезмәт күрсәттем икән соң? Иҗатым нәкъ менә чәчәк атып, киң колач белән эшләп килгән бер заманда гөрзи белән башыма китереп тондырдылар. Шул ук үзебезнең агай-эне, бер дә читтән килеп миңгерәтмәделәр. Әллә җәмәгать эшләренә катнашып, татар халкын якларга, аның тарихы барын авыз ачып расларга җөрьәт итүем ярамады, әллә бүген үзләрен «двуязычный» итеп күрсәтергә маташучы, әмма ләкин үзебезнең ана телен юньләп белмәүче яшьләребез «табагач» дип хурлаган гарәпчә язуыбызны каллиграф буларак яклавым ошамады, әллә инде мәдәни мирасыбызга игътибарлы булырга чакыруым, халыкның гамәли сәнгате өлгеләрен — эскәтер, сөлгеише нәрсәләрнең чигешләрен — рәсемдә күрсәтергә өндәвем, татар кешесен үзебезнең милли киемдә сурәтләвем берәрсенең күңеленә хуш килмәдеме — тәгаен әйтә алмамдыр, дустым. Гәрчә де-юре нидән гыйбарәт икәнен әйтә алмасам да, шуның де-фактосы һич инкяр итәрлек кенә булмады: утыз ел буена сезнең

барчагыздан, халкымнан аерым, чит җирләрдә яшәүгә дучар ителгән идем...

Көтмәгәндә җөмһүрият бердәнбер сәләт иясе дип үзенә дәшсен, имеш!

Әлбәттә, мин яшәү ритмын үзгәртү ягында түгел идем, шунлыктан уйлап-нитеп тормадым, отказ бирдем. Мәгәр күңелне кимерә башлады бит борчу корты: беткә ачуланып, тунны утка ягу килешерме? Әгәр дә мәгәр кайтсам илгә? Күреп килсәм туган якларны? Эшләп күрсәтсәм үзләренә милли киемнәрне? Борыннарына чиртсәм сәләтсез-дәртсез рәссам кисәкләренең?

Бездә бит, әле анысы — баласы, мичтә аның анасы, дигән шактый гыйбрәтле сүз бар. Нәкъ шулай килеп чыкты да бит: фаҗиганең олысы, күтәрә алмастае — Урманченың картаймышлы көнендә, утыз елдан соң илгә әйләнеп кайткач, ябырылды...

Ул бит моннан качкан иде, иң көчле, иң сәләтле чагында гомерен читтә үткәрде, аның картиналарында казакъ та үзбәк, дип лаф ордылар, үзбәк художнигы син, дип теңкәгә тиделәр, күзне дә ачырмадылар, үзләренең төшләренә дә кермәгән камил әсәрләремне дә күргәзмәгә үткәрмәскә, ничек кенә булса да үземне читләштерергә маташтылар...

Ә бит яраткан эшеңә бер кереп китсәң, бөтен бәла-каза, бөтен хәсрәтсагыш онытыла, дөнья мәшәкатьләреннән тәмам ваз кичәсең. Әйтик менә, сабан туендагы чабыш атына әйләнәсең. Ул да бит шулай, томырылып чабуын гына белә, күзенә һич ак-кара күренми. Син дә бер генә максатка табынасың: ничек тә уңышлы гына очлап чыгасы иде шушы эшне, аннары инде үлсәм дә үкенмәс идем, дисең. Әнә шул рәвешле, дустым, Уралдан алып кайткан мәрмәр ташларда үзем өчен кадерле затларның — Кол Гали, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев, Нәкый Исәнбәт, Муса Җәлил кебек гали затларның — сурәтләрен мәңгеләштердем.

Гомеремдә башкалардан көнләшкәнем булмады. Хатынымны да башкалардан көнләмәдем, сөйгән ярны да... Яшь идем чөнки, дәртле идем, кодрәтле идем. Мәңге бакый шулай көчле булырмындыр сыман тоелды. Юк икән, вакыт дигән нәрсә үзенекен итә икән...

Бу гомердә, дустым, хәтсез күп кеше белән очрашырга туры килде. Мин аларның матурларыннан, нигә мин дә шундый матур булмадым икән, дип көнләшмәдем. Нигә миңа да Ходай шундый акыл бирмәде икән, дип зирәкләрдән көнләшмәдем. Һай, миңа да шундый талант ярап куяр иде, дип, гали затларга кызыгып карамадым, берсенә бер иярмәдем, үз кыйбламнан тайпылмадым. Тик менә хәзер яшьләрнең җитезлегенә сокланып туя алмыймын. Син, ихтимал, көнләшеп карау хикмәте, дип бәяләрсең. Юк шул менә! Һич тә көнләшү була алмый бу халәт. Ни өчен, дисеңме?

Иң әүвәл, шуның өчен: яратам мин яшьләрне, сөенәм мин аларның һәр яңа казанышына. Икенчедән, үземнең гел шулар арасында буласым килә. Өченчедән, сезнең шикелле яшь булсам, трай тибеп уздырмас идем вакытымны, әллә ниләр эшләр идем, тау-таш актарыр идем...

Хәтер начарайды әле... Берни ятлар хәл юк. Ә бит әле күптән түгел генә шигырьне әйбәт ятлый идем... «Хәят»ны, беләсеңме, кайчан өйрәндем? Монда кайткач, 60 ны узгач! Мин аңарга күптән кызыгып йөри идем, теш кайрап... Аны бит аңлавы да кыен җитмәсә: Дәрдмәнднең һәрбер юлы тыгыз, мәгънәле; «Хәят»та аның тормышының бөтен мәгънәсе, фәлсәфәсе... Әйтәм бит, ул тиз генә ятланмады. Чөнки аның һәр юлы шигырь, бик бай колоритлы үзенең сүзләре белән дә. Тормышны үзенчә шигърият белән бирә ул. Бер генә сүзен ялгыш укысаң да, аңлашылмый, буталчык килеп чыга... Аны бит өйрәнергә вакыт кирәк. Буш вакытны мин ылыс ваннасы алганда таптым. Аякны шулай ылыс белән дәваладым. Йөрәккә дә сукты шул минем... Кереп утырам да шигырь укыйм, өйрәнәм. Күңелдән бикләнгәч инде, көн саен шуны

укыйм. Әле җитмәсә Дәрдмәнд белән вакытны билгелим: бар белгәнемне укып чыксам — җитте дигән сүз...

Кичен йокларга яткан чагында нишләптер сөяк-санакларым яман каты сызларга тотына. Әле менә иртән уянып китсәм — мәхшәр: котырыныпдавыллап төньяктан зәмһәрир җилләр исә, урамдагы биек-биек тирәк вә юкәләрнең яфраклары бер төн эчендә алтын төсенә кереп өлгергән, агачлар җилдә чайкалышып, яфракларын коеп утыра; асфальтка мул булып яфрак коелып, күз күреме җирдәге мәйдан ялтыравык алтынга төренгән.

Күпмедер вакыт әлеге сәер күренештән күземне ала алмыйча тордым. Һи-и-и! Бу чаклы да байлык булыр икән булса да!.. Сокланмаслык кына түгел шул, һич тә!

Бүтән вакыт булса, ашыкмыйча гына, җайлап кына, иплəп кенә, сабыр гына нишләргә икәнен уйлаган булыр идем. Ә бу юлы, урамнан күземне алмыйча гына, киштәдән һәйбәт кенә ватман кәгазе тартып чыгардым, акварель буяуларны, нәп-нәзек буягыч кыл-каләмемне хәстәрләдем. Буяуларымны-кәгаземне киң вә иркен тәрәзә төбенә җәеп салдым. Аннары җиңел генә артсыз урындыкны якынрак тартып, шуның бер читенә чөмәштем.

Сары төснең ниндирәк төсмерен алырга икән инде? Бусынмы? Юктыр, алай артык ачык булыр. Әһә, менә куерагы... Тик анысын да үзен генә алу ярамастыр, анысы да килешеп бетмәс, артык куе булыр. Менә болай иттереп кушып карыйк әле...

Зур ватман табагына яфрак икәне дә беленмәслек олы-олы сары таплар ятты, алар бере-беренә кушылып, берсе икенчесенең өстен өлешчә каплап гүя тоташ бер сары масса тәшкил иттеләр. Менә ул сап-сары массаның чит-читләреннән үзәккә табан, челтәр-пәрәвез үтәли күренеркүренмәс кенә булып көмешсу-яшел җепләр әлеге сары көлтәне — шушы алтын байлыгын күтәреп торган ботакларга әйләнде. Ул ботаклар һәммәсе бер җепкә тезелгәндәй, тирәкнең кәүсәсе пәйда булды; түбәнгә төшә-төшә ул тәгаен ачыкланды, юанайды, мәһәбәт кенә тирәккә әверелде. Хәер, тирәк ялгызы гына да түгел икән әле, әнә икенчесе, тагын да арырак өченчесе... бишенчесе...

Табигать шулай кыш җитәсен, кар төшәсен хәбәр итә иде. Әле моңарчы суыкның булганы юк, шулай да көн күрексез, җилле-давыллы, әнә яфраклар коела. Озакламый суытып җибәрер, яфрак коелу шуны искәртәдер кебек...

Инде менә табигатьтәге искиткеч бер күренешне, кабатланмас гүзәл мизгелне кәгазьгә төшерәм, дип өметләнеп, иртә таңнан иҗади рух белән урынымнан торсам... имәнеп китә яздым бит, дустым. Кичәге күренештән, алтын байлыктан берни калмаган, яфраклары коелып беткән шыр ялангач ботаклар як-якка тырпаешып торалар. Әйе, гүзәл мизгел табигатьтә дә, кеше гомерендә дә кабатланмый шул. Дөньяда, гомумән, берни кабатланмый...

Берән-сәрән генә җилдә җилфердәп, яшәү хокукларын исбатларга маташкан алтын яфракларга озаклап карап торулары күңелдә әйтеп бетергесез моңсулык уятты. Чынлап торып уйласаң, без фәкыйрегез дә яфракларын коеп бетергән тирәк хәлендә калды лабаса...

Урманче, гомумән, яз рәссамы була алмады инде, дустым. Гомере буена күзге көнне дөресрәк төсмерли, аңарга мәдхия җырлый, картиналар яза. Табигатьнең җәй буе җыйган байлыгын тасвирлау аның үзенә әйтеп бетергесез ләззәт бирә, яңадан-яңа иҗади казанышлар вәгъдә итәюнәлдерә. Көзге пейзажны Урманченың начар ясаганы юк һәм булмас та, шуны шәйләгәнсеңдер инде?

Һәй, эшләп тә күрсәтер идем үзләренә, яшьрәк булсам! Җитмештә генә дә түгел шул инде менә... Гомеремнең көзе җитте, көмешле-алтынлы көзе... Ихтимал, көзге пейзажларны оста ясавым да шуннан килеп чыга торгандыр... Остаруым да олыгая-олыгая килгәндер.

Һи, дустым! Яхшы картина бит күңелдәге моң ул. Синең күңелең урам шикелле буш булмаса, анда нидер булса, ягъни халкыңның язмышын-көнкүрешен, үткәнен-бүгенгесен маңгай күзе белән генә түгел бәлки әле күңел күзе белән күрә белергә, шуның өчен йөрәгеңнән кан саварга, күңел түрләреңдә моң туарга сәләтле икәнсең, өстәвенә син әдип йә сәнгатькәр икәнсең, менә шул чагында туа юньле әсәр — китап, җыр, картина. Шунда гына син халык күңеленә үтеп керә аласың.

Мәхшәр диген дә вәссәлам — Урманче төшендә генә актив яшәүгә күчеп, өнендә исә актив яшәүдән гүя бөтенләй мәхрүм ителдемени? Төшемдә улниләр генә күрмим, диген син! Береннән-бере мавыктыргыч, сюжетлы булу өстенә, әлбәттә, һәммәсе дә төсле бит әле җитмәсә! Һәркайсында, әлбәттә инде, яшьрәк буламын!

Бүген күргән төшем сөю-сөешүдән гыйбарәт, озынга сузылган татлы бер төш иде...

Гәрчә төшем сөенечле булып, анда бар әгъзаларым тойган рәхәттән-ләззәттән тиз генә арына алмыйча ятсам да, сөенмәдем, дустым. Юк, сөенмәдем! Нәрсә, шулай ук картаюым җитеп, ир-ат җенесеннән икәнлегем фәкать төштә генә үзен сиздерер микәнни? Сөешүнең татлы мизгелләрен төшемдә генә күрү-кичерүгә дучар ителдем микәнни? Шулай ук өнемдә сөю-сөелүләр, назлау-иркәләүләр, иҗатка рухландыручы дәртле сөешүләрдән мәхрүм ителдем микәнни?

Юк, болай батмый. Гүзәл затны йоклаганда назлау, имештер назлау белән канәгатьләнеп, кул кушырып утыруга чик кую зарурдыр. Бүгеннән үк дәртенә керешергә кирәк булыр. Югыйсә... Югыйсә үзеңә дә, бөтен кодрәтеңә-иҗатыңа да хурлыклы дәрмансызлык үтеп керәчәк. Фәкать хисләнеп-дәртләнеп яшәгән тәкъдирдә генә, чын-чынлап ир-ат булып калган очракта гына, синең иҗатыңда алга китеш ихтимал. Чылтыратам Сарага. Инде дә! Бүген үк чылтыратам!..

Кич җиткәнне, егет чагымдагыча, сабырсызланып көтеп алдым. Телефоннан иң әүвәл әйткән сүзем сөенечле хәбәр булды. Үземә калса инде, сөенечле, дигәнем. Хатынымны сөендерә алу-алмавым — анысы икенче мәсьәлә.

— Сара! Мин бит сиңа монда бер дигән пианино сатып алдым. Андагы төп йорттан рояльне кузгатмабыз да алайса, шунда торыр. Кайткан арада үзең дә уйнарсың, оныкларыбыз да өйрәнер. Ә инде минем янга килгәндә — синең өчен Германия-Алманиядә эшләнгән менә дигән, өр-яңа инструмент. Килгән җиреңә көйләтеп тә куярмын әле...

Ялгызлыкны бит аны үзе татымаган, үзе кичермәгән кеше генә белми. Ә инде әйләнә-тирәңдә сүз кушардай җан иясе булмаса, көннең-көн буена беркем яныңа килеп сүз әйтмәсә, иңбашыңа кулын салмаса, ай-һай, вәсвәсә кереп утырмас микән күңелкәеңә, ә?..

Андый чакны юк авыруларың табыла, моңарчы посып кына яткан чирләрең әкрен-әкрен баш калкыта. Шунда инде, бетәм икән, беркемгә кирәгем калмаган икән, дигән фикергә киләсең.

Шуннан йөрәк авыруына сабышасың. Рухи авыру, әрнү, тоташ сулкылдау матдигә күчә — йөрәгең сафтан чыга, бернигә ярамый башлыйсың.

Әнә вазадагы чәчәкләр дә, үзем шикелле үк, картайды, сулды, бөрешеп катты, элекке гүзәллеген җуйды... Тәмам чәчәк диярлеге, өстенә карарлыгы калмады...

Берни эшлисе килми, гомумән, эшкә кул бармый. Нәрсәгә генә тотынсаң да, берни чыкмый. Андый чакны, иҗат итәм, дигән булып үз-үзеңне алдау олы кешегә һич килешми. Кулыңа кыл-каләм алып та, «и» хәрефен чыгара алмагач, иҗат дип адарыну фәкать үзеңне алдау, чынбарлыкка, бүгенге халәтеңә күз йому булыр иде.

Соңгы күрешүебездә, гәрчә Сара миңа, бармыйм мин синең ул ач Казаныңа, дип тартынмый-нитми әйтсә дә, аерылышкан чагында икәүдән-икәү генә табын янында нәкъ электәгечә гәпләшеп-чүкердәшеп утыргannan соң, күңелемә бераз җылы кереп, өмет чаткысы кабынып калган

иде. Әмма бүген чылтыраткач, имәнеп китә яздым. Телефон чыбыгының аргы ягында гүя бергә-бергә гомер кичергән, күпме кыенлыкларны җиңеп чыккан, бер күз салу белән хәлемне аңлый торган асыл карчыгым түгел, ниндидер бөтенләй икенче кеше, гаҗәеп кырыс холыклы, каты бәгырьле зат сөйләшә иде:

— Синең җаеңны кайгыртып кына, синең көеңне көйләп кенә яши алмыйм бит инде! — диде ул. — Мин бит балалар анасы, аларның көйләрен, оныкларның көйләрен көйли алсам да, таман булыр иде әле,— диде. Аннары уфтанып куйды да иң яманын ярып салырга тәвәккәлләде, ахры: — Бакы-ы-ый дим, картайды инде Сараң, бар булган дәрманы-дәрте сүрелде, янып бетте. Минем гәүдәмә көле генә өелеп калды. Сиңа әйтергә генә базмый килдем. Элегрәк мин дә, синең шикелле үк, кеше идем. Сине сагына идем. Юксына идем. Бу арада әллә нишләдем дә куйдым. Хатыннар, гомумән, иртәрәк олыгая-картая икән. Мин моңа ышанмый килгән идем, икебез дә бергә олыгаербыз, дигән идем. Инде ахыры-соңы шул булырга охшый. Тәмам инандым бугай инде...

Беравык сүзсез торганнан соң янә тирән итеп көрсенде дә:

— Алла язганын күрербез. Монда каламын, Мәскәүдә, оланнарым янында...— дип өстәде.— Син олпатлы ир-ат әле, дәртең дә бар, дәрманың да. Аллаһы тәгалә саулык-сәламәтлек бирсен үзеңә...

Ялгызлыктан арыну өмете белән янә дә — ничәнче мәртәбә инде — Сарамны озаклап үгетләп азапланам. Аның аянычлы тавышы калтыраганны абайлыйм:

— Ба-а-акы-ы-ый! Син һәмишә аңларга теләмисең. Мин бит инде картайдым, элеккеге Сараң түгел инде мин, өлгерлегем дә бетте, хәлсез-дәртсез бер карчык мин. Сине элгәречә тәрбия кылып, синең кубызыңа биеп, синең көеңне көйләп торырлык чамам калмады. Оныкларымнан да аерыласым килми, — ди дә шундук төзәтә: — Просто алардан аерыла алмыймын... Бабагыз янына Казанга китәмен, дигән идем — елашып, чабуыма килеп ябыштылар.

Шуннан соң тирән итеп көрсенә дә гомерлек ярына әйтергә һич күңеле тартмаган, әмма намусы хәзер үк әйтүне-ачыклауны даулаган сүзләрне әллә кайлардан, бәгыренең яшерен-серле бер почмагыннан дерелдәвек-хәлсез тавыш белән тартып чыгара:

— Мин инде элеккеге Сара түгел, укаларым тәмам коелды...

Сарам, Сарам! Юкка уфтанасың. Мин дә сине куып җиттем бугай инде. Мин дә нык картайдым, Сарам. Икебез бер тиң.

Шулай да, Сарам, авыруларга бирешеп, картайдым инде, дип, түшәктә ятасы килми. Чак кына хәлем булса да остаханәгә төшү ягын карыймын. Үз мохитым, үз дөньям шунда минем. Үзем язган картиналарым шунда эленеп тора. Музейга сатылмаганнары, диюем. Хәзер инде берсен дә сатмыймын, беркемгә дә бүләк итмимен. Хөкүмәт үземә атап музей булдыру ягын кайгырта. Илле-алтмыш ел буена, гомер буена иҗат иткән әсәрләремне һәммәсен дә әнә шул музеема куярга хыялланамын. Уем әйберләрем дә, ягъни скульптураларым да, нәкышем дә, ягъни майлы буяу белән язган киндерләрем дә, сокландгыч акварельләрем дә, хәтта әле тушь, сангина, карандаш, күмер белән язган портретлар галереясы да — барчасы шунда тупланачак.

Остаханәмә төшәмен дә диварга эленгән киндерләремә сокланып карап торамын. Неужели мин яздым икән шулчаклы да камил, шундый да гүзәл әсәрләрне? Кайсына гына карасам да, шундук күз алдымда аны язган заманнар, шундагы хәлләр тулаем гәүдәләнә. Бергә булган чакларыбыз, Сарам. Бүгенге, менә хәзерге шикелле. Вагына-төягенә хәтле. Андый чакта онытылмый хәлең юк. Һич юк! Мин дә кеше ләбаса!

Хөкүмәткә гариза белән мөрәҗәгать иткән идем мин. Милли сәнгатьнең аксакалы буларак Роден шикелле. Барлык әсәрләремне бергә туплап күрсәтү мөмкинлеген, урнаштыру җаен тапсагыз, барчасын да халкыма, җөмһүриятемә бүләк итәм, дип. Гәрчә әле ул елларда ук атлыгып

тормасалар да, музей булдыру мәсьәләсе әнә шуннан соң калкып чыкты бугай. Тик менә күпме генә сөйләнмәсеннәр, тегесен эшлибез дә монысын эшлибез, димәсеннәр, тегеләй итәбез дә болай итәбез, дип вәгъдәләр бирмәсеннәр, әнә шул вәгъдәдән һич кенә дә уза алганнары юк әле. Һич тә! Күргәзмәләремә киләләр үзләре, шедеврлар икәнне күрәләр, юбилеемда мактау сүзләрен кызганмыйлар, тик менә әлеге музей мәсьәләсен хәл итә алмыйлар. Мәдәниятнең хәлләре хөрти шул, бер дә сер түгел инде. Югыйсә җөмһүриятебез Әдрән дингезгә хәтле кара алтын куа, заводларында барча җиһанны дер селкетердәй иң яңа төр самолетлар чыгара, космик ракеталарга детальләр житештерә — һәммәсенә таба малын. Ә менә мәдәният дигәндә, музей дигәндә, бер генә дә юк алга китеш бездә. Һич тә!

Сара!

Мин дә өшәндем инде, мин дә бик нык картайдым. Тик менә олыгаюыбыз-картаюыбыз бергә булмады. Шунысы аяныч. Тыныч кына, имин генә, бергә-бергә картаербыз, диеп өметләнгән идем — насыйп булмады. Мәзәк хәлгә дучар ителдем бит әле мин, Сарам. Кордашлар гына түгел, бездән шактый калыш агай-эне склероз белән интегә, хәтерләре бетә, зарланудан башлары чыкмый бичараларның. Ә минем аяк сынатты, колакта бар ул картаю, ә менә күзем әйбәт күрә, әлхәмделилла, башым эшли, хәтер дигәнем...

Үткәннең бер генә бизәге дә төссезләнмәде бит, Сара. Һәммә көрешүсөешүләребез исемдә. Төсләре-бизәкләре белән исемдә. Һәр елмаюың, һәр әйткән назлы сүзең исемдә. Һичберсен истән чыгарганым юк, онытканым юк. Беренче күрешүебездән үк һәммәкиен хәтерлим. Бер мәҗлестә очраштык без синең белән. Тиз арада кавыштык. Мин инде, мәңгелек ярга юлыктым, дип хыял дингезендә йөзгәндә, бәләкәчебезне үчтеки иттергәндә — зур сынау уздык, гүя сират күперен бергәләшеп үттек үзең белән. Син мине сайладың. Хәтерлисең микән, Сарам, шуның тәэсирендә мин синең алда Коръән тотып ант иттем: гомергә аерылышмаска, бергәбергә тату гына, матур итеп яшәргә ант иттем.

Их, шуның белән генә дөньябыз түгәрәкләнгән булсачы! Кызгылт рояльдә синең Моцартны, Шопенны, Сен-Сансны, Гайднны искиткеч бер камиллек белән уйнавыңа армый-талмый сокланып, ара-тирә синең илаһи сурәтеңне киндергә язып, Ходайның һәр бирмеш көнендә синең белән чүкердәшепсерләшеп, көннең бизәкләре-төсләре уңганнан соң инде, кичләрсен тәнеңнең гүзәллегенә мөкиббән китеп, күңелләрең булганчы үзеңне сөеп тә назлап кына узсачы гомеркәйләрем, дип ялварган идем, югыйсә, Аллаһы Тәгаләгә.

Кабул кылмады ул гөнаһлы бәндәсенең ихластан кылган догасын. Бер-бер артлы җибәрә торды безнең өскә дәһшәтен вә сынавын. Күпме кичтек без синең белән, Сарам, аянычлы хәлләрне, михнәт вә хәсрәтләрне, сират күперләрен!.. Фаҗига арты фаҗига... Кая гына барсам да, эземә төште Джугашвили-Сталинның әрсез әнчекләре. Безнең бәхетебезне күпсенде бугай ул миһербансыз бәндәләр. Фаҗига, фаҗига...

Миңа шул иҗатыма баш-аягым белән чумудан гайре берни калмады. Шулай гына мөмкин иде онытылырга, юлдан язмыйча калырга, кыйблама тугрылыгым сакларга. Әмма аерылган идем мин туган мохитымнан. Зимагур булып гомер кичердем лә-ә-ә!..

Кая гына барып, андагыларга сыңлы сәнгатьнең мөмкинлек вә могҗизаларын ничек кенә оста күрсәтсәм дә, казакълар әйтте: «Син татар, гуй!» — диде; үзбәкләр әйтте: «Син татарсың!» — диде; инде килеп үз милләттәшләрем: «Син казакъ! Син үзбәк! Син әллә кем, фәкать син татар гына түгел!» — диде. Фаҗигамы бу — фаҗига. Инде дә! Иҗатыңа адым саен балта чапсыннар әле, җыен булдыксыз-талантсыз-сәләтсез бәндәләр үзеңнән ихахайлап көлсеннәр әле, сине мәсхәрәләсеннәр әле!..

Әмма ләкин соңгы сүзне һәрчак халык әйтә. Синең ал-ял белмичә эшләгән эшләреңне аңлыймы халык? Син тасвирлаган теге яки бу мизгелгә-күренешкә ышанамы халык? Синең бөтен иҗатыңны тулаем кабул кыламы халык? Әнә шул мөнәсәбәт хәл итә һәммә нәрсәне.

Хәер, синең әсәрләрең күргәзмәгә эләкмәсә, картиналарың куелмаса, халык сине үзенеке дип кабул итә алмый да алмый инде. Һич юк! Чөнки ул синең үзеңне дә, картиналарыңны да белми — шуның белән вәссәлам! Әле ярый, мәшһүр сәнгать әһелләренең сурәтләрен һәйбәтләп, тәмам җиренә җиткереп куярга башым җитте. Мөгаен, минем ни дәрәҗәдә сәләтле икәнемне халкым иң әүвәл әнә шул өлкәдә күреп инангандыр. Әдипләр дә бит мине сынчы-уемчы буларак күтәреп чыктылар һәм Тукай исемен йөрткән олуг бүләкне-шөһрәтне алып бирделәр. Шул уңай белән халык та күрде-таныды. Икенче уңышым юбилей күргәзмәләренә чабатаны алдан ук киенеп куюым нәтиҗәсендә булды бугай. Халык агылды гына әсәрләремне күрергә. Өченчесе, әлбәттә, альбом. Шундый да нәзакәтле альбом инде җиңүгә китерде, урыс әйтмешли, полная победа, латинча ук әйтсәк — триумф! Шуннан соң инде, һәйбәт кәгазьдә, төсләрне тәгаен саклаган хәлдә, альбомда күргәннән соң инде, Урманче художникмы-түгелме, дигән мәсьәлә-проблема, гомумән, көн тәртибеннән төште.

Әлбәттә, һәркем сөенмәгәндер әлеге альбомга. Һич тә! Мине «рисовальщик түгел» дигән бәндәләр сөенергә тиеш түгелләр. Әмма инде минем шедеврлар әнә шул рәвешле халыкка барып иреште. Инде хыялым тормышка ашты. Инде халкым үзенең улы дип таныды, үземә искиткеч хур хөрмәт күрсәтте, олылады. Татар халкына мин рәхмәтлемен, халкым миңа бик күп изгелек эшләде. Инде минем үкенечем калмады бу фани дөньяда — хәлемнән килгәнне эшләдем шикелле. Инде үлсәм дә, шәт, үкенмәмдер... Фәкать эшләнәсе эшләр кала, эскизлар кала... Сарам...

Килер заман, бер-беренә үлеп гашыйк бу изге җаннар, олыгаеп, аккошлардай, берсе арты берсе дөнья куяр (Сара ханым Урманче — 1989 елны, Габделбакый Урманче — 1990 елны вафат). Аларның фани дөньяда күргән-кичергән хәсрәт-михнәтләре генә шунда очланыр, Сак белән Сок шикелле берсен-берсе сагынып та зарыгып яшәүгә дучар ителгән гаилә кыйссасы шунда тәмамланыр, гомерләре буена сузылган фаҗигаләренә шунда чик куелыр...

Әмма искитәрлек дәрәҗәдә гүзәл нәкышь әсәрләре, шулай ук бинигаһая камил уем-сыннар, әле тагын кояшлы акварельләр иҗат иткән сәнгатькәрнең шөһрәте-даны артканнан арта барыр, аның исемен татар халкы үзенең сөекле уллары **Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшев** исемнәре белән янәшә куяр — **Бакый Урманче...**

Янә килеп «Сара ханым улы Илдар белән» дигән картинада тасвирланган, үзенең йөрәк парәсен җир тетрәтерлек афәттән дә җаны-тәне белән араларга-сакларга әзер торган изге Ана образы, аның яшьлеге вә әйтеп бетергесез чибәрлеге мәңге бакый торып калыр җир йөзендә... Мәңге Б-А-К-Ы-Й...

Күңелемдә нинди ямансу!
Көннән-көн,
Минут саен якыная барам
Караңгы гүргә.
Куркыныч түгел үлем:
Тынгылык бирер тәнемә гүрем.
Ләкин нинди матур
Табигать вә дөнья кала!
Никадәр тәмле теләкләр,
Ясамаган эшләр кала...[1]

*1991—1996 еллар.*

---

[1] Б. Урманче шигыре.

# ШИГЪРИЯТ



## Илдус Гыйләҗев

### ТУГАН ИЛ ХИСЕ

* * *

Әсәрләнеп беткән күңелләрдә
Каршылыклы уйлар кузгатып,
Ике атна буе Канадада
Тәрҗемәче йөрде озатып.
Безнең илдә үскән, күчеп киткән,
Инглизчә әйбәт «җилгәрә».
Онытылып китеп, бик еш кына,
«Безнең монда»,— диеп җибәрә.
Нәрсәседер ләкин бездә калган,
Газапланып яши, күрәсең.
...Без киткәндә сөртеп алган яше
Сөйләде дә бирде кирәсен...

### Канадада

Боларга — гел сугыш кирәк түгел,
Тук тормышка нигез салынган.
Ризыкларның төре ким җыелмас —
Без ясаган танк санынннан...

* * *

Уолл-Стритка карап сокланганда
Йөз дә унынчы каттан,
Үзәкләрне өзгеч сыкрау белән
Сине уйладым, Татарстан.
Мондый могҗизалар корыр өчен,

Ирекле булу кирәк.
...Синең хәл бит — кеше арбасында
Йөргән ялчы кебегрәк...

## Бөтен шартың булса да...

Милләте юк, дәүләте бар:
Америка, Канада...

...Сине уйлап, туган халкым,
Бәгырьләрем канады:
Милләтең бар, дәүләтең юк...

Нигә?
Уйлап карале!..

* * *

Син тырышма, түрә абзыкаем,
Аңлап житәлмассың барыбер:
— Шагыйрьләрдә намус төшенчәсе
Кеше гомеренә бәрабәр...

* * *

Үлем тырнагыннан рус патшасын
Алып калды татар баласы.
Сырхау илен генә терелтерлек
Оста табиб кайдан табасы?..

## Әгәр...

Урыс булсам, мин дә шулай
Кәттә йөрер идемме?
Бүтән барлык милләтләрне
Түбән күрер идемме?
Халкын кырып, илен талап
Яши алыр идемме?
«Дөньяда мин — иң бөек,—» дип
Күкрәк кагар идемме?
Кабер ташы җыеп, өеп,
Чиркәү салыр идемме?

...Әгәр мин дә...
Аллам сакласын!..

## Матәм көне

Бездә бүген тагын матәм көне,
Ил башлыгы биргән боерык.
Җырламаска кирәк һәм көлмәскә,
Йөрү тиеш бары боегып.
Чыгып кына тора сәбәбе дә:
Әфганстан, Кавказ яклары...
Гаҗәп мени горур халыкларның
Корал тотып илен яклавы?!
Басып кергәч, әйе, үтерәләр.
Сугыш — явыз, усал холыклы.
Бөтен кеше дә бит татар түгел...
Тыныч кабул итми коллыкны.
Аңа китсә, безнең һәр көнебез
Матәм көне була алырлык.
Онытырлык мени ул ирләрне?
Һәрберсенә һәйкәл салырлык!
Татарда да булган асыл затлар,
Күмелгәннәр тарих көленә.
Күпсенмәгез, шулар хөрмәтенә
Ел да барам Хәтер көненә...

## Булмый кичереп

Ояты гел бетеп житмәгәндер,
Сөйләгәндә бераз кызарды:
— Не хочу я, мама, быть татаркой,—
Дип елый, ди, кече кызлары.
Тишеп үтте шулай йөрәгемне
Катнаш никахның бер хәнҗәре.
Барып чыккан икән, болай булгач,
Татар атлы милләт хәлләре.
Татар кызы булып җирдә яшәү,
Аңлыйм ансын, җиңел түгелдер.
Дистә еллар барган сәясәтнең
Нәтиҗәсе бүген күренде.
Милләт эчтән чери башлый икән,
Кызларында бетсә горурлык.
Сабый инде бездән ераклашкан...
Бәхәсләшеп торыр урын юк.
Мәхәббәтне битлек итеп алып,
Урыс каны йөри көченеп.
...Чит милләткә хезмәт итүчене
Аңлап була, булмый кичереп...

## Кайда да шул балык башы

«Рәсәйдән булгач, син дә барыбер
Урыс»,— диләр, исне китәреп.
Мин бит татар!

...Алар гөнаһысын
Чит илдә дә йөрдем күтәреп...

* * *

Син миңа әйт кенә:
— Сагындым, солтаным.
...Сулуым кабынса,
Яшьлеккә сылтармын.
Син миңа хәбәр бир:
— Юксынам, бөркетем.
...Ашкынып килерлек
Сәбәбем — бер көтү.
Син миңа хат җибәр:
— Җитмисең янымда.
...Хыялым аркылы
Җыр туа җанымда...

## Икебездән калсын истәлек

Безнең сөю күчәр йолдызларга,
Олы хисне бер көч тыялмас.
Без табынган сафлык, самимилек
Бу гөнаһлы җиргә сыялмас.
Каралтырлар аны, имгәтерләр,
Гайбәтчеләр телдән төшермәс.
Яме китәр аның, тәме бетәр —
Ирек куйсак, Ходай кичермәс...
Без сыналган инде, бирешмәбез!
Яшьләр үсә, алар адашыр.
...Чын сөюгә сусап йөргәннәре
Йолдызларга карап аңлашыр...

## Сүрелерме сагынулар?

Язмышыңнан узып булмаган кук,
Төп нигездән читкә качып,
Кайтмый йөреп кенә туган җиргә,
Сагынуны булмый басып.
Гел иелер кебек түгел иде
Махы бирмәс горур башым:
...Билем бөгә-бөгә Ыкка кайтып
Җыеп килдем мунча ташы...

* * *

Каным кайнады, акылым качты
Хыянәтеңне төшемдә күреп.
Сикереп тордым, Дездемонасын
Буып үтергән Отелло кебек.

Дөрес түгелен беләм, югыйсә...
Җаным кыбырсый, күңел шат түгел.
...Төштә булса да көнләшә белгәч,
Димәк, әлегә картың — карт түгел...

## Барсы да синең белән

Син авылга кайтып киттең,
Үгетләүдән нигә туктадым?
Яктыргандыр анда урамнар,
Шатлангандыр йөргән сукмагың...
Син авылга кайтып киттең...
Юксынудан бәгырь көйрәде.
Бар дөньяма төште караңгы,
Сукмагымны тапмый йөдәдем.
Син авылдан кире кайтсаң,
Күк йөземне каплар ак болыт.
Синең белән минем шатлыгым,—
Синнән калмый йөри яктылык...

## Афәрин!

Бөек акыл белән тоташтырган
Манарасы кисеп алынгач,
Башсыз калган гәүдә сыман булган
Дистә еллар безнең авыллар.
Башсыз гәүдә — уйсыз түшкә генә,
Татар илен баскан бозыклык.
Аракысы белән, урысның бит,
Марҗасына хәтле кызыктык.
Күреп калу, шөкер, насыйп булган:
Иман кайта! Димәк, өмет бар.
...Таң кояшы сыман, якты бөркеп,
Авылларда калка мәчетләр...

## Сине көткәндә

Каян шулай туры килә диген:
Өзгәләнеп сине көткәндә,
Юатырга мине теләгәндәй,
Ябалак кар яуды күкләрдән.
Тынычланып калган кебек булдым,
Карасана, нинди уртаклык:
Озак вакыт яумый торган булса,
Кар күрү дә олы бер шатлык...

## Курку

Мавыгу да түгел, саташу да,
Мин яраттым сине чын-чынлап.

Дога ятлап барган дәрвиш сыман,
Исемеңне йөрим пышылдап.
Яшерепләр калып булыр микән?
Инде чынлап шүрли башладым.
...Кеше барда ялгыш, онытылып,
Кемлегеңне әйтеп ташлармын...

* * *

Әйттем ич мин: — Бу җәйләрнең
Истәлеге мәңге яшәр!
Инде беттем дигәндә дә,
Искә төшеп, сиңа дәшәр.
Хәлем китеп, уйлап ятам:
Кышкы мунча... кәеф — төксе.
...Мәтрүшкәле себеркедә
Каен белән чәчең исе...

## Сөю хакына

Чатыртауга меник, дидем —
Бармадың.
Үзем генә китәм, дидем —
Калмадың.
Җитәкләшеп йөрик, дидем,
Күнмәдең.
Әйдә, өйгә керик, дидем,
Кермәдең.
Үз итмәгәч, бар кит, дидем,
Китмәдең.
Алайса, йә, бер үп, дидем,
Үпмәдең.
Инде тагын нәрсә кала?
Түзмәдем —
Оныттым да кемлегемне —
Тезләндем...

## Зөлфәт Хәким

# ГӨНАҺ

РОМАН

### 17

— Нәркизә! Кулымны суздым мин. Тик менә... никтер... ныграк сузмадым. Югыйсә, тырышкан булсам, кулым житәр дә иде шикелле.

— Үзең дә төшеп батырмын дип курыккансыңдыр.

Фәиз шатланып куйды, чөнки кемнеңдер аз гына булса да аклавы, бу вакыйгада аны акларлык кечкенә генә бер ишарәнең булуы бик кирәк иде. Ул инде ничәмә еллар дәвамында акланырга тырышып карый, ләкин һичничек үзен гафу итә алмый. Нәркизә аны аңларга тырышса да, ул үзен аклый алмастыр, чөнки бу турыда күп уйланды инде. Шуңа да карамастан, кемнеңдер акларга омтылуы барыбер кирәк иде аңа.

— Әйе, әйе, әйе,— дип кабатлады ул, сабыйларча шатланып.— Мин үзем дә батачак идем.— Тик кинәт шундук аның йөзе караңгыланды, чөнки күп еллар буена калыплашкан гаеп аның шатлыгын бер мәлдә юк итте.— Ә бәлки батмаган булыр идем. Кулымны сузып маташканнан соң мин йөгердем. Берәр таяк, күсәк табылмасмы дип. Әллә соң болай гына, куркып кына йөгердемме икән?

Ул хатынына карап катты, гүя, бу сорауга җавапны Нәркизә бирергә тиеш иде. Нәркизәдә исә бары тик бер фикер иде:

— Хәзер башыңны катырып утырма инде! Коткарырлык булса — коткарыр идең бит!

— Их, Нәркизә, алай гына түгел шул. Күңелем шунда ук ничектер сизде. Кулны сузганда әллә нинди көч тыйган шикелле булды мине. Коткарып була иде аны. Ярдәм итәргә мөмкин иде. Менә ничә ел узды инде, шуны һич аңламыйм, төшенә алмыйм — ник коткармадым мин аны???

— Үз-үзеңне шуңа «ашыйсың» мыни соң син?

— Әйе.

— Зәбирне кызганганга күрә генә үзеңне гаепле саныйсыңдыр.

— Юк, юк, алай түгел! Белмим, аңламыйм...— Ул тагын чыраен сытып хатирәләрендә казынды.— Алтынны үземә генә алу теләге дә юк иде ләбаса. Хәзинә үземә генә калсын дигән уй ялгышып кына да башыма килгәне булмады. Ник сузмадым кулымны? Нинди көч туктатты?..

— Сузгансың бит кулыңны. Коткарырга маташкансың бит инде!

---

Дәвамы. Башы 3 санда.

— Суздым. Ләкин кулны ныграк сузган булсам, ярдәм итә ала идем,— диде Фәиз ниндидер ялварулы тавыш белән. Ул тырышып-тырышып үзенең гаеплелеген исбатларга омтылды. Исбатлый алмавын бик авыр кичерде, шуңа күрә хатынына кат-кат аңлатырга тырышты. Ул үзенең гаебен исбатлауга һәм шул ук вакытта кемнеңдер, аның исбатлавына каршы торып, акларга тырышуына мохтаҗ иде.

Нәркизә бер чарасыз аптырап карап торды.

— Җәфаланма! — диде ул аптырагач.— Ник үзеңне-үзең бетерәсең?

— Аның белән бергә батып үлсәм, яхшырак булыр иде лә.

— Җүләр! — дигән булды Нәркизә. Ә үзе эчтән генә уйлап куйды: әлбәттә, шул вакытта батып үлсә, яхшырак булыр иде. Чөнки болай интегеп яшәүдән ни рәхәт! Һәм шундук бу дорфа, ямьсез уйдан башын арындырды.— Синең бернинди гаебең дә юк.

— Аңламыйсың син...

Ул сулкылдый башлады. Тагын өянәге купты. Нәркизә нишләргә белмәде, утырган урыныннан торып басты да шулай бер хәрәкәтсез аңа текәлеп карап торды. Фәизнең гадәттәгечә курку өянәге бу, мондый вакытта аңа ярдәм итеп булмый, ул үзенең даруын каба да, әкренләп тынычлана. Фәиз, гадәттәгечә, ары-бире йөренде, кыяфәтеннән төсе качты, салкын тир бәреп чыкты. Аның тынычландыра торган дарулары күп, ләкин аракы эчкәч дару кабарга ярамаганга, Нәркизә, кырт кисеп, каршы төште.

Нәркизә җан сыкравы белән иренең шашынып бүлмә буйлап йөренүен күзәтеп торды. Шулай да тора-бара Фәиз тынычланды. Күрәсең, куркыныч хикәяне тәмамлау, күп еллар күңелендә бикләп йөргән кайгыны башка берәү белән уртаклашу өянәкне зурдан куптармады — аның җанына әкренләп тынычлык керде.

Ул, тышка чыгып, ишегалдында саф һава сулап йөрде. Никтер бу юлы тәмәке тартасы да килмәде, тәмәке тартмау уңай тәэсир итте, ахрысы, чөнки тарткан саен күңелләр болганып, кан тамырларында спазмалар башлана да хәле авыраеп китә иде. Яңгырдан соңгы һаваның шифасы тидеме — өянәк тәмам ерагайды.

Сөйләдем... Нәркизәгә хәзер мәгълүм. Ул мине гаепләми. Миннән курыкмый. Киресенчә, аклый мине. Нигә сөенәм соң әле мин! Нәркизәнең гаепләмәве мин гаепсез дигән сүз түгел бит. Нәркизә берни аңламый! Мин бит үз-үземне аңламый иза чигәм!!! Шулай булгач, кайлардан килеп шул мескен хатын мине аңласын! Алайса, нишләп соң мин аның сүзләренә колак салып утырам! Әгәр ул мине гаепсез ди икән, моңа ышанудан миңа ни файда?! Иң мөһиме — мин бит үземә үзем ышанмыйм. Нәркизәнең фикере пүчтәк булгач, нигә мин аңа сөйләдем, нигә сөйлим?! Хәер, кемгәдер сөйләргә кирәк бит. Алайса, Нәркизә үз фикерен әйтергә хаклы. Әгәр ул мине гаепләсә, күңеллерәк булыр идемени?! Фәизнең башы тагын болгана башлады. Туктале, нишлим мин! Зур эш эшләдем бит. Ничек бар, шулай сөйләдем. Хатыным мине аклый. Тагын нәрсә кирәк? Ләкин эчтә кемдер, нәрсәдер «ЮК! ГАЕПЛЕ!» дип пышылдап торды. Фәиз ул авазга колак салмаска тырышты.

Ничек кенә булмасын, күңелдә барыбер канәгатьләнү бар. Сөйләүнең нәтиҗәсе бик куркыткан иде. Нәркизәнең аның яклы булуы шулай да бераз хәл кертте. Тора-бара тәгаен аңлармын үземне, күңелемнең асылына төшенермен, сорауларга җавап табармын, гаепleme-юкмы икәнемне ачыклармын дигән өмет барлыкка килде. Бүгенге сөйләүнең төп нәтиҗәсе шул булды — азмыни бу?

Ул өйгә керде. Нәркизә яткан иде инде. Фәиз бер сүз дәшмичә чишенеп ятты һәм күптән онытылган изрәү белән каты йокыга талды.

## 18

Фәиз сазлыктан ераккарак китәргә ашыкты. Бу минутларда ул урманда адашып калудан да курыкмады. Сазлык куркыныч, аңардан читтә булырга кирәк. Урман, чыннан да, кичеп чыксыз кебек иде. Ул тәмам хәлдән тайды, юан усакка сөялеп торды да тагын атлап китмәкче булды, ләкин шунда аңын җуеп, агач төбенә ауды.

...Аңына килгәндә өстә агач яфраклары да, күкнең алама болытлары да күренмәде. Өстә фәкать ак түс кенә иде. Кеше тавышы да ишетелгәндәй булды. Дару исе бугай...

Аңына килгәч, хастаханә палатасында ятуын аңлады.

Башын борып як-ягына карамакчы иде — җитешә алмады, аның өстенә ак халатлы абзыйның түгәрәк йөзе иелде. Ул дикъкать белән бик озак карап торды. Фәизгә ул хөкемдар булып тоелды. Төрмә микән әллә бу? Юктыр. Төрмә мондый булмыйдыр. Ә-ә-ә, төрмәдә дә больница бар бит. Әле суд булмады лабаса.

Төрмә булса да, хет җәһәннәм булса да, барыбер түгелме? Юк, юк! Хөкем барыбер куркыта. Дөньясына битараф булган суратта дә алда көткән нәрсә барыбер куркыта!

— Яшибезме? — диде ак халатлы абзый һәм ягымлы итеп елмайды.

Шуннан соң, караватк кырыена утырып, Фәизнең пульсын тикшерде, йөрәген тыңлады һәм караватта бер хәрәкәтсез ятучы тәкъдир колының башын сыпырып үзе үк җавап бирде:

— Яши-и-и-без...

Мондый ягымлылыкны, җылылыкны Фәизнең күптәннән татыганы юк иде, ә бәлки беркайчан да татыганы булмагандыр. Кинәт рәхәт булып китте. Тартылып, суырылып калган ап-ак ябык бите буйлап мөлдерәмә күз яшьләре тәгәрәп төште.

— Кая бара идең сазлыклар, урманнар аша? — диде сөйкемле тавыш.

— Белмим, — дип пышылдады Фәизнең күгәргән иреннәре:

— Онытгыңмыни?

Юк, юк, җавап бирергә кирәк. Белмим һәм оныттым дигән җаваплар белән барыбер котылып булмас. Интуиция дигән нәрсә үзе җавап бирде:

— Онытмадым. Казанга бара идем мин.

— Ә нишләп җәяү барырга булдың?

— Чөнки акчам юк иде.

Чыннан да, Фәизнең аңы түгел, интуициясе сөйләште. Сораулар бүтән ишетелмәде. Фәиз җиңел сулап куйды, һәм шундук тагын йөрәгә жу итеп китте — допрос түгел микән бу? Мөгаен, шулайдыр. Әкренләп барысын да сөйләтерләр, ахрысы. Ләкин табибның аталарча ягымлы тавышы тагын тынычландырып җибәрде.

— Истощение... — диде врач, ниндидер прибор белән мәшгуль булып. — Алай куркыныч нәрсә юк, энекәш. Рас инде сазлыкка батып үлмәгәнсең икән, димәк, озак яшәячәксең.

Врачның әйткән сүзләре тынычландырырга да өлгермәде, җөмләләр юкка чыгып, бары тик бер сүз генә болай да тубал шикелле күпергән башта чыңлап калды: С А З Л Ы К. Аның янә күз аллары караңгыланып китте, оеп беткән авыз тагын да ныграк тәмсезләнде. Ул, күзләрен йомып, пышылдады:

— Ә Зәбир???

— Нәрсә?

— Зәбир кайда?

— Нинди Зәбир, энем?

— Зәбирне коткармадыгызмы?

— Син берүзең генә түгел идеңмени?!

— Берүзем идем, — дип кырт кисте Фәиз.

Бу — район үзәге больницасы иде. Ике атна эчендә Фәиз аякка басты. Больницадан чыкканда палатада бергә яткан пациентлрдан әҗәткә акча сорап карады. Имеш, аннары Казаннан җибәрермен. Әмма бу сәер егеткә беркем дә акча бирмәде. Ә врачтан сорарга читенсенде — болай да түләп бетермәслек игелек күрде аңардан.

Шулай итеп, ул бер тиен акчасыз район үзәге буйлап атлады. Бу — поселок сыманрак шәһәрчек иде, үзәк урамда да агач йортлар булгач ничектер күңелдә өмет туды — бәлки ярдәм итәрләр. Каршысына ике милиционер килүен күргәч ул коелып иңде. Хәтта кире йөгерергә дә исәбе булды. Ләкин батырчылык итмәде йөгерергә. Милиционерлар, быдыр-быдыр сөйләшеп, аңа игътибар итми үтеп киттеләр. Фәиз кызурак атлады. Бер кирпеч йорт янындагы иске «Волга» машинасы астыннан берәүнең яртылаш гәүдәсе чыгып ята иде. Фәиз машина янына барып чүгәләде. Машинаның нәрсәсендер аһ-ваһ килеп борып ятучы агай, аның килеп туктаганын сизеп, үрмәләп чыкты.

— Исәнме, абый.

— Сәлам,— диде илле-илле биш яшьләрдәге пеләш башлы агай.— Тыңлыйм.

— Минем Казанга барышым...

— Шуннан? Илтеп куй дисең мәллә?— диде агай елмаеп.— Алдан ук әйтеп куям: бу карт тәре белән әллә кая ерак китеп булмый. Рессорлар беткән.

— Юк, мине илтергә кирәкми. Мин акчамны югалттым. Минем беркемем дә юк. Сезнең больницагызда ятып чыктым. Миңа ярдәм итә алмассыз микән?

Агай ачкычларын җыеп багажникка салды да, Фәизне җентекләп күзәтә-күзәтә, кулын чүпрәккә озак итеп ышкыды.

— Әйдә, керик,— диде ул.

Шуннан соң өйгә кереп киттеләр.

Аларны җете кызыл халат кигән юан гәүдәле апа каршы алды.

— Нәҗибә, ашарга бирәр нәрсә әтмәллә,— дип хатынына дәште абзый. Аннары Фәизгә мөрәҗәгать итте.— Исемең ничек?

Фәиз уйлап торды — ялган исем әйтүдән ни файда?

— Фәиз.

— Мин Тәлгать абыең булам.

Шактый бай җиһазлы һәм тук тормышлы йорт иде бу. Тәрәзә кашагаларыннан, савыт-сабадан, җиһаздан, гомумән, һәр нәрсәдән затлылык бөркелеп тора иде.

Нәҗибә өстәлгә каймак, күпереп пешкән йорт ипие, салкын каз ите чыгарды. Фәизгә шикләнеп карый-карый чәй ясады да ишегалдына чыгып югалды. Ир белән егет сөйләшә-сөйләшә ашый башладылар.

— Син әйдә, кыюрак бул. Аша,— диде хуҗа кеше Фәизнең чыраеннан ук ач икәнен күреп.

— Рәхмәт,— диде Фәиз һәм кыюсызланып кына ашарга тотынды.

— Син кайдан соң үзең?

— Т. шәһәреннән. Детдомныкы мин.

— Ә монда ничек килеп эләктең?

— Заводтан увольняться иттем дә. Казанга барырга чыктым. Авырып киттем.

— Нәрсә булды, кай төшең авырта?

— Нервное истощение диделәр бугай.

— Ә-ә-ә, нишләп алай? Япь-яшь килеш... минем яшькә җиткәч нишләрсең?

Фәиз ашаудан туктады. Тәлгать сораулары белән интектергәнен аңлап алды.

— Аша, аша,— диде ул.— Мин бит үзем врач кеше, шуңа кызыксынам.

Фәиз куркып карап торды. Врач булгач, чирләүнең сәбәбен аңламагае дип уйлады ул. Юк, әнә бит ул нинди йөзле. Мәрхәмәтле кешегә охшаган. Табиб бит ул. Табиб карак була алмыйдыр. Мондый кешедән әшәкелек көтәргә кирәк түгел.

— Казанда берәр туганың бармы?

— Юк.

— Син метеор белән барырга җыенасыңмы?

Дөресен әйткәндә, Фәиз моннан Казанга ничек барырга мөмкин икәнне дә белми иде.

— Метеор белән барып буламыни?— диде ул.

Агай аптырап карап куйды:

— Әйе, елга пристаненә төшәсең дә билет алып китәсең.

Фәизнең моннан тизрәк чыгып сызасы килә башлады. Аппетит начар, ә инде сөйләшергә ният бөтенләй юк иде.

— Тәлгать абый,— диде ул төссезләнеп калган күзләрен хуҗага төбәп,— зинһар, булышыгыз, акча биреп торыгыз миңа билетлык кына булса да.

— Бирермен, бирермен, аша әле син.

— Рәхмәт, туйдым мин.

— Ничә сум кирәк соң сиңа?

— Белмим.

— Егерме биш сум җитәме?

— Җитә,— диде Фәиз шатланып.— Җитә. Мин сезгә берәр айдан кайтарып бирермен. Ант итәм.

Тәлгать өйалдына чыгып кычкырды:

— Нәҗибә, кил әле!

Ишек ачык калганлыктан аларның сөйләшкәннәре ишетелеп торды.

— Нәҗибә, егерме биш сум бир әле.

— Нигә ул?

— Бу малайга биреп торыйк. Ятим ул. Казанга бара. Акчасы юк.

— Син аны беләсеңме соң?

— Юк.

— Шулай булгач, нишләп мин аңа акча бирергә тиеш!

— Алай ярамый инде. Бирик.

— Бер таныш түгел кешегә... Кыяфәтен кара син аның. Әллә нинди малай бит ул.

— Күп сөйләшмә инде. Яңа гына больницадан чыккан ул.

Нәҗибә борын астыннан мыгырдап өйгә керде, аның артыннан Тәлгать кереп өстәл янына утырды.

. — Хәзер,— диде ул, Фәизгә күз кысып.

Нәҗибә олы яктан егерме биш сум алып чыгып иренә бирде дә, Фәиз ягына шикле караш ташлап, янә ишегалдына юнәлде.

Хуҗа хатынның мөгамәләсе бик авыр тәэсир итсә дә, Фәиз акча булуыннан бераз хәлләнеп китте, җиңел сулап куйды.

— Берәр айдан мин сезгә кайтарырмын. Адресыгызны, фамилиягезне язып алыйм да.

— Юк, син ул акчаны монда күчертеп маташма. Минем Казанда улым укый медицина институтында. Шуңа кертеп бирерсең. Хәзер мин сиңа аның адресын язып бирәм. Ул анда бер карчыкта фатирда тора.

— Ярар.

Акчаны һәм адрес язылган кәгазьне кесәсенә тыгып куйгач, Фәиз ничектер читенсенеп, чыгып китәргә кыймыйча утырды.

— Рәхмәт инде сезгә, Тәлгать абый.

Тәлгать аның иңеннән какты:

— Әйдә, саф һавада бераз сөйләшеп утырабыз. Метеорга иртә әле. Ә билетны алырга җитешерсең, анда бүген кеше күп булмаска тиеш.

Алар йорт каршында яткан имән бүрәнә өстенә чыгып утырдылар.

— Димәк син Т. шәһәреннән?

— Әйе.
— Мин бит шунда эшләдем врач булып, үзәк больницада.
— Шулаймыни!— диде Фәиз гаҗәпләнеп.— Сез нинди врач соң?
— Хирург идем. Хәзер пенсиядә. Партком секретаре белән уртак тел табып булмый башлады соңгы вакытта, шуңа гына чыктым пенсиягә.
— Сукыр эчәгеләренә операцияне сез ясый идегезме?
Тәлгать сагаеп калды:
— Әйе, ясый идем. Ник алай сорадың?
— Минем әнием сукыр эчәгенә операция ясаган вакытта үлде. Шул сез эшләгән больницада.
— Ничәнче ел иде ул?
— 1968 нче елны бугай.
Тәлгать башын аска иеп уйланып утырды:
— Үлүчеләр булгалады инде... Нишлисең бит. Исеме, фамилиясе ничек иде әниеңнең?
— Зифа исемле иде, фамилиясе Сибгатуллина. Бәлки сез ясамагансыздыр операцияне. Сез бит анда бер генә хирург булмагансыздыр?
Тәлгать хәтерли иде Сибгатуллинаны. Ул ясады операцияне. Канны туктата алмадылар. Ул, ялганлап, мин түгел дип әйтә дә алган булыр иде. Әмма никтер алдашасы килмәде:
— Мин ясаган идем операцияне,— диде ул, авыр сулап.— Үлүчеләр булды. Гаебем бар, гөнаһым бар, ничек кенә аклансам да...
Фәиз торып басты:
— Ярый, киттем мин. Улыгызга кертеп бирермен акчаны, борчылмагыз.
— Метеорга ярты сәгать бар әле.
— Әле билет аласы бар. Шушы урам белән барыргамы?
Тәлгать урыныннан кузгалды. Ул аны чатка кадәр озата барды һәм уңга борылгач ишарәләп күрсәтте:
— Менә шушы урам белән төш, пристаньга килеп чыгачаксың.
Фәиз никтер саубуллашырга онытты. Тәлгать аның артыннан бик озак карап торды.
Фәиз, башын аска иеп, әкрен генә атлады. Нинди якты йөзле кеше, ә үзе күпме кешене коткара алмаган. Әнисе дә шуның өстәлендә үлгән. Коткара алмагач, гаеплемени инде ул? Башка күсәк белән органдай итеп хәтергә сазлыктагы вакыйга килеп төште. Фәиз, шул хатирәләрдән качарга теләгән сыман, тизрәк атларга тотынды. Әйтерсең, үзеңнән үзең качу мөмкин!
Метеорга кереп утыргач, ул тәрәзәдән карады һәм эсселе-суыклы булып китте — котычкыч күз карашы белән аңа бер бәндә текәлеп тора иде. Күн курткадан, башына иске эшләпә кигән, аякларында күнитек. Ул Фәизне танырга тырышып карап тора иде, ахрысы. Кем бу? Фәиз исенә төшерә алмады — таныш кеше түгел иде. Күзәтүче сәер зат кинәт метеорга таба ыргылды. Ләкин соң иде инде, метеор кузгалды. Күн курткалы бәндә чыраен сытып, йодрыкларын төйнәп төкереп куйды һәм пристань палубасында калып кечерәйгәннән-кечерәйде.
Кем бу? Уголовный розысктанмы? Охшамаган. Алтын белән бәйләме бу очрашу? Кем бу? Бәлки аңа карамагандыр әле... Юк, юк, аңа текәлеп карап торды!
Баш нәрсә уйларга белмичә, исәңгерәеп бетте. Барлык уйлар бер боламык булып башта кайнадылар.
Тирә-як гүзәл иде. Әмма бу матурлыктан ни мәгънә — җанда хәсрәт булгач! Метеор кош сыман очты. Мәңге барырга иде менә шулай, ераккарак, беркем куып җиталмый торган тарафларга, югалырга, онытылырга иде.

## 19

Күн курткалы кеше пристаньнан китәргә ашыкмады. Ул бик каты уйланып суга карап торуында булды. Янәшәдә генә унике-унөч яшьлек малай кармак белән балык тота иде, ул аннан җавап алырга өметләнмәсә дә, шулай да сорап куйды:

— Энем, метеорга бер саргылт чәчле яшь егет утырды, бәләкәй генә буйлы... Күрдеңме син аны?

— Әйе, күрдем.

— Синең аны монда моңарчы күргәнең бар идеме?

— Юк.

— Кайсы яктан килгәнен дә белмисеңме?

— Белмим. Тәлгать абый беләдер әнә...

— Кайсы Тәлгать?

— Теге, врач... «Волгасы» да бар аның.

— Әйе, әйе.

— Бу егет шулардан чыкты, алар әле бүрәнәгә утырып сөйләштеләр дә. Мин ул вакытта тиреслегебездә суалчан җыйдым.

— Точно Тәлгать абыеңнардан чыктымы?

— Әйе.

— Рәхмәт, энекәш.

Күн курткалы кеше, малайлар сыман җитез итеп, җиңел генә йөгерде. Малай калкавычын онытып абый кешенең чабуына аптырап карап калды.

...Үлгән пациенткасының улы белән очрашу пенсиядәге врач Вахитов Тәлгать Назыймовичка гаять авыр тәэсир калдырды. Ул хәтта машинасын рәтли башларга да янадан үзендә хәл тапмады. Әллә ничек бу язмышлар. Алай зур кайгылар да юк кебек, ләкин, ләкин... Бер уйлап карасаң, бу дөньяның кызыгы, рәхәте дә шуның хәтле генә. Үзең гаепле түгел дә шикелле, әй уйлап баксаң, кем гаепле соң?!

Операция өстәлендә үлүчеләр байтак булды. Әлбәттә хирургның гаебе була, әмма... сәбәпләр дә бихисап бит! Пациентның организмы ныкмы, юкмы. Тиешле дарулар вакытында кул астында буламы. Операциянең катлаулыгы ни дәрәҗәдә. Тик шулай да... Тик шулай да... Кулына скальпель тоткан кешенең өстенә төшә бит җаваплылык. Күп очракта аның гаепләме-юкмы икәнлеген исбатлап та булмыйдыр. Күп очракта гына түгел, гомумән билгеләү мөмкин түгелдер.

Сугыштан соңгы елларда Тәлгатьнең әтисе РайПО рәисе булып эшләде.

Авыр елларда да аягында нык торучы, хәлле, абруйлы кеше буларак, ул бердәнбер улына тиешле белем бирүне, аны аякка бастыруны иң мөһим бурычы дип санады. Тәлгать армиядән кайткач, әтисе хәтта аның белән киңәшләшеп тә тормыйча карар кылды: медицина институтына керәсең! Мәктәптә начар укыса да, медицинага күңеле тартмаса да, Тәлгать әтисенә буйсынды һәм танышлык белән институтка урнаштырылды. Уку җиңел булмады. Тырышуын тырышты, лекцияләргә тәртипле генә йөрде, белемне алырга омтылды, табиблык фәненә хәйран кызыксынуы да уянды. Тик нәрсәдер җитми иде — күңелдәме, баштамы. Әтисенең әшнәләре аша эткәләп-төрткәләп тәмамлады ул институтны. Блат белән кереп, башы җитмәгән килеш, катлаулы фәнне «кимереп» интегүеннән элегрәк үзе читенсенсә дә, тора-бара ияләште, чөнки аның шикелле танышлык-дуслык белән укучы студентлар — булачак врачлар бихисап иде. Аннары, укыгач, белем алгач, беркавым эшләгәч, практика үткәч, һичшиксез врач булачагына елдан-ел ышана барды. Бу ышанычны институттагы укытучылар гына түгел, әтисе, әнисенең дуслары да аңына сеңдерүгә өлеш керттеләр.

Диплом алып, Т. шәһәренең үзәк больницасына урнашкач, баштарак авыр булды. Монда да әтисенең дуслары ярдәмгә килде. Горкомның беренче секретаре Тәлгатьнең әтисе белән ахири дуслар иде. Күп тә үтмәде, Тәлгать инде бүлек мөдире булды.

Әмма ләкин, больницада эшли башлап, иялэнеп, хәйран гына тәҗрибә тупласа да, үзеннән канәгатьсезлек хисе күңелендә яши бирде. Укып йөргәндә андый канәгатьсезләнү юк шикелле иде. Бу — кешенең үз эшеннән канәгать булмыйча, яңадан-яңа үрләргә омтылуы түгел иде. Бу канәгатьсезлек — кемдер каршында, нәрсәдер алдында үзендә гаеп тою нәтиҗәсе иде бугай. Операция фаҗига белән тәмамланган саен аның үз-үзенә ышанмавы һаман арта торды. Үз урынында түгел иде ул. Китәргә дә соң инде хәзер. Должность бар, дуслар күп, блат һәм дәрәҗә җитәрлек. Кая китәсең һәм дә ник китәсең?! Бөтен ил шулай яши. Блат, кодалык, партиягә тугрылылык. Әнә бит, эшләр бара. Уңышлы тәмамланган операцияләр күпме! Күпме кеше рәхмәтләр укый. Ә инде үлемкитемгә килгәндә. Нишләмәк кирәк. Сирәк була бит андый очраклар.

Тик шулай да... Тик шулай да...

Кайвакыт тиешле, кирәкле дарулар җитми. Алар складта бар, әмма кемгәдер махсус алдырганнар аны. Кайсыдыр трест начальнигының туганнан туган сеңлесенең диплом яклыйсы бар икән, шундагы бер профессорның абыйсының малаена әлеге дарулар кирәк икән. Менә бит ул ничек, акылдан язарга мөмкин.

Завхозның гына да дус-ишләре күпме! Үзе бер дөнья, аерым бер тарих. Барыбер шуның белән бергә эшләргә кирәк, чөнки бер төен булып бәйләнгәннәр. Бер система, бер үк яшәү рәвеше. Син ул завхозга тел тидереп кара әле! Ул синең турыда әллә ниләр белә, хәтта үзең белеп бетермәгән нәрсәләрне дә исеңә төшерүе ихтимал. Сәлим Сәлмәневичне коры кул белән элэктереп булмый. Егерме ел бергә эшләргә туры килде. Бер-берсен күралмасалар да, тышка бик чыгарырга тырышмадылар. Болай, аңлатырлык сәбәп тә юк иде кебек дошман булырга. Шулай да уртак телгә килә алмый иде алар, никтер. Һәм ачыктан-ачык талашу-сугышуга да бармыйлар иде. Дошманлык фәкать эштә чагыла иде, чөнки эштә көн саен юллар кисешеп тора һәм бер-береңне күзәтеп торасың.

Больницаның баш врачы итеп билгеләнгәч, Тәлгать Назыймович шулай да баш имәс завхозны урынына утыртмакчы булып карады. Әмма конфликт тирәнәйде, ә Сәлим Сәлмәневичне ни эшеннән чыгарып, ни куркытып булмады. Таянычлы кешеләре бар иде завхозның. Ә Тәлгать Назыймовичның җәмгыятьтәге урыны әтисе исән вакыттагы кебек түгел иде инде. Күрәсең, дус-ишләр белән, танышлар белән кодалык элемтәләрен саклау — шулай ук аерым бер, үзгә сәләт таләп итәдер. Тәлгать Назыймовичта бу сәләт юк иде, ахрысы.

Кемнеңдер шикаяте буенча больницаны тикшерергә Мәскәүнең үзеннән комиссия килгәч, Тәлгать Назыймовичны баш врач эшеннән алып, гади хирург итеп калдырдылар. Ул моңа бик кайгырмады шикелле, ләкин җанында үзгәреш булмый калмады. Аның медицинага аяк баскан көннәрендә туган курку, үзендә бу өлкәдә эшләрлек сәләт тапмау, уңышсызлыкка ирешермен дип каушау янә бербөтен комплекс булып күңелдә калыкты. Үзен баш табиб буларак саклый алмаган, врачлар арасында зур абруйга ирешмәгән, дару-фәләннәр сатып-алып, караңгы вә кыңгыр эшләр белән күп еллар маташып ятучы завхоз Сәлимне җиңалмаган кеше кемнедер авырудан, үлемнән коткара алмыйдыр шикелле тоела башлады аңа.

Кызганыч ки, соңгы вакытта аңа катлаулы операцияләр туры килгәләде. Һәм ул үз-үзенә ышанычны югалта барган саен, операцияләр уңышсыз тәмамлана башлады. Пациентларның үлеп китү очраклары ешайды. Гәрчә инде Тәлгать Назыймовичның тәҗрибәсе зур булса да, Мәскәү комиссиясе, әйтерсең, аның тәҗрибә туплаган «мин»ен алып

китеп, блат белән тегендә-монда кертелә торган «мин»ен генә калдырып киткән иде.

Эштән азат итүләрен үтенеп, гаризаны ул үзе, беркемнән тәкъдим һәм боерык көтмичә язды. Калырга өндәүче булмады, шулай да яңа баш врач:

— Эшләр идегез әле,— дигән булды.

— Арыдым,— диде Тәлгать Назыймович.

Һәм ул, чынлап та, арыган иде. Ул системадан арыган иде. Әшнәлек, кодалык, кемгәдер һәрвакыт бурычлы булып, «син — миңа, мин — сиңа» тәртибе буенча ясалма туганлык ардырды. Кыскасы, гомер буе, артист булмаган килеш, артистланып яшәү ардырды. Өстәвенә әле, күңел кушуы буенча врач булмаган килеш, врач эшен башкарырга туры килде.

Тәлгать Назыймович пенсиягә чыккач, Сәлим Сәлмәневич та завхоз урынында озак эшләмәде. Ниндидер статья да кулланмакчы булганнар үзенә, әмма ләкин, сез нәрсә, ул бит больницаның завхозы булып эшләгән кеше гомер буе! Аны нинди статья алсын ди! Зур урман хуҗалыгының житәкчесе булып барды да урнашты.

Элеккедән ким-хуррак булмады, кайгыга батып, хәсрәт чигеп йөрмәде, зарланмады, кемнәргәдер үпкәләп йөрмәде. Тотты да алпавыт шикелле зур хуҗалык белән урманда яши башлады. Сәлим Сәлмәневич бит ул! Гомер буе хастаханәдә завхоз булып эшләгән кеше!

...Күн курткалы кешене Тәлгать Назыймович әллә каян ук күреп, танып алды.

Һәм аның җил-җил атлап якынлашуы күңелгә бер дә шатлык өстәмәде, киресенчә, бу кеше белән сөйләшергә туры киләсен белү болай да караңгыланып киткән күңелгә төкселекне ныграк өстәде. Хәтта качарга да нияте булды, тик никтер үзен туктатты һәм ачкычларны иске күн янчыкка тутырып машинаның багажнигына ташлады да килүчене көтеп капка янындагы эскәмиягә утырды.

Килүче — завхоз Сәлим Сәлмәневич иде.

«Бәлки минем янга килүе түгелдер. Ә кем янына килсен икән ул? Монда кеме бар аның? Беркеме дә юк бугай. Монда аның бер тапкыр да күренгәне юк иде. Урман хуҗалыгы ерак түгел түгелен. Шулай да, нишләп йөри икән ул монда? Минем янга килә инде, тагын кем янына килсен!»

— Әссаламегаләйкем,— дип елмайды Сәлим килеп житәрәк.

— Коммунист башың белән мөселманча исәнләшәсең,— дип шаярткан булды Тәлгать, желеген корыткан элекке завхозның бигүк чиста булмаган кулын кысып.— Утыр әйдә.

Сәлим янәшә утырып фуражкасын салды, шуның белән битендәге эре тир бөртекләрен сыпырды.

— Коммунист булсам да, мин бит урманда хәзер,— диде ул һәм Тәлгатькә карап тагын бер ыржайды.— Картаеп киткәнсе-е-е-ең.

— Гомер уза бит. Син дә яшәрүгә таба бармыйсың.

— Шулай шул,— диде Сәлим, авыр сулап,— урманда тынычрак булмасмы дигән идем. Кая ул! Җан тынычлыгы юк барыбер.

Тәлгать көлемсерәп:

— Үзеңнән үзең качып булмый шул,— диде.

Сәлим аңа житди генә карап куйды:

— Ә минем үземнән качарга тырышканым да юк. Бәлки син үзеңнән котылырга ниятлисеңдер...

Тәлгать башын чайкап көлеп җибәрде:

— Күрешмәгәнгә байтак вакыт узды, ә менә очрашкач әңгәмәбезнең рәте юк. Син миңа кунакка килдеңме, әллә минем белән талашыргамы?..

Сәлим кыяфәтен үзгәртергә ашыкты, ясалма ягымлылык белән Тәлгатьнең иңеннән кагып куйды:

— Нишләп мин синең белән талашыйм ди. Нәрсә, безнең бүлешәсе мал юктыр бит! Монда, поселокта эшләрем бар иде... Туктале, мәйтәм, Тәлгать Назыймович ни хәлләрдә яшәп ята икән... Ничек соң сәламәтлекләр? Нәҗибә ни хәлдә?

— Аллага шөкер, беркөе. Үзеңнең эшләр барамы соң?

— Бара. Авыр инде. Урман хуҗалыгы бит ул.

— Әле ничекияләшеп эшли аласың. Мин булдыра алмас идем.

— Башыңа төшсә булдырырсың. Т. шәһәрендә булгалыйсыңмы?

— Юк. Анда бер генә дә йомышым төшкәне юк, Аллага шөкер.

— Ха-ха-ха, Тәлгать Назыймович, син дә Алланы еш телгә ала башлагансың.

Тәлгать Назыймович бу ямьсез кешенең ни йомыш белән килгәнен аңларга тырышып, җентекләп карап торды. Махсус килгәнгә охшаган. Әдәп саклап, аны өйгә чакырасы итте:

— Әйдә, Сәлим Сәлмәневич, өйгә керик, берәр чынаяк чәй эчәрбез.

— Юк, юк, Тәлгать Назыймович, монда гына беркавым сөйләшеп утырыйк, вакытың булса инде.

— Вакыт күп хәзер.

Сәлим як-ягына карады, күккә башын күтәргән булды:

— Һава шәп, чиста.

— Һава әйбәт бездә,— диде Тәлгать, канәгать төстә.

Сорау Тәлгать өчен көтелмәгән булып чыкты:

— Синнән бер унбиш минут чамасы элек бер үсмер егет чыкты. Кем ул?

Тәлгать аптырап китте, чөнки элекке завхозның килүе больницадагы эшләр белән бәйледер дип уйлаган иде. Ул ничек җавап бирергә дә белмәде, аның каушабрак калуы Сәлимне дә бераз пошаманландырды. Үлгән пациентканың улы булганлыктан, Тәлгать әллә ниләр уйлап бетерде. Ник сорый Сәлим бу егет турында? Нәрсә кызыксындыра аны?..

— Нишләп ул егет кызыксындыра сине?— диде Тәлгать, нинди җавап бирергә дә куркып.

— Юк. Кемең ул синең? Нишләп дулкынлана башладың?

— Казан егете ул,— диде Тәлгать үзен кулга алып,— Маратның дусты. Монда бер кыз янына килгән дә юл уңаеннан Мараттан сәлам әйтергә кергән. Марат кереп чыгуын үтенгән.

Сәлим авызын кыйшайтып ямьсез итеп елмайды һәм сытып чыгарды:

— Алдыйсы-ы-ың, Тәлгать Назыймович, алдыйсы-ы-ың.

«Чыннан да, ник алдашып утырам соң әле мин...»

Кинәт аның күңелендә ярсу купты, күп еллар буена җыелып килгән нәфрәт менә-менә вулкан булып шартлап чыгар кебек иде. Тәбәнәк буйлы, кысык күзле бу кешене менә шушында, менә хәзер утыз икеле ачкыч белән башына сугып үтерсәң, гөнаһ булмас иде, мөгаен. Больницада үлгән авырулар өчен, киресенчә, үч алып савап кылу булмас иде микән? Нинди ямьсез кеше... Элегрәк, бергә эшләгән вакытта күзгә чалынмаган ямьсезлекләр бихисап икән бу бәндәдә. Нинди күзләр — шомырт бөртеге сыман гына. Башының формасын кара — кыска буена тәңгәл түгел, гарипләрчә олы, түгәрәк булып тора. Тәлгатьнең бөтен нәфрәте тышка бәреп чыкса, бу хәшәрәттән юеш урын, канлы тап кына калыр иде, мөгаен.

Әмма ләкин галәмәт гайрәткә ия булган бу нәфрәт, үзенчә үзгәреп, Тәлгать Назыймовичка ничектер, көтмәгәндә кыюлык өстәде һәм ул төп дөресен әйтеп бирде. Ник дөресен әйтмәскә!

— Бу егет детдомда үскән. Безнең поселок больницасында яткан. Монда беркеме дә юк. Миннән килеп әҗәткә акча сорады. Чәй эчерттем үзенә. Менә була бит шулай. Дөнья бик тар бит ул. Сөйләшә торгач мәгълүм булды: әнисенә безнең Т. шәһәрендә операция ясаганнар икән. Оперцияне мин ясаганмын. Үлде ул операция вакытында... Зифа Сибгатуллина. Мин, әлбәттә, яшерә ала идем операцияне үзем ясаганны.

Никтер дөресен әйтәсем килде, әйтеп бирдем: әниеңә мин ясаган идем операцияне дидем.
— Ә ул сине махсус эзләп тапканмы әллә?
— Юк ла. Очраклы рәвештә. Дөнья тар ич ул.
— Кая китте соң ул хәзер?
— Казанга.
— Адресын бирмәдеме?
— Адресы юк аның.— Тәлгать сынаулы караш белән Сәлимгә текәлде.— Ә сиңа нәрсәгә аның адресы?
— Болай гына. Алдашмыйсыңмы соң син?!
— Ни турында?
Сәлим Тәлгатьнең соры күзләрен аксыл пәрдә каплый башлаганны күреп алды. Кайчандыр түгәрәк йөзле, кара бөдрә чәчле чибәр Тәлгать Назыймовичтан сулып, бөрешеп баручы, җыерчыклар белән капланган, бөкрәебрәк төшкән Тәлгать абзый гына калып бара иде. Ул аңа төбәп озак кына карап торды, Тәлгать хәтта бераз курка да башлады. Сәлим аңлады: Тәлгать алдамый иде, ничек бар шулай дөресен әйтте ул — күренеп тора.
— Акча бирдең инде алайса?
— Бирдем, егерме биш сум.
— Ул аны сиңа кайтарачакмы соң?
— Нишләп кайтармасын, намуслы егеткә охшаган ул.
— Исеме ничек соң аның?
— Фәиз.
— Син ул егерме биш сум акчаңнан колак кактың дип сана инде. Кире кайтармаячак ул аны. Детдом баласы сиңа әҗәтен түләп торамы инде?! — диде Сәлим һәм зур игътибар белән Тәлгатькә карады.
— Кайтарача-а-ак,— диде Тәлгать, еракка, каршы бакчаның рәшәткәсе өстеннән офыкка карап,— улымның Казандагы адресын бирдем, шуңа кертеп бирәчәк.— Кинәт ул сискәнеп китте.— Ахмак мин! Ахмак! Әҗәт итеп бирмәскә иде миңа ул акчаны. Болай гына бирергә иде. Егерме биш сум да аз әле ул егеткә. Мин бурычлы түгелме соң ул ятим алдында?
Бу сүзләрне ул үзалдына мыгырдады, авызын кыйшайтып утыручы Сәлимдә аның хәбәре юк иде.
— Улың хәзер Казанда түгелдер бит?..
— Молдавиядә, стройотряд белән... Ике атнадан кайта бугай инде. Казанга хат язып салыйм әле мин, ул егеттән акчаны алмасын. Бәлки кайткандыр инде. Кайтмаса да, хат барып җитешер микән?
— Карале, Тәлгать Назыймович, мин бит иртәгә Казанга барам, кереп чыгыйм Маратның янына. Син кечкенә хат яз да, кертеп бирермен.
— Шәп булыр иде,— диде Тәлгать шатланып.— Хәзер. Алайса яхшы түгел, беркеме дә юк бит ул егетнең.
Ул абына-сөртенә өйгә кереп китте. Сәлим, коймага аркасын терәп, күзләрен йомды. Вөҗданы сулкылдый Тәлгать Назыймовичның. Операциядә вакытында үлгән кешенең улы каршыңа килеп басса, бигүк рәхәт түгелдер шул.
Күп тә үтмәде, конверт тотып Тәлгать капкадан чыкты.
— Менә, адресны конверт тышына яздым.
Сәлим конвертны алып курткасының эчке кесәсенә тыгып куйды.
— Син ул хәтле борчылма-а-а,— диде Сәлим елмаеп.
— Бөтен кеше дә синең кебек каты бәгырьле түгел бит,— дип әйтеп ташлаганын Тәлгать үзе дә сизми калды.
Сәлимнең шундук чыраеннан төс качты:
— Син үзеңне бел! Син тәүфыйклы булдың мәллә?! Беләбез синең кем икәнеңне дә!
— Мин синең шикелле күрә торып җинаять эшләмәдем. Ялгышлык, хата белән булуы ихтимал... Тәҗрибә җитеп бетмәгәнлектән. Ә син!

Тиешле дарулар вакытында килеп, синең складларда яшеренеп ятмаса, фаҗигаләр кимрәк булмас идемени?!

Сәлимнең бер дә исе китмәде:

— Мондый «чиста» кешеләр беләсеңме дөньяда күпме! Син үзең дә пациентларыңның фамилиясенә, дәрәҗәсенә игътибар итә идең. Монысы җинаять түгел идемени?

Тәлгатьнең куллары калтырый башлады, ул аларны яшерергә урын тапмады.

— Ярар, Сәлим, монда талашып утыруыбыздан мәгънә юк,— диде ул, тизрәк бу кеше белән хушлашасы килеп.

Ләкин тегенең хушлашасы да, ызгышудан туктыйсы да килми иде әле:

— Башкаларны тикшереп, тәнкыйтьләү җайлы ул! Менә үзеңне барлап, үзеңдә казынып кара!

— Болай да күп казынам инде мин үземдә. Анысы өчен борчылма.

— Улың Маратны да медицинскийга урнаштырдың бит әле үзең.

— Ул үз теләге белән керде анда!

— Син этеп-төртеп кертмәсәң, керер иде инде әллә кая...

Тәлгать түзмәде, утырган урыныннан атылып торды:

— Бир хатны! Һәм күздән югал.

Сәлим ямьсез итеп авызын кыйшайтты да, бер дә дулкынланмыйча гына торып басты:

— Күздән югал, дисеңме?! Минем үземнең дә сине бик күрәсем килеп тормый. Ә хатны тапшырырмын, барыбер Казанга барам.

Тәлгатьнең хатта хәбәре калмаган иде инде:

— Син өстәвенә әле көнләшәсең дә! Чөнки минем улым институтка керде. Ә синең малаең, хулиганланып, эчеп-сугышып йөри. Шуңа да ачуың нык килә синең.

— Минем улым да ким-хур булмас. Минем улым бит ул!

— Кит, туйдым, арыдым мин синнән!

Сәлим биш-алты адым киткәч туктап борылды:

— Бер дә көнләшер җирең юк. Нервыларың беткән,— диде, машинага ымлап.— «Волгаң» иске. Кыяфәтең ямьсезләнгән.

Шуннан соң ул үзенең әйткәннәреннән канәгать булып шаркылдап көлеп куйды.

Тәлгать утыргычка утырды һәм чак кына ишетелерлек итеп:

— Зерә болай әшәкеләнәсең, Сәлим,— диде.— Безгә... Сиңа да, миңа да үкенәсе эшләребез өчен үкенеп, шатланасына куанып, үзгәртәсен үзгәртергә тырышып, чистарынып булмасмы диебрәк яшәргә кирәк түгелме? Гомер кояшы баеп бара бит инде.

— Һе, үзеңдә гаеп сизәсең икән, чистарынырга тырыш!

— Син үзеңдә гаеп, гөнаһ таймыйсыңмыни?

— Изге кеше юк дөньяда! Тормыш бу! Кешелек дөньясы бу! Ярар, киттем мин! Хатны кертеп бирермен Маратка. Кайтмаган булса, хуҗа хатынга калдырырмын. Почта ящигына салып китсәм дә була. Ярый, хуш.

Тәлгатьнең хушлашырга теләге дә, хәле дә юк иде. Килгәндәге кебек үк җил-җил атлап китеп баручы элекке завхоз да аңа китүче булып түгел, бәлки каядыр яңа тормышка яңа ниятләр белән баручы оятсыз, намуссыз кеше кебек тоелды. Нәфрәт, кан тамырларының спазмасы булып, тәнне буып алды.

Бу кешедән кай төшем артык соң минем! Кайсыбыз пычраграк, кайсыбыз чистарак соң безнең?.. Мин үзем чиста булмаганга аны күралмыйм, ә ул мине үзе пычрак булганга күралмый түгелме? Кеше үзен тирәнрәк өйрәнсә, башка кешеләрне аңлый башлый. Үзеңне белим дисәң, башкаларны өйрән, башкаларны аңлыйм дисәң, үзеңне аңлау зарур.

Авырткан җиремә басты. Җитмәсә, Маратны мединститутка урнаштыру турында сүз катты, кабахәт!

Марат, Марат... Ни гаҗәп, табиб булырга тели бит.

Врачның эше авыр, хәтта куркыныч икәнен улына ул күп тапкырлар аңлатырга тырышып карады. Бердәнбер улының хыялларына башка юнәлеш бирергә маташты. Юк, врач булам һәм вәссәлам! Бәлки Нәҗибә, өндәп, улын якламаса, мединституттан баш тартырга үгетләп тә булыр иде. Нәҗибә тыңларга да теләмәде — юк, докторга укысын! Танышлары күп булачак, абруй казаначак, имеш. Нәҗибә бит белми, Тәлгать Назыймовичка ничек авыр булганны. Дус-ишләр янәшәсендә, акчага кытлык кичермичә, җиңел машинада гына йөреп яшәгәч тә, ул үзенең хатын-кыз башы белән ничекләр аңласын табиб эшенең коточкычлыгын! Соңгы елларда тормышлары үсүгә таба бармады, югыйсә. Юк, барыбер, мединститутны бетерсен улыбыз, имеш! Әле керә аламы институтка, юкмы, башта шуны уена китерсен иде... Хатын-кыз башы белән (үзе укытучы бит әле!), иренең элемтәләренә күнегеп, улын да җайлы гына укырга кертер дип ышануын кара әле син аның!

Тәлгать Назыймович, Тәлгать Назыймович... Тәки урнаштырдың бит улыңны мединститутка. Бәлки үзе дә керә алыр иде. Тик инде керә башлаган икән — әшнәлек белән файдаланмый булмады.

Намус дигән ниндидер бер нәрсә эчтән кимерсә дә, медицинага карата күңелендә нәфрәт баш калкытса да, ничектер, улының һәм хатынының теләгенә каршы килә алмады. Үзе укыган факультетка түгел, лечебный факультетка урнаштырды. Әйтерсең лә, бу факультетка ярый. Алдан улы белән ихлас сөйләште, форма өчен һәм үзен тынычландырыр өчен генә түгел — күңелендә бу изге эшкә чын тартылу булса гына, үзеңдә табиб сәләте тойсаң гына бар медицинага, диде.

Сәлим белә кайсы тәшкә сугарга.

Тәлгать эскәмиягә кадаклап куйган сыман утырды. Маратны чынлап та зерә керттем мединститутка. Минем язмыш кабатланмасмы?! Нужа күрмәде-күрүен, ә менә калган гомерне авыр булыр бит яшәве... Ярар, болай бик өзгәләнмим әле. Укып бетерсен әле, күз күрер. Бәлки җаваплылык азрак булган эш табылыр. Медицина зур өлкә бит ул. Укысын, укысын. Хезмәт хакы да, абруйлы эше дә кирәк шул бу дөньяда. Укысын, үземнең ялгышларны кабатламасын өчен чаралар күрергә тырышырмын, Алла боерса. Карале, чыннан да, Алланы еш телгә ала башладым түгелме? Аһ, бу Сәлим, үткер күзле, сизгер колаклы серткыч. Урманга киткәч тагын да ныгып, хайванланып киткән бит бу? Казанга китте. Хатны Маратка кертеп бирсә ярар иде. Фәиздән акчаны алмасын. Конверт эченә тагын бер егерме сум тыгарга идеме икән әллә?

Казанда беркемем дә юк ди бит. Әнисе минем өстәлемдә җан бирде бит. Бәлки Сәлимнең дә гаебе бардыр Зифа Сибгатуллинаның үлүендә?! Ә мин бүлек җитәкчесе идем. Завхоз минем кулда иде. Кулда... Тотарсың завхозны кулда! Менә хәзер гомер буе чишеп утыр инде: кем гаепле, кем күбрәк гаепле? Сәлимдә андый уй-кичерешләр юк, ахрысы. Ул андыйга охшамаган. Намус, вөҗдан дигән төшенчәләр бар микән соң аңарда? Ә булудан ни мәгънә?! Җинаятьтән соң вөҗдан газабы кичерүдән ни мәгънә?!

Ник бара икән Сәлим Казанга?

Ярсуы басылып, күңеле тынычлана гына башлаган иде, кинәт йөрәге тагын жу итеп куйды. Сәер, бик сәер — килде дә Фәиз турында сораштырды, Маратның адресын алды (Тәлгать үзе дә сизми калды, үз куллары белән улының Казандагы адресын тоттырды!) Туктале, туктале, ул бит Фәизнең адресын белмисеңме дип тә сорады, әйе, башта аның адресы белән кызыксынды. Казанда беркеме дә юклыгын белгәч, сөмсере коелды бит Сәлимнең. Димәк, Сәлим Фәизне эзәрлекли. Маратның адресын тикмәгә алмады ул — хат тапшыру сәбәп кенә. Фәизне эзәрлекли Сәлим. Ничек хәбәр итәргә Маратка? Фәиз турында сораштырса, Сәлимнең бер соравына да җавап бирмәсен иде ул!

Нигә Фәиз кирәк булган аңа? Әллә, Ходаем, операциядә үлгән пациентларның туганнарын, балаларын җыеп, Тәлгатькә каршы бирәр

матавык оештырмакчы була микән?! Алай дисәң, бөтенләй үк кан дошман түгел бит алар Сәлим белән. Әллә үзенә тагын берәр статья тагарга маташалар да, котылыр өчен элекке главврачны, ягъни Тәлгатьне батырмакчы була микән?!

Бетте баш! Ә нигә куркырга ул кадәре?!

Бүген үк китә микән Сәлим Казанга? Марат ике атнадан кайта дидем мин аңа. Ул, чыннан да, бер-ике атнадан кайтырга тиеш. Иртәгә үк Казанга барып, Марат яши торган фатирның хуҗабикәсенә әйтергә кирәк: Марат стройотрядтан кайткан көнне үк поселокка юл тотсын — кичекмәстән! Язу да калдырырга кирәк. Кичекмәстән кайт, дип! Әлбәттә, куркып калыр инде ул — берәр бәла-каза булмады микән дип. Әйдә, курыкса курыксын, үлмәс әле.

Туктале. Марат аша Фәизнең үзен күреп сөйләшергә кирәк — әллә Сәлимне белә микән ул? Берәр нинди уртаклыклары бар микән әллә? Фәиз әле тиз генә бармас та Марат янына, чөнки акча кайдан алсын әле ул. Берәр җирдә шабашка эшләп алырга да вакыт кирәк бит әле. Казанга иртәгә үк барырга һәм Маратны кисәтеп куярга кирәк.

Тәлгать, өйгә кереп, аптырашта калган Нәҗибәгә иртәгә Казанга китәсен әйтте.

Әмма Тәлгать икенче көнне үк Казанга китмәде. Бер үк көнне Фәизнең һәм Сәлимнең килүе, хәтердә яман хатирәләрнең кузгалуы, үзендә нииндидер гаеп-гөнаһ тою бик авыр тәэсир ясады, шул сәбәпле икенче көнне аның юлга чыгарга кәефе генә түгел, хәтта хәле дә юк иде. Депрессия үткәч, хәлем яхшыргач барырмын, диде ул үзенә.

## 20

Сәлим дә икенче көнне үк китмәде Казанга, чөнки Марат барыбер ике атнадан гына кайтачак ди анда... Урман хуҗалыгында эш өстендә эш өелеп ятса да, ул үзенә урын табалмый җәфа чикте.

Ничек табарга ул малайны?! Исеме Фәиз ди... Чак кына куып тотмадым бит ә?! Метеорга атылып керәсе калган. Кергән булсам да, гауга куптан булыр иде. Тавыш чыгарырга ярамы-ы-ый... Казан хәтле Казанда аны эзләп табу мөмкин түгелдер инде. Марат яши торган фатир янында да гел сагалап ятып булмый. Әллә китереп бирә ул егерме биш тәңкәне, әллә юк. Поселок хастаханәсендә яткан ди бит. Кичекмәстән шунда барырга, кызыксынырга кирәк — мөгаен, ул малай турында мәгълүматлар калгандыр анда. Сәлимнең дус врачы да бар анда, завхозы да таныш. Шунда барырга кирәк. Кичә үк кереп чыгасы калган да бит — ничек башка килмәгән.

Ул ашыга-ашыга мотоциклын кабызды.

Әмма барып йөрүләре юкка булган. Фәизгә авыру тарихын бөтенләй ачмаганнар. Хәтта фамилиясен беркая да язып куймаганнар. Дәваланган врачы исә бөтенләй белмәмешкә салышты, чөнки Сәлим үзен «шул малайның ерак туганы» дигәнгә һич кенә дә ышанмады. Дус врачы отпускыда, ә таныш завхозы хәбәрдар түгел иде. Шулай итеп, аның бердәнбер чарасы — Казанга барып Марат белән сөйләшү калды.

Бер атнадан барырга карар кылды ул.

Шул арада Т. шәһәренә барып кайтасы иде. Улы Ренат шунда бит аның. Сәлимнең фатиры да бар анда. Тәлгать кенә ул, җүләр, фатирын поселоктагы йортка алыштырды. Ә Сәлим дивана түгел шәһәрдәге фатирдан колак кагарга. Ренатны техникумга урнаштырасы бар. Инде алдан сөйләшенеп куелган — имтиханнарны ул «бирәчәк», укырга керүендә шик юк. Тик менә бик шук егет булып үсеп килә шул, күңел ачарга ярата, күңел ачып туйгач, сугышырга маһир. Инде милициядән дүрт тапкыр йолып калырга туры килде үзен. Дуслар бар-барын, әмма алар

алдында да оят бит. Укый башлагач та, фатирда берүзе яши алыр микән? Әллә хатыны Саимә яңадан күчсен микән шәһәргә? Алай да булмый инде ул. Хатыны калада, үзе урманда — тормышмыни инде! Юк, юк. Ренат белән тагын әйбәтләп сөйләшергә кирәк. Документларын техникумга тапшырырга киткән җиреннән менә бер ай буена өйдә күренгәне юк бит. «Урманда бүре яшәсен!» — дигән була, маңка. Милициягә эләкмәде микән?.. Армиягә тизрәк алсыннар иде инде ичмаса үзен. Бераз акыл кереп кайтмасмы. Иркә булды, иркә. Мул яшәдек, бернәрсәгә кытлык кичермәдек, гади сәвит кешесе сыман зарплатадан зарплатага акчаны кысып тотып яшәмәдек. Завхоз эше нужа күрсәтмәде, җил-яңгыр тигезмәде. Хәзер менә башны авырттырган бердәнбер нәрсә — шушы Ренат кына. Фатирның астын-өскә китереп бетерде микән инде? Тизрәк унсигез яше тулсын ичмаса, армиягә озатыр идек. «Берәр ничек армиядән алып кал!» — ди әле ул, чукынчык. Бер караганда, кызганыч та бит үзен ике елга армиягә озатырга. Техникумга тапшырдымы икән документларын? Аракы эчеп, гүләйт итеп йөри микән?.. Техникумда укулар башланырга әле вакыт байтак. Әллә Ренатка кушаргамы Фәизне эзләп табарга? Әй, юк, аны Казан хәтле Казанга берүзен чыгарып җибәрергә ярыймы соң?! Мондый ташбашны исән дип көтәргәме аннан, үле дипме? Аллам сакласын, Аллам сакласын!

Аллам сакласын, дип Сәлим Сәлмәневич завхоз булып эшләгәндә дә әйтә иде. Дару урлаганда да, дефицит препаратларны уңга-сулга саткан-да да Алланы телгә ала иде ул. Авырулар көтеп яткан ампулаларны складның яшерен почмакларына яшергәндә дә Алланы гел исеннән чыгармады.

Бу яман эшләрнең җинаять икәнен белсә дә, ул үзен акларлык фикерләр таба иде. Мин генә чиста, намуслы булып дөнья үзгәрмәячәк, мәрхәмәтлегә әйләнмәячәк, дип әйтә иде ул үзенә үзе. Кем ничек булдыра ала, шулай яши, ә беркемнең дә начар торасы килми. Менә шундый гап-гади мантыйк белән күңеленнән үзен аклап яшәде ул. Аллам сакласын дип әйтүе — Алла гөнаһлардан сакласын дип үтенүе түгел, бәлки кылган эшләрендә тотылмавын, рисвай ителмәвен, җәзага дучар булмавын үтенүе иде. Җинаять эшләгәнен белсә дә, аңламый иде ул. Аңламый иде. Бер акыл иясе әйткән бит: «Гөнаһ кыла икән — димәк, белми, аңламый...»

Айсбергның аскы өлеше булып галәмәт ныгыган, калыплашкан һәм беркая да язылып куелмаган күз күрмәс законнар, җинаять кодексыннан бик оста качып, кешеләр арасында хөкем сөрә икән — монда нишләмәк кирәк?! Сәлим Сәлмәневич нишләтсен бу дөньяны?!

Гүя, аның аң астындагы дөньясы белән аңында кайнаган тормыш арасында бернинди дә киртәләр юк, бернинди орган да комачауламый. Вөҗдан әллә йоклый, әллә... Юк, юк, бар ул, бар. Аның вөҗданы завхоз булып эшләргә куша аңа, шул ук вөҗдан кара эшләр эшләргә «рөхсәт бирә». Тик менә аңа җәза бирергә генә никтер ашыкмый ул. Җан газабын, вөҗдан газабын гына никтер «татымый» Сәлим Сәлмәневич. Кайчан да булса килергә тиештер бит инде ул... Үзеңә булмаса — балаларыңа килә, дөрес бәя бирмисең икән, белсәң дә аңламыйсың икән... Гаепләп буламы андый кешене?

Сәлим Сәлмәневич гаепләме соң? Аңарда юк бит ул! Салынмаган! Ә болай карап торуга начар кешегә охшамаган үзе. Хатыны, улы бар. Кешеләр белән аралаша белә, дуслары арасында абруе һәрвакыт булды. Надан дип тә әйтмәссең аны, китаплар да укымый түгел. Кешеләр уйлап чыгарган законнар барысы да — илнеке дә, җинаятьчеләрнеке дә. Җинаятьчеләр законы буенча яшәүне туктата алмаган закон гаделлек урнаштыра ала микән?..

Сәлим Сәлмәневич уйлап чыгармаган ул законнарның берсен дә. Дөньяны да, кешеләрне дә ул ясамаган. Шуңа күрә ул, кесәсендә партбилеты булган килеш, нинди генә эшкә тотынмасын, Алладан мәрхәмәт

өмет итә. Тик аның беркайчан да үзенә, үзәгендәге аң җитмәслек коточкыч чыганакка мөрәҗәгать иткәне булмады. Күңел тирәнлегеннән берәр аваз ишетелмәсме дип һичкайчан колак салмады, бермәлгә генә булса да тынып, үзенең вөҗүденнән ниндидер кайтавазны ишетергә теләмәде.

Чынлап та, шәһәрдәге фатирның эче шактый җыйнаксызланган иде. Шулай да өерелешеп аракы эчеп яткан күренеш эзләре күзгә чалынмады.

Ренат өйдә түгел иде.

Техникумга барып кызыксынгач эченә бераз җылы йөгерде — документларын тапшырган. Тик менә кайда йөри икән соң бу шакал? Аңсы өйдә ятмас инде ул ятуын. Тик шулай да үзен күрсәң җан тынычрак булыр иде. Болай бит шайтан белсен нинди юлда йөргәнен.

Ике тәүлек буена улын зарыгып көткәннән соң Сәлим милициягә шылтыратты. Малаенның милициядә түгеллеге бер яктан куанычлы булса да, икенче яктан күңелендә шом һәм курку бермә-бер артты. Дус-ишләренең адресларын да белми шул, әти-әнисенә беркайчан әйткәне дә булмады — кемнәр белән аралаша, кемдә кунадыр. Берәр җирдә үтереп ташладылар микән үзен? Аллам сакласын, дип кат-кат кабатлады Сәлим. Моргка шалтыратыргамы әллә? Юк инде, анда ук шылтыратмыйм әле.

Өченче көнне Ренат, авыр эштән кайткан кебек әвеш-тәвеш килеп, бусагада пәйда булды. Хәйран исерек, күз төбе шәмәхәләнеп янып тора.

— О-о-о-о, батя,— диде ул һәм елмаерга тырышты, әмма авызны фәкать бер якка чалышайта гына алды, чөнки иреннәрен дә сугып күперткәннәр иде.

Улының кыяфәте нинди булуга карамастан, аның исән-сау килеш өйгә кайтып керүе, ни дисәң дә, шатлык иде. Эчендәге шатлыгын улына күрсәтмәскә тырышып, Сәлим ата вазифасын үти башлады:

— Нинди «батя» булыйм мин сиңа? Татарча сөйләш!

— Да ярар инде. Че сразу орать начинаешь?— диде Ренат чыраен сытып һәм залга үтеп диванга гөрселдәп утырды.

Сәлим урындыкны ачу белән эләктереп алып диван каршына шапылдатып куйды һәм, хөкемдар позасын алырга тырышып, килеп утырды. Сораулар күп иде. Каты итеп ачуланасы да бар. Ничекләр итеп тәэсир итәргә бу башсыз маңка малайга, ә?

— Кайда йөрдең?— диде ул.

Һәрбер ата, һәрбер ана баласы озак югалып торгач, бу сорауны бирми калмыйлар.

Ренат, шешенеп беткән чыраена газап йөгертеп, әтисенекенә охшаган бәләкәй күзләрен чекрәйтеп карап торды:

— Правданы әйтимме?..

— Дөресен әйт!

— Подружкада булдым мин... Аның родители ялда, Сочида. Шуларда яшәп яттык.

— Тфү, шакшы! Оялмыйча миңа шуны сөйләп утырасыңмы!— диде Сәлим, улының ачыктан-ачык сөйләвенә никтер ярсып.

— Үзең дөресен әйтергә кушасың бит,— диде Ренат, күптән су күрмәгән, укмашып-майланып беткән саргылт чәчләрен артка таба сыпырган булып.

— Кыяфәтеңне көзгедән кара! Подружка! Күлмәгең катып беткән, чалбарың бөгәрләнгән... Подружкаң шәп икән!

— Она же не жена мне,— диде Ренат борын астыннан.— Спать хочу я.

— Менә бирермен мин сиңа спать! Кайда сугыштың тагын?

— А-а-а, кичә туган көндә... Пап, ну все нормально же. Ну че ты...— Ренат диванга сузылып ятты.

Сәлим түзмәде, сикереп торып, гәүдәгә дә, тазалыкка да шактый булган улын җилтерәтеп торгызырга көч тапты:

— Тор, бәреп үтерәм алайса!

— Пап, ты че...— диде Ренат әтисеннән бигүк өркемичә.

— Ни житми сиңа?— дип акырды Сәлим улының битенә.— Ник безгә тынгылык бирмисең, син, ә? Унжиде яшь кенә бит әле сиңа. Ананның чәчләре агарып бетте бит инде синең аркада. Мин әнә ничек картайдым! Ни телисең — шуны ашыйсың, ни киергә телисең — шуны алып кигертәбез. Акча күпме кирәк, биреп бардык...

— Әйе, мотоцикл алдыгыз и сразу взяли да продали,— диде Ренат иреннәрен турсайтып.

— Мыгырдап утырма!— дип ярсып кычкырды Сәлим.— Үзең исерек баштан җүләр сыман ары-бире чабып йөрдең. Саттым шул! Ату берәр баганага бәрелеп үләр идең. Син һәрвакыт башка кеше балаларыннан аерылып тордың — киемең белән дә...

Сәлимнең тамагына төер тыгылды. Елыйсы килде аның, тик елый алмады. Елыйсы урынга ул шап итеп бердәнбер улының башына уч төбе белән сукты.

— Ладно, тебе драться! Че сугасың!— дип мөгрәде Ренат, тукмак кадәр борынының тишекләрен киңәйтеп.

— Менә бирермен мин сиңа «че сугасың»! Мин сине әле бәреп үтерәчәкмен! Төрмә белән тәмамланачак бу синең гулянкаларың.

— Да ла-а-адно те,— дип мөгрәде инде мең тапкыр кабатланган бу нотыклардан тәмам җаны бизгән малай.

— Бирермен «ладно», бирермен «ладно»,— дип кабатлады Сәлим, тешләрен кысып.— Әнә, Тәлгатьнең малае Марат синнән ике яшькә генә олы. Нинди акыллы! Мединститутта укый. Эчми дә, тартмый да ди.

— Ха, мединститутка кертсәң, мин дә укыр идем.

Сәлим, чыраен җыерып, соңгы көннәрдә таушалып беткән яшүсмергә карады:

— И-и-и, утырган була бит... мединститутта укый алыр идеңме соң син?! Әле менә күз күрер, техникумда укый алырсыңмы икән?..

— Ничего-о, укырмын. Пап, я спать хочу.— Ренат тагын диванга сузылды.

Сәлим нотык укып туйган иде инде. Ачуланып утыруның мәгънәсе юклыгы күренеп тора лабаса. Аннары, Маратны исенә төшереп, Казанга барырга тиешлеген искәртеп куйды, диванга бөгәрләнеп яткан малаена озак кына карап торды — ул сабыйларча йокыга талган иде инде.

Их, улым, улым! Ни дисәң дә үземнең улым бит. Шундук тынычландыра торган уйлар да килә башлады. Укый башлагач тәртипләнәмәсме. Лесхозга алып кайтып мунча кертергә кирәк булыр моны. Оекбашлары да тишек икән. Подружкада... Муены катып беткән. Әллә битен дә юмый инде бу. Подружкада. Тфү! Алай бөтенләй үк адәм актыгы түгел лә аның бердәнбер малае... Яшь вакытта малайлар шук була инде алар. Милициягә күп кеше эләгә инде анысы. Менә Марат андый түгел бит . Марат, Марат. Күңел тагын атлыгып куйды. Теге малайны табарга кирәк, бит. Кем әле ул? Фәиз. Әйе, Фәиз.

## 21

Марат инде узган атнада ук стройотрядтан кайткан иде. Эшне срогыннан өч атна алдан тәмамлаганнар иде. Поселокка, әти-әнисе янына, атна-ун көн Казанда ял иткәч кайтырга ниятләде. Әлфияне бик сагынган иде ул. Әлфия дә аны зарыгып көткән. Фатир хуҗабикәсенең Зеленодольскидагы сеңлесенә утырмага китүе егет белән кыз өчен зур бүләк булды. Аларга беркем, бернәрсә комачауламый иде.

Алар кинотеатрдан кайтып чәй эчәргә утырдылар.

— Бүген танцыга бармыйбыз, яме,— диде Әлфия.

Марат аның сылу йөзеннән мөкиббән китеп торды. Коңгырт күзләр, куе чәч толымнары, алсу иреннәр, томшык кебек нәни борын — шундый чибәр кызның аныкы булуына Марат кайвакыт икеләнеп тә куя иде.

— Ярар, бармабыз,— диде ул һәм үрелеп кызны битеннән үбеп алды.— Нык сагындыңмы мине?

— Мең тапкыр әйттем бит инде, нык сагындым.

Әлфия дә беркавым Маратка карап торды, аның бөдрә кара чәчләренә никтер нәни бармакларын батырды һәм аны башыннан сыпыргандай итте.

— Син гел Казанда гына булдыңмы?

— Ике тапкыр Т.га кайтып килдем. Хатта язган идем бит, онытгыңмыни?

— Әйе шул. Баш буталды бөтенләй.

Әлфия стройотрядтан котылыр өчен «әнисе авырый» дип әтисеннән ялган белешмә ясаткан иде, шулай итеп, кызның җәе юкны бушка аударып, Маратны сагынып үтте.

— Синең белән Молдавиягә булса, мин стройотряд белән генә түгел, төрмә эшелоны белән дә барыр идем,— дип, пырхылдап көлеп җибәрде кыз.

— Декабрист хатыны кебекме?— дип, Марат аңа кушылып көлә башлады.

— Төзелештә эшләргә мин нәрсә... кәҗүнниме әллә?

Икесе дә рәхәтләнеп көлделәр. Аларга үзләренең юморы кызык булып тоелуның сәбәбе — аларның кавышуы иде. Бергә булу, уртак бәхетнең чәчәк атуы аларны шатлыклы, бәхетле итте.

— Син монда миннән башка егетләр белән чуалмадыңмы соң?

Әлфия буш чынаягын читкә куеп текәлеп карады:

— Юк! Миңа синнән башка беркем дә кирәк түгел. Тулай торакта шуңа күрә дә мине иң кыргый кыз дип саныйлар. Син үзең анда...— Ул, күзләрен чекрәйтеп, бармак янады:— Молдавиядә... шухрый-мухрый килеп йөрмәдең микән? Ә?

— Мин гел сине генә уйлап йөрдем. Көне-төне.

— Шулай микән, шулай микән...

Алар инде үбешергә генә җыенганнар иде, ишек кыңгыравы зеңгелдәде.

Марат аскы иренен күпертте:

— Хуҗа хатын кайтты микән әллә? Киләсе атнада гына кайтам дигән иде.

— Ник, аның үзенең ачкычы бардыр бит.

— Әйе шул.

Марат барып ишекне ачты һәм бер адым артка чигәргә мәҗбүр булды. Ишек төбендә ап-ак чырайлы, шыр сөяктән генә торган егет... егет дип әйтеп булмас, малай басып тора иде.

Өрәккә охшаган бу үсмер егет кай төше беләндер карт кешене дә хәтерләтә иде, кыскасы, чандыр гәүдәле, төссез күзле бу кешедә, укый белсәң, бөтен нәрсә бар иде, җыелма образ иде бу.

— Исәнмесез!— диде ул гасаби киеренкелек кичерүчеләргә хас кысынкы йомшак тавыш белән.

— Исәнмесез,— диде Марат, бу кеше ялгышып шылтыратадыр дигән өмет белән.

Килүче кеше чибәр, таза егеткә никтер озак кына карап торды, әйтерсең лә, аның буй-төсенә, йөзенә, кыяфәтенә соклана һәм көнләшә иде. Әле таныш булмасалар да, өрәкнең күңелендә Маратны өнәп бетермәү, хатта нинди дер нәфрәт тә бар иде шикелле.

— Син Маратмы?— диде ул, төссез күзләре белән аны әллә күреп, әллә күрмичә.

— Марат.

— Ә син Зәбиргә охшагансың,— диде ишек катындагы бәндә көтмәгәндә.

Марат моны авыру кешедер дип уйлады һәм таләпчән тавыш белән баскыч мәйданын яңгыратты:

— Сезгә кем кирәк?
— Син кирәк,— диде өрәк һәм кесәләрен капшый башлады, ул нидер эзләде.— Мин — Фәиз.— Ниһаять, ул кесәсеннән бөгәрләнеп беткән егерме биш сумлык кәгазь акча чыгарды.— Син сәерсенәсен... Әтиеңнән күп сәлам. Мин сезнең поселогыгызда булган идем. Тәлгать абыйдан егерме биш сум алып тордым әҗәткә. Синең адресыңны бирде. Менә, керттем.
Марат акчаны алырга ашыкмады, шикләнеп сорап куйды:
— Әтием бит стройотрядтан тагын ике атна узгач кайтасымны белә иде...
— Миңа ул турыда бер сүз дә әйтмәде,— диде Фәиз һәм кипшергән иреннәрен юешләр өчен ялап куйды. Аның хәле беткән иде.— Мин тизрәк... ул-бу була калганчы... бурычымны сиңа кертеп бирергә булдым.
Марат чакырылмаган кунакның куркыныч зат түгел икәненә ышанды һәм, ничектер, акчаны алып, шундук аның белән хушлашасы итмәде. Бу йончыган егет аңа бик кызганыч тоелды.
— Уз әйдә өйгә. Син ерак юл кешесенә охшагансың.
Фәиз, куркып, ни китәргә, ни керергә батырчылык итми торды. Ул әле кулындагы акчасына, әле Маратка карап куйды, аннары үрелеп фатир эченә күз салды. Һәм фатир эченә атларга үзендә кыюлык тапты.
Әлфия инде залда журнал актарып утыра иде.
— Исәнмесез!— диде Фәиз кызга.
Әлфия кунакны күргәч аптырап калды, сәләмә киемле, таушалып беткән егетне ул кем дип тә уйларга белмәде.
— Исәнмесез,— дип җавап бирде ул һәм журналына текәлде.
— Утыр,— дип Марат диванга ымлады.
Фәиз саклык белән генә диванга килеп утырды һәм як-ягына карап фатир эчен күзәтте.
— Әтидән сәлам алып килдең, димәк?— диде Марат.
Фәиз:
— Әйе,— диде һәм кискен хәрәкәт белән кулындагы егерме бишлекне сузды.— Менә егерме биш сум.— Һәм үзенең кем икәнлеген, поселокка ничек барып чыкканын сөйләргә үзен бурычлы дип санады.— Мин... нык авырдым. Анда больницада яттым. Акчам юк иде. Минем анда беркемем дә юк. Гомумән, беркемем дә юк минем... Әтиең машина ремонтлый иде. Барып акча сорадым. Ул бирде. Рәхмәт...
Ул үзен, елганы ерып чыгып, ярга яткан сыман хис итте. Аңлата алды бугай. Карап торды: башта Маратка, аннары Әлфиягә. Шикләнмиләр кебек. Ышандылар.
Марат акчаны алды:
— Рәхмәт. Әти нихәлдә соң анда?
— Беркөе,— дип аны-моны уйламый җавап бирде Фәиз.
— Чәй эчәсеңме?— диде Марат.
Фәизнең ашыйсы да, эчәсе дә килә иде.
— Эчәм,— диде ул, үзенә карата яхшы мөнәсәбәттән бераз терелә-неп.— Ипи дә бир,— дип өстәп куйды.
Әлфия, журналын куеп, Фәизгә текәлде.
— Әлфия, матурым, капкаларга берәр нәрсә әзерлә инде, зинһар,— дип эндәште аңа Марат.— Бөтен нәрсә шунда, суыткычта. Авыр булмаса, монда журнал өстәленә алып кер, яме.
— Хәзер.— Әлфия хатын-кыз эшенә яраклы булуына яшь кызларга хас горурлык белән ялт итеп кухняга чыгып китте.
Фәизнең кыяфәтеннән курку һәм киеренкелек бераз китте кебек. Марат моны сизеп алды да сорарга булды:
— Нәрсә белән авырдың?
— Истощение,— диде Фәиз, шул сүздән башка бүтән диагноз уйлап чыгара алмаганга.
— Ә-ә-ә, нишләп алай? Ашарга да акчаң юк мәллә?
— Юк.

— Ә бу акчаны кайдан алдың?
— Баржа бушатырга булыштым. Тоз бушаттык. Ардырды бик. Ун сум түләделәр. Атаң биргән акчадан унбиш калган иде. Менә егерме биш итеп керттем.
Марат аптырашта калды.
— Кайдан соң син?
Фәиз авыр сулап куйды һәм мәңгелек җавабын әйтте:
— Детдомнан.
— Хәзер кайда яшисең соң?
— Казанда урнашмакчы булам.
Ул тагын авыр һәм читен итеп сулап куйды. Әлфия тыз-быз ашарга әзерләп йөрде.
Фәиз тончыга-тончыга ашарга тотынды.
— Чәйне бераз көтегез инде, хәзер кайнап чыга,— диде Әлфия.
Марат егерме биш сум акчаны өстәлдән барып алды һәм Фәизгә сузды:
— Мә, берәр кайчан түләрсең әле. Сиңа хәзер акча кирәктер...
Фәиз битарафлык белән башын чайкады:
— Кирәк түгел.
— Ничек инде?! Үзең ашарга да акча юк дисең.
— Миңа бернәрсә дә кирәк түгел. Яшисем дә килми минем.
Әгәр дә ишек бусагасында пәйда булган мизгелдә, чырае ак чакта «яшисем килми» дисә, Марат котсыз калыр иде. Ашаганнан соң бите бераз алсуланып, күзләре җанланып киткәч, бу егетнең яшисем килми дип әйтүе куркыныч булса да, бөтенләй үк котсыз калдырырлык түгел иде. Әмма шулай да аның кичеп чыккысыз хәсрәте барлыгы, ниндидер бәлагә дучар булганлыгы күренеп тора иде. Сәбәбен белмәсә дә, Марат аны иң элек тынычландырырга омтылды:
— Юу-у-ук, син нәрсә, бу дөньядан ваз кичәләр димени? Яшисе дә яшисе әле. Син нәрсә! Чирнең шаукымыннан арына алмыйсың әле син. Тернәкләнеп киткәч яшисе килә башлар.
— Яшәү нигә соң миңа?
— Нәрсә булды болай сиңа?
Фәиз, сискәнеп, аңа карап катты. Аңа вакыты-вакыты белән инде бөтен дөнья беләдер шикелле тоела иде.
— Нәрсә булды...— дип кабатлады ул, нәрсәгә юлыкканын аңына китереп бетерә алмаса да, ниндидер коточкыч хәлгә тарыганын хәтерләп.— Нәрсә булганы билгеле бит инде...— Нинди коточкыч вакыйга булганын барысы да инде беләдер, аның үзенә генә, никтер, ул хакта тулысынча сөйләмиләрдер шикелле сәер, төштә генә була торган тойгылар кичерде ул. Әйтерсең, төш белән өн арасындагы халәт кичерә иде; бу вакытта үзенә буйсынмыйча, кемнеңдер, нәрсәнеңдер боерыгы, ихтыяры буенча йөри, сулый, хәрәкәт итә иде сыман.
— Әйтәсең килмәсә әйтмә,— диде Марат, әңгәмәдәшенең газаплanып ниндидер авыр уй-хисләр кичерүен күреп.— Чәеңне эч, Фәиз.— Акчаны тагын өстәлгә куйды.
Әлфия дә алар янына килеп утырды. Марат Әлфиягә карап торды— кыз аңлады һәм зал уртасындагы өстәл янына барып теге журналны яңадан актара башлады.
Фәиз чәй эчкәннән соң кинәт мәлҗерәп китте, аның башы салынып төште. Марат, куркып, сикереп торды.
Куркуы юкка булган — егет изрәп йоклый иде. Аны диванга сузып салдылар, баш астына мендәр тыктылар, өстенә одеал капладылар.
— Нәсимә апа кайтып керсә...— диде Әлфия хуҗа хатынның кайтуыннан куркып.
Марат бер дә аптырамады:
— Кайгсани. Йокласын инде, ял иткәч китәр. Әйдә магнитофон тыңлыйбыз,— дип, кызны кочаклап йокы бүлмәсенә алып кереп китте.

Фәиз озак йокламады. Бер сәгать чамасы каты итеп йоклаганнан соң ул торып утырды һәм, кайда икәнен аңларга тырышып, чыраен сытты.

— Сәгать ничә?— диде ул Марат белән Әлфиянең үзен күзәтеп торуларын абайлап.

— Биш,— диде Марат, стенадагы сәгатькә карап.

— Иртәнгеме, кичкеме?

— Кичке генә әле. Син бит озак йокламадың.

Фәизнең кыяфәте килеп кергәндәге кебек үк яман түгел иде инде — күзләре генә каяндыр төптән төссезләнеп карадылар.

— Хәзер, каты итеп чәй ясыйм,— диде Әлфия һәм кухняга йөгерде.

— Син бу егерме биш сум акчаны ал. Берәр кайчан кертеп бирерсең әле,— диде Марат һәм акчаны тагын Фәизгә сузды.

Фәиз акчага карап торды да, алып, чалбар кесәсенә тыгып куйды:

— Ярар, алайса, эшли башлагач түләрмен.

Әлфия барысына да чәй ясады һәм үзе дә алар янына утырды.

Фәиз бу юлы кызга игътибар беләнрәк карады.

— Син Казан кызымы?— дип кызыксынды ул.

Әлфия көлемсерәп Маратка карап алды:

— Юк, мин Т. шәһәреннән. Монда укыйм.

Фәиз чынаягын шалтыратып тәлинкәгә куйды:

— Т. шәһәреннәнмени?!

«Мин дә шуннан бит», дип әйтмәкче булды ул, ләкин ниндидер көч аны тыйды, анысын әйтми калды.

— Нәрсәгә гаҗәпләндең?!— диде Әлфия.

Эчтән Фәизне нәрсәдер җилтерәтә башлады, өндәме, төштәме булган теге вакыйга турында әңгәмә кузгатырга аны ниндидер көч этәрергә тотынды.

— Анда ювелирный кибетне басканнар дип ишеткән идем,— диде ул һәм усал итеп кызга карап катты, әйтерсең лә, ул вакыйгада шушы кыз бала гаепле!

Әлфия караңгыланып китте, дулкынлануы хәтта үз-үзен тотышында беленде.

— Булды шул андый хәл,— диде ул һәм урыныннан торып бүлмә буйлап атлады.— Марат, мин өйгә кайтып килим инде тагын. Ничек икән анда хәлләр.

— Ярар, ярар,— диде Марат, аны тынычландырырга теләп,— барыбер мин дә поселокка кайтып килергә тиешмен.— Ул барып Әлфияне иңеннән кочты.— Борчылма син.

Фәиз аларның сүзләренә колак салмады, тагын үз уйларына чумды. Т. шәһәре турында сөйләшәсе килде һаман. Ә ул шәһәр турында сүз ничектер үзеннән-үзе *теге вакыйга* белән бәйле булып чыга. Чәй өстәле янына килеп утырган кыз белән егеткә сөйлисе килде аның әлеге вакыйганы. Ләкин нәрсәдер эчтә комачаулады, ирек бирмәде.

— Ул кибетне ник бастылар икән?— диде ул һәм бу юлы Маратка карап катты.

— Алтын кирәк булган, шуңа басканнар,— диде Марат, сорауның мәгънәсезлегенә аптырап.— Менә, Әлфиянең әтисе бит ул кибетнең директоры.

Бу хәбәр Фәизгә нык тәэсир итте.

— Шулаймыни-и-и?!— дип сузды ул, күзләрен акайтып. Гүя, күптәнге танышын очратты.— Синең әтиеңмени анда директор?!

Әлфия күз яшен сыпырып:

— Әйе,— диде.

Кызны тынычландырыр өчен һәм бу вакыйга турында сөйләшүне туктатырга кирәклекне аңлатырга тырышып, Марат:

— Аларны барыбер тотачаклар,— дип әйтеп куйды һәм чәйнектән чынаякларга чәй өстәп чыкты.

Фәиз шабыр тиргә батты, аның авызы кыйшайды һәм ул, бераз алга иелде дә:
— Ә нишләп син тотарлар дип уйлыйсың?— дип пышылдады.
— Ха, кибет баскан бандитларны бездә тотмый калганнары юк әле.
Фәиз ялт итеп Әлфиягә борылды:
— Син дә шулай уйлыйсыңмыни?
— Әлбәттә, тотачаклар,— диде Әлфия, «башкача булуы мөмкин түгел» дигән ышаныч белән.
Фәиз кинәт аларны куралмый башлады. Аларны барыбер тотачаклар дип әйтүләре аны ничектер кимсетте, Зәбирнең юкка чыгуын белмәгән килеш җайлы һәм тыныч кына «тотачаклар аларны» дип әйтүләре Фәизнең үзенә карата ниндидер бер агрессия сыман кабул ителде. Нервылары артык нык киеренкелектән, кыз белән егетнең әйткәнен ул тиешенчә аңламады. Аның көтмәгәндә туган нәфрәте кибет директорының «каравылчы юк» дип әйтүен хәтерләтте.
Ул сикереп торды һәм болай да кәефе тәмам кырылган Әлфиягә акырды:
— Ахмак синең әтиең! Үзе гаепле!
Кыз белән егет сикереп тордылар.
— Тынычлан!— диде Марат үзен тыеп, әмма шактый усал итеп.
— Рәхмәт!— дип кычкырды Фәиз аның битенә төрәп диярлек. Шуннан соң ул кызу-кызу атлап ишек катына юнәлде.
Марат аның артыннан иярде:
— Ник психланасың син, аңламыйм?!
Фәиз кәкрәеп каткан ботинкаларын кия алмый җәфаланды. Ниһаять, ул аларны киде һәм тыныч кына:
— Син аның әтисен юньле кеше дип beләсеңме әллә?— диде.
Марат кыза башлаган иде дә, бу психопатның ишек катында инде аяк киемен киеп куюын күргәч, тынычланды.
— Син аның әтисен белмисең бит,— диде ул,— нишләп син кеше турында алай фикер йөртәсең?
— Кибет директоры бит ул! Кайда укый бу кыз?
— Финанс-экономика институтында.
Фәиз зур мәсьәләне чишкән сыман бармагын өскә күтәрде:
— Во! Әтисе директор булмаса, финанс-экономикада укыр идеме ул?
— Ярар, анысы синең эш түгел инде!— Марат бу истериктан туя башлады.— Син бар, саф һавага чык әле.
Фәиз чыгарга ашыкмады, Маратка якынрак килеп:
— Син үзең дә...— диде һәм туктап калды.
— Нәрсә мин үзем дә...
Фәиз башкачарак әйтергә булды:
— Синең әтиең минем әниемә операция ясаган.
— Шуннан?
— Минем әни операция өстәлендә үлгән.— Фәиз күңелендә нәфрәт кенә түгел, өйгә кертеп чәйләр эчерткән, йоклап алырга мөмкинлек биргән өчен рәхмәт әйтү теләге дә бар иде. Әмма гасаби киеренкелек нәтиҗәсе буларак кайнаган нәфрәт өстенлек алып, аның рәхмәте каргыш кебек яңгырады:— Рәхмәт!!
Шуннан соң ул ишек биген ачалмый интекте.
Марат ачарга булышты, Фәиз ишекне атып чыгып китте.
Марат белән Әлфия, өнсез калып, зал уртасында басып торганда ишек кыңгыравы зеңгелдәде. Марат барып ачты. Еш-еш сулап, тагын ап-ак булып Фәиз басып тора иде.
— Гафу ит!— диде ул, көчкә сулыш алып.
Марат аның гафу ит дигәненә сөенде һәм елмаеп:
— Ярар ла,— диде.
Ләкин ул дөрес аңламаган, Фәиз гафу үтенергә килмәгән икән. Ул егерме биш сумны бөгәрләп Маратның битенә ыргытты:

— Мә! Мин хәерче түгел синнән акча алырга!

Марат аның күздән югалганын сизми дә калды. Куып җитеп кирәген бирергә, кыйнарга, типкәләргә исәбе дә бар иде, әлбәттә, көче җитәр иде, әмма ярсуын тыеп, аяк астында яткан кәгазь акчага карап, ишек янагына сөялеп калды.

## 22

Икенче көнне иртүк Әлфияне Т. шәһәренә алып баручы автобуска утыртып озаткач, Марат кайтып янә йокларга ятты. Ике сәгать чамасы черем иткәч ишек кыңгыравы зеңгелдәде. Ачмаска булды. Нәсимә апа кайтса, аның ачкычы бар, ә бергә укучы курсташларыннан институтта да, стройотрядта да туйган! Кыңгырау үҗәтлек белән яңгырады. Кичәге сәер зат түгел микән? Ул булса, бигрәк тә кирәге юк. Ишекне дөбердәтә үк башладылар. Болай бит ишекне ватулары да бар. Ачарга булды.

Ялагай елмаю һәм ясалма ягымлылык белән, шул ук вакытта үзен бераз гаепле дә сизгән кебек кыланып, йокылы-уяулы егеткә Сәлим дәште:

— Исәнме, Марат!

— Исәнмесез...

Марат бу кешене бик яхшы белә, әтисе белән аның мөнәсәбәтләре дә мәгълүм иде. Ул аптырашта калды — ник килде икән бу ямьсез кеше монда?

— Үзең генәме? — диде Сәлим, чакыруны да көтмичә фатир эченә узып.

— Үзем генә, — диде Марат, канәгатьсезлеген тавышында яшермичә.

— Син гафу ит, Марат, минем сиңа кичектермәс эшем бар.

— Әйдәгез, узыгыз залга, — диде Марат, эссе булса да күн курка киеп, шабыр тиргә баткан чакырылмаган кунакка бигүк ягымлы карамыйча. — Курткагызны салып куегыз инде.

Сәлим уңайсызланган булып елмайды:

— Һи, әйе шул, — дип курткасын салып элде.

— Утырыгыз, — дип диванга күрсәтте Марат.

Әмма Сәлим, никтер, аның ымлавына игътибар бирмәде, өстәл янындагы урындыкка барып утырды. Марат аның каршысына урындык алып килеп урнашырга мәҗбүр булды.

— Уф, эссе бүген, — дигән булды Сәлим.

Марат аның ни йомыш белән килгәнен ишетергә зар булып көтте, ләкин теге ашыкмады.

— Тыңлыйм, Сәлим...

— Сәлмәневич, — дип өстәде кунак.

— Тыңлыйм, Сәлим Сәлмәневич.

Сәлим Сәлмәневич тамак кырып куйды, мондый кешеләргә хас булмаган дулкынлану белән сүз башлады:

— Сиңа әҗәтен түләргә бер үсмер егет килергә тиеш. Исеме Фәиз аның. Минем сиңа үтенечем бар, син аның кайда торуын, кайда эшкә урнашуын бел, зинһар. Кыскасы, аны күздән югалтма.

— Минем беркемгә дә бурычка акча биргәнем юк, — дип белмәмешкә салышты Марат.

— Әтиең Тәлгать Назыймович биргән аңа. Сиңа кертергә кушкан. Атаң шулай кушкан, аңладыңмы?

— Аңладым. Кем соң ул?

— Ул бик кирәк кеше. Ул сиңа да кирәк булачак. Әлегә мин сиңа әйтә алмыйм.

— Ул монда кереп чыкты бит инде.

Сәлимнең шомырт кебек вак күзләре маңгаена менде:

— Ничек инде?!

— Әйе, егерме биш сум акча кертте ул миңа, мин алмадым, чөнки аның ашарга да акчасы юк иде.

— Шул арада... Акча табып кертергә дә өлгергән... Кайда урнашканын әйтмәдеме?

— Юк.

— Тагын киләчәкме соң ул синең яныңа?

— Белмим. Тузынып чыгып китте ул. Акчасы булгач, кертеп бирергә тиеш, намуслы егеткә охшаган.

Сәлим өзгәләнеп ялына башлады:

— Марат, энекәш, зинһар белеш адресын да, кайда эшләвен дә, яме!

Маратта зур кызыксыну уянды:

— Кем соң ул? Нигә кирәк ул сезгә?

Сәлим, чыраен сытып, башын як-якка боргалады, аннары Маратка текәлеп карап торды. Дөресен әйтсәм, киресенчә, миңа каршы позицияне алуы бар бу Тәлгать малаеның, дип уйлады Сәлим. «Урман хуҗалыгыннан әйбер урлаган», дисәң шулай ук миңа ачу итеп Фәиз яклы булуы бар моның. Әнә бит ул ничек карый. Яратмый бит ул Сәлимне. Ничек инде Тәлгать Назыймовичның улы Сәлим Сәлмәневичне яратсын?! Шулай да бер фикергә килде Сәлим.

— Синең атаңның язмышы хәл ителә торган көннәр бу. Миңа да куркыныч яный, атаңа да!

Маратның исенә төште: Фәизнең әнисе операция вакытында үлгән... Ә Сәлимгә ярдәм итү әтигә зыян китерү булмасмы?! Ул Сәлимгә диккать белән карап торды.

— Ярар, килсә координатларын белешермен,— диде ул.

— Син әтиеңә әйтми тор. Аның йөрәге дә авыртып тора, без синең белән икәү ничек тә хәл итәрбез бу эшне. Ул малайны кичекмәстән табарга кирәк.

— Ярар.

Ишек төбендә дә, подъездга чыккач та Сәлим әле һаман ялынды:

— Срочно табарга кирәк аны!

Марат, ярдәм итәргә вәгъдә биреп, шактый авыр халәттә калды. Кичә сәер малайның тузынып чыгып китүе, бүген әтисенең дошманы килеп ялваруы — бөтенесе, чыннан да, бер вакыйганың ике өлеше кебек тоелды. Бу кешегә ышанып буламы соң? Әтисенә каршы берәр матавык чыгарырга йөрми микән? Нәкъ әтисенә килгән уйлар Маратка да тынгылык бирмәде. Фәиз килсә, аның үзе белән ничек тә ачыктан-ачык сөйләшү мәслихәт. Сәлим ул малайны, бәлки, берәр кыңгыр эше өчен эзәрлеклидер. Ниндидер зур кызыксынуы бар Сәлимнең ул егеттә — кыяфәтенә чыккан бит. Ә Фәизнең кыяфәте... Юк, юк, монда эшләр башкачарактыр, Сәлим Сәлмәневич әйткәнчә түгелдер. Чынлап та, әтисен борчымаска, бу турыда сүз катмаска кирәк. Туктале, әтисе күбрәк беләдер бәлки... Ник фаразлар белән башны алдан юкка катырырга! Әҗәткә акча биргән икән, димәк тикмәгә түгел, әңгәмә булгандыр, танышлардыр, ниһаять. Поселокка кайткач ачыкланыр әле барсы да. Иртәгә үк метеор белән кайтып китәргә кирәк.

## 23

Казан да Фәизне җылы каршыламады. Татарстан башкаласы бигүк сагынып көтеп тормаган икән аны. Төннәрне вокзалда уздырып, атна буе эш белешеп, эзләнеп йөрде. Тегендә кабул итмәделәр, монда үзе теләмәде — шулай итеп, вакыт үтә торды.

Ниһаять, Горбунов исемендәге авиация берләшмәсенә калайчылар цехына кабул иттеләр. Бүлмәләр җитмәү сәбәпле, вакытлыча тулай торакның кызыл почмагында раскладушка куярга вәгъдә бирделәр. Әмма Фәиз анда яшәргә теләмәде. Урынны кызыл почмакта биргәнгә түгел,

гомумән, умарта күчедәй кайнаган тулай тор актан читтәрәк буласы килде аның. Чөнки аулаграк урын кирәк иде аңа — *теге вакыйганы* хәтердә кузгатып, аны җентекләп анализлау ихтыяҗы туды күңелендә.

Кремль итәгендәге иске агач йортлар тезелеп киткән тирәләрдә йөри торгач, Федосеевская урамындагы әле бигүк карт булмаган, алтмышлардан узган Хәтимә әби аны фатирга кертте. Шактый киң, якты бүлмә саналган чардакны бирде ул аңа. Айга ун сум түләргә сөйләште Фәиз. Тыныч ишегалды, Казанка елгасы якын булганга бу фатирны ошатып, шундук яши дә башлады. Ашарга йөрергә якында гына, Ленин урамында, арзан бәяле ашханә бар. Әлбәттә, эшкә барып йөрергә ераграк, аның каруы, уйланырга, хәтердә, күңелдә казынырга монда шартлар уңай иде.

Яшәргә урын бар, эштә әйбәт бригадага эләкте, ләкин дөньяның яме югалган иде инде. Коточкыч стресстан соң ничек хәл кергәндер, моңа ул үзе дә гаҗәпләнде. Аңарда унсигез яшьлек егет психикасы түгел иде инде хәзер. Нәрсәдер кискен үзгәрде, кире кайтарып булмаслык ниндидер фаҗигага юлыкты. Аң гына әле моны ничектер кабул итеп бетерми, әле һаман ышанып җитмәү яши. Төштә түгел, өндә булды ул хәл. Аны сөртеп тә, юып та, җимереп тә, шартлатып та булмый.

Кайвакыт күңел, үзеннән-үзе дәртләнеп, хәл алып куйгандай була һәм дә шундый мизгелләрдә, кояшлы көнгә тагын да ныграк яктылык өстәп, каршысына җан дусты Зәбир килеп чыгар төсле тоела. Ул никтер урамда очрар кебек иде.

Әмма көннәр бер-бер артлы үтә торды, ә Зәбир — юк!

Ул инде хәзер алтын урлаганы өчен үзен тотып төрмәгә утыртуларыннан бөтенләй курыкмый. Каравылчының маңгаен кирпеч белән сугып ярган өчен дә үзен нык битәрләми. Тора-бара, вакыйганың чын-чынлап булганына ул тәмам инана башлагач, дустын коткармаган өчен дөньяда кеше уйлап чыгарган барлык җәзаларны үзенә алырга әзерләнде. Җәза сорый иде күңел. Җавап бирү ихтыяҗы бар иде эчтә, үзәктә. Күңелме ул, нәрсә ул, кем ул анда эчтә, үзәктә, шайтан белсен!

Еш, бик еш, бигрәк тә эштән соң, иске йортның сөрсегән чардагында ялгыз утырганда, ул кабат-кабат шул коточкыч вакыйганы капшап, һәр детальне, һәр мизгелне җентекләп барларга тырыша иде. Сазлы су өстеннән калкып торган бөдрә чәчле баш, акайган күзләр, янәшәдәге куак. Зәбир баткан урында күбекләр генә йөзеп йөри!.. Нишләп алай килеп чыкты соң?! Югыйсә кулны ныграк та сузып булгандыр бит?! Шушы сорауга ул күп еллар үзендә җавап эзләр! Әле хәзер, шушы сорауга җиткәч, ул бутала һәм тагын үзендә-үзе адашып бимазалана иде.

Яшь кеше буларак, аның психикасы әлегә тотрыклы иде. Депрессияләр, кичергән стрессның нәтиҗәсе буларак, вөҗүдтә кискен үзгәрешләр чамаланса да, җандагы җимергеч көчләр әлегә яшь организмны тәгаен авызлыклый алмадылар. Бу вакытта Фәиздә яшәргә омтылыш җитәрлек сакланган иде әле. Көн саен килеп кулга алуларын, төрмәгә ябуларын битараф рәвештә көтеп йөргәннән соң акрынлап аның халәте үзгәрде, төрмә турында ул уйламый башлады. Гәрчә күңелдә җәза теләге яшәп ятса да.

Заводта ул онытылырга тырышып, хәтта үзеннән-үзе качкан сыман ярсып эшләде. Тырышты, тырмашты. Шулай да халәт бик үзгәрүчәнгә әйләнде — йә күтәренке, йә бөтенләй түбән. Әйтерсең лә, *теге вакыйга*, онытылмасын өчен, вакыт-вакыт килеп китә. Онытылмый, онытылмый, онытылмый!

Бик онытылыр идең дә... Булмый шул!

Әмма яшәргә дә кирәк! Синең гомереңне кем яшәр, кеше?! Синең гөнаһларыңны, синең уй-кичерешләреңне, бирәсе җавапларыңны, түлисе бурычларыңны синнән башка кем күтәреп йөрер бу дөнья буйлап?! Син яшәмичә, әлеге авыр гомереңне кем яшәр?! Синең бүләгенме, җәзаңмы ул кыска гына гомер, әйтүе кыен. Ничек кенә булмасын, яшәргә кирәк!

Фәиз, бәлки институтка керермен дип, китаплар җыйнады. Ләкин китаплар укып, мәсьәләләр чишеп утырырга да үзендә түземлек тапмады. Ник алайдыр, институтка хәзерләнү аның өчен бик авыр мәшәкать булды, бәлки керә дә алыр, мөгаен, керә алыр иде. Дүрт имтиханны бирү аның хәле җитәрлек нәрсә, әмма мисаллар, сочинениелар белән шөгыльләнергә ул үзен мәҗбүр итә алмады. Баш бөтенләй бүтән уй-кичерешләр белән мәшгуль булды.

Ул үзендә җәяү йөрү ихтыяҗы тоя башлады. Күрәсең, хәрәкәт кан йөрешен яхшыртадыр, газаплы уйлардан да күпмедер дәрәҗәдә арындырадыр — ул хәтта үзенең бигүк зур булмаган куышында да ары-бире йөрергә гадәтләнеп китте.

Зәбир турында, кибет басуы, каравылчының маңгаена кирпеч белән бәрүе, җан дустын коткара алмавы турында аның кемгә дә булса сөйлисе килә башлады. Шул ук вакытта: «Ярамый!» дип аны кемдер, нәрсәдер кисәтеп тә торды. Шулай итеп, аң астындагы көч белән аңдагы ниндидер көчләр арасында берөзлексез көрәш башланды.

Яшь кеше булса да, андый кайгыны берүзенә күтәреп йөрү гаять авыр иде. Ул үзенә-үзе «бикләнде», дус-ишләре дә барлыкка килмәде аның; кызларга исә күңеле тартмады түгел, ул алардан курыкты. Ул, гомумән, кешеләрдән курыкты, кайвакыт хәтта алардан хайвани курку белән курка башлады.

Йортның хуҗасы Хәтимә әбинең күпме аралашасы килде аның белән, тик булдыра алмады. Ялгыз карчыкка кайвакыт сөйләшеп утырырга кеше кирәк иде, квартирантының иптәш, әңгәмәдәш булмавы карчыкның эчен пошырды. Егетнең, эштән кайтканнан соң, йә Казанка буенда йөрүенә, йә бүлмәсендә бикләнеп утыруына әби сәерсенеп карады, кызлар белән йөрмәвенә дә гаҗәпләнде, шул ук вакытта аның кызлар белән йөрмәве, әлбәттә, яхшырак та, чөнки теләсә нинди марҗаны ташып, чардакны пычратып бетергән квартирантлары байтак булды инде! Туйган андыйлардан!

Хәтимә әби берни сорашмады, төпченмәде. Ә Фәизнең исә әбигә сөйлисе килгән вакытлары күп булды! Хәтта бер тапкыр, төнлә уятып, йолдызлы Кремль итәгендә яшәсә дә, көненә биш тапкыр намаз укучы әбигә үзенең язмышын, нинди вакыйгага дучар булуын сөйләргә ниятләде. «Ярамый!» — дип боердылар тагын эчтән. Гүя, эчтә кемдерме, нәрсәдерме аны кайгысыннан арынырдип курка иде.

Сөйләмәскә, төенне чишмәскә куштылар эчтән. Чишелерлек микән соң ул төен?!

Эштә бригада мастеры гына эчне пошырды. Төпченеп, тәмам теңкәгә тия бит. Килә дә:

— Синең ниндидер проблемаң бар, ахрысы? — дип, котсыз калган Фәизнең күзләренә текәлә.

— Юк, юк, — ди Фәиз, күзләрен кызыксынучан мастердан яшереп.

Мастер кырык биш яшьтәге урыс Виктор Петрович Некрасов егерме ел шушы заводта, бер үк цехта эшләп абруй казанган кеше иде. Проблемалар турында сорашуы аның кешегә ярдәм итү ниятеннән түгел, бригада әгъзасының күңел серләрен мәгълүм кылырга теләүдән иде. Гадел житәкче дип танылса да, аңардан файда күрүче булмады. Күрәсең, зыяны тимәгәнгә әйбәт дип әйтәләрдер.

Тырышып-тырмашып эшләсә дә, Фәиз ясаган детальләр камиллектән шактый ерак тордылар. Аның эчке киеренкелеге эшчәнлегендә дә чагылды, дөресрәге, эшнең нәтиҗәсендә. Шуңа күрә аны төрле эшкә куеп, тегендә-монда җибәреп, өлкәнрәк слесарьлар өнәмәгән вазифаларны тапшырып йөдәттеләр. «Кара» эштән арынган чакларда гына ясый башлады ул заказлы детальләрне. Виктор Петрович детдом «татарчоныгын» өнәмәсә дә, әйткән һәр сүзне тыңлап, чабып йөрүче берәү кирәк булганга күрә аны күпсенмичә бригадасында тотты.

Верстагында деталь игәүләп маташканда бер тапкыр Фәиз янына Некрасов килеп басты. Фәиз каушады. Игәве кыек-мыек йөри башлады. Мастер килеп баскач ул гел каушый иде.

— Әйдә минем бүлмәгә, бер утырып тартабыз,— диде Виктор Петрович.

Фәиз курка калды:

— Ник?

— Ничек инде «ник»? Тартабыз... Сөйләшеп утырырбыз.

Цехта теләсә кемгә сүзе үткән мастерның үз бригадасында аерым бер шәхес булып башкалардан читләшеп йөрүче барлыгы белән барыбер килешеп бетәсе килмәде. Бер утырып ачыктан-ачык сөйләшергә күптән җыенып йөрде ул.

Мастер бүлмәсенә кергәч Фәиз, булачак әңгәмәдән куркып, әйтеп куйды:

— Минем анда ясыйсы детальләрем күп. Бүген җитешергә кирәк.

Виктор Степанович сәерсенеп карап торды да кыршылып беткән урындыкка утырды:

— Җитешерсең. Мин бит синең мастерың. Утыр.

Фәиз өстәлнең икенче ягындагы урындыкка утырды. Мастер биргән тәмәкене алмады:

— Юк, тартасы килми.

— Мин сине аңларга тырышып карыйм,— диде мастер, беломорын тирән итеп суыргач.— Әмма ләкин һич кенә дә аңлый алмыйм. Мин сине байтактан күзәтәм бит.

Кемнеңдер күзәтеп йөрүен ишетү Фәизне үз-үзенә тагын да тирәнрәк бикләнергә мәҗбүр итте.

— Нәрсә аңлашылмый?— дип мыгырдады ул.

— Син аңлашылмыйсың. Нишләп син кешеләрдән читләшәсең? Комсомол секретаре зарлана әнә...

— Мин бит взносларны түләп барам.

— При чем монда взнос! Анысын түләмәсәң дә, барыбер хезмәт хакыннан басып калалар бит. Синнән бригадага файда юк, аңлыйсыңмы?

— Аңлыйм. Ләкин мин бит бөтен кушкан эшне эшлим.

— Анысы дөрес. Тырыш егет син үзең... Кызганыч та син миңа. Җәллим мин сине. Ну менә болай бригаданы үз итмәвең, бригаданың сине ят итүе мине борчый. Мин күптән эшлим. Завод бит бу. План... бишьеллык.

Виктор Степанович буталып бетте, чөнки бу малай белән ничек сөйләшсә дә, мәгънәсез икәнне аңлады.

— Алайса... китим мин,— диде Фәиз.

Мастер кычкырып җибәрде:

— Кая?!

Фәиз сискәнеп куйды.

— Башка цехка,— диде ул башын аска иеп.

Виктор Степанович шундук тынычланды.

— Юк, Фәиз, мин сине кумыйм. Эшлә. Китәсең килсә — кит, каласың килсә — кал. Мин фәкать сине аңларга гына тырышам.

— Рөхсәт итсәгез, калам мин цехта,— диде Фәиз мастерның үзенә карата начар мөгамәләдә булмавын сизеп.

— Кал, мин сине кумыйм. Син фатир сорамыйсың, теге-бу кирәк түгел сиңа. Планны үтәп барабыз... Эшлә, син комачауламыйсың.

Фәиздә киеренкелек кимеде, чын күңелдән үз эшенә бирелгән бу мастер аңа бик якын кеше булып тоелды.

«Әллә сөйләргәме Виктор Степановичка барысын да? Җиңелрәк булып китмәсме? Ул аңлаячак... Ул бит инде минем кайгы барлыгын белә, күрә, сизә. Сөйләргә кирәк бит инде кемгә булса да. Виктор Степанович кырыс кеше булса да, бик яхшы күңелле. Ләкин ул бик туры кеше, коммунист. *Теге вакыйганы* сөйләгәч, куып чыгарса? Милициягә хәбәр

итсә? Юк, ул әйбәт кеше. Нишләп әле мин аңа сөйләргә тиеш? Кем ул шул хәтле?! Нишләп гайре табигый хәлемне аның белән уртаклашырга тиеш мин?! Сөйләргәме? Юк, юк. Белеп булмый бит, сөйләгәч, нәрсә эшләячәген».

— Нәрсә тагын уйга баттың инде? — диде Виктор Степанович аптырагач, елмаеп.

Фәиз башын күтәрде:

— Бик авыр миңа, Виктор Степанович.

— Нәрсә авыр? Эшме?

— Гомумән, авыр... Яшәү.

— Яшәү җиңел булмый инде ул, туган.

— Миңа бигрәк тә авыр.

— Соң, аңлыйм, аңлыйм. Ятимлекнең ни икәнен чамалыйм, әлбәттә. Шулай да төшенкелеккә бирелмә әле син. Хезмәт хакың ашарыңа җитеп барадыр бит?

— Җитә анысы.

— Мин аңлыйм, яшь кеше, матур киемнәр дә киясең килә. Тора-бара акча тупларсың. Әлегә торыр урының бар бит. Өйләнеп җибәрерсең.

— Армиягә алырлар, бәлки.

— Армиядән ныгып, тәмам житлегеп кайтырсың. Аннан соң карарсың тормышыңны ничегрәк җайларга. Минемчә, монда болай төшенкелеккә бирелеп йөрергә сәбәп юк та шикелле.

— Сәбәп бар шул, — диде Фәиз, йөрәгенең ярсып тибүен тоеп.

Мастер сагайды:

— Нинди сәбәп?

Фәиз Виктор Степановичның зәңгәр күзләренә мәрхәмәт өмет итеп карады:

— Бәйләнмәгез инде миңа, Виктор Степанович.

— Йа хода! Бәйләнмим лә. Үзең әйтә башладың лабаса. Син әйт, нинди кайгың бар, бәлки ярдәм итә алырмын. Эш бит менә нәрсәдә! Аңлыйсыңмы? Синең нинди уйлар белән караңгыланып йөрүеңне беләсем килә минем.

— Аңлыйм. Ләкин сез мине барыбер аңламаячаксыз.

Мастер тагын кыза башлады. Фәиз моны сизде дә гафу үтенергә ашыкты:

— Виктор Степанович, зинһар өчен, гафу итегез мине.

— Гафу үтенмә лә. Бигрәк сәер кеше син. Бу хәтле булсаң да булырсың икән. — Ул тагын тәмәке кабызды. — Мин бит сиңа яхшылык кына телим.

— Ә нишләп әле сез миңа яхшылык телисез? — диде Фәиз чамадан тыш шикләнеп.

Мастер башын читкә борды:

— Син җүләр, ахрысы.

Фәизнең күңелендә исә каршы тору көчләре өстенлек алды һәм ул серен чак кына ачмый калган җиреннән әңгәмәдәшен алдап адаштыру юлына басты.

— Минем серем бер генә, Виктор Степанович, — диде мастерның ышанамы-юкмы икәнен белер өчен туры карап. — Мин куркам.

— Кемнән?

— Кемнән түгел, нәрсәдән.

— Нәрсәдән?

— Армиягә алмаслар дип куркам.

Виктор Степанович беркавым иреннәрен кыегайтып торды да шаркылдап көләргә тотынды:

— Ха-ха-ха. Тиле! Тапкан куркыр нәрсә. Ха-ха-ха. Алырлар, алырлар. Ә алмасалар ни булган! Тапкансың кайгырыр сәбәп! Армиягә алмаслар дип курка. Ха-ха-ха. Шулай бик барасың киләмени армиягә?

— Әйе.

— Алырла-а-ар. Андый җиргә тиз алып китәләр ул. Сәбәп шул гына булса, төкер!

Фәиз игътибар белән карагач аңлап алды: мастер бөтенләй үк ышанып бетмәде ана. Шикләнә Виктор Степанович, шикләнә. Куркыныч. Эчтәгене яшереп, бикләп куеп булмый икән. Куркыныч!

— Башкача кирәгем юкмы? — диде Фәиз, мастер бүлмәсеннән чыгып, курилкада үзе генә утырып тәмәке тартырга ниятләп.

— Бар, эшлә, — диде мастер. — Һәм үзеңне юк нәрсәләр белән бимазалама.

«Бар эшлә», дигәнне ишеткәч, аяклар курилкага түгел, верстакка таба атладылар.

Юк нәрсәләр белән... Их, Виктор Степанович, белсәң иде син дөресен! Сөйләмәдем үзеңә. Сөйлисе калган мәллә? Тагын үземә генә калды бит хәсрәтем. Ә нишләп әле мин аны Виктор Степанович белән уртаклашырга тиеш?!

Детальне тискага кыстырып игәүли башлады. Һәм инде, әлбәттә, күңеле детальдә түгел иде. Игәү корыч кисәге буйлап кыек-мыек йөрде. Бу — эшләү түгел, үзенә игътибар итмәсеннәр өчен фәкать гадәти хәрәкәтләр башкару гына иде.

Армиягә алсыннар иде дип чын-чынлап хыялланды ул. Милиция килеп алып китәме, армиягә алып китәләрме — аңа хәзер барыбер иде. Сәламәтлегем армиягә яраклы микән дигән шик-шөбһәсе дә булды аның. Бу куркыныч бертөрлелектән, газаплы уйлардан, тынчу, шау-шулы шәһәр дөньясыннан ераграк китү теләге туды. Армиядә аны зур үзгәрешләр көтәдер, анда гөнаһ-гаепләрне юарга мөмкинлек тә, шартлар да буладыр. Кайвакыт, милициягә барып, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләргә нияте дә туып куя иде. Алтын урлаган өчен түгел, дустын коткармаган өчен, бергә үскән җан дустына кул сузмаган өчен җәза бирүләрен теләде ул.

Ләкин аек акыл өстенлек алып, бу ниятеннән баш тартырга мәҗбүр була иде. Чөнки аны бит Зәбир батып үлгән өчен түгел, алтын һәм каравылчы өчен хөкем итәчәкләр! Шуңа күрә үзендә милициягә барудан тыелырлык көч таба алды. Эзгә басып тоталар икән, тотсыннар, хөкем итсеннәр, ә үзем барып бирелү дөрес түгел!

Ялгызлыкка көннән-көн ныграк сусый башлады ул. Ялгызы калу, моңаеп, Казанка буенда җырлап йөрүләр — ял көннәрен уздыруның бердәнбер чарасына әверелде. Кешеләр белән аралашу аның өчен бик авыр, газаплы була башлады. Бу күренеш тә аның күңеленә шом өстәде. Мин шулай гел кешеләрдән өркеп яшәрмен микәнни, дип уйлаган чаклары ешайды. Кызларга, гомумән, хатын-кызларга кызыгуын-кызыга, әмма һич кенә дә танышып, аралашып, алып кайтып (югыйсә мөмкинлек тә бар — бүлмәсендә берүзе)... Юк, юк, куркыта. Вакыты җиткәч, хәл кергәч бераз, караңгы уйлардан тора-бара арынгач, көч, дәрт ныгымый калмас. Шундый хыял-өметләре дә бар иде. Аның бит әле күптән түгел генә заводтагы бер кызга гашыйк булганы да бар. Тик кыюлыгы гына җитмәде. Арада «шомырт чәчәк атмый» калды. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар, дип үзен юатса да, үз-үзенә ышанычы тагын да кимеде шикелле.

Ниндидер кискен үзгәрешләр кирәк иде аңа. Үзгәртеп, бутап, адаштырып бетерергә иде. Кемне, нәрсәне? Анысы билгеле түгел.

Үзгәрешләр булды. Дөньяның, яшәешнең төп шарты — хәрәкәт. Хәрәкәт исә, асылда, үзгәреш ләбаса. Үзгәреш кирәк икән, димәк, син галәм хәрәкәтенә тартыласың. Хәрәкәт, үзгәреш — яшәү шул бит инде!

Үзгәрешләр булды. Дөньяда да, Фәизнең вөҗүдендә дә.

Әмма әйтүе кыен: тегеяки бу үзгәреш яшәүчәнлек галәмәтеме, әллә, киресенчә, җимергечме...

Алда аны әле галәмәт зур үзгәрешләр көтә иде.

## 24

Улы кайткан көнне Тәлгатьнең кәефе, табигый ки, күтәренке булса да, аның күңелендә киеренкелек саклапды — тыныч кына, ирләрчә бер әһәмиятле әңгәмә корасы бар иде.

Нәҗибә тыз-быз мич тирәсендә кайнашты, бәлеш пешерү белән мәшгуль булган әнисенә Марат рәхәтләнеп сөйләп утырды: Молдавия турында, төзелеш отрядындагы кызык вакыйгалар хакында. Казан яңалыкларын да телгә алды. Тәлгать мунча янында мәш килде.

Бәлеш ашап, чәйләр эчкәч, газиз улының аркасыннан кат-кат кагып сөйгәч, Тәлгать җитди кыяфәт белән Нәҗибәгә, аннары улына карап:

— Бик җитди итеп сөйләшәсе бар синең белән, улым,— диде.

Нәҗибә сагаеп калды, чөнки иренең нинди сөхбәт корырга маташуын ул бик яхшы белә иде. Ни әйтергә аптырап, шул ук вакытта ничек тә иренең булачак нотыкларына комачауламакчы булып:

— Мунча кергәч сөйләшерсең әле! — диде ул усал итеп.

Гомер буе төрле оешмаларда бухгалтер булып эшләгәнгә күрә Нәҗибәдәге кырыслык табигый күренә иде, чөнки бухгалтерлар шактый иреккле, күпмедер дәрәҗәдә влачлы һәм ничектер серлерәк халык. Бухгалтер ул бик күп белә — оешманың җитәкчесе турында да, акчаның кайдан килеп кайда гаип булганын да. Шул сәбәпле бухгалтерлар, нинди генә формация килмәсен, бигүк кычкырып сөйләшмәсәләр дә, үзләренең бәясен, тормыштагы урыннарын һәм бу дөньяда кем көчле, кем көчсез икәнне дә аермачык, анык беләләр һәм аңлыйлар.

Тәлгать Назыймович баш врач булып эшләгән вакытта да ул балалар больницасында бухгалтер иде һәм һәрвакыт ире белән үзен бер дәрәҗәдә дип санады. Гәрчә ире район больницасының баш врачы, ә ул бары тик балалар больницасының бухгалтеры гына булса да. Аның иренә баш имәвенең сәбәбе ир белән хатын булуларында да түгел. Нәҗибә белә иде барысын да. Системаның бөтен якларын, бөтен пычраклыкларын белә иде Нәҗибә. Бер-берсенә нык бәйләнгән партия-кодалык-әшнәлек чылбырындагы кечкенә бер бөҗра-буынчык булган һәрбер кеше бер-берсенә ясалма ягымлылык, ясалма ихтирам белән карый иде — нинди генә урында утырмасын. Чөнки чылбырда, тирәнрәк уйлап баксаң, алар барысы да бертигез. Уйнап кына бер-берсенә буйсынып яшиләр иде барысы да, чөнки системасы шундый, күңел кушуы буенча түгел, эчке бөек кануннар таләбе белән түгел. Ә Нәҗибәнең, хатын булarak, иренең баш врачлыгына бөтенләй исе китми, буйсынырга да җыенмый ул, чөнки гаиләдә уйнауның, ясалма субординациянең кирәге бөтенләй юк. Гомер буе шулай барды. Тәлгать табигатьтән йомшак күңелле буларак, гаиләдәге мөнәсәбәтләрдән канәгать яшәде. Мул яшәүләренә дә, бернәрсәгә кытлык кичермәүләренә дә икесенең дә өлеше зур иде. Нәҗибә, больницада эшләп, кеше рәтендә, дус-ишләр арасында абруй казанып яшәүләреннән гел горурлык кичерде. Тәлгатьнең, эшеннән алынып, ә соңыннан бөтенләй пенсиягә чыгарылуыннан иң элек аның коты алынды. Ләкин ул шундук үзен тынычландырды: сау-сәламәт, акчалары җитәрлек. Нишлисең бит. Ул акылсыз хатын түгел, бик яхшы аңлый: Тәлгать кебек кешеләргә гел форманы саклау бик авыр — ул пассив кеше. Яшьләр килә торалар, җитәкчеләр үзгәрә, әшнәлек системасы да даими үзгәреп тора лабаса.

Т. шәһәреннән китүе бик авыр булса да, монда, поселокта да, тыныч, рәхәт. Нәҗибә тик утыра алмый. Райфога бухгалтер булып керде. Т.да калырга мөмкин иде. Тәлгать бит теңкәгә тиде: китик моннан, китик. Дусларының күбесе инде хәзер читләште. Бәлага дучар булгач, дуслар калмый икән ул. Һәркем үз мәнфәгатен генә кайгырта, бәла килсә, һәммәсе үзен генә коткарырга тырыша.

Маратны мединститутка кертергә Нәҗибә күндерде. Тәлгать озак каршы торып маташкан иде дә... Нәҗибә исә һаман үз киресен сукалады.

инде Марат үзе дә зур теләк белдергәч, танышлык белән урнаштырырга туры килде.

Их, белсә иде Нәҗибә Тәлгатьнең ниләр кичергәнен, нинди уйлар белән яшәгәнен. Больницада бухгалтер булып эшләп, бик күп нәрсәне мәгълүм кылып, гади кеше белмәгән нәрсәләрне аңласа да, күп еллар бергә гомер кичергән иренең күңелендә нинди бураннар уйнаганын белми иде шул ул. Тәлгать аңлый: Нәҗибәнең улын врач итәргә тырышуы үҗәтлек — дошманнарга үч итеп, менә карагыз, улыбыз да врач эшен дәвам итә дип кемгәдер, нәрсәгәдер исбатлау кебек иде. Нәҗибә, гомумән, тормышыннан канәгать иде, шуңа күрә улын да врач итәсе килде. Врачның абруе бар, ул кешеләргә кирәк, аңа баш иеп киләчәкләр. Ул Тәлгать сыман йомшак булмаячак, суксалар, әтисе шикелле икенче яңагын куеп тормаячак.

Тәлгатьнең Марат белән сөйләшергә җыенуы Нәҗибәнең күңелен кыбырсытты. Өченче курска күчкән студентны институтын ташларга күндермәсен тагын. Үзе җебек булгач та...

— Син атаң әйткән бөтен сүзне дә тыңлама,— дип ычкындырды Нәҗибә.— Синең үзеңнең дә башың бар.

Хатынына тавышын сирәк күтәрүче Тәлгать бу юлысы түзмәде:

— Тик кенә тор! — дип җибәрде.— Мин улыма начар киңәш бирмәм. Син тагы... Әйтмәгән саен...

Сирәк кычкырган кешенең тавышы һәрвакыт нык тәэсир итә — Нәҗибә каршы әйтергә җөрьәт кылмады, өйдән чыгып китәргә сәбәп эзләп як-ягына карангалады да, ниһаять, таз белән чиләген күтәреп чыгып китте. Бакчадан мунчага таба барганда, куаклар кыштырдавына кушылып, ачык тәрәзәдән Нәҗибәнең борын төбеннән мырылдап кемнедер орышуы тоныктоныклыгы кына булып ишетелеп калды.

Тәлгать өстәл янынннан кузгалды:

— Мунчаны соңрак керерсең. Әйдә елга буйларын әйләнеп кайтыйк әле.

Барыбер Нәҗибә иркенләп сөйләшергә ирек бирмәс, елга буенда, аулакта рәхәтләнеп сөйләшеп булачак.

— Әйдә,— диде Марат, әтисенең нindидер мөһим сүзләре барлыгын, әһәмиятле фикерләрен улына әйтәсе килгәнен сизеп.

Пристаньга таба бормаланып төшкән юлдан алар салмак адымнар белән елгага юнәлделәр.

— Үзгәрмәгән поселок,— диде Марат, як-ягына карап.— Т.ны сагынасыңмы?

Тәлгатьнең шундук чырае караңгыланды:

— Юк, сагынмыйм, Т.ны да, аның каһәр суккан больницасын да, кешеләрен дә. Хәтта шул чакларны да никтер сагынмыйм.— Ул Маратка карап куйды.— Ә син сагынасыңмы?

— Соң инде... шул шәһәрдә туып-үскән кеше ләбаса. Минем ул шәһәр белән бик якты хатирәләрем бәйле — балачагым шунда калды.

Тәлгать күңелендә шатлык тойды, чөнки улы үсеп җиткән, чын егет булган, әнә бит сөйләшүләре аның ничек акыллы. Бала-чага түгел инде. Егерме яшь бит.

— Әйе шул, улым. Бәлки чынлап та, анаң дөрес әйтәдер, минем бөтен әйткән сүзләремә бәлки колак салырга да кирәк түгелдер.

Алар, пристаньны узып, кечкенә баржалар, катерлар чайкалып торган яр буйлап елга агымы уңаена атладылар.

— Казанда сиңа бер үсмер керергә тиеш иде...

Ул әйтеп бетерергә дә өлгермәде, Марат дәвам итте:

— Фәиз исемле.

Тәлгать ялт итеп аңа карады:

— Килдеме әллә?

— Килде ул. Егерме биш сум акча кертте.

— Алдыңмы?

— Алдым. Син бурычка биргән булганың бит,— диде Марат, кашларын җыерып. Фәизнең тузынып, акчаны битенә ыргытып чыгып китүе исенә төште.

— Их, алмаска идең,— диде Тәлгать офтанып.— Шунсы сәер. Син бит Сәлим Сәлмәневичне беләсең...

— Синең элекке завхозыңнымы?

— Әйе.

— Белә-ә-әм, аны белмәгән кеше юктыр.

— Шунсы бик сәер. Сәлим Фәизне эзли.

— Ул да килде миңа.

Тәлгать шып туктады:

— Кит аннан?

— Килде. Фәизнең адресы белән кызыксынды. Кайда урнашканлыгын төпчинде.

— Әйтмәдеңме?— Тәлгать нык дулкынлана иде.

— Әйтергә... мин белмим бит ул малайның адресын.

— Бик әйбәт булган,— диде Тәлгать тынычланып.— Сәлим ник эзәрлекли икән аны, әйтмәдеме?

— Юк.

— Фәиздән акча алма дип записка җибәргән идем, бирдеме? Сәлим бирергә тиеш иде. Ул ятимнән акча алмаска кушып язган идем.

— Юк,— диде Марат тыныч кына.

Акчаны алырга теләмәгәнен, Фәизнең тузынып чыгып китүен әтисенә сөйләмәскә булды.

— Ник эзли икән Сәлим ул егетне?

— Детдом малае булгач, йә лесхоздан берәр нәрсә урлагандыр. Сәлим аңардан шикләнәдер.

Тәлгать улының күзләренә карап торды да:

— Бәлки минем өстән берәр матавык оештырырга йөридер,— дип пышылдады. Кинәт аның маңгаена тир бәреп чыкты, аскы ирене дерелдәп куйды.

Әтисен мондый кыяфәттә күргәне юк иде Маратның.

— Авырыйсыңмы әллә?— диде ул, пошаманга калып.

Тәлгать аны тынычландырырга ашыгып:

— Юк, юк, андый хәл бетеп куюлар гына була инде ул,— диде һәм атлавын дәвам итте.

— Нишләп синең өстән матавык оештырырга йөрсен инде ул? Аның үз мәшәкатьләре муеннандыр. Ә ул малайның монда ни катнашы бар?

— Ул егетнең, Фәизнең әнисе миндә операция вакытында үлгән иде. Менә шундый хәлләр.

Алар сөйләшүдән туктап яр буйлап атладылар.

— Соң инде... Операция вакытында була торган хәл.

Тәлгать тагын кинәт туктады.

— Алай димә!— диде ул ярсып.— Уйласаң уйла, әмма ләкин авыз тутырып алай димә. Була торган хәлме, юкмы... Барыбер кемдер җаваплы. Мин, улым, сиңа үземнең ялгышларны-хаталарны кабатламавыңны теләп әйтәм бит. Әниең минем нотыкларны өнәми, әмма ул бит, ни дисәң дә, хатын-кыз акылы белән фикер йөртә. Гомерләр бигүк озын түгел, үтә дә китә ул. Артка борылып карагач, ник яшәгәнеңә үкенерлек булмасын иде. Чөнки чистарынырга, офтанырга, үкенергә вакыт аз калуы бар. Минем сиңа аңлатасы нәрсәләрем күп. Әмма аңларсың микән? Дөресрәге, аңлата алырмынмы икән? Саф кешеләр дөньяда сирәк очрыйдыр. Тик минә кылган эшләре өчен офтанучылар, чистару юлына баскан кешеләр бихисап күптер. Минем сиңа теләк шул: үзеңне аңлап, үзеңне тоеп, акны карадан аера алып, дөньяның асылына төшенеп житкән чорында офтанырга, тәүбә итәргә, чистарыну юлына басарга мөмкинлегең һәм вакытың җитәрлек булса иде. Минем сүзләр бәлки бик төче тоеладыр...

— Юк, юк, әти.

— Менә шулай, улым. Әниең әйбәт кеше, ләкин аңа аңлата алмадым мин соңгы еллардагы халәтемне. Ә менә сиңа аңлата алырмын дип ышанам. Син уйла, үзеңнең күңеленә тагын-тагын колак сал. Бәлки башка юлдан китәргәдер сиңа. Врач эше ул, изге саналса да, кайвакыт рәхмәтсез дә булып куя.

— Юк, әти, мин врач булам!

Улы белән бәхәсләшеп торуның мәгънәсезлеге аңлашылды.

Елга акты да акты. Менә шулай ага гомер, һич кенә дә кире борып булмый аны. Шулай ук болганчык, шулай ук салкынча. Тикмәгә «Үзган гомер — аккан су», димиләр. Акчарлакларның чиылдавы да фаҗигале, сәер бер җыр сыман бит.

Әтисенең монологларын тыңлаганы бар Маратның, әмма бу юлы аны тыңлавы авыр иде, әтисен ихлас күңелдән кызганды ул.

— Әти, кайгырма син! — дип әтисенең иңеннән какты.

Тәлгать, кипшенгән иреннәрен җәеп, ясалма гына елмаеп куйды. Андый сүзләр белән генә юатып булса иде үзеңне! Шулай да улының акыллы, тәртипле егет булып, яхшы укып килүе аны бераз тынычландырып, шатландырып, киләчәккә өметләрен уятты.

— Син акылсыз бала түгел, улым, мин сиңа ышанам, — диде ул. — Син мине аңлыйсыңдыр.

— Аңлыйм, — диде Марат.

Аңлыйм дисә дә, ул үзенчә аңлый иде. Кеше күңелен, атаңмы ул, анаңмы, барыбер аңлап бетереп булмый. Ялгыз, һай ялгыз бу адәм баласы. Бик әйтергә теләгән очракта да сүзләр белән аңлатып булмый бит күңелендәге хәлләрне. Ялгыз бу адәм баласы! Нинди ялгызлык бу?!

— Карале, улым, теге... Фәизне табасы иде, ярдәм итәсе иде аңа. Аның беркеме дә юк.

Марат Фәизнең холыксызлануын бөтенләй сөйләмәскә булды, алайса әтисе тәмам кайгыга кереп батачак.

— Аны кайдан табасың хәзер? — диде Марат.

— Алай-болай очраса, зинһар, ярдәм ит, — диде Тәлгать. — Монда, безгә килеп йөрсен. Булдыра алган кадәре булышырга кирәк аңа.

— Ярар, бәлки очрар.

Әңгәмәнең күңелсез өлеше отыры бетә барды. Елга буендагы табигатьнең хозурлыгы сөйләшүне яктырак агымга күчерергә этәрде. Марат илһамланып стройотрядта булган кызык вакыйгаларны, Молдавиядән алып кайткан тәэсирләрен сөйләргә ашыкты. Аның сабыйларча онытылып, җан атып сөйләве әтисен әсир итте һәм, мунча барлыгын искә төшереп, өйгә кайтырга борылганда икесенең дә кәефе күтәренке иде.

Икенче көнне Марат кармак белән балык тотарга елгага төшеп менәргә булды. Пристаньга җитәрәк каршысына таныш кеше килгәне күренде. Сәлим Сәлмәневич иде бу, әлеге кеше аңа имәнгеч тәэсир ясаса да, аның очравы Маратны бу юлы шатландырды. Чөнки барыбер беләсе килә иде: Фәизне ник әзәрлекли икән ул?

— Сәлам! — диде Сәлим ерактан ук.

— Исәнмесез.

Сәлим килеп егетнең кулын кысты:

— Балыккамыни?

— Әйе, бераз чирттереп карыйм әле. Сез нишләп йөрисез? Берәр җирдән кайтасыз дисәм, метеор-мазар килгәне дә күренмәде.

Сәлим бик эшлекле кыяфәт белән фуражкасын салды, тирләп юешләнеп беткән сыек чәчләрен артка сыпырып куйды. Тубал хәтле башы тагын да олаеп киткәндәй булды.

— Мин, энем, пристаньга килдем. Лесхозга Казаннан ике инспектор килергә тиеш иде. Шуларны каршы аласым бар. Әле метеор килергә иртәрәк, ашханәгә барып тамак ялгап алам.

— Пристаньда буфет эшләмимени?
— Әй, андагы катып беткән пирожки белән.
Марат китәргә ашыкмады, Сәлимнең Фәиз турында соравын көтте. Ә теге сорамады.
— Инспекторлар килергә тиешмени? — дигән булды Марат, ни әйтергә белмәгәч.
Сәлимнең чырае тагын караңгыланды:
— Әйе, йөриләр шунда! Атаң өйдәме соң?
— Өйдә.
— Нихәлләрдә яшәп ята?
— Әйбәт болай, беркөе.
— Ярар алайса, ашханә ябылганчы барып капкалыйм инде мин.
Фәиз турында Марат үзе сүз катарга булды.
— Фәиз килгәние,— диде ул һәм сынаулы караш белән Сәлимгә текәлде.
— Килдемени?! Ә-ә-ә,— диде Сәлим битараф кыяфәт белән һәм китеп бармакчы булды.
Марат гаҗәпләнеп:
— Сез бит кызыксынган идегез аның белән,— диде.
— Хәзер кызыксынмыйм инде. Кирәге юк аның миңа. Ярый, хуш!
Сәлим ашханәгә таба китеп барды.
Марат бу хәбәргә куанды һәм шул ук вакытта соравы җавапсыз калды шикелле — башта ник кызыксынды соң ул аның белән? Артыннан барып, төпченеп йөрү дә әллә ничек, килешми.
Аю шикелле әвеш-тәвеш атлап баручы Сәлимгә ул тагын бер карап куйды да, кармак таягын иңенә салып, елгага төшеп китте.

## 25

Сентябрьнең икенче яртысы җитте. Табигатьнең алтын хәзинәләрен ашыга-ашыга пәрәвез белән капларга маташкан вакыты. Нинди беркатлылык! Үтә күренмәле япмалар белән якынлашып килүче җан өшеткеч кышлардан бу хозурлыкны, бу хәзинәне каплап яшереп буламыни?! Юк!
Бу дөньяда нинди дә байлыкны яшереп, саклап, мәңгеләштерү мөмкинмени?!
Гомумән, берәр нәрсәне саклап калып буламы бу дөньяда?! Мәңгелек нәрсә бар соң?! Бәлки кешеләрнең һәммәсе дә мәңгелектә калыр?! Бу дөньядагы бөтен нәрсә калыр бәлки мәңгелектә?! Тик бүгенге халәттә түгел, башкачадыр.
Мәңгелектә сине тәшкил иткән атомнар гына очып йөрер, бәлки, җиһан буйлап. Бөтен нәрсә үзгәреп тора бит. Һәркем белә балачагың гөрләп узган төбәкләрне кайтып танырга мөмкин, әмма ләкин ул инде син уйнап үскән төбәк түгел — ул үзгәргән, кайвакыт аны хәтта танырлык та булмыйдыр. Кайсы гына шагыйрьләр: «Шул ук сукмаклар... шул ук урманнар һ. б., һ. б.» дип нинди генә шигырьләр язмасын, бу бит дөрес түгел. Үзгәрә, ел саен, көн саен, сәгать саен бөтен нәрсә үзгәрә: җимереләсе — җимерелә, шытып чыгасы — шыта.
Нәрсә мәңгелек соң? Бу дөньядан төк тә алып китә алмаган кеше өчен мәңгелек берәр нәрсә бар микән? Теге дөнья?! Ярый ла, чыннан да, теге дөнья булса. Җаваплылыкның күп өлешен теге дөньяга калдырып, бераз җиңеләеп тә булыр иде. Анда кемгә нәрсә тиеш — шул булса, һәркемгә үзенә тиешлесен алырга насыйп икән һәм дә моның шулай булачагын алдан белеп, инанып торсаң, әлбәттә, җан тынычлыгына ирешергә мөмкиндер дә.
Ә теге дөнья әгәр юк икән?! Нишләмәк кирәк?! Әгәр кеше Җирдә яшәгәннән соң җавап бирергә дучар ителмәсә, коточкыч бит! Шушы

дөньяда, бер очрашканнан соң, кешеләргә бүтән бернинди дөньяда да кавышырга насыйп булмаса, ни хәл итмәк кирәк?!

Шулай да ышанасы килә: теге дөнья бардыр. Ул дөнья хакында уйланулар һәрбер инсанның котын алса да, теге дөнья юктыр дигән фикер никтер барыбер имәнечрәк тоела.

Бу дөнья бәлки куркынычрактыр да?! Чөнки гөнаһны монда кылалар бит.

Аның мондагы җәзасы катыракмы, тегендәгесеме? Монда җәзаланып, тегендә оҗмахка кергәнче, бәлки...

Юк, бу хакта сүз кату бөтенләй кирәкмидер.

Нәрсә мәңгелек? Нишләп мондый сорау туды да тагын колакта чыңлап тора соң әле? Бу сораусыз булмый, чөнки мәңгелек нәрсә генә кыйммәткә ия була түгелме? Алай дисәң, кеше гомере бик кыйммәт ләбаса. Гәрчә бик кыска гына булса да.

Кыскамыни бу гомер? Ул сиңа һәм миңа гына кыска булып тоела түгелме?! Ярый әле фани дөньядагы гомер мәңгелеккә сузылмый. Аны ничек яшәп бетерер идең?!

Шулай да, нәрсә мәңгелек соң? Кеше үземе? Аның җанымы? Җаны мәңгелек булса, аның саваплы эшләре һәм гөнаһлары да мәңгелек микән? Гөнаһлардан ничек тә арынадыр ул, монда кылган гөнаһлар белән мәңгелеккә ник кирәк ул?!

Ә менә ничек арына икән соң җан гөнаһлардан?.. Кайда арына икән? Мондамы? Тегендәме?

Сентябрь аеның дөнья мәшәкатьләренә ваемсызлыгын тамаша кылып, Фәизнең чардак тәрәзәсеннән, үзенең куырылып куркып калган күңелендәге тар гына төннектән дөньяга күз салып утырган бер көне иде. Ял көннәрен зарыгып көтсәң дә, (соңгы вакытта заводка теләр-теләмәс кенә йөри башлады), үзеңне кая куярга белмәгәч, ялы ни дә, эше ни. Эшкә барырга ялкаулануын ул «завод ерак булгангадыр», «эш авырлыктандыр» дип, берничә төрле сәбәп табып үзен юатырга тырышты. Чынында исә, көзге чорда караңгы уйларның көчәеп, төшенкелекне арттыру галәмәте иде бу.

Шушы чардак, кечкенә кораб булып, бер могҗиза гамәлгә ашып, кинәт кенә һаваданмы, елгаданмы йөзеп китсен иде дә, ерак диңгезләргәме, галәм чиксезлекләренәме кереп югалсын иде.

Бүген чардак астындагы бүлмәдә иртәдән бирле Хәтимә әби кем беләндер җанланып сөйләште дә сөйләште. Әңгәмәдәше хатын-кыз иде.

Баскыч янында кунакның тавышы ишетелде:

— Йоклый микән әллә һаман да?

Чардак баскычыннан ике баскыч күтәрелеп Хәтимә әбинең башы күренде:

— Фәиз, тордыңмы син?

— Тордым, тордым, күптән инде.

— Гөлүсә иденнәрне юып чыгарыйм ди. Синең дә күптән юылмаган бит.

«Бик кирәк иде»,— дип уйлады Фәиз, сөмсере коелып. Уйланып утырганда комачауласалар, бик читен. Ул инде хәзер үзенең газаплы уйларына хәтта ияләшеп бара, алардан башка нидер җитми кебек тоела аңа. Үзеңнең кайгың белән күзгә-күз калып утыру аерым бер утрауда утырган шикелле тойгылар уята, бу халәт читен булса да, үзеңне чынбарлыкта хис итү тагын да читенрәк ләбаса. Чөнки синең тирәдәге күренешләр белән, тирә-яктагы кешеләр белән аралашканда да күңелдәге газап онытылып, юкка чыгарга ашыкмый, вөҗүдне урталай аерырдай булып, бер өлешеңне чынбарлыкка ташлап, икенче өлешен үзе белән каядыр газап чигәргә сөйри кебек иде. Бу халәтнең авырлыгын аңлатып булмас, ахры. Аның бер генә мизгелен тасвирларга да каләм белән кәгазь җитмәс иде.

Баскыч шыгырдады, Гөлүсәнең башы чардакта пәйда булды.

— Булыш әле, егет,— диде ул, әллә көчәнүдән, әллә ялгыз егет янына чардакка менүеннән кызарып.

Фәиз йөгереп барып сулы чиләкне алды.

— Мин тышта йөреп торыйм алайса,— диде Фәиз.

Аның йөрәге ярсып тибә башлады: беренчедән, янына ят кеше килеп керүдән, икенчедән, аның хатын-кыз булуыннан. Урта яшьләрдәге, тыгыз, зифа гәүдәле бу хатынның баскычтан менгәндә ялтырап куйган шәрә ботлары, халат каплап бетерә алмаган олы күкрәкләре егет өчен күтелмәгән вакыйга иде, ул, баскычка таба атласа да, аның никтер чыгып китәсе килмәде.

Яулыгын матур итеп татарча бәйләгән, бигүк чибәр булмаса да, халат киеп идән юарга җыенган хатыннарга хас, аңлатылмаслык табигый матурлыгы белән үзенә тарткан бу хатын егетнең каушавын, әлбәттә, нәкъ үзе аңларга тиеш булганча аңлады һәм чардакны яктыртып елмаеп җибәрде:

— Юк, юк, син миңа комачауламыйсың, аякларыңны күтәреп караватыңда утырсаң, шул җиткән.

Фәиз буйсынды. Нәкъ ул әйткәнчә караватка барып утырды һәм аякларын күтәреп бөкләде.

— Сез кем буласыз?— дип сорарга батырчылык итте Фәиз.

— Гөлүсә,— диде хатын һәм чүпрәкне мул итеп манчыды да лачт итеп ташлап идәнне юарга тотынды.

«Нинди матур!» — дип уйлады үсмер, колак очларының кайнарлануын тоеп.

Гөлүсә ара-тирә егеткә күз ташлап идәнне юа-юа танышуны дәвам итте:

— Мин Хәтимә түти сеңлесенең кызы булам. Племянницасы.— Һәм Фәизгә карап тагын елмаеп куйды.

Фәиз, мөкиббән китеп, аның шоп-шома тезләрен, бик үк нечкә булмаса да, беленеп торган билен, таза беләкләрен күзәтте. Тагын нәрсәдер әйтмәкче булды, әйталмады. Телсез калып, маңка малайдай тик утырды.

Гөлүсә тиз арада идәнне ялт иттерде, тирләгән битен башындагы яулыгы белән сыпырды да, яулыгын халат кесәсенә бөгәрләп тыгып, караватта сентябрь шәкерте сыман кукыраеп утыручы егеткә тагын мөлаем иттереп елмайды.

— Уф, арыдым. Булыш миңа.

Фәиз сискәнеп китте:

— Ничек?

Гөлүсә рәхәтләнеп, калынча тавыш белән көлеп җибәрде:

— Бигрәк кызык малай икәнсең син. Сыерчык оясына кереп качкан чыпчык кебек.— Тагын киерелеп көлеп җибәрде.

Фәиз нык каушады, үзен яклап ни әйтергә дә белмәде.

— Мин,— диде ул һәм караваттан төшеп катып калды:— Мин чыпчык түгел.— Ник акланганын үзе дә аңламады ул.

— Булыш әйдә, мин төшәм, син миңа чиләкне бирерсең.

Фәиз кискен итеп җавап бирде:

— Ярар.

Гөлүсә акрын гына баскычтан төшә башлады, аның күзләре мут елмаеп һәм ничектер сабыйны иркәләгәндәй Фәизгә төбәлгәннәр иде. Фәиз өстән аның имиләрен күрде. Халат бөтенләй булышмый иде, олы имиләр анда яшеренеп ята алмыйлар, алар күренәләр, дәшәләр, алып китәләр. Фәиз чиләкне биргәндә дә ничектер хатынның күзләренә түгел, күкрәкләренә текәлгән иде. Баскычтан төшкәч Гөлүсә тагын бер тапкыр рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Фәизнең йөрәге баскычтан түгел, гүя, упкын төбенә төшеп китте — ул бит Фәиздән көлә ләбаса. Хәлсез, булдыксыз икән дип уйлыйдыр минем турыда. Миннән көләдер, дип үзенә үзе Фәиз яңа удар ясады. Кайдан килеп чыкты бу? Ул хәтле чибәр дә түгел үзе

югыйсә. Карт бит ул минем өчен. Барыбер ничек тә сөйләшергә иде аның белән. Булмады бит, каушатты. Мин гаеплемени? Ә кем гаепле?

Гөлүсәнең мыскыллап көлүе турында уйлап ярты көне үтеп китте. Хәтта ашханәгә дә бармады, ашыйсы бөтенләй килмәде. Кичкә таба Хәтимә әби каядыр китте, Фәиз дә Казанка буенда йөреп керим дип свитерын кия башлады. Шул вакытны чардакка, өстенә тастымал каплаңган тәлинкә күтәреп, Гөлүсә менде. Аның кыяфәтендә бернинди мыскыл итү-мазар чагылмады.

— Син көне буе ач түгелме соң? — диде ул аналарча кайгырту белән һәм тәлинкәне почмактагы кечкенә өстәлгә китереп куйды. Өстәлдәге искереп беткән тегү машинасын идәнгә урнаштырды, шул ук тастымал белән тузанны, борынын җыерып, сыпырып куйды.— Утыр, аша, кайнар кабартма. Хәзер чәй алып менәм. Хәтимә апа сине кыргый ди. Аска төшеп эчсәң дә була инде. Ярар инде, алып менәм. Ашый тор.— Шуннан соң ул баскыч чыгарган шыгырдавык көй астында төшеп китте.

Фәиз таң калды. Мондый яхшы, җылы мөнәсәбәт тә аңа чит-ят иде, чөнки күптәннән бирле инде кешеләрдән җылылык алганы, бигрәк тә хатын-кыздан назлы, җылы сүз ишеткәне юк иде. Ул инде мондый очракта үзен ничек тотарга да белми. Соңгы вакытта исә: «Күрәсең, мин яхшы мөнәсәбәткә хаклы түгелмендер», дигән бер хис тә барлыкка килде аңарда. Ә ни дисәң дә, Гөлүсәнең үзе сыман күпереп торган кабартмалар белән соры, тынчу тормышына килеп керүе аңа сәер күренеш иде, һәм дә бу яңалыкка тиз генә ияләшеп булмаса да, күңелнең бер өлеше изрәп китте, шул арада җылынырга да өлгерде.

Гөлүсә тагын берничә тапкыр аска төшеп менде. Чардакның чайкалып торган иске өстәлендә кабартмалардан тыш варенье, чәй, кыяр, помидор һәм җиде йөз граммлы шешә белән кызыл аракы урын алды.

Фәиз бер стакан вино эчкәч шундук исерде, ләкин каушавы әле бетмәде. Куркуы инде юкка чыкты. Башын кулына салып, ул Гөлүсәнең сөйләгәнен рәхәтләнеп тыңлап утырды.

Гөлүсә тормыштан зарланды. Шешә зур, виносы күп иде, хатын салды да эчте, салды да эчте. Аның бик күптәннән күңелен ачып аһзарларын сөйләгәне булмаган, күрәсең. Хәтимә карчыкка да бөтенесен сөйләү мөмкин түгел — апа кеше бит ул. Сары чәчле, бәләкәй генә бу үсмергә дә эчесеннән җебенә кадәр сөйли алмыйсың, әмма ни дисәң дә ул...— ир кеше. Һәрхәлдә, ир буласы кеше. Бераз үпкә дә белдерү мөмкин ир-ат затына, моңа «сез, ирләр» дип тә сөйләп була.

— Ирем эчмәсә болай килеп чыкмый иде. Эчте бит. Алкоголикның ирлеге дә бит инде аның, ничек дип әйтим... Ну син бала-чага түгел инде, аңлыйсың.

— Әйе,— дип мыгырдап Фәиз аңлавын белдерде.

— Үзе булдыксызланды да миннән көнләшә башлады. Безнең бит инде ундүрт яшьлек кызыбыз бар. Сиңа ничә яшь әле?

— Унсигез тулды.

— Синнән дүрт яшькә генә кече. Аерылышып, фатир бүлеп, йорт җиһазларын сугыша-сугыша бүлүләрнең читенлеген белсәң иде си-и-ин.

— Кайда яшисең соң хәзер?

— Фатирны бүлеп бетермәдек әле. Монда Хәтимә апада торам әлегә. Өйдә кунарга чут юк инде, көн саен исереп кайта, көн саен җәнҗал.

— Ә кызың?

— Кыз шунда. Аңа тими ул. Минем белән генә сугыша.

Гөлүсә дә исерде. Тузган чәчләрен гадәт буенча гына артка сыпырып, ул кызыл аракыдан мөлҗерәйгән малайга карап елмайды. Фәиз дә елмаерга тырышты. Хатынның халаты түше турында бөтенләй аерылган иде. Лифчиксыз имиләр тагын якты дөньяга чыгып күз алларын караңгылатты.

Фәиз ихлас күңелдән әйтеп куйды:

— Син матур.

Гөлүсәнең елмаюы авыз кыйшаюына күчте, шаярып әйтмиме икән, дип ригая белән карады. Чөнки ул үзенең чибәр түгел икәнен яхшы белә иде. Яшьрәк вакытта моңа ышанасы килми, утызга якынлашканда моның белән килешәсе килми иде, ә инде утыз бишкә җиткәч, килешәсең икән ул.

Шактый күпне күргән хатын исерек малайның карашыннан бераз югалып та калды шикелле, «син матур» дип шаярып әйтмәгәне күренеп тора, алай гына да түгел, үсмернең бөтен кыяфәтеннән утыз биш яшьлек хатын-кыз, һичшиксез, аңлый торган чакыру, эндәшү, теләү укыла иде.

— Син миннән куркасың бугай,— диде Гөлүсә, егетнең башын сыпырып.

Фәизнең йөрәге чардактан очып чыгып чиксез күктә юк булыр сыман иде.

— Юк, курыкмыйм,— дигән булды ул, еш-еш сулый башлап.

— Кил инде,— дип пышылдады хатын күзләрен йомып.

Фәиз, онытылып, аңа ыргылды, чәчләрен, битен, күкрәкләрен, беләкләрен үбә башлады. Иске урындык черек булып чыкты, алар гөрселдәп идәнгә егылып төштеләр. Ләкин егылу аларга кызык тоелмады, дөресрәге, бу мизгелләрдә аларга юмор кирәк түгел иде. Алар идәндә үбешеп аунадылар.

— Әйдә караватка,— дип пышылдады хатын.

Караватка менеп яткач, Фәиз үзендә ышаныч тапмады. Аңардагы дәрт мизгеле белән юк булды, тагын курку өстенлек алды. «Булыр микән?»

Тәҗрибәле хатын, аның хәлен аңлап:

— Син бер дә борчылма, курыкма син. Син молодец. Әйбәт булачак,— дип кайнар иреннәре белән егетнең иреннәрен, муенын, күкрәген өтеп-өтеп алды.— Курыкма. Яшь әле син, шуңа куркасың.— Ул ыңгырашуга күчте.— Мен-ә-ә шула-ай...

«Хан заманыннан» калган иске караватның шыгырдавы каядыр баш очында гына кичке алтыны суккан Кремль сәгатенең тавышыннан көчлерәк булып тоелды.

## 26

Гөлүсә чардакка еш менә башлады. Фәиз өчен зур вакыйга һәм гаять кискен үзгәреш булды бу. Тормышка булган мәхәббәте кире әйләнеп кайтмаса да (ул элек булды микән?!) үзен чын кеше дип хис итәргә өмете туды, егетлек миңа да хас, дигән бөек уй аның психикасында үзенең зур эшен башлады. Гөлүсәнең унҗиде яшькә олырак булуы турында ул хәтта уйламады да. Гөлүсә апа дип эндәшкәч Гөлүсәгә кызык, ул көлә. Гөлүсә апа. Рәхәт аның белән! Хәтимә әби генә нәрсәдер сизенә, ахры, аның йөзе караңгыланды, Фәизгә карата мөгамәләсе дә сөйләшүендә беленә башлады. Гөлүсә чардакка менгәч тә, юктан эш табып, астан кычкыра:

— Гөлүсә, бар су алып кайт! Гөлүсә, бар кибеткә!

Атна-ун көн вакыт узгач, Гөлүсә бөтенләй юк булды. Эштән кайткан саен Фәиз, ишектән кереп чардакка менә торган баскычка җиткәч, йә тамак кырып, йә башка төрле ысул белән үзенең барлыгын, кайтканлыгын белгертә иде.

Менә Гөлүсә бер көн юк, ике көн, өч көн. Әбидән соравы уңайсыз. Юк, күренми Гөлүсә. Калынрак булуга карамастан, матур яңгырый торган тавышы да ишетелми.

Шулай да беркөнне Фәиз Хәтимә әбидән сорарга җөрьәт итте. Әби нидер эзләп чардакка менде дә кыштыр-кыштыр килеп почмактагы иске обойларны араларга тотынды.

Фәизнең соравы сәер, кызык килеп чыкты:
— Әби, Гөлүсә апаның берәр әйберсен эзлисеңме әллә?
— Аның нәрсәсен эзлим мин?! — дип сорауга сорау белән җавап бирде әби.
Бер сүз каткач туп-туры сорарга булды:
— Кайда соң ул, күренми?
— Нәрсә күренми? — дип кашларын җыерды әби, әллә аңламыйча, әллә юри кыланып.
— Гөлүсә апа күренми.
— Өеңдә Гөлүсә апаң. Кайда булсын ул!
Әби эзләгән әйберен тапмады, ахрысы, буш кул белән баскычка таба юнәлде.
Аның төшеп китәргә җыенуын чамалап, Фәиз ашыгып сорап куйды:
— Фатирларын бүлделәрмени?
— Ни сөйлисең син, нинди фатир бүлү! — диде әби ачуланып.
Аның болай ачулы булганы юк иде, шуңа күрә Фәиз аның ачуын китергәнгә үзен бик уңайсыз хис итте.
— Ире белән аерылышырга йөри иде...— диде ул, башын иеп.— Шуңа гына соравым.
— Нинди аерылышу ди инде! — диде әби усал итеп. Аның бу җикерүе Фәизгә түгел, гомумән, барлык аерылучыларга, гаиләләрен саклый алмаучыларга багышланган иде.— Татулаштылар алар ире белән, тагын бергә тора башладылар. Нинди аерылышу ди инде ул тагын! Үсеп җиткән кызлары бар. Ай, нинди замана, ә! Оят та юк, бәрәкәт тә юк! Ай-һай...
Хәтимә әбинең соңгы сүзләре баскыч астыннан тонык кына булып ишетелде.
Фәизгә каты удар булды бу. Менә ничек икән, саубуллашмыйча да китеп барды. Ничек алай була инде.... Гөлүсә белән аның арасындагы хисләр, мөнәсәбәтләр алай тиз арада тапталыр дип уйламаган иде ул башта. Ничек инде ул, Фәизгә бер сүз дә әйтмичә? Гүя, Гөлүсә күңеленең бер почмагын ертып алып китте. Алып киттеме, берәр җиргә ташладымы. Туктале, туктале... Ул бит Фәиз белән вакыт уздыру өчен генә, монда тик ятмас өчен генә уйнаган булып чыга түгелме?! Уйлар караңгыланганнан-караңгылана барды. Тагын бер чираттагы коточкыч уй аны һушсыз калдыра язды. Гөлүсә миннән канәгать булмагандыр. Мин аны канәгатьләндерә алмаганмын. Шуңа күрә хушлашмыйча да китеп барган ул. Минем көчем җитмәгәндер, ирлегем җитмәгәндер. Шул сәбәпле иренә кайтып киткәндер ул. Шулай итеп, ул янадан үзен булдыксыз, көчсез, бернигә ярамас кеше дип башына сендерергә тотынды.
Асылда исә алай түгел иде. Гөлүсә гаиләне таркатмас өчен, кызын ятим итмәс өчен ире белән тагын бер тапкыр гына булса да уртак гаилә тормышын торгызып карарга талпынды. Фәизгә карата мәхәббәте булмаса да, аңардан канәгать булмады дип әйтерлек түгел иде. Бала-чага иде ул аның өчен, фәкать тормышының күңелсез бер мәлендә аяк астында чалынган бер малай гына иде. Ләкин егетнең ирлегенә килгәндә, бу мәсьәләдә аның бернинди ризасызлыгы юк иде, хәтта бу хакта уйлап та караганы булмады. Бераз рәхәтләнеп алдылар һәм бетте шуның белән! Фәиз башка үсмерләрдән артык та, ким дә түгел иде. Үсмерләр алар тора-бара ныгыйлар ир буларак.
Ә Фәизнең бу вакыйгага карашы үзгә булды. Ул үз-үзен әр-яңадан битәрли башлады. «Дөрес эшләдем микән, ул теләгәнчә булды микән», дип Гөлүсә белән шыгырдавыклы караватта булган һәр минутны искә төшерергә тырышты. Үзендә тотрыксызлык тою янә эләктереп алды. Гөрзи белән башка суккандай итеп ТЕГЕ ВАКЫЙГА искә килеп төште. Хәер, ул тәгаен онытылып, хәтердән гаип булмаган иде. Ул фәкать вакытлыча гына, яңа куәт белән орырга хәл туплап, аңның бер почмагында сагалап торган булган. Зәбирнең сазлык өстеннән калкып торган акайган күзләре чардак тәрәзәсеннән караган кебек тоелды. Гөлүсәнең

саубуллашмыйча, киткәндә бер генә җылы сүз дә әйтмәве гаҗәеп авыр тәэсир итте. Үзен тукмарга, «ашарга» сәбәп кенә кирәк иде Фәизгә. Чөнки эш үзен булдыксыз дип түгел, юып бетермәслек гаепле тоюда иде. Гөнаһын, кылган яман эшен юып, чистарына алмам дигән коточкыч уй каядыр тирәндә сулкылдый иде. Шуңа күрә ул үзендә тотрыксызлык, хәлсезлек сизде. Аны белән ул аны тотып аңлый алмый иде. Уй да түгел, нииндидер яман тойгы иде ул.

Бәгырь тамырларына ябышып, нерв җепселләренә тотынып, нәрсәдер югары үрмәләде. Вөҗүд кысылып калды, куркыныч уйлар бер-бер артлы түгел, бөтенесе бергә башка тулып, чуалып беттеләр. Һава җитми башлады. Фәиз салкынаеп калган куллары белән тартылып агарган битен сыпырып куйды. Тышка, урамга чыгарга кирәк. Юк, урамга түгел, анда кешеләр йөри. Казанка буена.

Саф һавага чыккач спазмалар бераз йомшарды, тәндәге тартышу да кимеде, куллар җылынып китте. Китәргә иде, дип уйлады ул. Китәргә иде. Аның китәсе килде. Кайдан? Һәм кая? Бу дөньядан китәргәме икән әллә? Ул әле бу турыда уйламый иде. Дөньяның яме югалса да, үзенә кул салу турында аның әле бер генә тапкыр да уйлаганы булмады. Дөрес, Зәбир белән сазлыкта батып үлсәм яхшырак булыр иде дип уйлады уйлавын, әмма үзенә кул салу теләге бик авыр минутларда да әле моңарчы тумады. Китәргә иде!

Үзеңнән китү мөмкинме соң ул?! Юк, булмый үзеңнән качып! Алай бик җиңел, бик рәхәт булыр иде дә ул, юк шул, булмый.

Нишләп милиция начар эшли икән, дигән бер сәер уй килде башына. Һаман тоталмыйлар. Әллә эзләмиләр микән? Эзләвен эзлиләрдер. Тотарлар микән аны? Тотсыннар әйдә. Ә бит төрмәдә читендер. Ә болай рәхәтме? Тотсалар, бәлки җиңелрәк булыр иде, тиешле җәзасын алыр. Юк, куркыта төрмә. Ә болай иректәме соң?! Юк, хәзинә өчен хөкем итәчәкләр. Ә Зәбирне бу дөньяга кайтарып булмас инде. Юк, юк, үзләре тотсалар гына. Үзе ник барсын ул?! Аны дусты батып үлгән өчен хөкем итмәячәкләр. Аны кибет баскан өчен төрмәгә утыртачаклар лабаса!

Күзгә кичнең эңгер-меңгер төшкән вакыты иде. Ул бик озак болганчык суга карап утырды. Кайтмаска иде шул чардакка. Бармаска иде шул заводның мең авазлы шау-шуына. Алып ташларга иде бу йөкне. Каезлап алып ташларга иде күңелнең бу сыкрауларын. Болганчык су агамы, бер урында торамы — аңларлык түгел иде. Шулай тораташ булып күңелнең болганчыгында казынып утырганда аның башында бер фикер туды. Әлеге уй аны җилкендереп, хәтта күпмедер дәрәҗәдә канатландырып та җибәрде кебек. Зәбирнең мәетен барып табарга кирәк! Аны чыгарырга кирәк сазлыктан. Күмеп куярга кирәк, кешеләрчә, кабер ясап. Хәзер үк шул тарафларга китәргә һәм дустын сазлык төбеннән табып алырга теләгәндәй ул җәһәт кенә торып басты. Хәтерли бит ул урынны, һичшиксез, эзләп табачак аны. Туктале, үзе генә гамәлгә ашырырмы соң бу ниятне?! Аны ничек чыгармак кирәк... Үзем дә батачакмын. Ул кинәт үзенең үлемнән курыкканын сизеп алды. Куркам икән бит мин батып үлүдән, диде ул үз-үзенә. Берничә кеше барсак, бәлки башкарып булыр. Ә кемне алып барырга соң? Кемем бар соң минем? Беркемем дә юк. Шулай да, ичмаса тырышып карарга кирәк. Зәбиргә бердәнбер соңгы ярдәмем булыр иде. Аз гына булса да гаебемне киметер иде бу адымым. Сазлык төбеннән мәетне ничек эзләргә кирәклеген күз алдына китерә алмаса да, аның шунда, ШУЛ УРЫНГА кичекмәстән барасы килә башлады. Монда, ул урыннан еракта уйлар ныграк куркыта. Ә анда баргач, мәетне йоткан сазлык куркыныч булса да, уйлар бу кадәре үк газаплы һәм коточкыч тоелмас кебек.

Икенче көнне бригада мастерыннан ике атналык түләүсез отпуск алып булмасмы дип кызыксынды. Мастер каршы килмәде һәм вәгъдә дә итмәде. Тизрәк, кичекмәстән барырга кирәк, юкса озакламый кыш җитә-

чәк бит, дип аңлатып булмый шул мастерга. «Октябрьнең икенче яртысында уйлап карарга булыр»,— диде мастер, кат-кат үтенгәч.

Дустының мәетен сазлыктан чыгара алса, җан газабы кимер иде шикелле тоелды аңа. Тик менә куркыта бит, куркыта. Әле бит анда бару да куркыныч. Коточкыч урын бит ул. Аннары... мәет нинди кыяфәттәдер бит. Сасып, череп бетмәде микән? Хәер, сазлыкта мәет черемидер. Шулай да куркыныч. Җан өшеткеч күренешләр аның фантазиясен нык эшләттеләр. Әмма ничек кенә куркыныч булмасын, ул анда барырга тиеш. Бу аның бурычы. Үлемнән коткара алмаган икән, ичмаса мәетен, һәрхәлдә сөякләрен булса да коткарырга тиеш ул!

Шушы уй-ният белән йөргән көннәрдә военкоматка еш чакыра башладылар. Медкомиссияләр үтте, тешләрен пломбаладылар, аласын алып ташладылар.

Һәм, беркая да китмичә, яңа повестка көтәргә куштылар.

Аны иң гаҗәпләндергәне медкомиссиянең соңгы нәтиҗәсе булды: ул яраклы иде.

Армиягә алалар! Куанычлы хәбәр иде бу аның өчен. Бигрәк тә психологик яктан аның «яраклы булуы» үзен гел булдыксыз, көчсез, әшәке дип санаудан күпмедер дәрәҗәдә арындырып торырга ярдәм итте. Тик менә, ТЕГЕ УРЫНГА барып булмас микәнни? Сазлык аны инде тагын да ныграк тарта иде үзенә. Армиягә китеп нәрсәдән булса да котылам дип куанса да, күңелендә әлеге сазлыкка тартылу бар иде аның. Бу — психиканың авыр, кичеп чыккысыз депрессияләр сазлыгына таба тартылуның чагылышы иде, ахрысы. Фәиз моны аңламый, ул фәкать үзенең бөтен сазлыклардан өстәрәк чайпалган, бу дөньяның миллионнан бер өлешен генә дә тәгаен аңлап бетермәгән аңы белән яшәешне тоеп гомер сөрүен дәвам итте.

ТЕГЕ УРЫН үзенә гел тартып торса да, КИТҮ хисе шулай ук көчле иде. Кайвакыт бу өметле хис күп тапкырлар көчлерәк, сихәтлерәк булды.

Әмма ТЕГЕ УРЫН аны мәңге ташламаячагын да аңлый иде, тик күңеле үзгәреш таләп итте, чөнки шул сурәттә аның УЛ УРЫНГА мөнәсәбәте үзгәрү ихтимал иде.

Фәиздә һаман өмет яшәде: «Кулымны ныграк сузган булсам, Зәбирне коткара ала идем. Ник сузмадым???» — дигән сорауга кайчан да бер җавап табылыр. Ләкин моның өчен тынычланырга, УЛ ВАКЫЙГАНЫ кат-кат анализлап аңларга кирәк!

Армиягә ашкынуы да кайгыдан куркып бөтенләйгә качу ниятеннән түгел ләбаса. Анда, еракта, онытылып, баштагы боламыкны тәртипкә салгач, аңларга мөмкин булыр: гаепләме ул, юкмы? Гаеплесен һичшиксез гаепле ул! Әмма күпме дәрәҗәдә гаепле? Берәр ничек акланып, чистарып, яшәүне дәвам итәргә хаклы булырмы ул? Насыйп булырмы аңарга?.. Дустын югалтуны, аның фаҗигале үлемендә үзенең гаебен капларлык берәр чара, берәр мөмкинлек тумасмы киләчәк тормышта? Дөнья киң, аны хәтта чиксез дә диләр. Гомер дә шактый озын, яшиселәр алда бардыр бит әле. Ни гаҗәп! Яшисе дә килә әле!

Ноябрьнең башында Фәиз, призывник булып, Татвоенкомат ишегалдында авызына тәмәке төпчеге кабып, үзе шикелле үк сәләмә киемле үсмерләр төркеме арасында, кай тарафларда хезмәт итәргә язган икән дип, түземсезлек белән көтеп йөри иде.

Татвоенкоматның шыксыз барагында, меңләгән призывниклар арасында, коры тактадан эшләнгән нар өсләрендә шактый вакыт аунарга туры килде.

Дүрт тәүлек йоклар-йокламас, ашар-ашамас ятканнан соң, ниһаять, аны ике йөзенче командага билгеләделәр.

Бу команданы поезд урманнар, кырлар, шәһәрләр, күперләр аша Белоруссиягә таба алып китте.

## 1

Ноябрь ае Белоруссиядә алтын көз чоры икән. Биек наратлар, түшәк-түшәк томаннар — барысы да нәкъ җырдагыча яңгырап, китаптагы кебек күз алдына гүзәл табигать, матур чынбарлык булып килеп басты.

> «Молодость моя, Белоруссия,
> Песни партизан, сосны да туман».

«Песняры» ансамбленең җыры поезд вагоннарына тулды, бу матур җыр нәкъ вакытында яңгырады, әйтерсең лә, күп сугышларны кичереп, үзенә миллионнарның канын һәм күз яшен сеңдергән белорус җиренә кергәндә әлеге моңлы җыр дога урынына иде.

Күпме сугышлар узгандыр бу җирләр аша, ничәмә телдә сөйләшүче гаскәрләр сокланып үткәндер күк гөмбәзенә кадәр сузылып үскән бу наратларга, корбаннарын — үзенекен дә, дошманныкын да — үз кочагына алган изге җирне михнәтләрдән саклап капларга яткан шушы куе томаннарга.

Инде ап-ак карга күмелгән Казаннан соң тагын чалт кояшлы алтын көз кочагына килеп керү сабыйлыктан әле тәмам арынып бетмәгән яшь солдатларга кызык һәм рәхәт тоелды. Шау-шу катырак яңгырады, шаярулар, мәзәк сүзләр, ачусыз һәм нәфрәтсез сүгенүләр, шаркылдап көлүләр — ваемсыз бер гауга булып болай да калтырап барган вагоннарны гөрселдәтте.

Фәизгә үзе кебек йөзләгән малайлар арасында җиңелрәк иде, моңа ул хәтта гаҗәпләнде. Шартлар бик уңай булмаса да, аның өчен бу яңалык, зур үзгәреш иде. Хәзер инде кырыс тавышлы офицерларның кычкырып-кычкырып боеруларына буйсынасың, монда инде син үзеңнеке түгел. Бу халәт, гадәттә, призывникларның күбесенә авыр тәэсир итә. Аларның буйсынасылары килми, ирекне яратучы һәм аңа һәрвакыт омтылучы яшьлек боеруны гомумән яратмый. Фәиз исә бу халәтне күңел шатлыгы белән кабул кылды, чөнки аңа авырлык, җәза кирәк иде, юлында киртәләр булуын теләде ул. Шуның белән бергә аңарда мең шифалы, мең дәвалы горурлык хисе дә барлыкка килде — ул да солдат, ул да бу өч йөздән артык үсмерләр рәтендә, ул да беркемнән дә ким түгел. Аның соңгы вакытта тәмам какшап беткән психикасы өчен гаять зур, бөек хис иде бу.

Хәрби частькә җитәрәк булачак солдатлар барысы да айнып беттеләр, эчәсе аракылар эчелеп бетте. Нинди часть, нинди гаскәр икән — әле мәгълүм түгел иде. Үзара имеш-мимешләр таралды: имеш, «яшерен гаскәр» икән. Армиядә «бабайлар» яшьләрне кыерсыталар, кыйныйлар, үзләре өчен эшләтәләр дигәнне һәркем гражданкадан ук ишетеп белә иде. Частькә килеп җитәрәк бу турыда барысы да уйлана башлады. Поездан төшеп, строй белән комлы юлдан барганда инде шаярулар сүрелде, барысы да «бабайлар» ничек каршылар икән, дип шүрләбрәк атлады. «Бабайлардан» да куркынычрагы, әлбәттә, билгесезлек үзе иде.

Бу часть ракета гаскәрләренең «учебкасы» булып чыкты. Монда, алты айга якын, ракета гаскәрләренә сержант званиесендәге специалистлар хәзерлиләр, шул сәбәпле батальоннарда «карт» сержантлар гына бар иде (аларны «замок» дип атыйлар). Бу хәбәр кинәт боегып калган һәм әниләрен сагына башлаган такыр башлы малайларга бераз дәрт бирде. Хәрби кием кигәч, бер вагонда килгән малайлар бер-берсен башта танымый тордылар. Яңа кыяфәткә керү кызык та, куркыныч та иде.

Төрле батальоннарга таратылгач, бер командада килгән егетләр бер-берсен югалтып та бетерделәр.

Фәиз алтынчы батареяга эләкте. Алты взводтан торган батарея бер казармада урнашкан булып чыкты.

Беренче төнне үк казармада кабер тынлыгы хөкем сөрде.

«Замок»ларның үзәк өзгеч тавыш белән: «Подъем!» — дип акырулары казарманы түбәннән үк кубарып алгандай булды. Бөтен нәрсә бергә буталып бетте: ак ыштанлы малайларның кием эзләп кайнашуы, күнитекләр, әле исләнергә өлгермәгән ыштырлар, гимнастеркалар, куллар, аяклар, коточкыч ыгы-зыгы, этеш, кычкырыш, сүгенү, кабаланып киенү...

Совет армиясенә хас чуарлык батарея тезелеп баскач шундук күренде. Кем генә һәм нинди генә солдат юк иде монда. Шыр сөяклесе дә бар, тупырдап торган түгәрәге дә, кәтүк хәтле гәүдәлесе дә, башы түшәмгә тиярдәе дә.

Аларның барысын да бер үк нәрсә укмаштыра иде: коммунизм идеяләренә тугры булып, Октябрь илен саклау! Коммунизм идеяләрен саклау һәркемнең изге бурычы иде — телисеңме, юкмы.

Теләми кара!

Анда әнә Кытай тик тормый. Америка белән мөнәсәбәтләр начарланып бара. Калак сөягең гимнастерканы ертып чыгарга җитешеп тырпаеп торса да, син ярты глобусны биләп алган Туган илеңне сакларга әзер булырга тиешсең. Буең батарея командирының кендегеннән генә булса да, син сафта үрә катып торырга тиешсең.

Учебканың ни икәнлеге беренче көнне үк аңлашылды. Китте муштра да, эш, строевая подготовка, политподготовка, махсус занятиеләр. Каты режимга күнегү шактый авыр булса да, аның тигез ритмда, минутына кадәр төгәл баруы яшь организмга икенче яктан уңай тәэсир итте.

Физик күнегүләрдән нык курыкты Фәиз. Турникта бер генә күнегүне дә үти алмый җәфа чикте. Хәтта бер-ике тапкыр тартылганнан соң хәле бетеп сикереп төшә торган иде. «Замок» сүгенеп, инде әллә ничә тапкыр аны бөтен взвод алдында бетереп ташлады:

— Җыен ублюдокны армиягә алалар! Син бит булачак сержант, мать твою!..

Беренче ун көн эчендә үк инде Фәиз үзенә төбәлгән мыскыллы сүзләрне күп ишетте. Арада аның шикелле ябык, бәләкәй солдатлар тагын бар иде, әмма, никтер, «замок» аңа каныкты. Никтер ошатмады Фәизне. Әллә Фәизгә генә шулай тоелдымы? «Замок» милләте буенча чуваш иде. Олы колаклы, чувашка бөтенләй охшамаган табак битле, таза өлкән сержант иде ул. Фәиз махсус занятиеләрдә гел бишлегә генә укыды, фәнгә башы әйбәт эшли иде аның, тик шуңа да карамастан Кулиш («замок»ның фамилиясе шулай иде) Фәизгә гел бәйләнеп торды.

Взвод командирлары, батарея командиры һәм аның урынбасарлары, замполитлар көндез берничә сәгать күренәләр дә, кайдадыр юкка чыгалар, курсантларны «тәрбияләү тулысынча «замок»лар өстенә төшә, «замок»ларның казармада аерым бүлмәләре бар, алар шунда йоклыйлар, тәүлек әйләнә режимның сәгатеннән-сәгатенә төгәл буйсынып, батареяның җан тирен чыгаралар иде. Устав, ант, режим, коммунизм сакчылары... Ни сулга, ни уңга, ни алга, ни артка. Сарык көтүе шикелле буйсын, йөгер, эшлә, команда белән ят, команда белән тор!

Фәиз, нечкә күңелле буларак, кимсенүләргә бик сизгер иде. Иң рәнҗеткәне — башкалар алдында ачуланулары, төрле мыскыллы сүзләр белән битәрләүләре. Андый вакытта, киресенчә, үзеңә тагын ныграк бикләнәсең; тирәнгәрәк посарга тырышасың һәм инде болай да барлы-юклы хәл бөтенләй бетә дә куя. Сүгенеп кычкыруы да ярар. Ул бит саф алдында каршыңа килеп, битеңә төкрекләрен чәчеп кычкыра. Җавап биреп тә, акланып та булмый. Фәиз үзендә гаеп сизсә дә, бер үк вакытта аптырашка кала иде: «Бу чуваш, югыйсә, якташ бит, ник болай артык каты бәрелә икән? Булдыксызлар мин генә түгел, әнә күпме алар. Кушылган эшне җиренә җиткереп башкарам, занятиеләрдә гел бишлегә укыйм,

турник кына инде менә». Күмәк хезмәт рәхәт булыр шикелле иде, алай түгел икән ул. Армиядә котылу табармын дигән иде, алай түгел икән.

Тора-бара нык рәнҗи башлады Фәиз. Кулишка гына түгел, гомумән, кемгәдер, нәрсәгәдер. Бернигә яраксыз икән, дигән әшәке бер хис янә нерв җепселләре буйлап үрмәләде. Хәле түзәрлек икәнне Фәиз үзе дә аңлый: режим бар, солдатларча ашау, иртәнге зарядкалар, йөгерүләр, нарядлар. Дөрес, түзәрлек, әмма «замок»ның бәйләнүләре, взвод командиры килгәч, Фәиз турында аңа «слабый» дип әйтүләре казарма атмосферасында үзен-үзе битәрләнүдән кинәт тышкы якка юнәлтелә башлады.

Фәизнең караваты белән янәшә татар фамилияле солдат ята иде — Мирзин. Ул урта буйлы, тыгыз гәүдәле һәм бик тере, җитез егет. Инде атна-ун көн үтүгә карамастан, алар әле һаман үзара таныш түгелләр иде, чөнки режим шулкадәр каты, отбойдан соң шундук йокыга китеп, иртәнге подъемнан башлап тагын отбойга кадәр һич аралашырга вакыт булмады.

Алтынчы батареядан беренче дивизион нарядына Фәиз дә эләкте.

Ашханәгә бәрәңге әрчергә нарядка Кулиш Фәизне, Мирзинны, тагын ике украин егетен билгеләде. Шунда танышып киттеләр.

Зур ванна янына бәрәңге әрчергә утыргач Фәиз, татарча эндәште:

— Син татар бугай?

— Әйе,— диде Мирзин.— Но татарча начар сүлим.

— Кайсы яктан?

— Татариядән. Т. шәһәреннән.

Фәизнең шатлыгы чәчрәп чыкты:

— Чынлап әйтәсеңме?! Мин дә шуннан бит. Шунда тудым. Әни үлгәч, детдомда яшәдем.

Ул кинәт караңгыланып, коелып инде. Өстенә тау ишелгәндәй, бөтенесе бергә аның хәтеренә җимерелеп төште.

— Тешең сызлыймы әллә? — дип сорап куйды Мирзин.

— Юк. Болай...

— Детдом искә төштеме?

— Әйе.

— Исемең ничек?

— Фәиз. Ә синеке?

— Ренат.

— Кайсы урамда яшисең анда?

— Менделеев урамында. Родительләр лесхозга күчтеләр. Батя шунда эшли потому что. Т.дагы квартира да үзебезгә калды. Батя, сволочь, мине җитәкләп военкоматка илтеп бирде. А то бы хәзер техникумда укыр идем, квартирада берүзем. Кызлар, гулянкалар... сам понимаешь.— Ул лачт итеп төкереп куйды.— Давай закурим.

Тәмәке кабызып әңгәмәне дәвам иттеләр.

— Ә нишләп әтиең җитәкләп алып барды военкоматка?

— Не говори! Как будто аннан башка алып китмәсләр иде армиягә. Мин гулять любил, милициягә забирали...

— Аңлашылды. Сиңа армиядә дә начар түгел, тазалыгың бар, турникта шәп бөтереләсең. Мин генә ул...

— Да-а, син хилыйрак шул,— дип куйды Ренат.— Теге чуваш сине шуңа яратмый бит.

— Кулишны әйтәсеңме?

— Ну. Я не понимаю, син нәрсә, аның оскорблениеләренә түзәсең?

— Ә мин нишли алам?

— Ну син әйт, алай сүләшмә диген... Жаловаться буду, диген.

— Алай ярамас,— диде Фәиз, авыр сулап.— Сержант дәрәҗәсен алмассың, ди бит әле ул.

Ренат авызын кыйшайтты:

— Ник... кирәк ул сержант званиесе?!

Фәиз Ренатның битарафлыгына һәм ныклыгына сокланып утырды. Менә шундый булсаң икән ул!

Алар әрчелгән бәрәңге белән ванна тулганчы рәхәтләнеп сөйләшеп утырдылар. Ренат белән булган әңгәмә Фәизгә ничектер көтелмәгән яңа тәэсир ясады. Нәрсәнедер башкарып чыга алмыйм икән, нишләмәк кирәк, гаепле булсам да, мине армиягә алуларына мин гаепле түгел ләбаса. Ренатның теләктәшлек белдерүе аның соңгы вакытта нечкәреп килгән һәм көннән-көн ныграк уяна барган гаделлек таләп итү хисен тагын кузгатып җибәрде.

Үз-үзен битәрләвенең тышка бәреп чыгуы, аңа карата агрессия белдергән объектка юнәлтүе шул вакытларда башланды. Якташының, милләттәшенең янәшә булуы, аның сүз белән булса да ярдәм итүе Фәиз өчен зур нәрсә иде.

Буйсынасы килми башлады. Көнаралаш диярлек чираттан тыш наряд алырга тотынгач, аның нәфрәте арткannан-арта гына барды.

Бервакыт шулай офицерлар шәһәрчегенең клубында концерт булды. Бөтен батарея концертка китте, һәрбер взводтан берәр кешене идән юарга, урын-җирне тигезләргә, кыскасы, казарманы җыештырырга калдырдылар. Алтынчы взводтан, әлбәттә инде, Фәиз калды. Ул үзенең взводы яши торган почмакны җыештырырга тиеш иде.

Шунда ул катгый карарга килде: кыл да кыймылдатмыйм! Үпкә, рәнҗү, нәфрәт белән кинәт аның күзләре томаланды. Туалетның тәмәке тарту өчен ясалган бүлмәсенә керде дә тәмәке тартып, уйга батып утырды. Кинәт ул үзенә беркемнең дә боерырга хакы юк дигән кискен фикергә килде. Башкалардан ким яклары булса да, аның бит өстен сыйфатлары да юк түгел. Хәйран башлы, бишлегә укый. Аннары, ул кичергәнне бу казармада хет берәрсе күрдеме икән?! Берәрсе Фәиз кичергәнне тойдымы икән? Кинәт күңел ярсый башлады, әллә тәмәке күп тартудан, әллә ардырган иде — тыны бетә башлады. Дөнья караңгы төскә буялды. Хәрби тормыштан яңалык, үзгәреш көткән булып... Монда исә җинелрәк түгел икән. Алай гынамы, сине куралмаучы кеше көн саен каршыңда басып тора һәм кычкыра, сүгә, мыскыллый. Аның бит әле взводтагы иптәшләре дә санга сукмыйлар. «Замок» суккәнгә генә түгел, гомумән, стройның иң соңгы кешесе булып торган солдатны кем ихтирам итсен инде. Күз аллары караңгыланып китте, кинәт ниндидер бик таныш халәт бугазга ябышты. Кемдер, нәрсәдер каршында үзеңне гаепле, җаваплы итеп тою. Бу бит *теге* халәт. Ул бит *теге вакыйга* нәтиҗәсендә туган халәт. Оят, хурлык! Бу кичеп чыккысыз халәт иде! Кем алдында оят? Кем каршында хурланырга?! Кулиш каршындамы? Татарны куралмаучы чуваш алдындамы?! Ул бит, замок булса да, яшь ярымга гына өлкәнрәк Фәиздән! Ә монда Кулишның ни катнашы бар соң? Фәизнең башында уйлары чуалып бетте. Бите тартылып калды, куллары салкынайды. Аяклары оебрак киткәндәй булды. Күнитекләрен салып, чолгауларын яңадан сүтеп урады. Аяклар да салкын иде. Бетте баш! Армия коткармады бугай мине. Минем ниләр кичергәнне батальонда, армиядә беркем белми. Шулай булгач, ник куралмый мине «замок»? Әллә берәр сәерлек сизә микән миндә? Күзләремнән укый микән әллә берәр нәрсә?

Уйлар тагын *теге вакыйга* тирәсенә алып киттеләр. Эзлиләр микән? Төрмәдә җиңелрәк булмас иде микән? Зәбир, Зәбир. Зәбир бәхетлерәк булып чыкты түгелме?! Минем кебек җәфа чикми. Шундук дусты алдында зур гөнаһлы икәнен тагын тойды, спазмалар бөтен тәнне әсир итте.

Ул шулай оеп утырганда бинаны гөрселдәтеп батарея концерттан кайтып керде.

...Кулиш аны отбойдан соң политзанятиеләр үткәрелә торган Кызыл почмак бүлмәсенә алып керде. Фәиз бүлмә уртасында линолеумның саргылт сызыкларына текәлеп катып торганда «замок» аның тирәли йөренде.

Беренче соравы аның бөтенләй көтелмәгән яктан булды:

— Син, чыннан да, татармы?

— Татар,— диде Фәиз, татар булганы өчен дә гаепләүләрен сизеп һәм кимсенеп.

— Мондый сары чәчле татарлар да буламыни?

Кара чәчле чувашлар да бар бит дип әйтәсе килде Фәизнең, әмма ләкин алай дип әйтсәң — бетте баш! Ул фәкать иңнәрен генә сикертеп куйды.

— Нишләп приказны үтәмәдең? Расположениедә нишләп уборка ясамадың? — дип җикерде Кулиш боегып берешкән солдат каршына басып.

— Син ник миңа гел бәйләнәсең? — дип ычкындырганын Фәиз үзе дә сизми калды.

Кулишның табак бите кып-кызыл булды, яңак җепселләре кыймылдый башлады:

— Нәрсә-ә?! — дип сузды ул, шаккатып.— Син начальнигың белән ничек сөйләшәсең?!

Фәиз тавышын күтәрде:

— Син миңа беренче көннән ук бәйләнәсең! Мин эштән дә курыкмыйм, режимнан да, укуым да әйбәт. Турникта да бөтерелә башлармын әле! Ник миңа каныгасың?!

Кулиш моны көтмәгән иде. Хәтта югалыбрак та калды. Аның инде олы колаклары да кып-кызыл булган иде. Ул беркавым, борын тишекләрен киңәйтеп, үзенең кыюлыгыннан үзе куркып агарып каткан курсантка карап торды да гәҗит-журналлар өелгән өстәл янындагы урындыкка барып утырды.

Пилоткасын салып гәҗитләр өстенә ташлагач, терсәкләре белән тезләренә таянып уйланып утырды.

— Мин синнән чын сержант ясамакчы идем, иптәш курсант,— диде ул аңа хас булмаган тыныч кыяфәт белән.— Син ракета гаскәрләренең иң җаваплы урыннарының берсендә хезмәт итәсе кеше. Гади солдат кына түгел, техник расчет начальнигы буласы кеше бит син.

— Гел нарядка куеп, строй алдында теләсә ни әйтеп ныгытмакчы буласыңмы мине?

Кулиш аягын аягына атландырып киерелеп утырды:

— Син нишләп әле минем белән «син» дип сөйләшәсең?

Фәиз төссезләнгән күзләрен күтәрде:

— Ә мин сине күралмыйм. Минем синең белән «син» дип тә, «сез» дип тә, гомумән, сөйләшәсем килми.

Кулиш авызын кыйшайтып елмайды:

— Син Совет армиясендә икәнлегеңне оныттың бугай.

Ник алай дип әйткәнен Кулиш үзе дә аңламый калды, чөнки курсантның нәфрәте, бигрәк тә аның ачыктан-ачык нәфрәтен белдерүе өлкән сержантка көтелмәгән хәл булды.

— Ник күралмыйсың син мине? — диде Фәиз, никтер Кулишның колагына карап.

Тегеңә кызык булып китте.

— Ха-ха-ха. Менә кызык, ә! Ул мине күралмый, ә мин аны яратырга тиешме? Син беләсеңме минем инде елдан артык синең кебек молокосослар белән командовать иткәнемне! Детдомнан да булды малайлар. Синең шикелле сарыкны беренче мәртәбә күрәм.

Фәиз аңа таба атлады:

— Син әйт миңа аныклап, нинди сыйфатларым ошамый? Турник...

Кулиш аны кырт кисте:

— Турник, турник... Син әллә нинди. Синең эчең ниндидер черек... При чем монда турник!

Фәиз җавап табалмый аптырап торды.

— Мәсәлән... Кайсы төшем черек? — диде ул.

— Синдә коллективлык, иптәшлек хисе юк.

— Бәлки, мин үз гомеремдә әллә ниләр күргәнмендер. Бәлки, минем кайгым бардыр?

Кулиш көлеп җибәрде.

— Бу яшьтә ниләр күрдең соң әле син?!

Фәиздә кинәт көтелмәгән бер теләк туды, ниндидер бер шеше тулып, тишелеп бушарга тиеш сыман тоелды аңа. *Теге* сазлыкта булган, *теге вакыйганы* сөйлисе килде аның. Гомумән, ничек Зәбир белән детдомда яшәгәннәрен, кибет басуларын, урманнарда адашып йөрүләрен һәм ниһаять, *теге вакыйганы*... Шуны сөйләсә, Кулиш та, батареядагы йөз сиксән кеше дә башкачарак мөнәсәбәттә булыр шикелле тоелды Фәизгә. Күңелендәге кайгысын ачып салса, аңа күп нәрсәне гафу итәрләр, көчсез булганы өчен, шул каһәр суккан турник өчен битәрләмәсләр бәлки. Ниләр кичергәнен тәфсилләп аңлата алса, аны, гомумән, аңларлар, кимчелекләрен кичерерләр бәлки. Башкаларга, гомумән, кешеләргә якынаер иде бәлки Фәиз. Ләкин үзен кичергәннәрне аңлатып буламыни соң! Хисне сүз белән җиткереп булмый лабаса. Хәтта әйтәсе килгән фикергә дә сүзләр җитеп бетми бит.

Ул, Кулишны сынаган сыман, ниндидер сәер бер караш белән аңа текәлеп торды. Юк, бу «замок» аңламаячак аны. Дөресрәге, ул аңлар, әмма үзенчә аңлаячак. Нәрсәдер комачаулый иде. Әллә алагаем олы колакларымы.

Кулишка аның кыяфәте кызык тоелды һәм «замок», сирәк елмая торган эре тешләрен якты дөньяга күрсәтеп, авызын ерды.

— Син көлмә миннән! — диде Фәиз таләпчән итеп.

— Ә син миңа тавышыңны күтәрмә! Сизәсеңме, сине взводта беркем дә яратмый. Хәтта Мирзин да. Ул да татар югыйсә.

Кулиш торып басты, пилоткасын киде.

Фәиз тагын коелып иңде. Ямьсез, тимер тавышлы Кулишның әйткәннәре хак тоелды аңа. Дөрес әйтә түгелме Кулиш?!

— Курсант Сибгатуллин!

Фәиз үрә катты:

— Мин!

— Йокларга, шагом марш!

— Есть!

Ул төнне Фәиз йоклый алмады. Кулишның әйткән сүзләре колакта чыңлап торды. Нәрсәдер сизеп, күреп алды бугай миндә. Эчең черек, ди. Хаклы түгелме соң ул? Минем белән аралашучы да юк бит взводта. Авыр, бик авыр иде бу казарма һавасы. Тир, чолгау исе белән куерган һава тамак төбен әчеттерде. Җитмәсә, бугазда төен төйнәлгән. Мәңге чишелмәслек төен!

*Дәвамы киләсе санда.*



# ШИГЪРИЯТ



## Нәҗибә Сафина

### ЯЗДА ШУНДЫЙ САДӘ МӘЛ БАР...

* * *

Исеңдәме ул көз, ул сентябрь?
Исеңдәме яфрак яңгыры?
Зәңгәр күккә кошлар күтәрелгән,—
саубуллашу өне яңгырый...

Исеңдәме ул көз, ул сентябрь?
Исеңдәме җылы яңгыры?
Зәңгәр күлләвектә сары яфрак,—
мәктәп кыңгыравы яңгырый!

Исеңдәме ул көз, ул очрашу?
Исеңдәме, көзге ул тынлык?
Фәкать йөрәкләрне ишетергә —
икебез дә дәшми тын тордык.

Көзге күлләвекләр көзге иде,
шул көзгедә күзләр очрашты:
Көзге күлгә, бөтен дөньясына
сыймас зур мәхәббәт без ачтык.

Шундый мәхәббәттән без качтык!..

### Ди-ва-на!

Бүген тагы син төшемә кердең:
Син яшь идең,
Мин дә яшь идем.

Мин тагы да киттем сине ташлап.
«Китмә»,— диеп хет бер дәш идең...

Кайтыр идем кебек, кайтыр идем,
Син дәш идең...
Эх, мин яшь идем!

Инде гомер буе
    менә шулай
Төшләр генә күреп яшимен.
Кояш көлә, җилләр әй уфтана.
Яфрак сөйли,
Чаган уйлана:
«Мәхәббәттән китү —
Ул кәүсәңне
Ташлап китүдер бит,
Ди-ва-на!»...

* * *

Мин кайттым. Мине өемдә
Беркем дә көтеп тормаган.
Катып калган сәгать теле,
Беркем ачкычын бормаган.

Мин калдырган килеш тора
Тустаганда сөтсез чәем.
Хушлашырга базмый шаулый
Инде үтеп киткән җәем.

Ачык калган тәрәзәмнән
Сары яфрак очып кергән:
Әйтерсең лә, минсез өйгә
Минем гомер — еллар килгән.

...Җәйдән калган тузаннарны
Сөртергәме, сөртмәскәме?
Гомеремнең көзе шакый —
Кертергәме, кертмәскәме...

## Язда бар шундый сәер мәл

Язда бар шундый сәер мәл:
Җуела иске эзләр,
Былтыргы яфраклар яна,
Елмая моңсу күзләр.

Язда шундый садә мәл бар —
Бөреләр керфек кага.
Бөреләрнең йөрәгендә
Соңга калган кар яна.

Бар шундый көч яз мәлендә:
Югала ара-чикләр.

Йөрәкләрнең кайтавазы
Бер-берсен тапкан чаклар.

Әй, садә, илаһи хисләр
Җирнең эченнән ага:
Җирнең язга узган чагы!
Мәхәббәт — йөрәк кага...

## Синнән миңа

Синнән миңа шулкадәр аз кирәк —
Бер җылы сүз генә.
Синнән миңа шулкадәр күп кирәк —
Син миңа түз генә.

Шулкадәрле синнән аз сорыйм мин —
Сөеп кенә кагыл.
Синнән миңа шулкадәр күп кирәк —
Илһам булып агыл.

Бик аз гына сорыйм. Бик аз гына —
Бары тик наз гына.
Күп тә сорамыйм бит: сөюемнән
Акылдан яз гына...

Күп тә түгел, аз да түгел инде —
Җаныма яз сорыйм,
Җылы сүзсез, назсыз, җанда язсыз —
Мин барыбер корыйм.

...Аллам бул, дип сорыйм!

## Төн — минеке!

Йоклап ятканнардан
Рәхәтләнеп көлеп йөри Ай:
Күпме югалтасыз, әй, кешеләр!
Нинди мәхәббәтне, ай-яй-яй.

Төн — минеке!
Йоклап ятканнарның
Тәрәзләрен кагып китә җил:
Күрми каласыз бит, әй, кешеләр!
Нинди хәрәкәттә дөнья гел.

Төн — минеке!
Йоклап ятканнарга
Челтер-челтер дәшә сулары:
Без китәбез, күрми каласыз бит,
Хушлашасы иде — шул бары.

Төн минеке!
Йокы кирәк түгел!

Йокысызга йөрәк кирәктер? —
Айга, жилгә, агымсуга салып
Мин чайкыймын төнге йөрәкне...

## Заман-челлә

Челлә. Көннәр шундый кайнар.
Тик йөрәгем кайнаррак:
Сандал өстендәге кызган
Тимердән дә болайрак.
Ләкин юкка гына аны
Үзгәртмәк булып кыйныйлар:
Күрмиләр — тормыш-сандалда
Җаным икәнен тоймыйлар.
Суккан саен утлы очкын,
Суккан саен кып-кызыл кан!
Рәхмәт инде тимерчегә,
Суккан саен тарала чаң.
Җанда челлә. Өннәр кайнар.
Кибә елга, кибә җырлар.
Буш ярларда ут агымы,
Җан-вулканнар атылалар.

Нинди авыр! Челлә... заман...
Тик, барыбер бәхетсездер —
Шул челләне татымаган!

## Бәргәләнү

Төн буена керфек какмый
Үткән төнем төнмени?
Кулларымнан эшем төшкән,
Сансыз көнем көнмени?

Яфракларга битем сөеп,
«Үп» — дип үтенгән төнем.
Кояшсыз, җылы карашсыз
Болытны куган көнем...

Болары да үтеп китте —
Көзнең саргайган көне.
Күңелемә сеңә генә
Коелган яфрак өне.

Төн буена уфлап йөргән
Мин түгел, бары җилләр...
Яфрак көүсәсеннән төште —
Мәхәббәт, мине җибәр!!!

Язмышымны җилгә салыйм —
Бәлки ул сиңа илтер.
Саргаеп кипкән яфраклар
Сөйлиләр келтер-келтер:
«Ышанма, җил — хыянәтче.
Гел каеручы гына.
Яфракларны көүсәсеннән
Ул аеручы гына.

Шул ук җилләр яңгыр ташый,
Беркетә безне җиргә.
Тапталып беткәч хәтта
Кирәлмибез кабергә».

Төн буена керфек какмый
Көткән кешем — син, беләм.
Сары яфрак-хисләремне
Таптый-таптый кем килә?
Көз көлә...

## Мансур Вәли

# ИРТӘНГЕ ПАРОХОД

НОВЕЛЛА

*Яшьлеккә, гүзәллеккә гел гашыйк булып яшәгән мәшһүр шагыйрь Нури ага Арсланның якты истәлегенә.*

— Кара әле, картлач... Син үзең менә шуны сизәсеңме икән?..— Эчке бүлмәгә узып бер мәл тыныч кына, басылып кына утырганнан соң Нурулла ашыкмыйча гына шулай дип сорап куйды. Һәм сүзеннән азга гына тукталып, эчендәге кичерешләргә тагын бер мәртәбә колак салып алды да, әйтергә теләгән фикеренең чыннан да дөреслегенә ышангач, үзе үк җавабын да бирде:

— Бу бүлмәңдә нindiдер бер илаһият бар бит синең! Ничектер җан иркенәеп, сулыш киңәеп, күңел канатланып китә кебек синең менә шушы бүлмәңә кереп утыргач...

Әйе, Нурулла белән Вахит бу бүлмәдә беренче мәртәбә генә утырмыйлар. Кордашы Нурулла үзенең яшьләрнекечә озын чал чәчләрен җилфердәтеп кунакка кергән саен, алар менә шушы артык зур да, әллә ни кечкенә дә булмаган уңайлы бүлмәгә үтәләр дә, аның түр почмагынарак — кышларын бигрәк тә тансык тоелган җылылык батареясына табарак куелган ике тирән кәнәфигә чумалар.

Хәзер инде аларның икесенең дә вакытлары күп. Һич кенә дә кабаланасы, ашыгасы түгел. Алтмышны тутырып ялга чыкканнарына да ун еллап вакыт узган бит инде... Бу фатирның хуҗасы булган Вахит үзенең җәмәгате белән тигез генә картаеп килә, ә менә Нурулла — шагыйрь кеше — гомере буена хатын-кыз белән бер түбә астында озак яши алмады. Хәзер дә, менә бу көннәрдә дә, ул — ялгыз. Ләкин үзенең Вахит дустыннан ерак түгел урнашкан йорттагы бер бүлмәле фатирында да ялгызы күпкә чыдый алмый ул. Таныш-белешләренә йөри, матуррак көн икән — озаклап урамда була, үзе әйтмешли, яратып кына кызлар күзли. Кордашы Вахит янына да бик еш сугыла ул. Бигрәк тә Вахитның «корткасы» каядыр чыгып киткән булса, алар — ике карт — озак-озак гәпләшеп, тәмләп кенә әңгәмә куертып утыралар.

Менә бүген дә, җәмәгате: «Сеңелләргә барып кайтыйм әле...» — дип чыгып киткәч, ничектер, эче пошып һәм бер эшкә дә кулы бармаганга күрә, Вахит үзе телефоннан хәбәр бирде Нуруллага.

Ара якын булгач рәхәт шул: озак көттермәде, кереп тә җитте Нурулла. Керә керешкә үк иркенләп, рәхәтләнеп көлә-көлә һәм бер үк вакытта чишенүен дә дәвам итеп:

— Нәрсә, әллә алып куйган әйберең бар идеме? — дип тә сораган булды.

Шулай шул — инде житмешен тутырган булса да, һаман яшьлеге белән саубуллашырга ашыкмый Нурулла. Урамга чыкса һаман кызлар күзли, каршысына чибәрләр очраса, бөтен дөньясын оныта. Бу фани дөньяның башка ләззәтләрен дә читкә куймый. Узып барышлый гына кереп, аяк өсте генә, йөзәр граммнарны «чиртеп» тә чыга ул. Кыскасы, картаерга теләми әле Нурулла! Һаман яшәргә, яшьлегендәгечә ут чәчрәтеп яшәргә кызыга Нурулла!

Менә хәзер дә ул үзе — кәнәфидә, ә үзе аңа гына сыя-сыеша алмаган тәсле гел кымырҗып утыра.

— Минем бүген, нишләптер, күңел кузгалып тора бит әле, малай... Әнә теге, синең тәрәзә артындагы тупыл сымак, «очып китәм, очып китәм» дип җилферди бит әле бүген минем йөрәк!

Шулай диде дә, олы олпат гәүдәсе белән кәнәфидән торып, авыр гәүдәсенең авырлыгыннан паркет идән такталарын шыгырдата-шыгырдата тәрәзә янына килде Нурулла. Ә аннары гүя бүлмәне дә, андагы кордашы Вахитны да бөтенләй онытты. Тын калды.

...Буйдаклар табыны әзер булып — ике кәнәфи арасындагы тәбәнәк өстәлгә бәләкәй генә ике касә һәм озын муенлы савытта шәраб, сыр, казылык телемнәре иплəп кенә тезеп куелгач, Вахит үзенең сабыр, йомшак тавышы белән җай гына итеп дустын өстәл янына дәште:

— Әйдә, монда табарак кил...

— Шулай дисеңме...

Нурулла башта борылып өстәл өстен күздән кичерде, акрынлап аның йөзенә канәгать елмаю җәелде. Аннары инде гадәттәге салмак-саллы адымнары белән урынына килеп утырды. Озын ап-ак чәчләрен — элек бик куе булып, хәзер инде шактый сирәкләнгән чәчләрен — артка сыпырып куйды. Аннары ул үз алдындагы касәгә текәлде. Кышкы тәрәзәдән төшкән яктылык касәдәге шәрабне гаҗәеп матур алсу төскә керткән, аны ниндидер бер яңа, илаһи эчемлеккә әйләндергән кебек иде.

Бераз шулай хисләнеп утыргач, Нурулла кинәт кенә Вахитка күтәрелеп карады. Сыек зәңгәр күзләрен мөлдерәмә итеп тутырып, гаять тә моңаеп, әллә нинди иләслек белән карады ул аңа... һәм бер генә сүз әйтте:

— Әйдә!

Икесе дә күтәреп куйдылар.

Тынлык. Гүяки бу тынлык житмешне узып баручыларның гомер кичләре тынлыгы... Гүяки бу — куркыныч һәм мәңгелек тынлыкның башы, менә шушылай башланып китүе иде. Авыр, бик тә авыр икән ул андый дәһшәтле, шомлы тынлык.

Вахит та үз кордашының күңел төбендәге уйларны чамалагандай булды.

— Әйе... Гомерләр узып китте... Әйләнеп карарга да өлгермәдек...— диде ул сузып кына.

Бу сүзләргә Нурулла игътибар да итмәде кебек. Башын игән хәлдә утыра бирде ул. Вахит исә, касәләр буш тормасын дип, аларны тагын тутырып куйды.

Ә Нурулла, бүтән көннәрдә бик тә иплəп-җайлап кына, әңгәмә арасында гына салгалап утыра торган Нурулла, бүген әйтерсең касәләрнең тулуын гына көтеп торган — дәшми-тынмый гына шундук икенчесен дә каплап куйды. Вахит аның карашы белән очрашырга теләп, күзләрен кордашына текәде, берәр төрле сүз, аңлату көтте. Ләкин Нурулла әлегә аңа игътибар итми. Гүя ул бер үзе, бер ялгызы эчеп утыра. Гүя Вахит, аның белән инде менә ничә ел сер уртаклашып яшәүче кордашы, монда бөтенләй дә юк.

Хуҗа кеше Вахит өчен авыр хәл иде бу. Үз фатирыңда бөтен күңелеңне биреп кунак сыйлап утырган килеш, сине күрмәсеннәр, исә алмасыннар әле — ихтыярсыздан ачуың килер, ирексездән күркәң кабарыр!

— Нигә дип әле болай...— Шулай дип сүз башлады да, ярты сүзендә төртелеп калды Вахит. Гәптәшен гаеплисе, битәрлисе килә сыман иде аның. Ләкин менә «ни өчен» дигәне үзе ачык кына билгеле түгел. Сүз югыннан сүз булсын дигәндәй «Нигә бер үзең эчеп утырасың?» дип булмый ич инде гомерлек дустына.

— Син, Вахидулла, аптырама әле...— Күңеленең аеруча нечкәреп киткән чакларында әнә шулай, үз исеменә якынайтыбрак эндәшә аңа кордашы Нурулла.

— Әз генә аптырарлык урын бар инде монда барлыкка...

— Шулайдыр анысы. Аптырарга да, гаҗәпләнергә дә мөмкиндер.— Нурулла тагын, үз эчендә аккан ниндидер серле дөнья агышын тыңлаган төсле берничә секунд кына тынып, уйланып торды, шуннан соң бөтенләй бүтән дулкынга күчеп сүзен дәвам итте:

— Бик тә ачык булыпискә төште бит ул көн... Шундый да якты, кояшлы булып. Кичә генә узып киткән көн диярсең! Мондый хәлнең инде байтактан бирле булганы юк иде.

Тагын тынлык урнашты. Инде Вахит та дустының күңел халәтен чамалый башлады кебек. Шуңа күрә аны үз иркенә куеп, ашыктырмыйча, бимазаламыйча гына утыра. Артык һәм урынсыз сүз ычкындырып кордашының менә хәзер, менә шушы минутларда тулып ташырга тиешле кичерешләр дәрьясына комачаулаудан, аңа аркылы төшүдән сакланып, тыелып утыра ул.

Бүлмәдә тып-тын. Бары тик күршеләрнең берсендә генә кемдер скрипка уйнарга өйрәнә, ахрысы — бу бүлмәгә, бу тарафка да өзек-өзек музыка авазлары саркылып керә. Якынлашып килүче эңгер һәм әнә шул ишетелер-ишетелмәс кенә скрипка тавышы әллә нинди бер серле мәгънәгә иядер кебек тоелып китә.

Нурулланы яшьлек хатирәләре биләп алганны яхшы аңлады хуҗа кеше. Ләкин зиһене юньлерәк сүз уйлап тапканчы аның теле болай дип әйтеп ташлады:

— Яшьлек сагындыра шул инде ул... Сагындыра! Һәркем үзенең яшь чагын: матур да, көчле дә булган чагын сагына. Әмма сагыну белән генә табигать, дөнья агышын үзгәртү мөмкин түгел шул...

Хуҗа кешенең әлеге сүзләрен башта ук кире кага башлады Нурулла. Ризасыз төстә баш чайкавы белән кире какты ул аларны. Сүзсез генә итеп: «Юк! Юк! Юк!» — дип кабатлый кебек иде ул үзенең әлеге баш чайкавы белән.

«Әллә миңа хәтле дә салыбрак кергән иде микән соң бу...» — дип тә уйлап куйды Вахит эченнән генә дустының баш чайкавы артыккарак китә башлагач.

Әмма тегесенең ризасызлыгы чынлап та бик көчле булган икән шул.

— Син аны беләсеңмени соң?!! — дигән сүзләре кычкыруга да, яраланган җанварның үкерүенә дә охшап чыкты аның авызыннан. Сәер, ә күзләре, Нурулланың сыекланган зәңгәр күзләре, ни өчендер ялварып, тилмереп карыйлар аңа бүген. Гүяки алар әлеге ямьсез тавыш өчен гафу үтенә, гүяки ул моңлы күзләр эчтәрәк яткан серле агымны, серле дөньяны аңлауны, төшенүне, кабул итүне сорый.

Әнә шунда гына хуҗа кеше сүзнең ни дәрәҗәдә җитди икәнен аңлый башлады бугай. Әнә шунда гына ул биредә үзенең гомуми сүзләр сөйләп маташуының никадәр көлке һәм урынсыз нәрсә икәнлеген төшенә башлады шикелле. Әйе, Нурулланы аңлап бетерү җиңел түгел. Аның күңел дигән дөньясы гаять тә нечкә, үтә дә сизгер хисләрдән үрелгән. Юк, шагыйрь исемен йөреткәнгә генә алай түгел. Аларның да төрлесе бар. Үзе галим булса да Вахит ул мөхит кешеләрен дә шактый яхшы белә. Араларында шундыйлары да очрый: таррак сукмакта очрашсаң, ике дә уйламыйча бәреп кенә китәчәкләр! Мондыйлары, күрәсең, шагыйрьлекне кәгазьгә шома юллар тезеп, куплет саны буенча акча каеруда һәм дан алуда гына күрә. Аларның иманы да, мәккәсе дә шул гына. Ә менә Нурулла исә — бөтенләй башка. Ул — җаны һәм тәне белән шагыйрь!

Гүяки ул бары тик бик олы йөрәктән һәм утлы, кайнар хисләрдән генә тора. Бүтәннәр көн-төн чаба торган фани дөнья мәшәкатьләре гүя аның өчен бөтенләй юк. Кешеләрнең үзе хакында ни сөйләвенә дә, башкалар бик исләре китә торган дан-дәрәҗәләргә дә әйләнеп тә карамады ул гомере буена.

Вахитның каршында утыручы җитмеш яшьлек сабый Нурулла әнә шундый инде... Менә хәзер дә «ул көн...» дип исе китә бит аның. Үткәндәге нииндидер бер көнгә чын күңелдән соклана, сөенә ала ул. Ә бит инде аның яшьлеге әллә кайларда калган. Еракларда, бик тә еракларда бит инде ул. Тукта, әллә соң бу Вахит өчен генә шулай микән? Бәлки, чыннан да, шулайдыр? Бәлки шагыйрь күңелле җаннар алар, чыннан да, картаймый торганнардыр... Әнә бит Нурулла да үзенең яшьлек хатирәләрен кичә генә башыннан кичкән хәл кебек итеп сөйли белә. Шуның белән Вахитны да еш мавыктыра ул. Авызын ачтырып тыңлатып утырта. Әнә шундый берәр матур хикәят тыңлагач икесенең дә тормышлары бераз гына булса да яктырып киткәндәй тоела аларга. Сүнеп баручы гомер кояшы яңадан бер балкып, кабынып алгандай була. Икесенең дә җанына, тәненә әлеге ерак һәм якын балкышның яктысы, җылысы төшкән шикелле була. Әнә шул балкыш аз гына булса да җылыткан шикелле тоела аларны.

Әнә шундый эмсенү, кызыгу, кызыксыну уяна Вахитның күңелендә. Нурулланың хикәятләре аны да үткәнгә — аның да яшь һәм матур чагына алып кайта.

— Ярый алайса... Мин дә берне күтәреп куйыйм инде...— Вахитның кыяр-кыймас кына тавыш белән әйтелгән сүзе һәм соңга калып кына күтәрелгән касәсе әйтерсең лә бу ике адәмнең ике биеклектәге күңел кошын тигезләп куярга тиеш. Гүя әлеге алсу сыеклыкта әнә шундый сихри көч, сәләт бар.

— Йә, инде бераз тынычландыңмы? Әз булса да башыңа киттеме?— Шулай дип үз кунагының хәлен белешергә теләде хуҗа кеше Вахит.

— Барып җитүен җитте лә ул... Тик менә тынычлану дигәнең генә күренми, сизелми әле. Анысы кая соң аның?

— Булыр, булыр... Анысы да булыр...— дия-дия һәм ваклап туралган казылык кисәкләрен чемченә-чемченә хуҗа һаман үз кунагының күңелен күрергә тырышты.

Нурулла исә өстәлдәге казылыкның бер генә телемен дә капмады шикелле. Тик хуҗа гына моны искәрмәде, шәйләмәде. Ул һаман кунагының күңелен тынычландыру турында баш вата иде сыман. Әйтелгән сүзләре дә шуны раслады:

— Мин белмәгән хатирә дип, авызга җим салдың бит әле син. Хәзер инде мин синең карамакта. Хәзер инде ычкыну юк. Әйдә, сөйлә болай булгач.

— Ха-ха-ха...— Нурулла гәүдәсен артка ташлый-ташлый, үзенең ихлас көлүе белән кычкырып көлде башта.— Кармакка каптым дисеңмени инде?.. Юк, Вахит дус, син түгел, ә мин эләккәнмен бүген бу кармакка! Мин! Шуңа күрә сөйләмичә һич котыла алмыйм! Югыйсә... Югыйсә, ничек дип әйтим икән: югыйсә көн туып та кояш чыкмый калган кебек була минем өчен. Көнем караңгы кала минем! Аңлыйсыңмы — якты көнем булмый минем!

Әйе, дустының күңелендә уен гына уйлар түгеллеген чамалаган иде инде Вахит. Тик менә үзе ни чара күрергә белми генә утыра ул. Ничек ярдәм итәргә белмичә генә.

— Соң, сөйләп җибәр инде... Үзеңә дә бераз җиңеләеп китәр. Миңа да бәлки кызыклы булыр.

Ул арада Нурулла да йөрәген кузгаткан хисләр ташкынының бер җаен, тәртибен табып алды, ахрысы — аның йөзенә нииндидер эчтән үк бәрә торган олы сөенечнең яктысы төште, күзләре дә дәртләнеброк,

нурланыбрак китте. Хәтта кул хәрәкәтләре дә ышанычлырак һәм мәгънәлерәк сыман иде аның.

Кәнәфигә дә җайлабрак утырды, арткарак авышты. Әнә шул хәлдә гүя үз алдындагы ниндидер бер агымга, ташкынга тотынды ул. Шуңа күңел җепләрен ялгады.

Әйтерсең лә Нурулла каршысына, менә хәзер Вахит утырып тора торган урынга, бер ап-ак пәрдә элеп куйганнар да, Нурулла хәзер әнә шундагы күренешләргә карап онытылырга тели. Әлеге матур күренешләр иркендә калырга тели.

Болай дип сөйләп китте ул.

— ...Ул җәйне мин сиңа мәгълүм редакциядә рәссам булып эшли идем. Инде дәрелфөнүндәге, ягъни университеттагы, укуымны бетергәнгә дә дүрт-биш еллап вакыт узган булгандыр. Өйләнгән дә идем инде, бер кызыбыз да бар иде. Ничек, ни рәвешле өйләнүем турында сиңа сөйләгәнем булды — бу кадәресен үзең дә яхшы беләсең, шулай бит... Әмма менә өйләнгәнче йөргән икенче бер кыз турында син әле, хөрмәтле Вахит дус, бөтенләй дә белмисең.

Күрше авыл кызы иде ул. Аның бөтен чибәрлеге дә, яшьлегенең сөйкемлелеге дә, аннан бөтен дөньяга бөркелеп торган наз һәм нур да — боларның һәммәсе дә аның исемендә чагыла сыман иде. Луиза дигән исемдә!

Аһ, Луиза, Луиза... Мин яшьтән үк тыңлап, мавыгып үскән бөтен музыка әсәрләре, һәммә гүзәл симфонияләр әнә шул бер исемгә кушылып яңгырый, әнә шул бер исемдә ишетелә кебек иде! Әйе, бу безнең татар исеме түгел. Каяндыр Аурупадан, күрәсең, немецтан кергән ул, ахрысы — аның әти-әниләре укытучы иде шул. Ә без аның белән икәү Казанда укыйбыз. Мин дәрелфөнүндә, ә ул исә әти-әнисе узган юлдан барырга тели, укытучы булмакчы.

Һәр икебезнең дә дәресләр күп инде, билгеле. Бигрәк тә беренче елларда авыр була бит авыл баласына. Шәһәрнең чыдап булмастай һавасына да түзәргә өйрәнергә кирәк, урысча пупалау да мәҗбүри итеп куелган анда, шул ук вакытта башкалар белән рәттән һәммә сабакны әзерләп барырга да кирәк. Өлгерергә кирәк! Ул «чит тел» дигән нәрсә үзе генә дә ни тора! Әмма мин үзем, авыл мәктәбен бетереп килгән булсам да, чит телне урта мәктәптә миңа караганда ике мәртәбә озаграк укыган шәһәр егетләре-кызлары белән бер төркемдә әйбәт кенә бара алдым — бирешмәдем. Әнә шул сынатмауда да Луиза исеменең, шул исем аркылы минем күңелдә немец халкына карата тоелган ниндидер бер әчке симпатиянең тәэсире булды кебек. Шуның өстенә, бит әле укытучыбыз Маргарита Карловна үзе дә Алманиядән күчеп килгән чып-чын немка иде. Үзе чибәр, үзе сабыр һәм бик акыллы хатын иде!

Менә шушылар барысы бергә миңа — яшь авыл егетенә бик тә булышты, ярдәм итте инде. Яп-ят диярлек шәһәрдә беренче терәк булды.

Дәресләр бетеп тамак ялгау белән мин Луиза торган фатирга — шәһәрнең бөтенләй икенче башына чабам. Көннең, кичнең кайсы вакыты икәнен карап торган да юк. Луизаны күрәсе килә — и вәссәлам!

Ә шулай да без шәһәрнең урамнарында түгел, күбрәк бакча-паркларында йөрергә ярата идек. Авыл балалары, табигать балалары идек бит без! Үзең беләсең: хәзерге шәһәр яшьләре күбрәк кочаклашып урамда йөри, яки кафе-ресторанда күңел ача. Күрәсең алар шуннан башка рәхәтне белми. Күрәсең аларны әнә шундый мескен генә рәхәтлек тә канәгатьләндерә ала.

Ә җәйләрен пароход белән авылга каникулга кайтулар! Юк — хәзерге сыман, су өстеннән җен кебек кызу чабучы метеорлар түгел иде әле ул вакытта. Пароходлар иде. Әле аларның да байтагы иске фасонда — ике ягында ике зур куласалы... Су өстендә акрын гына йөзүче сихри бер мәрмәр сарай шикелле тоела иде әнә шул ап-ак пароходлар миңа... Ә ерактан торып караганда аккош шикеллерәк тә күренә иде алар... Без

үзебез дә яшьлегебез дәрьясының яшь аккошлары кебек идек шул ул чакта.

— Нәрсә булды соң? Юлларыгыз нишләп аерылды соң сезнең? — Әңгәмәдәшен игътибар белән тыңлый башлаган Вахит хәзер инде Нурулланың тизрәк төп сүзгә тотынуын көтә иде. Аның тавышында бераз гына түземсезлек төсмере сизелеп алды.

— Хәзер барып җитәм, яме... Аңа хәтле Мостай Кәримнең менә бу шигырен генә синең хәтереңә төшерим дә... Беләсеңдер инде, аның менә мондый бик шәп шигыре бар бит:

Адым да аерылма дусыңнан,
Учларын җибәрмә учыңнан.
Чөнки бит Җир шары әйләнә,
Җир шары корылган хәйләгә.

Әйе, күрәсең, язмышның нык үзгәрүе өчен дустыңның кулын бер мәртәбә ычкындыру да җитә... Хәтта артыгы белән җитә икән!

Нурулла чиксез моң тулы күзләрен тәрәзәгә текәп тын калды. Бу тынлык хәтсез дәвам итте. Вахит исә дәшми генә көтте.

— Юк, әллә нәрсә булгандыр дип уйлама, Вахит дустым! Юкка гына үпкәләштек тә, мин аның янына ничәдер көн бармыйча йөредем. Менә шул гына булды. Үч иткәндәй, ул да килеп чыкмады минем янга. Әллә инде эшләре тыгыз булды, әллә хатын-кыз холкынча бераз ялындырырга уйлады... Кыскасы, безнең очрашмый тору ике-өч атнадан да узып киткәндер дип чамалыйм. Шулай уйлыйм.

Ә соң шул ике-өч атнада яшь-яшь егет тик кенә тора димени инде?! Тулай торакның тап-тар бүлмәсенә генә сыеп ятып булмый бит инде! Мин студент чакта үзем бик тә зыялы булырга тырыша идем: симфоник концертларга да еш йөредем, рәссамнарның да күргәзмәләрен калдырмаска тырыша идем... Һәм билгеле инде: татарның, урысның спектакльләрен дә... Син инде бу өлешен беләсең — менә шунда танышылды да, озак та үтмәстән өйләнелде дә...

Ул чагында мин үзем белән булган хәлләрнең чын мәгънәсенә төшенеп тә җитмәдем шикелле. Боларның һәммәсенең асыл мәгънәсе миңа шактый соңыннан гына аңлашыла башлады. Әмма иң кызганычы булган иде инде. Луиза белән, әле генә ике аккош булып йөзгән Луиза белән, безнең юллар аерылган иде инде! Миңа үз тормышымдагы менә шушы фактны танудан башка чара калмаган иде инде!

Шулай акрынлап вакыт уза торды. Өйләнгәчтен үзең беләсең, һич тә көттермичә бала багу мәшәкатьләре башлана. Мин дә бик рәхәтләнеп чаптым. Яшь чак бит: һәммәсе дә кызык, бәләкәй генә үз кызың булгач бигрәк тә! Аны кечкенә арбасы белән һавага, йөртергә алып чыгасың, кичләрен юындырырга булышасың, кибеткә вак-төяккә йөрисең... Әле җитмәсә соңгы курста укыганда эшкә дә кергән идем. Шуңа күрә — өлгер, житеш кенә барысына да!

Шулай да яшь чагында һәммәсенә дә житешәсең икән ул, малай! Мин дә бәләкәй бала мәшәкатьләре белән шактый әйбәт чаба идем: кибеттән кибеткә дә, поликлиникага да, балалар бакчасына да...

Менә шулай бара иде дөнья...

Менә шулай үтә иде гомер вак-төяк мәшәкатьләр арасында... Ләкин көтмәгәндә-уйламаганда бер **КӨН** килде... Килде ул **КӨН**!

Аннан бирле инде менә ничәмә ничә ел үтте, әмма һич кенә дә онытасым, истән чыгарасым юк — искиткеч матур июнь ае иде ул. Июньне инде үзең беләсең: бөтен дөнья, барча табигать ямь-яшел, искиткеч ямьле була бит ул чакны! Һәммә җирдә — кояш, җылы, наз, иркәләнү, рәхәтләнү... Ул чакны барча җан иясе үзенең чыннан да җанлы икәнен

искә төшерә, чын-чынлап яши башлый, ачыла. Һәр нәрсә, һәркем табигать тарафыннан үзенә салынган асылына кайта.

Әнә шундый гүзәл июнь аеның иртәнге сәгатьләрендә мин дә дөнья мәшәкате белән шәһәребезнең Үзәк кибетенә килгән идем. Хәзер инде нәрсә алырга теләгәнем төгәл генә истә түгел, берәр вак-төяктер инде — нәрсә булсын тагын!

Кибет эче шактый зур булса да, барыбер эссе, бөркү. Шуңа күрә үз-үзеңә ачу килә, халык күплеккә ачу чыга. Андый чакта шулай бит инде ул: синең генә йомышың мөһим, ә бүтәннәр нишләп чуала инде аяк астында — нишләп миңа комачаулап йөриләр инде, дисең. Эзләгән әйбереңне табып, кибеттән тизрәк чыгып таясы, урамга ычкынасы килә.

Шулай йөгерә-чаба дигәндәй бер бүлек янынннан узып бара идем, ничектер, колакка таныш аһәң чалынып киткәндәй тоелды. Башта әле берни аңышмадым да, бернинди сүз ишетмәдем дә — бары тик ниндидер бер серле сигнал гына туктатты шикелле мине... Юк, алдыйм икән әле: әле башта барган җиремнән туктамадым да мин хәтта. Бераз акырынайдым гына шикелле. Аннары инде: теге мин аңламаган, төшенмәгән серле дулкын һаман миңа таба агылуын, һаман да килүен дәвам иткәч, һаман туктамагач — әнә шунда инде мин үз-үземә ачык итеп сорау куйдым бугай:

— Кем тавышы соң әле бу?!

Әнә шунда гына тәмам тукталып, үземнең кайда басып торуымны чамаларга, белергә теләдем. Баксаң — хатын-кыз әйберләре бүлеге икән бу. Әнә тегендәрәк — мин әле генә үтеп киткән җирдә — байтак кына хатын-кыз чиратка баскан. Мине тукталырга мәҗбүр иткән тавыш та шуннан килде, ахрысы. Шул тарафтан булды бугай... Әйе, бүтәнчә мөмкин түгел иде.

Мин инде кире борылып, теге чиратка таба якынайдым.

Хәзер инде теге серле тавыш та тынды. Ул ишетелми иде. Әмма минем күңелгә тәмам корт керде бит! Инде хәзер мине чамасыз кызыксыну хисе биләп алды: шуның кадәр нык тәэсир итәрлек кем тавышы булыр икән ул? Кайсы танышым килеп чыгарга мөмкин соң бирегә мондый иртәнге сәгатьтә үк?

Акырын гына якынлаша торгач хәзер инде миңа бу чиратның алды да ачык кына күренә башлады. Анда исә ике кыз, бер-бер артлы алмаштыра-алмаштыра, товар карыйлар. Тегесен алалар, монысын куялар, тагын өченчесенә дә үреләләр...

Шунда, тагын да текәлебрәк карасам, ни күрим — ышанасыңмы, юкмы: боларның берсе Луиза бит! Әйе, әйе — Луиза! Инде мин әллә ничә ел күрмәгән Луиза...

Юк, Вахит дустым, мин аны тану белән дәшәргәме, дәшмәскәме дип баш ватып тормадым. Ничектер, учакка тартылган күбәләк яисә көчле магнитка суырылган тимер кисәге сыман, аңсыз-уйсыз халәттә якынайдым мин аңар.

Якын килгәчтен дә бер генә сүз әйтә алдым. Аның дөньядагы иң матур, иң аһәңле, иң серле исемен генә:

— Луиза...

Ул үзе башта ишетмәде... Миңа аркасы белән тора иде ул.

Бары тик дус кызы аңа нидер пышылдагач һәм башы белән миңа таба ымлагач кына борылды Луиза.

Әнә шул июнь аеның ап-аяз күгедәй зәп-зәңгәр күзләр... Матур итеп бер якка салып куйган сары чәч... Әз генә сипкел белән бизәлгән бераз озынчарак аксыл-алсу йөз... Һәм беркайчан истән чыкмастай йомшакиркә иреннәр!

Хәзер ул иреннәр бераз гына елмаеп һәм шул ук вакытта аз гына җитдилек тә саклап, ә күбрәге, әлбәттә, гаҗәпләнеп һәм аптырап, ярым ачылып калганнар. Күзләрендә дә аптырау катыш гаҗәпләнү, ниндидер эчке бер гаҗизлек.

Әнә шул чагында мин аңа ярдәмгә килдем кебек.

— Ярый, аласы әйберегезне алыгыз инде. Мин монда көтеп торырмын!— дидем мин, гүя алар белән бергә килгән кеше шикелле итеп.

Шулай дидем дә, бер читкәрәк китеп бастым. Ә Луиза исә, бу хәлләрнең төш түгеллегенә бик тә ышанырга теләгән сыман, әле тагын миңа таба карап торды. Аннары гына иптәш кызына таба борылды. Аңа кызу гына итеп нәрсәдер әйтте. Тегесе дә сатучыга нидер дәште дә, шуннан соң сатучы хатын боларның икесенә бер генә төргәк төреп бирде. Үзләре караган әйберне алмаска булды ахрысы Луиза...

Шуннан ни булды дисеңме?

Мин бит инде үземә үтә дә нык үпкәләгән кызны очратырмын дип торам. Луизаны миңа карата чамасыз ачулы итеп саныйм. Шуңа күрә аның эчендәге яман хисләр нәкъ менә хәзер бәреп чыгар диеп көтәм...

Карыйм: ә ул иптәш кызы белән миңа таба нәкъ урамдагы кояш шикелле балкып, елмаеп килә! Гүя безнең арада бернинди ташлашу, аерылышу, үпкәләшү булмаган. Әйтерсең лә күрешми, очрашмыйча торган еллар һичнинди эзсез югалганнар, юкка чыкканнар!

Мин бер мәл менә шуңа бик аптырау кичердем. Сүз дәшә алмый тордым.

Әле бит көтелмәгәндә очрашу бу, һич уйламаганда...

Андый чакта нишлисең инде? Билгеле, сүз югында табарга теләп, җыен юк-бар сүзләрне тезә башлыйсың... Әле бит шуның өстәвенә Луиза үзе генә дә түгел. Ә минем шундый сәер гадәт бар, син беләсең: ялгыз калганда әйбәт кенә сөйләшсәм дә, хатын-кыз күп булган җирдә югалыбрак калам мин. Үземне алар теләгәнчә үк матур итеп, чын джентльменнарча тота алмыйм. Алар арасында аларча булу өчен ир-атка шактый гына артист булырга, ягъни аларга җайлашырга, икейөзлеләнергә кирәк бит. Ә миннән алай чыкмый инде ул! Үтерсәң дә булмый инде миннән андый кылану, кылтымлану, көязләнү! Минем өчен иң кулае — үземчә булу, үз күңелем теләгәнне эшләү, үз йөрәгем кушканны үтәү.

Ул көнне кызларга эндәшкән беренче сүзем дә әллә ни җүнле булмады шикелле. Алар турында берни дә белмәгәнгә, дөресрәге Луизаның хәзерге тормышыннан бөтенләй хәбәрдар булмаганга күрәдер инде, болайрак дип әйтеп куйдым:

— Иртәрәк уянгансыз әле сез...

Мин моны билгеле аңа гына, Луизага гына карап әйттем инде. Аның белән сөйләшергә теләми мин тагын кем белән сөйләшергә тиеш соң инде — йә?!! Һәм Луиза үзе дә моны бик тиз сизде, әлбәттә.

— Шулайрак килеп чыкты шул! Тик нишлисең, без гаепле түгел инде — пароход шулай иртә килеп туктады бит Казаныгызга!

Әйе, әйе, ул нәкъ әнә шулай диде — «Казаныгызга» диде!

Чү, нәрсә соң әле бу? Нәрсә дигән сүз бу?! Аның шундый сүзләрен ишеткәч, мин баскан урынымда каттым да калдым.

— Нинди пароходны әйтәсең син? Нишләп Казаныгызга дисең?

Минем гаҗәпләнүемә Луизаның гүя исе дә китмәде. Миңа карап бераз хәйләле елмаеп басып тора бирде ул... Ә җавапны мин аның иптәш кызыннан ишеттем:

— Бәй, менә гаҗәп кеше! Бүген иртүк Чаллыдан килеп төштек лабаса без! Шуны да белмәскә син! — Аннары мут елмаеп тагын өстәп куярга итте Луизаның дусты.— Татарстанның иң яшь каласының иң гүзәл кызлары булуыбызны бер дә чамалап булмыймыни соң, ичмасам!

Менә сиңа мә! Луиза хәзер Чаллыда икән бит... Мин сораулы карашымны аның үзенә текәдем.

— Син хәзер андамыни?..

Ул көлемсерәп куйгандай итте. «Шуны белмәвеңмени...» диюе булдымы бу аның — һич аңламадым. Ә теле белән әйткән сүзләре шундый иде:

— Вакыт бара бит, Нур. Аны туктатып булмый бит... Мин дә укып бетердем. Мәнә Чаллыга эшкә җибәрделәр...

Аның бу сүзләрен ишетүгә, минем хәтердә үзебезнең элекке матур хыяллар яңарды. Аларның барысы да гел Казан белән генә, ул чакта безгә иң матур, иң ямьле булып күренгән шәһәр белән генә бәйле иде ич. Әнә шул уйларымны эчемдә саклап кала алмадым.

— Казанны ташладың инде алайса...— дип әйтеп куйдым, бу сүзләргә үземнең һич тә урынсыз булган үпкәмне салырга тырышып. Гүя боларның барысы өчен дә Луизаны гаепле санап. «Соң, аның нилектән монда, Казанда калырга теләмәвен син бик яхшы белергә тиеш идең бит инде!»

Ә ул эченнәнниләр уйлагандыр, әмма тыштан моны миңа сиздермәде.

— Туры килде инде...— дип кенә куйды, бик артык исе китмәгәнрәк кыяфәттә.

Шуннан соң авыр тынлык урнашты. Әле ярый тик басып тормыйбыз, каядыр барабыз. Дөресрәге мин аларга ияреп барам. Ә Луизаның иптәш кызы күрәсең безнең хәлләрне ныклап белми, аңламый. Ул үзенчә безне сөйләштерергә тырыша, мәзәк хәлләр дә кыстыргалый. Ә Луиза белән бездән аңа ни «ә», ни «җә» юк! Шулай әкертен генә атлый-атлый кайсы урам чатына җиткәнбездер, хәзер инде анысы төгәл генә хәтердә түгел, бер мәлне Луиза үзенең иптәш кызына карап болай димәсенме:

— Синең апаңнарга барып тора алмам инде мин, Әлфия! Мәнә иске дус очрады бит... Сөйләшәсе сүзләр дә бар иде аның белән.

Ә мин ни дип әйтергә дә белмим. Луизаның сүзләрен хуплаган сыман берничә ымлык кыстырып куйдым бугай инде шунда.

Тирә-юньгә күз салсам, без трамвай тукталышына килеп басканбыз икән... Бераздан Әлфиянең трамвае килде. Ул теләр-теләмәс кенә трамвайга керде — соң аның уй-ниятләре бөтенләй үзгәрде бит! Аннары безгә кул болгап, шулай ук елмаерга да, елмаймаска да белмичә, шактый ук күңелсез йөз белән күздән югалды.

Ул киткәч, без Татарстан урамы буйлап каядыр юл алдык. Хәер, әлеге урамны син бик яхшы беләсең бит инде. Аның Идел буена, Елга портына алып чыкканын беләсең дип әйтүем.

Мәнә, син ышанасыңмы-юкмы — анысы синең эш — әмма валлаһи дип әйтәм, чын дөресен сөйлим: икәү генә калгач, без нәкъ элеккечәгә әйләндек тә куйдык. Нәкъ әүвәлгечә!

Луиза белән икәү генә калгач, мин дә үзем булдым да куйдым бит әй! Исең китәрлек! Икебез ияләнгән көйгә шаяртып көлдерә дә башладым. Ул да ихлас күңелдән, онытылып, чын көлү яме һәм тәме белән дөньяны балкыта-балкыта көлә — чыркылдапмы чыркылдый мин сиңәйтим! Юл уңаеннан шәраб кибетенә дә сугылып чыгасы иттек. Ләкин анысын эзли-эзли төп юлыбызны югалта яздык. Үзе бер хикмәт инде! Ул чагында шәраб хәзерге шикелле адым саен очрап тормый иде ич әле...

Шул кибетне эзләп йөргәндә болай дип көлдергәнем бигрәк тә истә калган:

— Мин Казан урамнарында көндез йөреп күнекмәгән шул...— мин әйтәм.— Шуңа күрә көндез адашыла икән...

Бу сүзнең ничек телгә килүен әйт әле син! Чыннан да, ул чакта без — яшь шагыйрьләр, яшь артистлар, рәссамнар — төннәр буена беребездән-беребезгә кунак булып йөри идек. Кайвакытларда әнә шулай Казан урамнарын таптый-таптый таңнарны да аттыра идек. Әй, күңелле яшьлек төннәре диген син, ә Вахидулла!

Әйе, сүз бит әле Луиза турында.

Шәраб кибетеннән соң инде без яңадан Елга портына, Идел буена таба атлыйбыз...

Нурулланың шулай диюе булды, моңа кадәр аны сүзсез генә диярлек тыңлап утырган Вахит түзмәде:

— Минем дә сүнгән хисләремне уята башладың бугай әле син бу хикмәтле хикәятең белән,— дип ул да сүзгә кушылды. Ә үзе бер кулына шәраб тулы касә тоткан. Күзләре дә дәртлерәк елтырыйлар, иреннәренә дә елмаю кунган.— Әйдә, сез ике яшь йөрәкнең алдагы матур юлы өчен. Пароходка кадәр исән-сау барып җитүегез өчен!

Нуруллага да дусты сүзен тыңларга туры килде. Акырын гына чәкәшеп, эчеп куйдылар. Сөйли-сөйли Нурулланың авыз эче дә кибешкән икән. Ул бигрәк тә тәмләп, дәртләнеп эчкә суырды ялкын төсле алсу эчемлекне. Әйтерсең, үзенең хикәяте белән генә түгел, ә менә хәзер иреннәре белән дә ут чәчеп, ялкын сулап утыра.

— Хикәятнең бу өлеше үземне дә бик дулкынландыра бит әле, малай...

Нурулла яшь егетләрчә әнә шулай «малай» дип куйды. Күңеленнән чыннан да әлеге яшь чакларына кайтты бугай ул. Шагыйрь халкы шундый серле, хикмәтле шул инде ул! Алар эчендәге хиснең, тәэсир дәрьясының көчен, аның илаһиятен бу фани дөньядагы бер генә нәрсә белән дә чагыштыру мөмкин түгелдер, мөгаен.

— Бер башлагач дәвам итмичә булмый шул инде! Ничек инде менә сине кызганмыйча, шулай ымсынган килеш калдыра аласың?!! — Шулай дип Нурулла Вахитка текәлеп көлеп тә куйды. Ә фатир хуҗасы Вахит, чыннан да беraз үпкәләгән сыманрак нәүмизләнеп, Нуруллага текәлеп утыра. Күзләрендә бераз кырыслык та чагылып киткәли. Гүяки менә хәзер, Нурулла әлеге сүзен дәвам итмәсә, Вахит аңа гомер-гомергә эндәшмәячәк. Бер генә дә сүз катмаячак!

— Сиңа җиңел ул, Вахит дус, сөйләп бетер дип әйтүе... Ә мин менә ул хәлләрне, ул кичерешләрне ничек итеп, нинди сүзләр белән сиңа аңлатыйм? Ничек итеп синең күз алдыңа китерим?! Син «шагыйрь» дигәч тә, мин дә бит адәм баласы! Пәйгамләрләр куәте, җеннәр сәләте юк ич миндә!

Шулай бераз назланып алды да, Нурулла сүзен дәвам итте:

— Идел буена якынайгач шул исемә төште: инде бит аны, шушы мәгъруp дәрьяны күрмәгәнемә дә әллә ничә ел икән ич инде! Мин моңа шаккаттым! Өйләнгәч дөнья мәшәкатенә чумып, вак-төяк ыгы-зыгы арасында маташып, мин ничектер моңа бөтенләй игътибар да итмәгәнмен икән. Яшьлегемнең пароходлы ул матур дәрьясын онытa да башлаганмын икән бит!

Иделгә якынаю һәм, аңа якынайган саен борынга, бөтен тәнгә-җанга су исе, дәрья шаукымы ныграк, тулырак, көчлерәк, тула бару — мине гел иләсләндерә, тагын да ныграк канатландыра барды. Ә инде Луизаларны Казанга алып килгән ап-пак пароходның канатына зур-зур хәрефләрдән язылган «Сергей Есенин» дигән сүз мине күкнең җиденче катына ук менгерде! Әллә бу Идел дәрьясында йөзүче бөтен пароходларга да әнә шундый илһамлы, илаһи затларның исемнәрен куялармы икән? — дип уйлап алдым мин әнә шул чакны. Әллә бу исем һәм бу пароход Луизаны алып килгәнгә күрә генә миңа шундый илаһи булып тоеламы икән? Минем, юк безнең бәхеттән генә туры килдеме икән бөек шагыйрь исемен йөрткән бу гүзәл пароход?

Син, Вахит дус, минем мондый лирикага бирелүем өчен ачуланма инде. Беләм, сиңа — фән кешесенә — фактлар, вакыйгалар гына кирәктер инде. Ләкин минем йөрәк хәлләре дә, җанның ул чагындагы һәм менә хәзер — ул сәгатьләрне искә төшергәндәге талпынулары — болар да тормыш фактлары түгелмени соң?! Сез, галимнәр, нигә дип әле гел дә тотып карардай нәрсәләрне генә тормыш фактлары дип саныйсыз?! Ә күңел, ә җан яшәешен — аның нечкә кылларын һәм аның югарыга очынуларын — нигә дип реаль чынбарлыкка кертмисез? Нигә аларны бер дә санга сукмыйсыз?!

Кайчандыр пролетариатка гына хезмәт итүне максаты санаган «материализм» чире түгелме соң бу? Шуңа бик тә ошаган бит ул! Мин үзем

аннан бик тә чирканам. Андый карашлар җанны да, тәнне дә туңдыра. Өшетә хәтта!

Әйе, бераз мавыгып киттем бугай. Шулай шул: сез галимнәр кебек бер эздән генә бара да, йөри дә алмыйм... Әллә инде менә бу касәдәге шайтанның хикмәте шулай үзен сиздерә башладымы икән? Хәер, мин моның белән гомер буе дус бит, үзең беләсең... Ләкин хәзер эш анда гына түгел! Юк, һич тә шәрабта гына түгел эш!

Эш әнә шул көннең, әнә шул сихри июнь аеның әнә шул сәгатьләре һич истән чыкмас дәрәҗәдә күңелгә, йөрәккә сеңеп, берегеп калган булуда! Менә хәзер ул минутлар минем күз алдында ул чактагыдан да тererәк, шул вакыттагыдан да тәэсирлерәк, гүзәлрәк булып җанланалар бит! Син шуны аңлыйсыңмы, Вахит дус?!

Ә аның Вахит дусты хәзер дәшмичә, елмаеп кына утыра. Әллә ул тәмам йомшаган, шәраб тәэсирендә эрегән инде? Яисә Нуруллага ияреп ул да яшьлегенә кунакка киткәнме? Аның да әнә шундый ләззәтле яшьлек хатирәләре күз алдына килеп басканмы әллә? Кем белсен... Үзенең йөрәк хәлләрен кем соң тиз генә төшендереп, аңлатып бирә алсын...

Нурулла исә Вахитка карамый да диярлек. Ул инде хәзер үзенең үткән яшьлеге дәрьясына тәмам чумган.

— Ямьле җәй көненең кояшлы бер иртәсендә яр буенда тып-тын гына торган ап-ак пароходны күргәнең бармы синең? Җир йөзендә мөмкин булган иң илаһи, иң югары матурлык сыман тоела ул! Аның акка буялган һәрбер рәшәткәсе, һәр култыксасы һәм түгәрәк тәрәзәсе дә дөньяның иң яхшы осталары кулы белән ясалгандыр дип уйлыйсың. Шуңа ихлас ышанасың. Ә инде бу гүзәллек, бу зиннәтле ап-ак сарай мәгърур Идел өстендә дә булгач — әлеге пароходның бәхет бишеге икәнлегенә бернинди шигең дә калмый.

Басмалардан ни рәвешле үтүебезне, пароход эченә кергәчтән өскә дә, аска да төшүче тимер баскычлардан ничә мәртәбә үтүебезне, кайсы коридорлардан шык-шык басып баруыбызны — менә боларның берсен дә мин күзем белән күреп, зиһенем белән кичереп бара алмадым. Мин андый хәлдә түгел идем. Мин ул мәлдә хисләрдән исергән, онытылган хәлдә идем... Әгәр дә нинди дә булса берәр сәбәп килеп чыгып, без әле генә узган юлдан миңа үземә генә кирегә чыгарга кирәк булса да, мин, һичшиксез, бер адым атлауга ук адашып калачак идем. Менә шушы ап-ак диварлар, ап-ак тар коридорлар арасында башым әйләнеп, ушым югалып калачак идем мин! Хәзерге бер шагыйрәнең «...бураннарга кереп адаштым» дигән юллары бар бит әле. Шуның сыман, мин дә, теге чакны ап-ак пароходтагы ак хисләр бураны эчендә адаштым...

Луиза белән Әлфия икесенә бер каюта алганнар икән. Ишекләре каршысына килеп баскач:

— Менә шушы була инде безнең су өстендәге фатирыбыз...— дия-дия сумкасыннан ачкычын чыгарды Луиза.

Вахит! Син менә хәзер мине тыңлап утырасың, әйе бит? Ярый, анысы өчен рәхмәт, билгеле. Әмма син менә шушы мизгелләрнең миңа ни дәрәҗәдә кадерле, кыйммәт икәнлеген аңлап җитә аласыңмы икән?! Юктыр дип уйлыйм, ачуланма, зинһар! Гомумән, минем үземнән башка бүтән бер генә кеше дә аңлап, төшенеп җитә алмыйдыр шикелле ул бәхетнең, ул рухи ләззәтнең тирәнлеген, аның чиксезлеген! Бәлки, булса Луиза үзедер, бәлкем... Ул гынадыр...

Менә хәзер, әгәр көчемнән килсә, мин ул эпизодларны төсле кинога төшерер идем дә — гомерем буена башка бер ни дә эшләмичә, бүтән бернинди дә гамәл кылмыйча, бары тик әнә шул сихри кадрларга гына мөкиббән китеп утырыр идем. Шулай яшәр идем мин! Менә бит ул йөрәк ни ди, Вахит!

Луизага ияреп әкерен генә, песи кебек кенә басып, мин дә каютага үттем. Керү белән күзгә бәрелгәне шул булды: каютадагы бердәнбер тәрәзә ярым ачык, аның ак кисея пәрдәләре дә ике якка тартып куелган, шуңа күрә кояшлы Идел өсте аерым-ачык булып ялтырап ята. Болай да гүзәл бу күренешкә тагын да яңа бизәкләр өстик әле дигәндәй акчарлаклар тавыш-тын чыгармыйча гына, талгын гына очып үтәләр. Гүяки тәрәзәне кисеп үтәләр. Тәрәзәне генә түгел, әйтерсең лә минем бәгырьне телеп үтәләр алар...

Юк, безнең Луиза белән беренче генә мәртәбә ялгыз калуыбыз түгел иде бу. Ул торган фатирда бергәләшеп вакыт кыскарткан чакларыбыз элек тә байтак кына булган иде. Әмма егет белән кыз идек без ул чагында. Чаманы узмый идек.

Шуңадырмы, каютага килеп кергәч тә бер-беребездән әллә ни кыенсыну сизмәдек диярлек. Әле онытылып җитмәгән элеккеге мөгәмәләбезне сакларга тырыштык.

— Бу әйберне өстәлгә куйыйм микән соң?..

Шәһәрдә алып кесәгә тыккан шәрабне кыюсыз гына чыгарып, өстәлгә куйганчы башта Луизага карадым. Безнең моңа кадәр аның белән беркайчан да шәраб эчкән юк иде. Студент чакны үзе янына килеп йөргәндә дә, әгәр мин дус-ишләр белән бераз кәккән булсам — ул шактый кырыс тавышка күчеп ачулана да иде әле. «Минем янга мондый хәлдә килмә!» — дия иде.

Ә бу юлы ул дәшмәде. Мин исә урысларның «дәшмәү — ризалык билгесе» дигән сүзен истә тотып, кыюлана төштем. Теге сихерле суны (шәрабны әйтәм) өстәлгә үк утыртып куйдым.

Бераздан Луиза да килеп утырды ул кечкенә өстәл янына. Минем каршыга... Үзе әкренләп кенә сораштыра.

— Тормышлар ничегрәк бара соң, Нур?

Мин исә җавап бирергә ашыкмыйм. Җавап бирәсе урынга акырын гына үрелеп шәраб шешәсен ача башлыйм. Шуннан соң гына авыздан сүзләрне тартып диярлек чыгарам.

— Нәрсә дип әйтергә инде... Акрынлап ага инде дөнья дигәннәре...

— Балагыз бар дип тә ишеткән идем...

Аның шул сүзләреннән мин никтер кызарып, уңайсызланып киттем. Белмим — ни хикмәт булгандыр? Ни өчен кызарып утырганмындыр инде мин ул чакны...

— Әйе, дөрес. Кызыбыз бар.

Боларның барысы да мин шәраб шешәсен ачкан һәм касәләргә салган арада сөйләшенде.

Ә кулга касәне тоткач — үземнең хәлне бераз җиңеләйтү юлын сизеп алып ахрысы — мин дә аннан сорыйсы иттем.

— Син нигә дип Чаллыга киттең соң әле?!

Үзем шулай дип сорадым, ә үзем аның җавабын да көтеп тормыйча ук, аны кыстый да башладым: «Әйдә әле, әйдә...» Шулай дип эчәргә кыстыйм мин моны. Һәм ни гаҗәп — ул карышмады!

— Әйдә соң алайса!.. Очрашу өчен булсын! — диде ул.

Үземнең тост сыман берәр җүнле сүз әйтергә тиешлегем шунда гына исемә төште. Әйтәм ич — артистлык юк миндә дип!

Ә теге — Чаллыга китү турындагы соравым исә — һавада асылынды да калды. Гүя Луиза аны бөтенләй ишетмәде дә!

— Без синең белән пароходта кайта торган идек... Исеңдәме?

Бу — Луизаның соравы.

Ничек минем исемдә булмасын ди инде! Җәй көнге ул гүзәл сәяхәтләр ничек итеп онытыла алсын соң инде алар!!!

Шуңа күрә мин җавап бирердәй сүзләр дә таба алмыйм. Уфылдап аның янәшәсенә барып утырам. Ул да акырын гына кулын минем җилкәгә сала һәм назлы да, кызганган да тавыш белән:

— Нигә уфтанасың? — дип сорап куя.

Ә минем дөресен әйтергә тел бармый. Кыюлык җитми.
— Болай гына...— дигән булам.
Ул да, бик аңлаган сыман итеп:
— Ә-ә-ә...— дигән була.
Менә шуннан соң сүзләр бетте безнең...
Ул торып тәрәзәне дә, пәрдәне дә ябып килде...

Менә шулай булды инде...
Аннан соң да әллә ни сөйләшмәдек кебек без. Ничектер — барысы да сөйләшенгән дә һәм, шул ук вакытта, әле бер ни дә әйтелмәгән дә, аңлатылмаган да кебек калды безнең ара... Ләкин шуны гына әйтим: андый шашып яратуны минем бүтән беркайчан да очратканым булмады. Миңа үз гомеремдә бүтән андый олы бәхет тәтемәде. Шуңа күрә Луизаның ул көнне шаша-шаша «бәгырем!» дип пышылдавы менә хәзер гел дә, гел дә искә килеп төшә...

Аларның пароходы икенче көнне иртән генә китәргә тиеш иде. Мин ул көнне көне буе һәм төнен дә Луиза янында булдым. Ә аның иптәш кызы апасыннан кунактан иртән генә кайтты. Әмма ул иртүк мине каютада күреп бер дә гаҗәпләнмәде.
Пароход киткәндә мин аларны пристань кырыена ук чыгып басып озатып калдым...
«Саубуллашканда син нәрсә дип әйттең соң?» — диярсең инде. Ә соң мин аңа — Идел дәрьясы өстендәге ап-ак пароходның югары катында басып торган ул яшь гүзәлгә, үземнең бөтенләйгә китеп баручы мәхәббәтемә — аста, пристаньнең тупас салкын тимер идәнендә, кадакланган сыман басып торган килеш, нәрсә дип кенә әйтә ала идем соң ул чакта?!! Аның әле һаман, безнең яшьлектәгечә ап-ак пароходта булуы, ә минем исә ярда калуым — бу хәл үзе үк безнең арада нинди олы каршылык килеп чыгуын әйтеп, күрсәтеп тора иде түгелме соң?!
Шуңа күрә баскан килеш Луизага текәлеп карап тордым да тордым инде... Мәңгегә истә калдырырга теләгән сыман — озак, бик озак карап тордым мин аңа...

Нурулла, богауланган бөркет сыман, үзенең кәнәфиенә ике куллап чытырдатып ябышкан, куллары белән култыксаларны сытардай итеп кыскан килеш, эчке ярсуыннан очып китәрдәй булып утыра. Аның мондый халәте әле генә сөйләгән сүзләренең ихласлыгын, эчкерсезлеген һәм аларда тормышның аяусыз хакыйкате ятканлыгын бик тә ачык итеп гәүдәләндерә иде. Бер мәл гомер үткәннән соң Нурулла тагын сүзен дәвам итә алды:
...— Ә берничә көннән... мин эшләгән редакциягә «үз кулына гына тапшырырга» дигән хат килеп төште. Ул хат Луизадан иде. Яшермим, шактый озын хат иде ул. Аны укыганда үзеңнең гомер буе язган шигырьләрең дә онытылырлык иде. Шуның кадәр дә хисле, шундый да кайнар хат иде ул чөнки!
Ә хәзер ул хатның менә мондый бер җөмләсе генә хәтеремдә калган.
«Идел буйлап бик озак, бик рәхәтләнеп сәяхәт итәм диеп чыккан идем дә, ул матур сәяхәтем икенче көнне үк тәмамланды! Син ярда торып калган көнне тәмамланды минем ул сәяхәтем!» — дип язган иде Луиза үзенең Идел буендагы Н. шәһәре пристаненнән җибәрелгән хатында...
Әйе, ул матур җәйнең әнә шул иртәнге пароходы минем гомеремнең дә бөтен ямен, яшәвемнең бөтен тәмен алып киткәндер күк тоела миңа...

Бүлмәдә озын тынлык урнаша. Нурулла әйткән бу сүзләр белән һәр икесе дә килешә. Шуңа күрә алар моңаеп кына, бер сүз дә дәшмичә генә, үткән гомер ялкыны кебек кып-кызыл шәрабне эчеп куялар...

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Әдәбиятыбызның проза жанрындагы бүгенге хәлләр күпләрне борчый. Уңышларыбыз да, борчуларыбыз да житәрлек. Шуны искә алып, редакция байтак кына әдипләргә түбәндәге сораулар язылган анкета тараткан иде:

**1. Бүгенге прозаның кайсы яклары Сезне сөендерә? Соңгы елларда басылган кайсы проза әсәрләрен яратып укыдыгыз? Нинди яңа авторларга аеруча зур өмет баглыйсыз?**

**2. Бүгенге прозаның нинди житешсезлекләрен күрәсез? Аларның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

**3. Прозабызны үстерү өчен хәзер нәрсәләр эшләргә кирәк дип саныйсыз?**

Беренче саннан башлап редакциягә алынган җавапларны урнаштыруны дәвам итәбез.

**Амур ШАКИРҖАНОВ:**

Мәгънәсез сүз заманы инде үтеп бара, берьюлы барлык кыйблаларыннан мәхрүм ителгән каләм иясенең җиде юл чатына килеп чыгышына да инде 5—6 ел булды. Дәрәҗәсен җуймаска тырышучы әдәбият үзенең исемлектә саналучы гаскәрен ажагандай тормыш кочагына чакырды, иярергә омтылды. Сафлар тигезлеге бозылды, бераздан сирәгәйде, иярә алмаучылар аксый-аксый артта калды, кайберләре күздән дә югалды...

Укучы яратып йөргән персонажларның чынбарлык өчен бернинди әһәмияте калмады, автор белән персонаж бер-берсен танымый башладылар. Мондый сәер очрашуларның берсен 1990 елда Әхәт Гаффар «оештырды» — Нәфисәне («Намус» романының герое) Гомәр ага Бәширов белән күрештерде һәм аларның озак кына сөйләшүен «тыңлап» торды (язма «Шәһри Казан» газетасында басылды).

1989 елда Һади Такташка да «Киләчәктән хатлар» килде. Ул да, теге дөньяда булуына карамастан, Мөхтәр бабай белән күрешә, «коммунизм кырын» күреп китте («Татарстан яшьләре»).

Вакыт агымына каршы торучылар бар иде, әлбәттә, ләкин аларның кысырлыгы барысын да аңлатты. Үз баласы кебек якын күргән образларыннан да элек онытылу ихтималлыгы тынгы бирмәде аларга.

Кыскасы, тиңе булмаган күренеш ачылды — авторларны аяусыз заман бик кыен һәм сагышлы эшкә жикте: алар үзләре тудырган геройларны күмәргә тиеш булып чыктылар. Чынбарлыктан һәрвакыт читтә торган персонажлар үзләре дә ояла башладылар, ахры — каршылык күрсәтмәделәр.

Шул рәвешчә, әдәби мәйдан бераз бушап калды, чөнки персонажларның үлеме аларны көчәнә-көчәнә тудыручы әдипләрне дә үзенә тартты, мәктәпләр өчен әдәбият программалары төзү кыенлашты — әдәбият өйрәнүнең рәте-башы югала язды.

Ә укучы халык, үз тарихы белән дә юньләп танышырга өлгермәгән татар халкы (вакыт бирмәделәр), һаман киләчәге турында уйланды, нидер көтте, өметләнде һәм мәгънәсез әсәрләрне күрми дә, укымый да башлады, абруйлы фикер, искермәс сүз көтә башлады — «үткәннәрнең авыр әкият» икәнлеген ахырынача аңлады.

Үзен сафта санаучы каләм иясе бүген, минемчә, ике рольдә йөри — автор да ул, персонаж да.

Мондый хәлнең әле татар дөньясында бүгенгедәй ачык чагылганы юк иде. Теше-тырнагы белән хакыйкатькә каршы торырга (димәк, вөҗданына да) маташучы әдәбият әһеле бүген максатсыз калды. Әдәбият диңгезендә җилкәнсез дә, компассыз да калган көймәчеләргә ярның кайсы якта булуын шәйләүчеләрнең берәр кинәш яки хәлиткеч әмер бирүе, бәлки, кирәк тә булгандыр, ләкин бу хәлдән һәркем үзенчә чыгып килә.

Әмер бирүче табыла калса, нәрсә дияр иде сон?! Әле, шактый вакыт узгач та, андыйларның күренмәве безне шатландырырга тиеш. «Ярый әле, эшләр аңа барып җитмәде» дип, һәр прозаик, учларын ышкый-ышкый, куанырга тиеш.

«Казан утлары» журналы прозаның бүгенге халәтен төгәлрәк билгеләү өчен укучыларын да, әдипләрен дә ачык әңгәмәгә чакырып, гади генә өч сорау тәкъдим итте. «Гади» диюем, әлбәттә, сорауларның куелышына гына кагыла, ләкин аларга җавап бирү мавыктыргыч озын һәм катлаулы юлларга (сукмаклар да күп) алып керә. Шуңа күрә журнал үтенечен тулысынча җиренә җиткереп башкару мөмкин түгел. Мөгаен, сорауларны таррак кысаларда, шаккаткыч төгәл һәм анык куярга кирәк булгандыр. Әмма бу хакта сүз кузгату үзе генә дә ни тора!

Хикмәт шунда ки, проза дөньясында балкучылар да, ара-тирә үзен «күрсәтеп» алучылар да, «үз көенә иплəп кенә» атлаучылар да, чуалып йөрүчеләр дә житәрлек. Әлбәттә, бер генә тәнкыйтьче дә бу төркемнәрдәге затларның исемнәрен язып куярга кыюлык таба алмый һәм моның кирәге дә юктыр. Шуңа күрә «яратып уку» турындагы сорау мине әле һаман аптырата. Үземә калса, мин яратып укый белмим, мин укый гына беләм. Укыгач — аңлыйсың, яратканыңны да, яратмавыңны да.

Инде сизенәсездер, теге яки бу язма (әсәр) күзгә ташлансын өчен, укучы аның, ни өчендер, бик таныш язучыныкы булуын тели һәм, үзе дә сизмәстән, яңа яшь авторны «күрми» кала, бер сүз белән әйткәндә, сайлап укый. Бу — табыгый күренеш, талымсыз булырга да ярамый бит!

Гомумән алганда, проза язмышы борчылырлык түгел. Беренчедән, олы һәм күләмле әсәр туарлык мәгълүмат туплау өчен (сүз бүгенге вакыйгалар хакында) әле вакыт бар — Лев Толстой «Сугыш һәм тынычлык» эпопеясен 1812 ел сугышы тәмамланып, ярты гасыр үткәч яза башлаган. Икенчедән, яхшымы-яманмы, әлегә рухи ачлык кичермибез. Өченчедән, журнал сорауларыннан ук күренгәнчә, проза исән, хәтта сәламәт, аңа озын гомер генә кирәк.

Иҗат ирегe яшәгәндә, художникларның (бу сүз төгәлрәк булыр кебек) мөмкинлеге чиксез киң, әмма бу мөмкинлекләр вазифасыз һәм кагыйдәсез түгел — аларны сайлый белү мөһим. Тасвирлау чараларының да күп булуын күздә тотканда, иҗатчы эше әйтеп бетергесез дәрәҗәдә катлаулана. Шуңа күрә теге яги бу әсәр турында фикер йөрткәндә, тәнкыйтьчеләр «гади укучы» игътибар итмәслек нечкәлекләрне дә күрергә, кайбер очракта аларга басым ясарга тиешләр һәм, киресенчә, һәр яктан уңышлы әсәрнең сизелер-сизелмәс житешсезлеген гафу итәргә дә әзер торырга тиешләр. «Гади укучы» диюемә берәү дә үпкәләмәсен — әлбәттә, әдәбият белән даими танышып баручы «гади» булуыннан туктый, таләпчән укучыга әверелеп, бервакыт үзе дә тәнкыйтьче сүзен әйтә ала, ләкин яңа әсәрләрне «ошады» яки «ошамады» кебек сүзләр белән генә бәяләү берәүгә дә файда китермәячәк. Бер карасаң, болай бәяләү бик гадел булып күренә, чөнки матур әдәбият кеше күңелен кузгатырга, аның әлегә «йоклап» яткан хисләрен уятырга, хәтта сокландырырга тиеш, монысы — һичшиксез. Ләкин автор, төп максатына ирешеп тә, әлеге дә баягы чараларны уңышсыз кулланса, укучының кәефе бозылырга да күп сорамый — әсәрне «йомшак» дип, тамгалыйлар һ. б. Димәк, әдәби тәнкыйтьнең көче дә, югарылыгы да тәнкыйтьченең гомуми хәзерлегенә, белеменә, намусына, хәтта холкына да бәйләнгән. Бу сыйфатларның иң мөһиме, мөгаен, намустыр (белемсез тәнкыйтьчене күз алдына да китереп булмый), чөнки автор белән укучыны таныштырудан уза алмаучы тәнкыйтьчеләрнең төп омтылышы мәдхия укуга таба авышты. Баллы-майлы сүзне абруйлы әдип авызыннан әйттерү гадәткә керде, кәсепкә әверелде, урта куллы авторларның (аеруча шигърияттә) «чәчәк атуына» китерде. Чикләвекнең буш булуы ваткач барыбер беленә — укый торгач, кемнең кем булуы ачыклана. Кыскасы, үз вакытында суганлы-борычлы сүз ишетүче авторлар бүген бәхетлерәк.

Ахырынча ватылып бетмәгән элекке система яңа эзләнүләрне, сүзне яңача яңгыратучыларны яңага эзәрлекли кебек. Дөрес, бу эш элеккечә үк тупас башкарылмый, ләкин иҗат ирегeн үлчәп кенә бирү яки ваклап өләшү дәүләт аппаратында оялаган затларга һәрвакыт ләззәт бирә, алар шунсыз яши алмый.

Өзлексез дәвам итүче «реформалар» укучының да, әдипләрнең дә зәгыйфьләгән күрсәтте инде: тел законы эшләми, нәшрият аксый, язучы хезмәте гадел бәяләнми, редакцияләрнең күбесе хезмәт хакы да түли алмый, басмалар тиражы кимүгә бара һ. б. Шуңа да карамастан, әдәбият яшәргә омтыла — башын бигүк түбән имәскә тырыша. Прозага табынучылар да эзләнәләр, актаралар, нидер табарга телиләр һәм табып та торалар. Шул табылдыкларына тутыкмаслык, онытылмаслык исемнәр кушарга тырышалар... Әлеге табылдык, чыра яндырып эзли торгач, сәке астында табылган борчакны гына хәтерләтсә дә, һәр мескенне куандыра.

Әлеге хыялларыбыз да ихтыяждан олы түгел, кавын-карбыз эзләсәк тә, борчак табабыз, аны төшереп югалтабыз, тагын эзлибез, шул ук вакытта туймас күзләребез мәңге сүнми торган, таныш булмаган ялтыравыклы нәрсә күзләвен дә дәвам итә. «Эзләгән — таба» диләр бит — эзләргә кирәк!

**Фәрит БӘШИР:**

1. Заман авырлыгына һәм матди кыенлыклар кичерүгә дә карамыйча дөньяга чыгарга, яшәргә тырышкан әдәбият үзе — сөенечтер. Шундый инде бүген хәлләр, һәр басылган татар китабы ихтирам хисе уята. Аларның кайберләре нииндидер могжиза яки юллар белән Татарстанның китап нәшриятында дөнья күрә, икенчеләре исә, авторларның үз хисабына, яки кемнеңдер, кайсыдыр җәмгыятьнең, предприятиенең матди ярдәме белән басыла. Аннан килеп, Казанда, Чаллыда әлегә эшчәнлекләре күпләргә таныш булмаган китап нәшриятлары (оешмалары) да азмы-күпме эш башкаралар. Бик хуп! Булсын! Китап басуның төрле юллары булсын! Бу буталчык заманда, беренче чиратта, татар китабын саклап калу зарур. Китапны саклау — язуга этәрүче көч дигән сүз! Шөкер, «Казан утлары», «Идел», «Аргамак» кебек журналларыбыз нәшрият бурычларын да зарланусыз үтәп киләләр. Кыскасы, татар китабы бүген җан тырмашып булса да үз укучысы белән элемтәне югалтмаска тырыша. Бәс, шулай икән, прозабыз да яшь һәм аның кояш астында үзенә урын дәгъва итәргә һичшиксез хакы бар дигән сүз. Заманы өчен зур сөенеч инде бу, нишлисең бит. Коры килгән елны авылда тал яфрагы да печәнгә исәпләнәдер иде.

Инде китапка булган мөнәсәбәткә килсәк, шәхсән үзем бик консерватив укучымын, минем еллар дәвамында сыналган даими авторларыбыз бар. Гомернең нинди генә халәте булмасын — борчумы, шатлыкмы, эч пошумы, әллә рәхәт чигүме — үз җаныма кайтавазны мин ул язучылар иҗатында күрәм һәм таба алам. Рухи дөньямда күптәннән урын алган әдипләрдән иң әүвәл Әмирхан Еники һәм Мөхәммәт Мәһдиев исемнәрен атыйм. Күңелгә ошаган әсәрләр күп ул, ә менә кайта-кайта укый торган, китапларының аерым өлешләре тәмам ятланып беткән язучылар — алар. Иҗатын яраткан әдипнең сыңар мәкаләсен дә ихтирам итәсең, сабырсызланып аның яңа чыгачак әсәрен көтәсең. Рухи ачлыкны алар гына баса алыр кебек. Гафу, мин татар прозасының иң яхшы үрнәкләре — үткәндә дигән фикер калдырырга теләмим. Соңгы елларда күңелне кузгатырлык, уйландырырлык, табышлары белән сөендерерлек әсәрләр дә, шөкер, дөнья күрү бәхетенә ирештеләр. Минем уемча, соңгы елда татар прозасы саллылана, гамьләнә төште. Сүз сәнгатен идеологик ләмнән, сыйныфлык дип лаф орган пропагандачыл лайладан аралагач, чистарткач, ул яктыртып, ачылып, фикернең хәрәкәтсез яткан оячыкларына җан кертте, тормыш, тарих, мирас кебек төшенчеләргә тирәнрәк үтеп керергә мөмкинлек тудырды. Моны «боз кузгалу» белән тиңләп булса, ул фикер туңлыгын чатнатучыларның бер үрнәге, һичшиксез, Фоат Садриевның «Таң җиле» романы булды. Инде ничәнче мәртәбә бу китапны кулыма алам, инде ничәнче тапкыр татлы газап белән өретелгән дулкынлану хисе кичерәм. Салкын кан белән генә укып булмый бу романны. Аеруча төп каһарман Нуриасманың олуглык, мәртәбәлек, горурлык вә изгелек белән сугарылган бәхилләшү сәгатьләре моңга әверелеп җандагы һәр күзәнәк аша уза. Ул көй сагайта, сискәндерә, искәртә, өнди, чакыра. Бу моң каршында дөнья ыгы-зыгылары, борчу-мәшәкатьләре бик вак, кечкенә нәрсә булалар да калалар. Гаделсезлек белән очрашканда, алдауга, хөсетлеккә тап булганда мин китап киштәсендәге «Таң җиле» романына үреләм. Әсәрнең ахырындагы аналар турындагы сүзләр, һичшиксез, уку дәреслекләренә керергә тиеш дип саныйм. Андый изге, җылы гыйбарәләрне шигар-лозунг итеп язып һәр мәктәпнең диварына эләргә иде. Бала шуларны һәрдаим күреп торсын иде, изге дога итеп күңеленә сеңдерсен иде ул аларны. Тагын да шул, «Таң җиле»н укыганда бер уй роман вакыйгаларына

уралган фикер агышына килә дә кирә генә бит. Бирдә мин әсәрнең теле, эчтәлекне бирү рәвешен күздә тотам. Безнең әдәбият белемендә шулай кабул ителгән инде: беренче чиратта әсәрнең идея юнәлеше тикшерелә, сюжет-композиция үзенчәлеге анализлана, аннан тәфсилләп уңай герой проблемасы өйрәнелә. Сүз монда әдәбият белеме ирешкән уңышларны инкарь итү турында бармый, ә әдәби әсәр турында сөйләгәндә башка күзәтүләрне дә үзәккә алу кирәклеге күтәрелә. Язучы нинди генә зур, актуаль проблема күтәрмәсен, ул аны беренче чиратта, укучы күнеленә якын тел белән, үтемле, аңлаешлы чарасыуллар аша китереп җиткерергә тиешле. Язучының таланты вакыйгаларны оста үрә барып, кирпеч калынлыгы роман язу белән чикләнми, ул әле укучы белән риясыз әңгәмә кора белергә дә тиеш. Элемтә кора алмыйсың икән, укучыдан үзеңне яраттыра алмыйсың инде. Бигайбә! Мин үзем, шәхсән, әсәрнең эчке структурасын җанлы итеп, үтә җылы тәзи алуны Ходайдан бирелгән талант дип саныйм. Чынлап та, әсәрнең көче тема белән генә чикләнми бит әле. Әйтик, бер үк агач кисәгеннән скрипка да ясарга мөмкин, шул ук вакытта аны ит чаба торган бүкәнгә дә әверелдерергә була. Инануымча, теге яки бу әсәр турында сөйләү һәр структур компонентны тигез хокукка куеп башкарылырга тиеш. «Җаны гына юк» диләр бик матур сурәт яки югары зәвыкъ белән эшләнгән әйбер турында. Нәкъ менә үтемле сөйли белүе белән язучыларыбыз арасыннан Туфан Миңнуллин игътибарны үзенә тарта. «Өмет» дип аталган проза китабыннан соң күренекле драматургның язмаларын, уйлануларын калдырмый укып барырга тырышам. Ялгыш күрми узсам, соңыннан барыбер табып укыйм. Минем шулай укымый калдырырга ярамый торган авторларым бар. Шулар арасыннан янә Н. Гыйматдинова һәм Зөлфәт Хәким исемнәрен күрсәтер идем. Икесе дә чагыштырмача яңа авторлар, әмма әдәбиятта үз юлларын билгеләгән, үз исемнәрен яңгыраткан үзенчәлекле талантлар. Нәбирә сер, тылсым белән өретелгән гыйбрәтле дә, мавыктыргыч та вакыйгаларны сыгылмалы-нәфис сөйләмдә тасвирлавы белән игътибарны җәлеп итсә, З. Хәким исә усал, әмма осталарча ябыштырып көлүе, сатирик каләме белән әдәбиятта үз дөньясын тудырды. Тик соңгы вакытта иҗаты белән күңелне үзенә тарта алырга сәләтле Фәүзия Бәйрәмованы гына күз уңыннан югалттым әле. Бер вакыт аннан язуы хакында сорагач, сәясәттән кысып калган вакыт хисабына гына каләмгә тотына алмыйм дигәнрәк фикер әйткән иде. «Моңымны югалтудан куркам»,— дигән иде ул. Әгәр көрәш хисе иҗатка урын калдырмаса — ни аяныч, әдәбият өчен ни югалту булыр иде! Юк-юк, киләчәктә язучы Фәүзия Бәйрәмова белән тагын да очрашырбыз әле, Аллаһы боерса!

**2.** Бу сорауга кыска гына җавап бирү кыенрак. Бүген бер проза гына түгел, гомумән әдәби хәрәкәт кризиста. Без — күчеш этабында. Үткәндәге иҗат алымнарының күбесе заман таләпләренә туры килми, ә яңа принциплар яки бөредә генә, яки әле бөтенләй анык түгел. Без басып торган чорлар күперен куе, тыгыз томан сарган. Моңарчы актив үсеше белән характерланган прозабыз да таныш түгел күпергә килеп кергәч, сөрлегеп, адымнарын акрынайтты. Ул бүген куе томанда кыйбласын тапмый изаланган мосафир хәлендә. Прозаның нинди планда үсәчәген аңлау өчен соңгы 15—20 елда үткән юлын бераз булса да күзәтеп чыгу зарур. 60-еллардан зур куәт алган чәчмә төрнең төп, характерлы юнәлешләре түбәндәгеләр иде.

**Бөек Ватан сугышы темасы.** Әдәбиятта әтрафлы өйрәнелгән өлкәләрнең берсе. Әмма рәсми идеология бу гомумкешелек фаҗигасен күп очракта бар кырыслыгына һәм чынбарлыгына ачарга мөмкинлек бирмәде. Тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин билгеләгәнчә, бу юнәлеш еш кына «социалистик реализм» принципларына нигезләнеп язылган норматив «әдәбият үрнәге» рәвешен алды. Идеологик кысалар алып ташланган бүгенге чорда исә, бу темага алыныр фронтовик язучыларның сафы, кызганычка каршы, бик сирәкләнеп калды. Ә утны-суны кичкән, сугыш афәтен җилкәләрендә күтәргән фронтовиклардан гайре кем ул чор турында сөйли алыр соң? Мин бирдә ике төрле юл күрәм. Беренчедән, аз санлы булсалар да, актив иҗат белән яшәгән фронтовикларыбыз, шөкер, барлар әле. Әйтик, «Казан утлары»ндагы (1995 ел, 12 сан) әңгәмәсендә сугыш афәте өстенә Сталин лагерьларын үткән Гурий Тавлин «Үлем дәрьясы» дигән әсәрен тәмамлап килүе хакында хәбәр биргән иде. Икенчедән, сугыш темасына язарга алынучы яшьрәк буын өчен дә эшләргә җирлек бар. Сугышны кичкән әдипләребезнең архивларындагы көндәлек дәфтәрләрендә, фронт блокнотларында нинди генә мәгълүматлар юктыр дисең? Гомумән, алга таба Бөек Ватан сугышы темасы нигездә документаль проза юнәлешендә үсәр дип фараз кылам.

**Производство темасы** — эшчеләр (нефтьчеләр, төзүчеләр һ. б.) тормышына багышланган әсәрләр. Бүген тәнкыйтькә иң нык дучар ителгән әдәби юнәлеш. Үз чорының рәсми пропагандасын тормышка ашыручы үтә идеологик тармак. Заманында «яңа тема, яңа геройлар» идеясе белән әдәби байрак дәрәҗәсенә күтәрелгән әсәрләр, «үтә җете тиз уңар» дигән тормышчан фәлсәфә мантыйгында, вакыт сынавын уза алмаган китаплар галереясының үзәген тәшкил итәләр. Мәсьәләнең икътисади һәм сәяси ягына гына басым ясап, милли, әхлакый, фәлсәфи ягы белән кызыксыну җитмәү эшчеләр турындагы повесть-романнарны кырыс заман хөкеменә куйды. Бу тема хәзергесе көндә көчле кризис кичерә, һәрхәлдә, соңгы елларда сүз алып сөйләрлек нинидер зур әсәрне хәтерләмим. Әгәр дә производство темасы киләчәккә дәгъва кыла икән, ул һичшиксез, үзенең принципларын, адымнарын тамырдан үзгәртеп корырга тиешле.

**«Авыл прозасы»** — татар әдәбиятының нигезен тәшкил итә торган өлкә. Татар әдәбияты элек-электән авыл әдәбияты булып килде. Бүгенге сәяси-икътисади шартларда ни куәтле булып тоелган әлеге тема да мәгълүм бер сүлпәнлек кичерә. Сәбәпләре күптөрле. Иң мөһимнәреннән дип түбәндәгеләрне саныйм. Беренчедән, катлаулы, буталчык заманга килеп кергән авыл элекке авыл түгел инде. Аның кешесе дә башка. Моңа кадәр язучы авыл тормышын белеп, аңлап яза иде. Дистә еллар шәһәр шартларында кайнау да әдипкә авыл мохитын тоеп язарга комачаулык итмәде. Авыл, колхоз тормышында нинидер яңару сыйфатлары күзәтелсә дә, вәзгыятьнең нигезе тотрыклы калды. Шуңа күрә ул яналыкларны тотып алып, иҗатында чагылдыру язучы өчен артык кыен түгел иде. Ә менә бүгенге авыл турында язу өчен иске багаж — тәҗрибә генә җитмәве көн кебек ачык. Ничек сурәтләргә замана авылын, аның улын, кызын? Идеологик күрсәтмәләр чоры узган, айлар буе хезмәт хакы ала алмый бушка эшләргә мәҗбүр ителгән колхозчыны алдынгы сыер савучы яки үрнәк механизатор рәвешендә аһ-аһ килеп кызгану мыскыл булып күренергә мөмкин... Гомумән, урта буын прозаиклары өчен бүгенге авыл — ул энгер вакытындагы карурман сыман. Гомере буе татар авылына, аның кешеләренә тугрылык саклаган М. Мәһдиев «Бәхилләшү» повестенда бу хисне ачык чагылдыра: автор үзе белгән, үзе күргән авыл белән хушлаша. Яңа заман авылы аның темасы түгел инде. Ул бу эстафетаны башка буынга тапшырып калдырган. Димәк, авыл прозасының язмышы бүгенге әдәбиятка килергә тиешле яшьләрдә. Хәлбуки, татар милләтенең бишеге булган авыл үз иҗатчысын тудырмый калырга мөмкин түгел. Шуңа күрә авыл прозасының бүгенге пассивлыгын вакытлы күренеш дип санарга кирәк.

**Тарихи тема** — бүгенге шартларда иң актив юнәлеш-тармак. Алда күзәтелгән темалар торгынлык яки сүлпәнлек чорын кичерсәләр, тарихи әсәрләр өчен бу көн — буалар ерылган вакыт. Мәгълүм тыюларның җимерелүе, идеологик басымның алып ташлануы тарихи планда иҗат итүчеләр өчен чиксез мөмкинлекләр ачты. Тарихи романнар авторы Н. Фәттах моннан чирек гасыр элек үк «Казан утлары» (1972 ел, 6 сан) журналында «Татар әдәбияты өчен татар тарихы ул беркем аягы басмаган иксез-чиксез карурман кебек», — дип язып чыккан иде. Соңгы елларда татар язучылары бик актив рәвештә һәм беркадәр ашыгып та тарихыбыздагы «чирәм җирне» төрле аспектларда үзләштерә башладылар. Татар халкының милли-азатлык хәрәкәтенә караган (Җ. Рәхимов, В. Имамов), шәхес культы елларын фаш иткән (И. Салахов, А. Гыйләҗев, Р. Мөхәммәдиев, Г. Тавлин), Казан ханлыгына, аның ахыргы фаҗигале көннәренә һәм ханлыкның хөкемдары Сөембикәгә багышланган (Батулла, М. Хәбибуллин, Ф. Латыйфи) әсәрләр татар прозасының тарихи фондында лаеклы урын алдылар. Соңгы вакытта халыкның милли үзаңы уяну да мирасыбызның үткәндәге катламнары белән кызыксынуны бермә-бер көчәйтте. «Идел» журналы оештырган тарихи хикәяләр конкурсы да шушы ихлас кызыксынуның бер күренеше. Әдәбияттагы бүгенге вәзгыятьтән торып караганда прозабызның өченче меңъеллыкка тарихи проза байрагы күтәреп керәчәге бәхәс уятмый булса кирәк.

**3.** Алдагы бүлемдә әлеге сорауга күпмедер җавап бирергә тырыштык инде. Өстәп тагын бер мәсьәләгә тукталу зарур. Милли хис һәм аң уянуның күркәм биеклекләргә күтәрелүе «кая барабыз?», «без кем?» дигән тарихи сораулар янәшәсенә «без нинди?» мәсьәләсен ачыклау бурычын да бөтен кискенлегенә куйды. Бу исә үз чиратында милләтне яшәтә торган төп көчләрнең берсе — әхлак проблемасына килеп ялгана. Яңа гасыр бусагасын нинди мораль кагыйдәләр кысасында атлап керергә җыенабыз без? Киләчәк дәвергә узганда тарихка янә бер кат күз салуны таләп итә бур сорау. «Үткәннәргә карап зикер ит тә, алдагыга карап фикер ит...» Тарих — кабатлана. Иҗат принциплары да кабатлана, әмма дистә еллар дәвамында ул алымнар үзгә сыйфатлары белән ачыла барып, әдәби

хәрәкәтнең эчтәлегенә турыдан-туры йогынты ясыйлар. Хәтерлик, XX гасыр башы татар әдәбиятында төп темаларның берсе — «аталар һәм балалар» проблемасы иде. Искелеккә каршы көрәш, яңалыкны раслау идеясе проза өлкәсендә аеруча Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов иҗатларынын үзәгендә торды. 20—30 еллар әдәбиятында бу проблемага сыйнфый каршылык идеясе сеңдерелгәч, «аталар һәм балалар» конфликтын хәл итү хөкем карарын үтәү төсен алды. 60-еллардан әлеге тема бөтенләй үзгә формада яктыртыла башлады һәм, нәтиҗәдә, «аталар», «балалар» дигән төшенчәләр капма-каршы сыйфатларына ия булып (уңай — тискәрегә, тискәре уңайга әверелү күренеше), әдәбиятта яңа эчтәлек барлыкка килде. Әлеге хәрәкәт Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» (1965) әсәреннән башланды булса кирәк. Бу очракта инде өлкән буын вәкиле Акъәби халыкның гасырлардан килә торган гореф-гадәтләрен, әхлакый кануннарын, яшәеш кагыйдәләрен үзендә саклаган образ буларак характерлана. Аның «үтә заманча» балалары исә үз дөньяларына бикләнеп яшәүче төксе, шәхси мәнфәгатьләре белән генә көн күрүче буын вәкилләре булып күзалланалар. Акъәбинең туган туфрак, туган нигез хакындагы уйлары, буыннардан-буыннарга тапшырылырга тиешле мөкатдәс сүзләре — соңгы васыяте таш күңелләргә бәрелеп челпәрәмә килә. Аннан соң бу характердагы эчтәлек үзенчәлекле төсмерләрдә А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» повестенда, Ш. Хөсәеновның «Әни килде» («Әниемнең ак күлмәге») драмасында дәвам иттерелде. Тагын да соңрак бу тема әдәбиятта гамьсезлекне, битарафлыкны фаш итү җәһәтеннән генә түгел, бәлки, әйтергә кирәк, фаҗигале аһәң белән сугарылган хәлдә яктыртыла башлады. Моның аерым гыйбрәтле күренешләре заман үзгәрешләренә сизгер булган М. Мәһдиев иҗатында чагылыш тапты. Әдипнең «Исәнме, Кәшфи абзый!» повестенда ата белән улы арасындагы конфликт ахыр чиктә үтеп чыгалмаслык упкынга әверелә. Республикага исеме таныш тракторист Кәшфи бердәнбер улын да үзе кебек җиргә гашыйк, эшчән кеше итеп күрергә тели. Әмма аның эшен, исемен һәм нәселен дәвам итәргә тиешле өмет ата-анага бары тик борчу, оят-хурлык китерүче хәсрәт төенчеге булып җитешә. Гауга белән өйләнә, талаш белән аерыла, ямьсез кычкырышып, авылын ташлап китә, сукбайлыкта йөри, кабат туган нигезенә кайтып төшә, баш ташлап эчүгә сабыша һәм фаҗигале һәлак була. «Бәхилләшү» повестенда исә, язучы тагын да җанөшеткечрәк хәлләрне сурәтли. Ике әрәмтамак егет акча даулап әтиләрен кыйнап үтерәләр. Әдәбиятта шул рәвешле сагаюлы, сискәнүле шом урын алды: кемнәр алмашка килә? Үз вакытында К. Сибгатуллин бу хакта әрнеп һәм кисәтеп язган иде:

> Каты буын үсә.
> (Кем буыны?!)
> Барысы да килә кулыннан.
> Машиналар шавы кыйммәт бүген,
> кыйммәтрәк халык моңыннан.

Шулай да чыккысыз өметсезлеккә үк бирелергә җирлек юктыр. Кешеләр өметсезлеккә бирелгәндә бөтен бер милләт җанында куркыныч авыру — депрессия башланырга мөмкин. Тормыш үз чиренә каршы дәвасын үзе табар.

Бу — яшәеш кануны. Философиядә «капма-каршылык теориясе» дигән төшенчә бар. Логик эзлеклелек буенча фикер йөртсәк, болай булырга тиешле: хәзерге кырыс, каты буынга алмашка килгән буын үз яшәү принциплары белән киләчәк, ә алдагысына исә нык тәнкыйть белән караячак. Димәк ки, хәзер без сагаеп, борчылып, шом белән карый торган күренешләргә дә каршы позициядә булачаклар. Ул буын — һәм моңа бик ышанасы килә — югары әхлакый кысаларны кыйбла итеп сайлар. Башбаштаклыкны, гаделсезлекне инкарь итү шуңа китерергә тиеш ләбаса инде. Югары әхлакый кагыйдәләрне сүз белән күңелләргә үткәреп, үз буынын тәрбияләргә алынучы әдипләр дә Исхакыйлар, Әмирханнар, Ибраһимовлар мәйдан тоткан чордан соң бер гасыр вакыт үткәч әдәбият дөньясына килерләр. Тарихта кабатлану шулайрак булырга тиеш. Хәзер иҗат итүчеләр ул заманны үзләштерә алмаслардыр инде. Яңа фикер, яңа караш, үзгә яшәү кануннары белән коралланган алдынгы яшь буында өмет. Күңелнең көткәне — бүген әле «Туган тел»не өйрәнеп кенә йөрүче, Галиҗанап Сүз серләренә төшенеп кенә килүче татар угылында.



Солтан Шәмси

# КУЛИКОВО КЫРЫ САБАКЛАРЫ

*Егылганнан соң кабат күтәрелә алу сәләте бөек халыкка хас бер сыйфат булып тора. Каһәрләнүе бик авыр булуга да карамастан, тиешле сәгать суккач, ул үзенең таркау яткан рухи көчләрен туплый, аларны бер бөек затта яисә берничә бөек шәхестә гәүдәләндерә һәм алар юлдан вакытлыча төшеп торган халыкны тарихның туры юлына кабат алып чыгалар.*

В. Ключевский, урыс тарихчысы

## I

**1980** елның сентябрь аенда «совет халкы» зур шау-шу белән Куликово сугышының 600 еллыгын билгеләп үтте. Урыс дөньясы өчен зур әһәмияткә ия вакыйгага үз өлешен кертмәгән бер генә газета-журнал да калмагандыр. Мин ул чакта өйгә 7—8 журнал алдыра идем. Әле дә хәтердә, шушы датага хәзерлек йөзеннән журналлар җәйге айлардан ук зур-зур мәкаләләр-очерклар бастыра башладылар, һәм вакыйганың иң олы тантанасы балалар чәчәк тотып мәктәпкә барган сентябрь аенда булды. Шулай ярты ел чамасы матбугат чараларында «монгол-татарны» һәм «татарны»,— аның «иго»сы өчен сүгү-каһәрләү дәвам итте. Бу айларда үз тарихын рәтләп белмәгән татар кешесе ирексездән татарлыктан баш тартырга, «мин татар түгел, болгар, болгар!..» дип бәргәләнергә мәҗбүр ителде. Хәер, ул елларда тарих фәнендә «болгар теориясе» әле бик көчле булып, ул бөтенләй какшамас сыман тоела иде.

Әмма шулай тоелган гына икән. Шул ук 80 нче еллар азагында галимголяманы гына түгел, гомумән киң җәмәгатьчелекне нык дулкынландырган бу мәсьәлә матбугат битләренә бәреп чыкты, кызу гына «болгармы?-татармы?» бәхәсе булып алды. Аның койрык очы әле бүген дә ара-тирә ялтырап-ялтырап киткәли, үзен сиздергәләп куя.

Сүзне Куликово сугышы юбилееннан башлаган идек. Әмма Куликово кыры вакыйгаларына барып җиткәнче берничә күзәтү ясап үтмичә ярамас, чөнки 1380 елда булып узган бу сугыш берничә гасыр дәвамындагы барышның мөһим бер баскычын тәшкил итә.

Көнчыгыш Аурупаның урта гасырлар тарихына гомуми караш ташлаганда, беренче чиратта, без анда ике зур суперэтносның — төркиләр белән славяннар берлегенең гаять катлаулы һәм каршылыклы мөнәсәбәтләренә, үзара көрәшенә игътибар итәбез. Ул түбәндәге баскычлардан тора.

1) Кубрат ханның Бөек Болгариясе таралганнан соң Көнчыгыш Аурупа далаларында төркиләр төзегән Хәзәр дәүләте генә торып кала. Бу дәүләт белән Киев Русе арасында барган көрәш 965 елда кенәз Святославның хәзәрләрне тар-мар итүе белән тәмамлана.

2) X йөзнең азагыннан (990 елдан) Киев Русе белән бәҗәнәкләр союзы арасында көчле бәрелешләр башланып китә. Әмма бераздан бу көрәш өзелеп кала. Эш шунда, XI йөз башларында Кыймак каганлыгыннан аерылып чыккан кыпчаклар Көнбатышка таба юл тота. Алар бәҗәнәкләр яшәгән далага килеп керә. Бәҗәнәкләр гайрәтле һәм гаять ишле кыпчаклар тарафыннан кысрыкланып, тагын да арырак — Дунай буена күчеп китәргә мәҗбүр булалар.

3) Шулай итеп, бәҗәнәкләр урынын алган кыпчак ырулары үз чиратында Киев Русе белән көрәш башлый. (1061 елда кенәз Всеволод кыпчаклар тарафыннан тар-мар ителә.) Көрәш байтак вакыт дәвам итә һәм бары тик көчле кенәз Владимир Мономах (1125 елда вафат) заманында гына кыпчакларның активлыгы беразга тукталып тора. Урыс кенәзләре, кыпчакларны үз якларына аударып, үзара сугышканда алардан бик оста файдалана. Кенәзләр улларын кыпчак кызларына өйләндерә, шулай үзара туганлашу, кода-кодагыйлык башланып китә. Шуңа да карамастан, төрки-кыпчаклар белән урыслар арасында киеренкелек сакланып кала. (Әйтик, 1168, 1182, 1184, 1202, 1205 елларда Киев кенәзләренең кыпчакларга каршы оештырган яулары шул хакта сөйли.) Сугышларның тынмавы дала батырлары кыпчакларның урыс кенәзләрен даими борчып, аларга каршы көтелмәгән һөҗүмнәр оештырып торуы белән аңлатыла. Кыпчаклар исә шактый таркау яши. Әле бер, әле икенче кенәз ягына чыгып, күп яуларда катнашалар.



*1203 елда кыпчакларның Киев шәһәрен алуы.*

Бу вакыт урыс кенәзләре үзара мөнәсәбәт ачыклау, «Киевнең алтын өстәленә-тәхетенә» утыру өчен күп көч куйсалар, шул сәбәпле гаять таркау яшәсәләр, дала уллары кыпчаклар арасында да үзара берләшеп, көч туплап, берәр дәүләт сыманрак нәрсә оештыру турында уйлаучы табылмый. Шуңа күрә XI йөз урталарында бик зур гайрәт белән Көнчыгыш Аурупа далаларына бәреп кергән кыпчакларның, уртак бер идея тирәсенә туплана алмыйча, теләсә кем белән сугышып, теләсә кемгә хезмәт итеп, һәр хан үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүләре аркасында тарихи җегәре-энергетикасы әрәм-шәрәм булып бетә. Дөрес, бу чорда Көнчыгыш Аурупа далаларында төркиләр массивы арта төшә, калынайа һәм бу хәл, монгол яулары башланып, Алтын Урда дәүләте төзелгән вакытта унай роль уйный.

# II

**1223** елда Көнчыгыш Аурупа далаларында монгол армиясе бәреп керү белән монда яшәгән этнослар өчен зур сынаулар, үзгәрешләр чоры башланып китә. Калка елгасындагы беренче сугышта берләштерелгән кыпчак-урыс гаскәре дошманга каршы чыга. Ләкин монголлар бу бәрелештә җинә. Олуг тарихчыбыз Ризаэтдин Фәхретдин фикеренчә, «Җужи ханның (Чыңгыз ханның улы» Дербенттан килеп чыгуының төп максаты — кыпчак төрекләре белән берлек төзү иде. Ләкин урыс кенәзләренең котыртулары аркасында кыпчаклар белән тау халыклары Җужи хан гаскәренә каршы тордылар һәм, урысларның сугыш мәйданын ташлап качулары сәбәпле, җиңелделәр» (Р. Фәхретдин. Алтын Урда ханнары. Казан, 1996. 16 б.).

Бу чыннан да дөрескә охшый, чөнки монголларның сугыш алдыннан кыпчакларга кеше җибәреп, без сезнең белән кан-кардәшләр дип, тегеләрне сугышмаска өндәве тарихи чыганакларда теркәлеп калган.

Шул ук елны монгол гаскәре даладан читтәрәк яшәгән Идел Болгарстанына да кылыч тартып карый, ләкин, бик нык каршылыкка очрап, кыйналып кире борылырга мәҗбүр була. Ә инде тагын 13 елдан монголларның бик зур гаскәре, Җаек елгасын кичеп, Көнчыгыш Аурупадагы дәүләтләрне яуларга керешә. 1236 елда Идел Болгарстаны, 1237 дә Рязань, Мәскәү, Владимир кенәзлекләре егыла. Ике елдан соң алтын гөмбәзле чиркәүләре белән дан тоткан гүзәл Киев каласы да алар кулына төшә, аннан төрки-монгол гаскәре Галиция, Волынь, Польша, Силезия, Моравия, Венгрия, 1241 елда хәтта Вена шәһәре диварларына кадәр барып җитә.

Шушы дәһшәтле яулардан соң 1243 елда үзәге Идел буеның мул үләнле даласына урнашкан Җужи олысына, ягъни Алтын Урда дәүләтенә нигез салына.

Әлеге вакыйгалар турында сүз барганда без гел «монгол гаскәре», «монгол яулары» дигән гыйбарәләр кулланабыз. Бу урыс тарих фәненә иярү күренеше. Ә бит чынында Көнчыгыштан килгән ифрат зур армиядә монгол элементы шактый аз булган. Гаскәрдә күпчелекне яулар барышында һаман өстәлә торган төрки кавемнәр тәшкил иткән. Шуңа күрә бу яулар турында сүз барганда анда канкардәшләребез төркиләрнең ролен гел истә тотарга кирәк. Миңа хәтта бер төрек аркадаштан «монгол яулары» дип язган өчен шелтә дә ишетергә туры килде. Ул, мәсәлән, Алтын Урданы фәкать татар дәүләте дип саный һәм дөрес эшли.

Әлбәттә, Чыңгыз хан империясен монголлар төзегән, ханнары да чыңгызыйлар, ягъни Чыңгыз хан нәселеннән чыккан затлар булган. Әмма төп масса төрки халыклардан торган. Дөньяга яңа этәргеч биргән, аңа «кан алыштырырга» ярдәм иткән бу яуларда төркиләрнең өлеше ифрат зур. Моның белән горурлана белергә кирәк. Гомумән, Монгол империясен төзегән Чыңгыз хан феномены, Александр Македонлы (Искәндәр Зөлкарнәйн) һ. б. бөек җиһангирлар эшчәнлеге кебек үк, Галәм, Илаһи Көчләр катнашыннан башка тормышка ашырыла алмас иде. Бу хакта әле фәнни әйләнешкә кермәгән эзотерик (яшерен) чыганакларда шактый ачык кинаяләр бар.

Алтын Урданың барлыкка килүе Көнчыгыш Аурупа далаларындагы таркау этносларны да, ничә гасыр буе үзара тарткалашып гомер кичергән утрак халыкларны да бер дәүләт кысаларына туплый. Объектив яктан караганда бу, һичшиксез, алга китеш, тәрәккъыять күренеше. Әлбәттә, сугышларда күп кан коела, рухи һәм матди байлыклар да харап була. Ләкин яңаны төзү, үсешнең яңа баскычына күтәрелү һәрвакыт искене җимерү, аннан баш тарту, инкяр итү юлы белән бара түгелме? Бу бит эволюциянең төп кануны. Н. К. Рерихның «Держава Света» исемле китабында бу хакта кызыклы фикер бар. «Халыкларның бөек күченеше — очраклы хәл түгел,— дип яза ул.— Даими булып торган дөньякүләм күренешләрдә очраклылык була алмый. Шушы үзенчәлек аркасында халыкларның иң тормышчан куәте, сәләте чыныгу ала. Яңа күршеләр белән аралашу аңны киңәйтә, яңа расаларның формасын барлыкка китерә. Шуңа күрә тере хәрәкәтчәнлек ул зирәклек галәмәте булып тора».

Монгол яуларының асыл мәгънәсе нәрсәдә соң? Мондый сорауга җавап биргәндә иң элек теге яки бу күренешнең эволюция барышына ни өстәвен ачыкларга кирәктер, шәт. Үзебезгә якын Көнчыгыш Аурупаны күз алдына китерик. Бу вакытта Русь кенәзлекләре ни хәлдә? Пыр тузынышып сугышып яталар, үсеш тукталган, алга китү онытылган. Ә монгол яулары шушы сөрсеп яткан дөньяга хәрәкәт, яңа җилләр алып килә. Алтын Урда составына кереп, урыслар яңача төзелгән дәүләт үрнәген күрәләр; яңа хәрби система белән танышалар; яңача идарә итү, салым җыю тәртипләрен үзләштерәләр; элемтә чаралары, ягъни

тиз арада хәбәрләшү ысулларын ачалар (ям); яңа сәүдә юллары барлыкка килә; яңа кануннар белән танышалар һ. б., һ. б.

Бу яңалыкларны алга китеш, тәрәккыять дип карамыйча мөмкин түгел. Рас шулай икән, халыкларның бөек көчешен, олуг яулар, шул исәптән монгол яулары белән Алтын Урда дәүләте төзелүне дә Илаһи Көчләр ярдәме белән башкарылган гамәлләр дип карау дөрес булыр иде. Чөнки Галәм кешелек дөньясының эволюциясен гел кайгыртып тора, әмма кирәксезгә Җир эшләренә кысылмый, барысын да адәми затның үз кулы белән табигый рәвештә башкара. Кешеләр моны сизми генә — үзеннән-үзе шулай килеп чыкты дип уйлый. Эзотерик чыганаклар безгә шул хакта сөйли.

Монгол яуларына кадәр дә Көнчыгыш Аурупа далаларында кыпчак массивының шактый көчәюен, бу кавемнең славяннарның төп көндәшенә әверелүен искәртеп үткән идек. Алтын Урда барлыкка килү белән бу далалар, гомумән, Кыпчак даласына әйләнә — тарихка да ул Дәште Кыпчак исеме белән кереп кала. Шулай кыпчаклар бередә төп этнос булып китә, ә аз санлы монголлар бераздан йотылып, тәмам кыпчаклашып-татарлашып бетә, ассимиляция кичерә. Төркиләр хаким халыкка әверелә. Әлбәттә, Идел Болгариясе дә бу процесстан читтә калмый. Болгарларның «татарлашуы» да шушы вакытта башланган дип исәпләргә нигез бар.

*Половецкие воины XII века. Реконструкция М. В. Горелика по половецким каменным изваяниям и материалам археологических раскопок.*



*Кыпчак яугырләре (XII йөз). М. В. Горелик реконструкциясе.*

Форсаттан файдаланып, Алтын Урдадагы халыкның «татарлашуы» хакында бер күзәтүем белән уртаклашасым килә. Моңарчы күпме тарихи хезмәтләр укысам да, әле Үзәк Азия далаларында Чыңгыз хан белән көрәшкән татарларның нинди телдә сөйләшкәнен ап-ачык итеп, өздереп әйткән хезмәт очратканым юк иде. Бәлки, туры килмәгәндер. Тик шунысы сәер, тарихчылар да бу мәсьәләне гел әйләнеп узалар. Чыннан да, кайсы телдә сөйләшкән соң ул татарлар? Төрки телдәме, әллә инде монгол яисә башка берәр телдәме?

Ниһаять, «Мирас» журналының 1996 ел, 7-8 саннарында басыла башлаган кыйммәтле чыганак — Ибне әл-Әсирнең «Елъязмалар төзү өлкәсендәге камиллек» исемле хезмәтендә моңа күпмедер ачыклык кертелә кебек. Чыганакта сүз Алтын Урданың Җучи улы Бәркә хан заманы турында бара. Аңа Мисыр солтанынннан илчеләр килә, аларның хан тирмәсендә кабул ителүе тасвирлана. «Бәркә (хан) тәхеттә утыра, янәшәсендә олы хатыны, арырак 50—60 әмир эскәмиядә утыра. Илчеләр патша (Бәркә хан) янына кергәч, ул вәзирләренә хатны укырга кушты... Бәркә (хан) янында булган баш казый хатны тәрҗемә итте һәм исемлекне (нинди исемлек икәне аңлашылмый — *С. Ш.*) ханга җибәрде; хатны Бәркә (хан) кешеләренә (тезелешеп утырган әмирләр булса кирәк — *С. Ш.*) **төркичә укыдылар. Татарлар моңа куандылар...»** (189 б.)

Әйтергә кирәк, соңгы җөмләдә бик кыйммәтле мәгълүмат бар. Димәк, Алтын Урда дәүләте төзелгән елларда ук (беренче хан Бату 1255 елда вафат), төрки-татарлар дәүләтне идарә итүдә актив катнашканнар. Илчеләрне кабул иткәндә хан янәшәсендә утырган 50—60 әмирнең күпмесе төрки-татарлардан булгандыр — анысы билгесез, тик Мисыр солтанынннан килгән хатның алар өчен махсус төркичә тәрҗемә ителеп укылуы һәм татарларның моңа куануы игътибарны җәлеп итә. Бу факт Алтын Урданың чыңгызый ханнарының татарларга (асылда төрки-кыпчакларга) таянып идарә итүен бик ачык күрсәтә. Шунлыктан дәүләттә кыпчак («татар») теленең тиз арада рәсми телгә әверелеп китүе табигый хәл булган, дип әйтә алабыз.

Шулай итеп, Алтын Урда дәүләтенә кергән барлык төркиләр, кыпчаклык казанында кайнап, иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни яктан бер үзәккә тартылып, көчле дәүләттә уртак тел, мәдәният һәм әдәбият хасил итәләр.

III

Һәр тере организм, үзгәрүчән система кебек, Алтын Урда дәүләте дә төрле заманнар кичерә. Тик аның иң биек, иң шәһрәтле һәм гайрәтле чагы, мәмләкәт барлыкка килеп, бер гасыр вакыт узгач, Үзбәк хан (1312—1342) идарәсенең соңгы елларына туры килә. Бу вакытта аның сәяси абруе, җәйгә салынган тормышы, икътисады, мәдәнияте шундый югарылыкка ирешә ки, күрше дәүләтләр өчен ул өлге-үрнәккә әверелә. Нәкъ шушы дәвердә ислам дине чын мәгънәсендә мәмләкәтнең рәсми диненә әйләнә. Мөселман дөньясының төрле тарафларыннан Сарайга дин әһелләре, галим-голяма, шагыйрьләр агыла. Шушы елларда Алтын Урда җирләре аша узган мәшһүр ислам сәясәтчесе һәм олуг дин белгече Ибне Баттута юлларның иминлеге, дәүләттәге тәртип һәм тынычлык, һәр тукталышта юлчыларны кабул итәргә әзер торган кәрван-сарайлар, ханәкәләр, анда яшәп яткан суфилар, дәрвишләр турында хәйран калып яза. Сәяхәтче юлда дала тутырып баручы процессия белән очраша, арбаларга йөзләгән тирмәләр утырткан бу халыкның Үзбәк хан бичәсен озатучылар икәнен белеп бик нык гаҗәпкә кала.

Әмма нәкъ Үзбәк хан заманында җәйгә салынган тормыштан, үзәккә агылып торган байлыктан, мәмләкәт ирешкән абруйдан, һәртерле дипломатик уңышлардан тынычланып калу, киләчәкне уйламыйча рәхәткә чумып яшәү, ваемсызлык галәмәтләре дә күренә башлаган булса кирәк. Билгеле хакыйкать — берәр нәрсәгә ирештем дип тынычланып калдыңмы — беттең. Бу инде үсеш тукталды дигән сүз.

Үзбәк хан шулай ук кул астындагы урыс кенәзлекләренә дә бик зур иркенлекләр бирә. Моңа заманында Р. Фәхретдин дә игътибар иткән. Бу ханның эшчәнлегенә бәя биргәндә тарихчы аның ялгышларына да күрсәтеп үтүне тиеш таба: «Үзбәк хан алдан күреп эш итүчән, гакыллы, галиҗәнап падишаһ булса да, сәяси җәһәттән зур бер ялгышы инкяр ителмәс. Бу ялгыш Мәскәү кенәзлеген куәтләндереп, Урдага каршы киләчәк дошман әзерләүдән гыйбарәт. Үзбәк хан гамәлдә үз араларында сугышып, кырылышып торган вак кенәзлекләрне бетереп, бер ноктага җыйды. Шул сәбәпле урыслар куәт алып киттеләр»,— дип яза тарихчы. Алай гына да түгел, Үзбәк хан Русия митрополиты Петрга православие дине өчен чикләнмәгән ирекләр бирә, монастырь җирләрен ясак түләүдән азат итә. Бу динне яклап хан тарафыннан бирелгән ярлыкта, Р. Фәхретдин сүзләренчә, хәтта «кем дә кем христиан динен сүксә, чиркәү, монастырь вә часовняларга тел тидерсә, ул адәм үтерелер», дигән сүзләр дә булган.

Әлбәттә, һәр халыкның үз динен, гореф-гадәтләрен тотарга тулы хакы бар. Бу яктан караганда Алтын Урда дәүләте заманның иң алдынгы, һәр диңгә иркенчелек, тигезлек бирелүе белән Аурупа илләреннән аерылып торган. Чит илләрдән килгән кунаклар да моңа игътибар иткәннәр, андагы вөҗдан ирекен күреп гаҗәпкә кала торган булганнар, чөнки үз илләрендә бу хакта хыялланa да алмаганнар. Гомумән, Алтын Урдада көчле идеологик корал итеп карау, моны аңлау бөтенләй булмаган, ахры, дип әйтергә туры килә.

Шул ук православие динен алыйк. Әгәр дә ханнар бу динең мөселман татарга каршы юнәлтелгән идеологик корал икәнен дә күрсәләр, аның урыс халкын берләштерүче, мөселманнарга карата дошманлык тәрбияләүче көчле чара икәнен чамалый алсалар, андый ук иркенлекләр бирмәсләр иде. Урыс халкы мескенлектән фәкать үзенең руханилары тырышлыгы белән чыкты, рухи яктан ныгый барды һәм күпмедер вакыттан соң Сарайга каршы корал күтәрерлек көчкә әверелде. Шулай итеп, Алтын Урда үз куенында үсеп җиткәч үзен үк чагачак елан үстерде. Шунысы кызык: Үзбәк хан тәхеткә чыгу белән монголлар арасында һаман әле яши биргән буддизмга каршы аяусыз көрәш башлый, үз дәүләтендә аның тамырын корыту өчен күп көч куя. Шуның аркасында ветераннары белән каршылыкка да керә. Ә менә православие диненә бөтен иркенлекләр дә бирелә. Бу ялгышы киләчәктә дәүләт өчен зур мәшәкатьләр тудырасын башына да китереп карамый.

Үзбәк хан белән Җанибәк ханнар заманында Алтын Урда әле яшьнәп яши, ләкин алардан соң тәхеткә чыккан Бирдебәк хан 1359 елда үтерелгәннән соң, дәүләттә эчке чуалышлар, низаглар башланып китә. 1360-1361 елларда дәүләт

икегә аерыла — уң һәм сул канатка. Иделдән көнчыгыштагы җирләр сул канатка керсә, көнбатыштагылары уң канатны тәшкил итә. Уртада — Идел елгасы. Бер якта гел алышынып торган Сарай ханнары булса, икенче якта, Сарайны кулга төшереп, анда үз ханын утыртырга омтылучы гайрәтле Мамай мирза хәрәкәт итә. Шулай итеп, дәүләттә ватандашлар (дөресрәге, ватанны харап итүчеләр!) сугышы башланып китә. Ул 20 елга сузыла һәм дәүләтне эчтән җимерүче факторга әверелә. Татарның үзара талашуыннан бик оста файдалана белгән Мәскәү кенәзлеге исә шушы елларда матди һәм рухани яктан шактый ныгып кала. Әгәр дә Алтын Урдада бу низаглар, тәхет даулары булмаса, 1380 елда урыслар корал тотып Куликово кырына чыгу түгел, ул хакта уйларга да җөрьәт итә алмаслар иде.

Ике дистә елга сузылган башбаштаклык, акылсыз сәясәт татарны шундый хәлгә төшерә. Бу үлчәүнең урыслар ягына авыша башлавы да ихтимал дип кисәтүче ишарә була.

Дөрес, Куликово сугышында берләштерелгән урыс армиясенә каршы бөтен Алтын Урда гаскәре түгел, ә дәүләтнең Мамай мирза кул астындагы уң канаты гына катнаша. Шуңа күрә без, урыс тарихчыларына ияреп, бу сугышта «Алтын Урда гаскәре тар-мар ителде» дигән фикерне катгый төстә кире кагарга тиешбез. Чөнки нәкъ ике елдан (1382) Мәскәү шәһәре Урда татарлары тарафыннан алына һәм олуг кенәз Дмитрий Иванович Донской, элекке кебек, Сарайга ясак түли башлый.

## IV

Алтын Урда тарихын өйрәнгәндә сәер бер хәл игътибарны җәлеп итә — бу дәүләтнең сәясәтенә мөселман руханиларының йогынтысы бик зәгыйфь булуын күрәсең. Дин әһелләре ханнар өчен рухани остаз, кыен мәсьәләләрне хәл иткәндә киңәшче дәрәҗәсенә күтәрелә алмаганнар, ахры, дигән фикер туа. Чыганаклардан күзгә ташланган бердәнбер зур вакыйга Үзбәк ханның улы Җанибәк хан заманына карый. 1357 елда Мөхетдин әл-Бәрдагый дигән атаклы бер шәех Сарай шәһәренә килә дә Әзербәйҗанда хөкем сөрүче Мәлик Әшрәф өстеннән Җанибәк ханга шикаять бирә, аның халыкны бик нык җәберләвен, залимлеген, комсызланып мал җыюын бик тәэсирле итеп сөйләп бирә. Хан мәшһүр шәехнең сүзен игътибарсыз калдырмый, гаскәр туплап залим хөкемдар өстенә яу чаба. Ике гаскәр Тәһран елгасы буенда очраша, зур сугыш була. Мәлик Әшрәф гаскәре тәмам туздырыла, ул үзе Җанибәк хан хозурына китереп бастырыла.

Киң күңелле, мәрхәмәтле Җанибәк хан Мәлик Әшрәфне гафу итмәкче булса да, Әзәрбәйҗанның олуг адәмнәре ханнан аны үтертүен үтенәләр, чөнки «ул сәламәт калса, бу тараф халкына һич рәхәтлек булмас, аның яңадан әйләнеп кайтуыннан һәркем куркып яшәр», диләр алар. Һәм Әшрәф хан әмере белән җәзага тартыла. Дөрес, бу очракта Җанибәк ханның нияте хакыйкатьне торгызу гына булмаган, күрәсең, чөнки кулга төшкән малның гаскәргә бүлеп бирелгәннән калган өлеше 400 дөягә төялә һәм Сарай шәһәренә кайтарыла.

Бу вакыйганы җәелеп язуның сәбәбе аңлашыладыр дип уйлыйм. Эш шунда, Алтын Урда тарихында мондый фактлар бик сирәк очрый. Бу исә дин әһелләренең сәясәткә йогынтысы әлләни зур булмавын күрсәтә шикелле.

Ә менә урыс тарихында руханилар, нигездә митрополитлар, яисә үзенең яшәеше, тормыш рәвеше белән изге дип танылган абруйлы затларның кенәзләргә, соңрак патшаларга да йогынтысы гаять көчле булган. Урыста дәүләт сәясәтен идарәче-хаким белән дин әһеле кулга-кул тотынышып алып барган. Мәгълүм ки, дин әһелләре, җәмгыятьнең иң укымышлы катламы буларак, дәүләтнең идеологиясен эшләгәннәр, аны заман таләпләренә җайлаштырып, үзгәртеп торганнар. Шулай итеп, хакимнәргә дәүләтнең төп яшәү максатларын ачыкларга ярдәм иткәннәр. Әлбәттә, бу традиция урысның үзендә барлыкка килеп, табигый рәвештә үсеп чыккан нәрсә түгел. Ул әзер килеш православие дине, шуңа бәйле бай мәдәният белән урысларга Византия (Царьград) империясеннән килә, аннан инде җирле шартларга яраклаштырыла, үзгәрешләр кичерә.

Сарай ханнары кул астыннан чыгарга хыялланып яшәгән, хәтта бу юнәлештә инде кайбер адымнар да ясарга җыенган Мәскәү кенәзе Дмитрий Иванович 1380 елның җәй ахырында Мамай мирзага каршы яуга кузгалыр алдыннан, гадәткә кергән йола-традиция буенча, көч-таянычны дин әһелләреннән өмет итә, Куликово сугышы алдыннан алар белән күрешеп, хәер-фатиха алырга ниятли. Тик кем

белән очрашырга, кемнән фатиха алырга? Эш шунда ки, моннан ике ел элек, 1378 елда, Мәскәү митрополиты Алексий вафат була, аның урынына яңа кеше әле расланып өлгерми, чөнки урыс руханилары арасында митрополит кафедрасы өчен ун елга сузылган тарткалашу башланып китә. Бу очракта кемгә мөрәҗәгать итәргә, урыс руханилары арасында кем иң зур абруйга ия дә, кем бөтен халык тарафыннан танылган изге зат санала?

Дөресен әйткәндә, олуг кенәз Дмитрий Иванович алдында андый сорау бөтенләй тормый, чөнки ул елларда рәсми куелган митрополиттан үзгә изге гамәлләре, тормыш-яшәеше, рухани батырлыклары белән халык тарафыннан танылган бердәнбер асыл зат Сергий Радонежский була. Әйтергә кирәк, татарда бу руханига карата мөнәсәбәт шактый катлаулы, чөнки урыс халкын Алтын Урда белән җан-фәрман көрәшкә өндәүче, аңа көч-куәт биреп торучы, күңелләренә өмет нуры салучы төп фигура да шушы Сергий атакай Радонежский бит. Ләкин бу хәл аңа карата тискәре мөнәсәбәт саклар өчен сәбәп була алмый. Ул бит мәгълүм бер заманда, конкрет бер вәзгыятьтә үз халкының азатлыгы, аның бәйсезлеге өчен көч куйган зат, шуңа күрә бүгенге көндә тулы бәйсезлек хакында хыялланучы татарның аңа карата кинә саклавы чикләнгәнлек галәмәте булыр иде.

Аның бу вакытта зур абруй казануын тагын бер факт раслый: 1377 елда вафатына бер ел калган чакта митрополит Алексий, көннән-көн хәлсезләнә баруын исәпкә алып, йола буенча үзе исән чакта урынына кеше билгеләп калырга тели. Шул нияте белән Сергий Радонежскийга мөрәҗәгать итә, митрополитлыкны аңа тапшырмакчы була. Тик Сергий атакай моннан баш тарта: «Гафу ит, Владыко, мин яшь чагымда да алтыннан киенмәдем, карт көнемдә дә мохтаҗлыкта яшәргә тиешлемен дип беләм»,— дип җавап бирә ул. Ә тагын бер елдан митрополит Алексий вафат була. Һәм, әйткәнебезчә, руханилар арасында митрополитлык өчен көрәш башланып китә. Шунысы игътибарга лаек: митрополит булырга теләүчеләрнең һәркайсы көрәш барышында Сергий Радонежскийның фатихасын алырга тырышалар. Бу исә дин әһелләре арасында аның аерым бер урын алып торуын, зур абруйга ия булуын күрсәтә.

## V

Әйе, Алтын Урда ике канатка аерылып 20 ел буе үзара сугышлар алып барган, шул сәбәпле татар үз дәүләтен эчтән җимергән, хәлсезләндергән, потенциаль дошманы Мәскәү кенәзлегенә көч тупларга ярдәм иткән мәгълүм елларда татарлар арасыннан бу хәлнең дәүләтне һәлакәткә китерәсен аңлаган, төрле низаглардан, үзара көрәшүче фиркалардан өстен торган берәр олуг шәхес үсеп чыкканмы? Үзенең ханнар да колак салырдай саллы сүзе белән ике якны килештерә, сукыр сәясәтнең бөек татар мәмләкәтен нинди авыр хәлгә куячагын күрә белгән, шуны аңларга тырышкан берәр асыл зат булганмы? Кистереп әйтә алабыз — юк, булмаган андый шәхес. Булса, аның исеме, һичшиксез, тарихта калыр иде, андый затны халык онытмас иде. Бу очракта без чыганаклар сакланмаган дип тә котыла алмыйбыз. Халыкның хәтере дә бар бит әле. Андый шәхесләр чыганакларда гына түгел, халыкның йөрәгендә яши, риваятьләр, дастаннар булып буыннан-буынга күчә. Әнә бит, Идегәй мирза белән Туктамыш ханның үзара көрәше дастанга әверелгән, гасырлар аша безгә килеп җиткән.

Бу елларда Алтын Урда коточкыч инкыйраз-кризис кичерә, ханнар белән хөкүмәт ваклана, әлсери, идеаллар түбән тәгәри. Балык башыннан чери дигәндәй, идарәчеләрнең әхлагы түбән булгач, гади халыктан ни көтәргә кала? Гомумән, бу кризис, болганышлар чорында илне кайгыртучы олуг шәхеснең мәйданга чыга алмавы Алтын Урда канаты астына тупланган чуар кавемнәрнең уртак идеалы әле калыплашып җитмәве турында сөйли шикелле. Әгәр дә дәүләт тагын илле ел (ике буын) гына тыныч шартларда яшәсә, инде борынлап килгән уртак үзәк, уртак идеал, һичшиксез, ныгып өлгергән булыр иде. (Бу мәсьәләгә язманың азагында киңрәк тукталырбыз.)

Урыс дөньясында исә бу елларда, бердәм булсак җиңәрбез, үзара талашуларны, әләк белән Сарайга, ханнар хозурына йөрүләрне туктатып, бер йодрыкка тупланырга кирәк, дигән фикер көннән-көн, елдан-ел ныгый бара. Мәскәү кенәзләре, аларның таянычы булган урыс руханилары бу фикерне пропагандалаучы төп көчкә әверелә.

Татарда исә бу елларда кая карама башбаштаклык, сәяси сукырлык, рухи сәрсү. Бөек мәмләкәтнең тарихындагы бу дәвергә Р. Фәхретдин дә игътибар иткән, бик нык аптырагач, аңлатыр сүз таба алмагач, «җәнабы Алланың үзенә генә мәгълүм булган сәбәпләр аркасында хөкүмәтләр өстенә кайбер вакыт кисәктән фалиж (паралич) хәстәсенә охшаган бер афәт килә»,— дип чикләнергә мәҗбүр була ул.

Шулай да Алтын Урдада XIV йөзнең 60 нчы елларында башланган «бөек болганыш»ның килеп чыгу сәбәбе нидә икән? Ни өчен көчле дәүләттә кинәт эчке низаглар кабынып китә? Кайбер тарихчылар моны далада халык саны кирәгеннән артып киту (?), хәзерге атамаларга күчерсәк, демографик шартлау белән аңлатырга тырышалар. Янәсе, көтүләр йөртү, җәйләү-кышлау өчен уңайлы урыннар, маршрутлар елдан-ел кысыла, тарая барган, шуның аркасында каршылыклар килеп чыккан. (Э. Кульпин. «Путь России». Кн. 1, с. 91).

Ләкин халык санының бик нык артып китүенә ышануы кыен. Ни өчен?

Әйткәнебезчә, Үзбәк хан заманы дәүләтнең чәчәк аткан, иң нык күтәрелгән чагы дип санала. Табигый ки, бай һәм имин заманда халык саны да үзенең иң бөек ноктасына җиткән булса кирәк. Тик Үзбәк хан үлгәч, дүрт ел да узмый, 1346 елда Алтын Урда өстенә зур афәт килә — Аурупадан чыккан чума эпидемиясе Дәште Кыпчак, Идел буе һәм Кырымда бик күп халыкны алып китә. Елъязмаларда бу хакта «Үзбәк (хан) җирләрендә... шәһәрләр һәм авыллар бушап калды», диелә. Бер Кырымда гына да шушы эпидемиядән 85000 кеше кырыла. Бу фаҗига илгә бик зур зыян сала, аның авыр нәтиҗәләре шактый елларга сузыла. Ә шушы хәлдән соң 13 ел узгач, Алтын Урдада «бөек болганыш» — ватандашлар сугышы башланып китә. Аның сәбәбен далада җир җитмәү белән бәйләү беркатлылык түгелме?

Минемчә, сәбәп бередә «җир җитмәүдә» түгел, ә 1359 елда Бирдебәк хан үтерелгәннән соң дәүләттә хакимиятнең ихтыярсыз һәм очраклы кешеләр кулына күчүендә. Шуннан башлана да инде тәхет тирәсендә ыгы-зыгы, тавыш-гауга, кырылыш. Ә үтерелгән Бирдебәк хан кияве — гайрәтле Мамай мирза, форсаттан файдаланып, Иделдән Кырымга хәтле сузылган җирләрне үзәк хөкүмәт кулыннан тартып алуга ирешә. Дөресрәге, сепаратист сыйфатында Сарай ханнары белән көрәш башлап җибәрә. Шушы 20 еллык даулар 1380 елда Куликово сугышы белән тәгәлләнә.

Болганыш елларында дәүләтнең бер-берсенә дошман ике өлешкә бүленүенең тагын бер сәбәбе бар кебек. Үл дәүләтне икегә бүлеп аккан Идел елгасына да бәйле. Идел — табигый географик чик. Бу очракта элегрәк заманда Нугай мирзаның Теләбуга һәм Тыктай ханнарга (үзәк хөкүмәткә) каршы алып барган көрәшен искә төшерү дә җитә. Мамай мирза Нугай мирза заманында ук башланган күренешнең дәвамчысы, аның эзеннән баручы, дәүләттә яшәп килгән тенденцияне дәвам иттерүче генә. Гомумән, без Алтын Урда тәхетендә көчле ханнар утырганда гына сул канат белән уң канат арасында тату мөнәсәбәтләр саклануын күрәбез. Монда дәүләтнең һәр канатында үзгә менталитетка ия халык яшәвен дә онытмаска кирәк. Һәр канатның үз сәяси ориентирлары һәм мәнфәгатьләре булган. Ә Мамай мирза Сарай ханнарына каршы алып барган көрәшендә еш кына Кырымга, андагы бай сәүдәгәр-җәнүизләр акчасына, Литва кенәзләре ярдәменә таяна. Бер сүз белән әйткәндә, Мамай мирза үзенең сәяси карашлары буенча ярылып яткан «көнбатышчы» була.

## VI

Вожа суы буенда Урда гаскәренең җиңелүе (1378) Мамай мирза алдына кискен рәвештә Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне ачыклау бурычын китереп куя. Табигый, бу югалтуны ул авыр кичерә. Чыннан да, гомер буе урысларны дер калтыратып яшә дә көннәрнең берендә җибәргән гаскәрең кыйналып кайтсын әле. Мона ничек түзмәк кирәк тә, бу хәлдән соң агай-эне белән бәкләрнең күзенә ничек күтәрелеп карамак кирәк? Җитмәсә, шушы бәрелештә аның Бигеч, Хажи бәй, Карабелек кебек олы мирзалары да һәлак була. Мамай мирза үзе тәхеткә чыгарган Мөхәммәт Бүләк хан да бу затларның үлемен аннан күрә бугай. Ә үзе Мамай мирзаның кин җилкәсенә ышыкланып чип-чиста кала. Бу шартларда Мәскәүнең олы кенәзе Дмитрийны тез чүктереп кенә Урдада абруен саклап кала алачагын Мамай мирза яхшы аңлый. Ул узынып киткән Мәскәү кенәзлегенә зур яу оештырырга кирәк дигән ныклы карарга килә. Тик бу эшкә ул

инде Мөхәммәт Буләкне катнаштырмаячак. Җинелгәндә читтә торып калып, җинеп кайтканда дан-шөһрәттә коенып яшәмәсен әле.

Чыннан да, урыс елъязмачылары теркәп калдырганча, Вожа суындагы кыйналудан соң «кесә ханы» Мөхәммәт Буләк белән аның тарафдарлары юк ителә, Мамай мирза Тулуг бәкне хан итеп күтәрттерә. Шулай итеп, ул каршы сүз әйтердәй кешеләрне тәхеттән читләштерүне кирәк таба.

Куликово кыры вакыйгаларына, аңа әзерлек көннәренә кучкәнче тагын бер мөһим мәсьәләне ачыклап үтү кирәктер шикелле.

Дөресен әйтергә кирәк, Мамай мирза үзәк хөкүмәткә каршы юнәлтелгән көрәшендә төп максатка барыбер ирешә алмый. Көрәшне башлап җибәргәндә ул Сарайны бөтенләйгә кулга төшерү, шунда тәмам ныгу, Алтын Урдага хуҗа булуны максат итеп куя. Дөрес, ул Сарайны берничә тапкыр чыннан да кулга төшерә, анда үз ханнарын да утырткалый, тик дошманнары хөкем сөргән көнчыгыш олыслар аңа башкалада ныгып калырга ирек бирмиләр. Һаман саен Сарайны ташлап чыгарга туры килә. Менә аның Чыңгыз хан нәселеннән булмавы, шул сәбәпле, тәхеткә чыга алмавы да нык комачаулый. Ул гомере буе башка берәүне тәхеткә утыртып, аның исеменнән идарә итеп азаплана. Бу хәл аны ахыр чиктә бик нык туйдыргандыр, күрәсең. Ул үзенең Сарай тәхетенә беркайчан да чыга алмаячагын, ниһаять, аңлый булса кирәк. Ә бу инде гайрәтле һәм максатчан, үз дигәнен эшләргә өйрәнгән Мамай мирза өчен ниятенең тормышка ашмый калуы — гомерлек хыялына ирешә алмавы дигән сүз.

Әлбәттә, бу хәл белән килешү Мамай мирза өчен бөтен хыялларның җимерелүе, алардан баш тартуга тиң булыр иде. Тик Мамай мирза кебек көчле шәхес ятып кала аламы? Әлбәттә, юк. Һәм ул, бөтен көчен туплап, тагын бер ыргылыш-акция оештырырга кирәк таба. Ул Мәскәү кенәзлегенә яу белән барачак та, аны басып алып, олуг кенәзне төшереп, Мәскәүне үз биләмәләренең үзәге итәчәк. Шулай итеп, ул үз татарлары өчен дә, урыслар өчен дә хан кебек олуг идарәче-хаким булачак.

Ә Сарай?.. Нишлисең бит, Сарай аныкы булмады, тәкъдирдә шулай язылгандыр. Яшәсен үзенчә, болгана бирсен. Ул инде туйды, әнә картлык та якынлашып килә, аңа да соңгы елларын тынычта уздырырга, бераз ял итәргә вакыттыр.



*Мамай мирза. Р. Шәмсетдинев сурәте.*

Мәскәүгә яу оештыру планы менә шундый уй-фикерләр, ниятләргә бәйле булмады микән? «Сказание о Мамаевом побоище» исемле әсәрдәге юллар шул хакта сөйли түгелме: «Яко аз не хощо тако сътворити, неко Батый, но егда дойде в (Руси), убию (большого князя их, и который его град красный довлеет нам, и ту сядем ведати и Русью владети, тихо и безмятежно поживем». Татарча тәрҗемә иткәндә бу болайрак була инде: «Мин Батый кебек эш итәргә җыенмыйм, ләкин Руська барып җиткәч, аларның (олуг) кенәзен үтереп, аның безгә яраклы матур каласында урнашып калырмын һәм Русь белән идарә итәрмен, тыныч һәм борчуларсыз яшәрмен».

Дөрес, бу сүзләрне, Мамай мирзаныкы дип, урыс авторы үзе теркәп куйган. Аларның бигүк хак булмавы да бар. Тик алар бер сәбәпсез генә «Сказание» битләрендә урын алмагандыр. Һәрхәлдә, вакыйгалар логикасы, Мамай мирзаның тынгысыз тормышын күздән кичерү бу фикернең дөреслеккә якын торуын күрсәтә кебек. Мирзаның ахыр чиктә Мәскәүне үзенең төп базасы итеп сайларга җыенуы мөмкин хәл. Ни өчен дигәндә, ачык далада урда корып гомер итүнең шактый мәшәкатьле, хәтәр нәрсә икәнен ул әйбәт белгән. Артында көчле

дошманнарың тормаганда бу әле мөмкин, ә Сарай ягыннан көн дә һөҗүм көтеп яшәргә калгач, авыргарак туры килер шул.

Әйе, ул элеккечә Кырымга да барып урнаша алыр иде, тик аннан торып кыпчак даласына хуҗа булу кыенрак. Аннан соң Кырымга кереп бикләнүнең хәтәр ягы да бар: Кырым — капчык, авызын бәйләп куйсалар, кая барырсың? Җәнүизләргә дә ышанып бетеп булмый, сәүдә әһеле, артык шома халык... Ә Мәскәү — диварлы, ныгытылган ышанычлы кала. Анда кыш чыгулары да уңайлы. Бер кулга төшереп, тәртип урнаштырсаң, карт көнеңдә бер кайгысыз гомер итәргә мөмкин.

Менә шундыйрак планнар белән җыенмады микән Мамай мирза Мәскәү явына? Һәрхәлдә, моны гипотеза буларак кабул итәргә мөмкин шикелле.

## VII

Бу вакытта Мәскәү кенәзлеге өстенә яу йөрү өчен шактый уңай шартлар туа. Эш шунда, Алтын Урданың сул канатында барган көрәшләрдә Ырыс хан һәлак булганнан соң, аның уллары Туктамыш белән тарткалаша. Билгеле, аларның уе әлегә Мамай мирзада түгел. Аннан соң Мамай мирзага Мәскәү өстенә йөрү өчен артында дошман тормау да зарур. Бу яктан караганда да уңайлы чак — Әстерхан белән Төньяк Кавказ да аның кулында, ягъни әлегә Иделдән көнбатышка таба сузылган җирләрдә урыслардан башка аңа каршы торырлык көч күренми. Кырым җәнүизләре дә аңа ярдәм итәргә әзерләр.

Әлбәттә, мондый зур эшкә алынганда аркадашлар-союзниклар турында да уйламыйча булмый. Мамай мирза, Литва кенәзе Ягайло белән элемтәгә кереп, аны да бу яуга тартуга ирешә. Шулай ук Рязань кенәзе Олег та аңа ярдәм итәргә мәҗбүр була. Ни өчен дигәндә, башкача эшләргә хәле юк. Әле Бигеч мирза отряды тар-мар ителгәч тә, шул ачудан 1378 елның сентябрендә Мамай мирза аның биләмәләрендә ут уйната. Вожа вакыйгасыннан соң татарлар һөҗүмен һич көтмәгән кенәз Олег, калаларын саклап та тормыйча, Оканың теге ягына качып котыла. Билгеле булганча, Ока елгасы һәрвакыт татар белән урыс арасыннан үтә торган чик булып хезмәт итә. Ул чакта татарлар Дубок, Переяславль Рязанский калаларын алып, бай ганимәт малы җыеп, кире кайтып китәләр. Ә бит Мамай мирза Мәскәүгә каршы кылыч тарта калса, татарлар кабат Рязань кенәзлеге аша узачаклар. Шулай булгач, кенәз Олегка һич тә татарлар ягында сугышмый калу мөмкин түгел.

Кайбер рус тарихчылары, Ягайло белән Олег кенәзләрнең бу яуга мөнәсәбәтен аңлатып, алар менә ничегрәк фикер йөрткән дип язалар: «Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Иванович Мамай мирзаның зур яу белән үзенә киләсен, ә безнең аның белән килешү төзегәнне белеп алып, йә Мәскәүдән ераграк җирләргә чыгып качачак, яисә Великий Новгород белән Двина тирәләренә китеп югалачак. Ә без исә Мәскәү белән Владимирга төпләнеп калырбыз, ханны (Мамай мирзаны — *С. Ш.*) анда зур хөрмәт һәм бүләкләр белән каршы алып, кунак итеп, соңрак өенә (далага) әйләнеп кайтуын үтенеп сорарбыз. Үзебез исә аның рөхсәте белән Мәскәү кенәзлеген ике өлешкә бүләрбез — берсен Вильнога, икенчесен — Рязаньга китереп кушарбыз. Шул биләмәләр өчен ярлыклар сорап алырбыз да аларны мирас итеп балаларыбызга калдырырбыз». (С. М. Соловьев. Сочинения в 18-и книгах. М., 1938. Т. 3, 275 б.).

Бу сүзләр, чыннан да, дөрескә охшаган. Монда Ягайло өчен дә, кенәз Олег өчен дә тулы бер программа-максимум салынган. Әмма алар Мамай мирзаның кем икәнлеген генә исәпкә алып җиткермәгәннәр. Ә бит билгеле — ул беркайчан да, беркем кулында да уенчык булмаган. Киресенчә, гомере буе башкаларны үз кубызына биетеп яшәгән. Еш кына татарның гомуми максатларына зыян китерсә дә, гел үзенекен иткән.

Урыс тарихчылары Рязань кенәзе Олегны еш телгә алалар, нигездә сүгеп, гел гаепләп язалар. Бу аңлашыла: кенәз урысларның милли мәнфәгатьләренә хыянәт итүче үтә дә булдыклы һәм хәйләкәр зат булган. Өстәвенә, сүзгә дә кесәгә кермәгән, шул тасма теле аркасында әллә нинди кыен хәлләрдән шома гына чыга белгән. Кирәксә, берьюлы ике хуҗага хезмәт итүдән дә тайчанмаган.

Бу юлы да шулай килеп чыга: Мамай мирза аңа планнарны сөйләп биргәч, күп тә үтми кенәз Олег, Мәскәүгә кеше җибәреп, кенәз Дмитрийга татарларның зур яу оештырачагын ачып сала. Бу аңа Мамай мирза белән килешү төзүен яшерү өчен кирәк була. Кенәз Дмитрийга ул болай дип яза: «Мамай үзенең барлык көчләре белән минем тарафка Рязань җирләренә һәм сиңа таба килә. Ягайло да

анын белән. Син белеп тор — безнең кул әле биек («еще рука наша высока»): әзер бул, нык тор».

Аннан «безнең кул әле биек» дигәне, куллар әле корал тотарлык, дип үзенең Дмитрий яклы булуын исбатлау өчен кирәк булгандыр, күрәсең.

Шулай итеп, Мамай мирза яуга әзерләнә башлау белән үк, анын барлык планнары, көне-сәгате белән дигәндәй, Мәскәүгә барып та житә. Хәер, серне кенәз Олег ачмаган очракта да, бу хәбәр сер килеш саклана алмас иде. Ни өчен дигәндә, Мамай мирза яуга зурдан кубып әзерләнергә жыена, анын кешеләре, гаскәрне бөтен Дәште Кыпчак даласыннан — Әстерхан, Төньяк Кавказ, Азак-Дон, хәтта Кырымнан да яллыйлар. Гаять чуар гаскәрдә «татарлардан» тыш яслар (осетиннар), чиркәсләр, бортаслар, әрмәннәр, кавказ яһүдиләре, Кырым яр буенда яшәүче җәнүиз-итальяннар да була. Шундый кинлекләрдә хәбәр йөргәч, халык хәрәкәткә килгәч, ул ничек сер булып калсын, ди. Сәүдәгәр халкы йөреп тора, ә алар — гомер-гомергә беренче шымчылар булган.

Шулай гаять зур гаскәр тупларга карар кылына. Анын күпме булуы төгәл билгеле түгел, тик урыс тарихчылары анын урыс гаскәреннән күбрәк булуын искәртергә яраталар. Бу Куликово сугышынын әһәмиятен тагын да күтәрү өчен эшләнә булса кирәк.

## VIII

Табигый, әле жәй ахырларында ук татар явы турында хәбәр алган олуг кенәз Дмитрий да кул кушырып утырмый. Рязаньнан чапкын килгәч, башта пошаманга төшсә дә, бераздан исен жыя, якыннары белән киңәш-уңаш иткәннән соң, кенәзләргә атчабарлар озата. Полклар, дружиналар йөртүче кенәзләр, воеводалар, бояр уллары барысы да билгеле вакытка Мәскәүгә һәм Коломнага килеп житәргә тиеш булалар. Шуңа игътибар итик: башка вакытта шактый таркау булган, бер-берсенә аяк чалган, хәтта үзара тарткалашып яшәгән урыс кенәзләре бу юлы хәлне тиз аңлап алалар, зур бердәмлек, оешканлык күрсәтеп, олуг кенәз байрагы астына ашыгалар.

Гадәттә, Куликово сугышына урыс гаскәренең тиз жыелуын халыкта татарга карата нәфрәтнең, аннан үч алу теләгенең көчле булуы, патриотизм хисләре белән аңлаталар. Әлбәттә, анысы да булгандыр. Тик бу очракта Э. Кульпин фикеренә колак салу да артык булмас. Ул менә ни дип яза: «Мамай Русь илендә хакимлек итү һәм акчага хужа булуны үз кулына алырга омтылыш ясады, тегесенә дә, монысына да куркыныч белән янады. Мәскәү кенәзләренең төп мәнфәгатьләренә кагылды. Шулай ук Мамай явы олуг кенәз кул астындагы дружинниклар белән служилый боярларнын мәнфәгатенә дә бик нык китереп сугачак иде. Шундый хәвеф янаганда Дмитрий Донской тиз арада зур гаскәр туплый алды, калаларны саклаучыларсыз калдырды, шуңа күрә халык кайгыга батты. Дружинникларсыз калган калалардагы гади халык, акрын селкенүче урыс гаскәрен әйләнеп узып, сакланмаган урыс тылларыннан татарларнын тоткарлык-сыз-нисез үтү мөмкинлеген бик яхшы аңлый иде. Әйе, бу мөмкин иде, тик бу юлы татарлар Русьне жәзалау өчен барырга жыенмадылар» (Э. Кульпин. «Путь России».— С. 95.).

Шулай Ростов, Белоозеро, Ярославль, Владимир, Переяславль, Кострома, Муром, Дмитров, Можайск, Звенигород, Углич, Серпухов h. б. калалардан үзәккә гаскәр агыла башлый. Суздаль-Новгород һәм Тверь кенәзлегеннән генә олуг кенәз карамагына полклар килми. Рязань кенәзе Олег, әйтелгәнчә, Мамай мирза ягында була. Шуңа күрә тарихчылар урыс армиясе 150 меңнән дә артмагандыр дип исәплиләр. Мамай мирза гаскәре урысныкыннан күбрәк дип язсалар да, бу яуда Алтын Урданың уң канаты гына катнашуын исәпкә алсаң, татарлар урыслардан күп булмагандыр дип уйларга нигез бар. (Мамай мирзанын союзниклары кенәз Олег белән кенәз Ягайло да яуда катнашмый кала. Хәер, ул хакта әле алда сүз булыр.)

18 августта Мәскәү кенәзе үзенең кенәзләре, воеводлары белән яуга чыгып китәр алдыннан фатиха алыр өчен Троице монастырена килә, анда инде телгә алынган монастырь башлыгы игумен Сергий Радонежский белән очраша. Чиркәүдә гыйбадәт кылганнан соң игумен Сергий кенәзне төшке ашка калуын үтенә. Аш вакытында олуг кенәздән:

— Бу сугышны булдырмас өчен син барысын да эшләдеңме? — дип сорый.

— Барысын да эшләдем, тик уңышка ирешә алмадым, — дип жавап бирә олуг кенәз.

— Алайса дошман ахыр чиктә җинелүгә дучар булачак, ә сиңа Ходайдан ярдәм киләчәк. Син җиңәчәксең!— ди.

Булачак дәһшәтле сугышның нәтиҗәсен шулай кистереп әйтү — үз өстеңә җаваплылык алу. Ләкин игумен Сергий андый җаваплылыкны үз өстенә алудан курыкмый. Гомумән, аны гадәти генә рухани булмаган диләр. Аның биографиясендә алдан күрә белүче, Илаһи Көчләр белән бәйләнештә торучы зат булганлыгын раслаучы фактлар аз түгел. Бу затны гәрчә ул үзе сугышта катнашмаса да, Куликово сугышының, Мамай мирза белән кенәз Дмитрийдан кала, өченче төп каһарманы дип әйтергә мөмкин. Шуңа күрә аның эшчәнлегенә бераз тукталып үтү бу очракта үзен аклар дип уйлыйм.

Малай чагында ук аның белән серле бер вакыйга була. Әтисе аны кырга атларны эзләп алып кайтырга чыгарып җибәргәч, малай анда юан имән төбендә утыручы бер карт монахны күрә дә янына килә. Карт та аны күреп алып:

— Балакай, сиңа ни кирәк?— дип сорый.


Малайның бу сораудан кинәт күнеле тула, ул үзенең мәктәптә бик начар укуын, күпме генә тырышса да, укуны алдыра алмавын, шуның аркасында ата-анасының да, укытучыларның да аны гел шелтәләп-тиргәп торуыннан зарлана, картның дога укып, үзенә ярдәм итүен сорый.

Карт нәрсәдер укый да малайга просфора (махсус пешерелгән түгәрәк ипи) каптыра:

— Бу сиңа Ходайның рәхмәте билгесе. Изге Китапны аңлау өчен бирелә. Моннан соң, балакай, уку турында борчылма, Ходай сиңа ярдәм итәр,— дип башыннан сыйпый.

Шушы вакыйгадан соң малайның рухани дөньясында ниндидер үзгәреш була, ул дини китапларга ябыша, гыйбадәткә тартыла башлый.

Бервакыт Стефан Пермский дигән дин әһеле чиркәү эшләре белән Мәскәүгә барган'чакта, Троице монастырена дусты янына кереп чыгарга вакыты булмаганга, тугыз чакрымда узган юлда атларын туктата да монастырь ягына карап басып: «Сәлам сиңа, рухани туганым!»— дип бил бөгеп сәлам бирә.



*Сергий Радонежский.*

Бу мәлне Сергий Радонежский монастырь ашханәсендә монахлар белән тәгам җыеп утыра икән. Рухы белән дустының сәламен кабул итеп, ул аягына торып баса да, ашап утыручы монахларны гаҗәпкә калдырып, билен бөгеп үзе дә сәлам бирә. Аннан монахларга епископ Стефанның юлдан җибәргән сәламен алуын аңлатып бирә.

Әлбәттә, Сергий Радонежский тормышыннан мондый хәлләрне күп китереп булыр иде. Әмма укучыларның җитмеш елдан артык матдиятчелек (материализм) философиясе белән тәрбияләнеп, инде шактый авырая төшкән рухы аларны кабул итмәскә, скептик көлемсерәү булып бары тик йөзләренә генә чыгарга мөмкин. Шуңа күрә могҗизаларның матди дөньяга якынрак торганнарын сайларга туры килә. Әйе, илаһияттән бик ерак шул әле безнең рухыбыз.

Шулай ук бу затның вафаты хакында да бер-ике сүз әйтү дөрес булыр, дип уйлыйм.

Фани дөнья белән саубуллашырга ярты ел калганда аңа бу хакта хәбәр килә. Карт монахларны үз янына җыя да шушы көннән монастырьны шәкерте Никодим кулына тапшыруы турында белдерә. Ә үзе аерым хөҗрәгә кереп бикләнеп, берәү белән дә аралашмый, соңгы айларын тулы тынлыкта уздыра. Тик вафаты көнендә генә янына җыелган руханиларга:

— Мине Ходай үзенә чакыра, аның хозурына китәм. Ул сезгә сыенә һәм дә дошмани ятьмәләрдән саклаучы нык дивар булсын,— дип, фани дөньядан мәңгелеккә күчә.

Ул өзелгәндә хөҗрәдә тәмле ис таралды, дип язалар картның үлемен күргән шаһитлар.

Сергий Радонежский тормышына мул урын бирелүенең сәбәбе Куликово сугышы белән бәйле,— анысына соңрак тукталырбыз. Ә хәзергә вакыйгалар чылбырын сүтүне дәвам иттерик.

## IX

Олуг кенәз Дмитрий башкаланы сакларга воевода Федор Андреевичны калдыра да үзе Коломна каласына юнәлә — анда кенәзне төрле яклардан җыелган гаскәр көтә. Монда Литва кенәзе Ольгерд уллары — Андрей белән Дмитрий полклары да олуг кенәзгә килеп кушылалар. Девичье поле дигән җирдә гаскәрне барлау үткәрелә.

Шулай әзерлек эшләре белән шөгыльләнгән чакта олуг кенәзгә Мамай мирзаның Дон аръягында торуын, анда Ягайлоны көтүен хәбәр итәләр. (Урысларның разведкасы әйбәт эшләгән, күрәсең.) Ул да булмый, Коломнага Мамай мирзадан илче килеп төшә. Ул, элекке тәртипләрне олуг кенәзнең исенә төшереп, Үзбәк һәм Җанибәк ханнар заманындагыча ясак түләүне таләп итә. Кенәз Дмитрий, ясак түләүдән бөтенләй баш тартмаса да, элекке күләмдә түләргә риза түгеллеген белдерә. Илче моңа риза булмый, кайтып китә.

Сорау туа: илче ни өчен килгән? Ясак таләп итү өчен генәме, әллә инде урысларның хәлен-хәләтен, каршы торырга исәпләре бармы-юкмы — шуны белергәме? Урыслар элекке тәртипләргә ризалашса, бәлки, Мамай мирза яу чапмаска да әзер булгандыр? Кыскасы, сөйләшү уңай нәтиҗә бирми, мәсьәләне кылыч белән хәл итәргә кала.

Шул ук көннәрдә урысларга Рязань кенәзе Олегның, ике якка да ярарга тырышып, хыянәтчел уен алып баруы билгеле була.

Ниһаять, 20 август көнне урыс гаскәре Коломнадан чыгып китә, Мәскәү кенәзлеге җирләрен үтә дә Ока елгасы буенда туктала. Монда гаскәргә олуг кенәзнең туганы Серпухов кенәзе Владимир Андреевич белән Мәскәү воеводасы Тимофей Вельяминович полклары да килеп кушыла. Шулай итеп, урыс гаскәре 26 августта тәмам тупланып бетә, иртәгесен яу Ока елгасын кичеп, Рязань кенәзлегенә килеп керә. Бу хәл кенәз Олегны тәмам пошаманга сала, чөнки аның фаразы буенча, Мәскәү кенәзе татар явы турында ишетү белән качып китәргә тиеш иде. Кем уйлаган бит аны — әнә Мәскәүнең җыелма гаскәре аның бусага төбендә үк тора. Аның татарлар һәм Ягайло белән элемтәгә кергәнен белә калсалар, бетте баш. Шундый уйлар белән вәсвәсәләнгән Рязань кенәзенең ул көннәрдә ниләр кичерүен күз алдына китерүе кыен түгел. Ул ачыктан-ачык Мамай мирзага да, олуг кенәз Дмитрийга да килеп кушыла алмыйча анда-монда сугылырга мәҗбүр була... Кыскасы, кенәз Олег ике арада торып кала. Шуңа күрә Мамай мирзадан да, Мәскәү гаскәреннән дә ераграк йөрергә, күзләренә ташланмаска тырыша.

Урыс гаскәре 27 августтан 6 сентябрьгә кадәр Дон елгасына таба хәрәкәт итә, елга башына килеп җиткәч, яр буйлап юлын дәвам иттерә. Гаскәр юлда чакта урысларның разведкасы зур эш күрсәтә, дала буенча арлы-бирле чабып, татарларның кайда икәнлеген белергә тырыша. Тарихчылар фикеренчә, Лопасня тамагыннан сугыш булган Непрядвага хәтле ара 150 чакрымнар тирәсе икән. Шушы 150 чакрым араны урыслар 9—10 көн үтә. Димәк, тизлек көненә 15 чакрымнан артмаган. Алар ни өчен шулай акрын барган? Әлбәттә, бу акрынлык, беренче чиратта, татардан курку көчле булуга бәйле. Урыслар бит татар җиренә, кыпчак даласына аяк басты, ят җирдән атлыйлар, шуңа күрә зур саклык белән хәрәкәтләнергә туры килә. Житез татар гаскәре, көтмәгән яктан килеп чыгып, өстенә ташланырга да күп сорамас. Аннан соң бу вакытта аларга Мамай мирза урдасының кайларда икәнлеге төгәл генә билгеле дә булмый. «Дон аръягында» дигән хәбәр дә эшне җиңеләйтми. Шуңа күрә барган чакта, төрле якка кечкенә отрядлар җибәреп, даими рәвештә разведка чаралары күрергә туры килә. Бер үк вакытта үзләренең килүен дә яшерергә тырышалар. Зур гаскәрне дошманга сиздермичә алып бару җиңел эш түгел. Шунлыктан барлык чаралар да күрелә. Ни өчен дигәндә, дошманның борын төбендә кинәт калкып чыгу — җиңүнең яртысына тиң.

Бу вакытта Мамай мирза исә тыныч кына Ягайлоны көтә, ул урысларның, курка-курка гына булса да, татар җиренә аяк басуын, йоланы бозып, үзләренең һөҗүм итү ихтималын башына да китерми.

Ниһаять, 6 сентябрь көнне урыс гаскәре Дон ярына килеп тукты. Елга буенда татарларның сакчы отряды булган, ахры, чөнки Мамай мирзага урыс гаскәренең кинәт Дон ярында калкып чыгуын шул көнне яраланган сугышчылар килеп әйтә.

Дөресен әйткәндә, бу Мамай мирза өчен һич көтелмәгән хәл була. Айлар буе урыска каршы яу әзерлә, төрле сөйләшүләр алып бар да, инде барысы да житеште, гаскәр тупланып бетә дигәндә борын төбендә дошман калкып чыксын әле! Әлбәттә, ул хәл аның җен ачуларын чыгаргандыр, ул каударланып, сугышка әзерләнә башлагандыр. Тик шунысы бар — бу вакытта урыслар да тик тормый, хәлиткеч бәрелешкә әзерләнә.

Алар 6 сентябрьдә, татар сакчы отряды белән очрашканнан соң, көне буе Мамай мирзаны көтәләр, ул күренми. Иртәгесен дә тулы әзерлек белән Дон ярында торалар, татарлар һөҗүмгә ташланыр дип көтәләр. Яр буенда җыелган кенәзләр, воеводалар уйга кала — дошман әлегә һөҗүм итәргә җыенмый. Елганы кичәргәме, юкмы? Фикерләр икегә бүленә: берәүләр язмышны сынамаска, татарларны бу ярда гына каршы алырга кирәк дисә, икенчеләре Донны кичеп теге якта сугышуны кулай күрәләр. Каршы якка чыгып орышкан очракта беркем дә татардан куркып чигенә дә, кача да алмаячак, диләр. Бу фикерне кенәз Ольгерд уллары әйтә.

Биредә бер психологик моментны да исәпкә алу кирәктер. Яр буенда кичүкичмәү хакында бәхәс барган чакта олуг кенәз Дмитрийга Сергий Радонежскийдан атчабар килеп төшә дә грамота тапшыра. Анда татарга каршы яуга рухландыручы гомуми сүзләрдән тыш конкрет киңәш тә була: вакытны сузмыйча үзенә һөҗүм итү кирәк, диелә. Бу очракта абруйлы затның сүзе кенәзгә тәэсир итми калмагандыр. Игумен Сергий Дон буенда шундый хәл килеп туасын кайдан белгән дә, алдан грамота яздыртып, нәкъ тиешле вакытында олуг кенәз кулына ничек китереп тоттырган? Гаскәр яуга чыгып киткәч игумен Сергий көнен-төнен гыйбадәт өстендә үткәргән, дип язалар. Аның рухы күп нәрсәне алдан белеп торган булса кирәк. (Гаскәрне яуга озатканда аның, үз-үзенә бик ышанып, башкаларны да ышандырырлык итеп, «җиңәчәксез!» дип әйтүен генә искә төшерик.) Бүгенге көндә Галәм (Иләһи Көчләр) белән элемтәдә торучы арадашчыконтактерлар гадәти күренешкә әверелеп бара, алар аша төрле прогнозлар алу мөмкинлеге ачылды. Минемчә, Сергий Радонежский да шундый затлардан булган, ахры. Ул барысын да алдан белеп торгандыр. Башкача моны аңлатып булмый.

Инде арадашчылык турында сүз чыккан икән, бераз алга йөгереп булса да, фикеремне ныгытырлык тагын бер дәлил китереп узыйм. Сергий Радонежскийның биографиясендә шундый факт та бар. Һәм ул Куликово сугышына карый. Бәрелеш вакытында ул, Троица монастырендә калып та, монахларга орышның ничек баруын, кайсы кенәзнең, кайсы воеводаның һәлак булуын әйтеп торган. Бу сыйфат үзе үк аның гади заттан булмавы турында сөйли. Андый кешеләрне хәзер психик күрү сәләте ачылган затлар дип йөртәләр.

7 сентябрь көнне дә татарлар һөҗүм итмәгәч, кичке 5 белән 6 сәгатьләр арасында урыс гаскәре Донны кичә башлый. Таң атканда кичү тәмам була. Әлбәттә, зур гаскәрнең елганы кичүен каршы як белеп торган, башкача мөмкин түгел. Тик Мамай мирза сүлпәнлек күрсәтә, кичү вакытында дошманга һөҗүм итми. Юкса иң җайлы чак бит. Бәлки, ул аларның бу якка чыгуыннан үзенчә файдаланмакчы булгандыр? Орыш башлангач, дошманга чигенергә мөмкинлек калмаячак, шул чак аны ярга китереп кысып, берьюлы эшне бетерергә уйлагандыр? Әллә инде урысларның кинәт килеп чыгуы аны каушатып җибәргәнме? Гаскәре тупланып җитмәгән, таркау хәлдә булганмы?

Монда сораулар күп һәм аларга беркем дә җавап биреп бетерә алмаячак, бары тик фараз кылырга гына кала. Тик шунысы ачык — Мамай мирза, үз-үзенә артык ышанып, урысның көчен, мәкер белән дә эш итә белүен бәяләп җиткермәгән, саксызлык күрсәткән булса кирәк.

Бу вакытта урыс гаскәре исә, елганы алдан кичеп, Куликово кырында үзенә җайлы урын-позиция сайлап алырга өлгерә.

## X

**1380** елның 8 сентябрь таңы бик авыр ата. Җир йөзен каплап алган иртәнге томан озак таралмый тора. Томан җәелгәнгә кояш та, гүя, бу киң яланда бүген зур кырылыш булачагын, йөзләрчә мең адәмнәрнең каны коелачагын сизенгәдәй,

җиһанга кызгылт йөзен ачарга ашыкмый. Ниһаять, томан таралып бетә, шул чакта гына яланның капма-каршы ягында тезелешкән ике яу бер-берсен күреп ала, акрынлап якынлаша башлый.

Бәрелеш алдыннан, һәр яктан берәр батырны алга чыгарып, аларны орыштыру гадәте бик борынгыдан килә. Куликово кырында да шундый хәл булган, диләр. Урыслар ягыннан монах Александр-Пересвет, ә татар ягыннан Чәләбибаһадир дигән бер зат ике гаскәр арасында калган ачык җирдә көч сынашканнар, имеш. Бу хәл чыннан да булган, ахрысы, чөнки батырларның берсе — инок Александр тарихта билгеле шәхес. Чыгышы белән Брянск бояры булып, ул дин юлына басканчы Пересвет исемен йөрткән. Урыс гаскәре яуга җыенганда Сергий Радонежский аны, оста һәм көчле сугышчы булганы өчен, олуг кенәз Дмитрийга ярдәмче итеп җибәрә.

Ә татар баһадиры Чәләби (кайбер чыганакларда Тимер мирза) турында башка мәгълүматлар сакланмаган. Шундый зур эшкә алынгач, ул да татарның атаклы баһадиры булгандыр, дип уйларга кирәк.

Орышта алар икесе дә һәлак була.

Дәһшәтле сугыш сәгать унберенче яртыда гына башлана.



*Куликово сугышы алдыннан.*

Урыс тарихчылары Куликово сугышы турында язганда, тарихта мондый сугышлар аз булган дип, аның әһәмиятен күпертергә яраталар. Гадәттә, аны Искәндәр Зөлкәрнәйн яуларын, Каталаун кырында мәшһүр Атилла белән римлы Аэций арасындагы «халыклар орышы»н яисә гарәпләр белән франкларның тарихи бәрелешен искә төшерәләр. Алай ерак йөргәнче ник берсе Аксак Тимер белән Туктамыш хан арасында булган Кондызча (1391) сугышын телгә алсын. Ә бит анда бер Аксак Тимер ягыннан гына да 200 мең кеше катнаша, шәрекъ тарихчылары язганча, «40 фәрсах җир мәет белән тула». Кем әйтмешли, үзеңнеке — үзәктә шул. Әмма гаделлек өчен әйтергә кирәк: урысларның әле бу кадәр гаскәр җыя алганы да, мондый бәрелештә катнашканы да булмый.

Тарихчылар шулай ук Куликово сугышы башлангач, татар атлы гаскәренең урыс сафларына бик нык китереп сугуын язалар. Шулай итеп, бәрелеш татарлар өстенлеге белән башлана, печән чапкандай кеше кырыла, аяк астына түшәлә бара. Кан исеннән, кысанлыктан, тимер чыңлаудан, акыру-бакыру тавышларыннан ярсыган атлар туктаусыз пошкыра, түзеп тора алмыйча арт аякларына күтәрелә.

Орыш башында тәмам буталып беткән татар белән урыс гаскәре берәр сәгать узуга акрынлап аңга килә башлый, яу кырында ниндидер тәртип, акыл белән эш итүгә охшаш сыйфат барлыкка килә. Аннан татарлар, зур тырышлык һәм гайрәт күрсәтеп, олуг кенәз Дмитрийның кара байрагына таба юл ярырга керешәләр. Бу хәлне күреп, Мәскәү полкының яшь сугышчылары качарга ук тотына. Бары үзен аямыйча орышкан кенәз дружинасы гына төп байракны татарлар кулына төшүдән саклап кала.

Бу вакыт калкулык өстендә яу кырын күзәткән Мамай мирза, борчылып, урыс гаскәре пәйда булганнан соң озаткан атчабарларының әйләнеп кайтуkайтмавын белешеп торгандыр, күрәсең. Ул, урыс гаскәре күренү белән, кенәз Олегны ашыгычлык белән үзенә чакырткандыр. Шулай ук Ягайлога да кеше җибәргәндер. Тик аның белән ара ерак, килеп җитә алмас. Кенәз Олег исә күптән бергә булырга тиеш иде. Һаман күренми. Алдарга микәнни исәбе? Итек очын яларга җитешеп вәгъдәләр бирүенә карамастан, хыянәт итүеме бу? Кайдадыр качып ята булыр. Соңыннан ниләр сөйләр, ни дип акланыр икән?... Сугыш барганда Мамай мирза менә шулай фикер йөрткән булса кирәк.

Әйе, Мамай мирзага сугышны уңайсызрак шартларда башларга туры килде. Урыслар ничектер һич көтмәгәндә, җир астыннан үсеп чыккандай, кинәт пәйда

булды. Җитмәсә ул хәстәрен күреп өлгергәнче Дон суын да кичеп чыктылар — сафларын җайлы урынга төзеделәр.

Ике сәгатьләп узгач, сугышның иң җаваплы чагы — үзәге якынлаша. Инде һәр як ифрат күп яугирләрен югалткан, арый-талчыга башлаган. Шулай үлчәү тигезләнә. Инде кайсы якның, гайрәт туплап, тагын бер талпынырга көче житсә — шул өстен чыгачак, җиңәчәк.

Әйе, һәр җитди бәрелештә була андый мизгел — үлчәү тигезләнә дә әле бер, әле икенче якка авышa алмыйча беравыкка катып кала. Иң хәтәр чак. Үз гомерендә күп сугышлар күргән Мамай мирзаның бөтен җаны-тәне бу мизгел якынлашканны сизеп тора. Һай, аз гына ярдәм булсачы, берәрсе килеп җитсәче дип як-ягына карана ул. Татарларга ярдәмгә килүченең орышка керүе дә кирәк түгел, якынлашып килүләре дә җитә калыр иде. Шулай дошманның йөрәгенә курку-шом иңәр, җанына качу уе кереп урнашыр иде. Әмма юк, Мамай мирзаның аркадашлары күренмәде... Хәерлегә була күрсен...

Бу вакыт кенәз Олег, чыннан да, качып ята. Ул ни татарларга, ни Мәскәү кенәзенә ярдәм кулы сузмый. Хәер, аның үз хәле хәл инде. Кайсы якка басса да — «вай!». Чөнки икенең берсенә барыбер кан дошман булып калачак. Шуңа күрә ул бу бәрелештән читтә калуны кулайрак күрә. Башта сугыш төгәнсен, җиңүче ачыклансын, анда күз күрер, дип фикер йөртә. Моңа хәтле дә, килеп туган вазгыятькә карап, ул антын тиз боза килде. Бу юлы да үз табигатенә тугры калды. Ярар, Ходай ярдәменнән ташламас әле...

Күп сугышларда тиешенчә сер саклый белү, дошманга кинәт һөҗүм итү яисә берәр көтелмәгән алым-ысул кулланунын җиңүгә китерүе чал тарих сәхифәләрендә теркәлеп калган. Бу очракта да урыслар, Мамай мирза өчен шундый бер «күчтәнәч» әзерләп куялар, саклык чарасы күрәләр. Гаскәрнең сул флангында урнашкан имәнлек артына олуг кенәзнең туганы кенәз Владимир Андреевич Серпуховский белән Мәскәү воеводасы Дмитрий Волынский-Боброкларның атлы гаскәре яшерелә. Урысларда андый алай «засадный полк» дип аталган. Татарда исә ул «постырма» дип йөртелгән, ягъни яшереп-постырып куелган гаскәр. Гомумән, бу алым урысларга күп гасыр буе төркиләр белән аралашу аркасында күчкән, Алтын Урда дәверендә урыс аны инде тәмам үзләштереп өлгергән, бәлки әле «үзенеке» дип тә уйлый башлагандыр. Әлбәттә, Мамай мирза да үз гомерендә аны аз кулланмагандыр, тик бу юлы урысларның Дон буена кинәт килеп чыгуы аны кыен хәлгә куя, мирзага сугышыр өчен җайсыз урын туры килә.

Шулай дәһшәтле сугыш өченче сәгатенә киткәндә урысларның постырмада торган полкына да чират җитә. Ул, имәнлек артыннан атылып чыгып, кинәт татарлар өстенә ташлана. Бу һөҗүм шулкадәр көтелмәгәндә була, Мамай мирза сугышчылары ни уйларга да белмичә аптырап кала. Шулвакыт ялланган Кырым җәнүизләре, Кавказ яһүдиләре белән әрмәннәр, гомумән, качарга тотына. Андый чакта бер зур төркемнең түгел, бер-ике бәндәнең кача башлавы да нык тәэсир итә. Ә монда... гаскәрнең бер өлеше табан ялтыратсын әле! Табигый, бу хәл күпләрнең йөрәгенә шом сала, паника башлана. Дөрес, Мамай мирза баһадирлары качучыларны кире борырга тырышып карыйлар, тик бер кузгалгач, кая ул...

Гаскәрнең бирелә башлавын күрү Мамай мирзаны бер утка, бер суга салып, җанын ничек өзгәләгәнен күз алдына китерүе кыен түгел. Аның гомерендә бу минутлар иң авырлардан булгандыр. Шул вакытта язмышы хәл ителгәнне аңлады микән ул? Гомере буе тәхеткә ханнар утырту-төшерү уенын уйнаган горур мирза моны аңлар хәлдә булды микән? Хакимият адәмнәрне боза, ә озак еллар хакимлек итү икеләтә боза. Кеше үз-үзенә тәнкыйть күзе белән карау сәләтен югалта, аның урынына мин-минлек, тәкәбберлек, кеше фикерен санга сукмау кебек сыйфатлар җанның саф авазын басып китә.

Ничек кенә авыр һәм оят булмасын, Мамай мирзаның үзенә дә, янәшәсендә торган бәкләргә дә кача башлаган гаскәр артыннан иярергә туры килә. Гадәттә, урыс тарихчылары урыс гаскәренең татарларны арттан куа баруын, турый-чаба озак эзәрлекләвен тәмләп язарга ярата лар. Тик моңа ышануы кыен, чөнки бу сугышта урыслар да артык күп көч югалта, бик нык хәлсезләнә. Киресенчә, орыш тәмамланганга сөенгән булырга тиешләр. Шулай да татарларның олаулары, азык-төлек, сугыш кирәк-ярагы төялгән арбалар дошман кулына төшкәндер. Анысын инкяр итүе кыен.

Канкойгыч орыш тәмамлану белән олуг кенәзнең туганы кенәз Владимир Андреевич Серпуховский, елъязмаларда язылганча, «өелгән сөякләр өстенә менеп басып» («встал на костях»), яу кырында быргылар кычкырттыра. Бу тавышны ишеткәч, төрле тарафка таралышкан сугышчылар олуг кенәзнең кара байрагы тирәсенә җыела башлыйлар. (Бу факт үзе үк урыс тарихчыларының уйдырмасын фаш итә: алар Мамай мирза гаскәрен күп чакрымнар эзәрлекләгән булса, орыш тукталу белән үк быргы тавышына җыела алырлар иде микән?) Шулвакыт бер сәер хәл ачыклана — олуг кенәз Дмитрий Ивановичның кайда икәнлеген берәү дә белми (Н. М. Карамзин. История государств Российского. Т. 5— Жур... «Москва», 1988, № 10, с. 123). Кенәзләр белән воеводалар тәмам хафага төшә, тирә-юньгә таралышып, мәетләр арасыннан олуг кенәзне эзләргә керешәләр. (Гаскәр башын — олуг кенәзне дә югалтырлык булгач, урыс гаскәренең хәле гаять мөшкел булган, дип уйларга кала. Димәк, урыслар соңгы чиккә җиткән булган.)

Кенәз Владимир Андреевич олуг кенәзне эзләп табучыга зур бүләкләр вәгъдә итә. Бераздан мәетләр арасыннан аның байрак йөртүчесен табып алалар. Ниһаять, читкәрәк китеп эзләүче ике сугышчы ауган агач ботаклары арасында яткан берәүне күреп алып сөйрәп чыгарсалар — ул олуг кенәз Дмитрий Иванович үзе булып чыга. Аңын җуйган, тын алуы да зәгыйфь.



*Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Иванович Донской.*

Барысы да аның янына җыела. Бераздан ул аңына килә, күзләрен ача, эчәргә су сорый. Шуннан соң гына кенәз Владимир Андреевич, аның каршына тезләнеп: «Олуг кенәз! Син дошманыңны җиңдең!» — дип әйтергә җөрьәт итә. Шуңа кадәр әле берәү дә җиңү турында авыз ачарга батырчылык итми. Ни өчен дигәндә, бу сугышта, урыс тарихчылары күрсәткән 150 мең гаскәрнең бары тик 40 меңе генә исән кала. Югалтулар шулкадәр зур була ки, урыслар башта хәтта үзләренең өстен чыгуын да аңлап җиткермиләр.

Урыс тарихчылары олуг кенәз Дмитрий Иванович турында: ул бер генә яра да алмаган, башындагы шлемы, тимер киемнәре генә дошман белән орышудан яньчелеп беткән булган, дип язалар. Яра алмавы да, ауган агач ботаклары арасыннан табылуы да бигүк аңлашылып бетми бетүен, нишлисең бит, үзләре шулай яза ич...

Бу вакыйганы җентекләп өйрәнгәндә тагын бер нәрсә игътибарны җәлеп итә — агач астыннан табып алганда сулар-суламас яткан олуг кенәз, җиңүен ишетеп алу белән ничектер бик тиз аякка баса, тәмам савыгып китә дә яраннары белән яу кырын карап йөри, кенәзләргә, воеводаларга, бояр улларына рәхмәтләр әйтеп, барчасына да зур-зур бүләкләр вәгъдә итә.

Күренекле урыс тарихчысы С. М. Соловьев Куликово сугышы нәтиҗәләре хакында менә нинди фикер әйтә: «... Куликовская победа была из числа тех побед, которые близко граничат с тяжким поражением. Когда, говорит предание, великий князь велел счесть, сколько осталось в живых после битвы, то боярин Михайло Александрович донес ему, что осталось всего 40 тысяч человек, тогда как в битву вступило больше 400 тысяч...» Шушы сүзләрдән соң тарихчы китерелгән санга үзенең мөнәсәбәтен дә әйтеп үтә: «Если историк и не имеет обязанности принимать буквально последнего показания, то для него важно выставленное здесь отношение живых и убитым», — ди ул. (С. М. Соловьев. Күрсәтелгән хезмәт. 278 б.)

Әйткәнебезчә, бүгенге тарих фәнендә урыс гаскәренең гомуми саны 150 мең булып, шуның 40 меңе генә исән калган дигән фикер кабул ителгән. Шушы «150

мен» дөрес булган очракта да урысларның югалтуы 110 мең кешегә тиң. Бу саннар Куликово кырындагы җиңүнең урыслар өчен чын җиңү булмыйча, аның бары тик мораль факторга гына кайтып калуын бик ачык күрсәтәләр.

Куликово кырында урыс гаскәре 4 кенәзен, 13 боярын югалта. Шуңа күрә бу сугыш урыс риваятьләрендә, бер яктан бөек җиңү дип сурәтләнсә, икенче яктан, олуг кайгы һәм фаҗига буларак телгә алына. «Оскудела совершенно вся земля Русская воеводами, и слугами, и всяким воинством и от этого был страх большой по всей земле Русской»,—дип яза шул ук С. М. Соловьев. (Шунда ук. 278 б.)

## XII

Литва кенәзе Ягайлоның ни өчен вакытында Мамай мирзага ярдәмгә килеп житә алмавы тарихчылар арасында бәхәс уята. Бу аңлашыла да, чөнки бик мөһим мәсьәлә. «Летописьная повесть» дип аталган чыганакта Ягайлоның, яуга кузгалып та, акрын хәрәкәт итүе аркасында ярдәмгә килеп өлгерә алмавы, ә инде Мамай мирзаның Куликово кырында җиңелү хәбәрен ишеткәч, куркып калып кире борылуы әйтелә. «Сказание о Мамаевом побоище» әсәрендә исә кенәз Ягайлоның сугыш башланган чакта Одоев каласы янында көтеп торуы (сугыш кырыннан ике-өч көнлек юл арасы) хәбәр ителә.

Әйтергә кирәк, тарих фәнендә бу мәсьәләгә багышланган гаять бай әдәбият бар. Шулар арасында тарихчы В. А. Кучкинның фикере аерым игътибарга лаек дисәк, һич арттыру булмастыр. («Знание—сила», 1980, № 9, 23 б.). Ул нииндидер Епифаний исемле инок тарафыннан гыйбадәт кылу ярдәмлеге битләренә теркәлгән бер язуга игътибар иткән. 1380 елның 21 сентябренә караган бу язуның эчтәлеге болай: «Весть прииде, яко Литва грядут с Агаряны» (татарчасы: «Хәбәр алынды, гүя, Литва белән Агаряннар килә, имеш»).

Бу хәбәрдәге «агаряннар»ның Алтын Урда мөселманнары икәне шик уятмый, бу билгеле нәрсә. Ә менә 8 сентябрь көнне генә булып узган дәһшәтле Куликово сугышыннан соң «җиңелгән» Мамай мирзаның, Литва белән берләшеп, кабат Мәскәүгә каршы кылыч тартырга җыенуы шактый сәер хәл. Тик беренче карашка гына. Димәк, без Мамай мирза тарихын җитәрлек дәрәҗәдә белмибез булып чыга. Димәк, ул Куликово кырында «җиңелгәннән» соң да шул ук сентябрь аенда яңа гаскәр тупларга өлгергән һәм Мәскәүгә яуга җыенган. Һәм шул хәбәр көне-сәгате белән урысларга килеп тә җиткән.

Бу очракта инок Епифаний хәбәренә ышанырга мөмкиндер дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, Сергий Радонежскийның биографиясен өйрәнгәндә миңа әлеге инокның кем булуы тәмам ачылды. Епифаний—изге атакайның бик яраткан, якын иткән бер шәкерте булган икән. Ул соңрак, остазы вафат булгач, аның тормыш юлын тасвирлап китап та яза—атаклы каләм остасы да булып китә. Күрәсең, бу хәбәр Сергий Радонежский даирәсендә билгеле булган һәм Епифаний аны гыйбадәтнамә битенә теркәп куйган.

Тарихчы В. А. Кучкин «Сказание о Мамаевом побоище» әсәрендәге бер урынга да игътибар итә: анда Мамай мирза белән кенәз Ягайлоның Мәскәүгә каршы яуны көз җиткәч башларга ниятләүләре турында ап-ачык итеп әйтелә. Ә борынгы урыс календаре буенча **көз бары тик 24 сентябрьдән генә башлана торган булган**. Кабат искә төшерик: инок Епифанийның язмасы 21 сентябрьдә теркәлгән. Моннан нәрсә килеп чыга соң? Димәк, Мамай мирза Мәскәүгә яуны 4 сентябрьләр узгач башларга тиеш булган, шул хакта кенәз Ягайло белән алдан сөйләшеп куйган. Шуңа күрә, әлегә актив хәрәкәтләргә күчмичә, Дон аръягында тыныч кына кенәз Ягайлоның килеп кушылуын көтеп яткан. Ләкин урысларның көтмәгәндә аның өстенә килеп чыгуы мирзаның бөтен планнарын чуалтып җибәргән. Менә кайдан килә аның сүлпәнлек, пассивлык күрсәтүе! Аның гаскәре тупланып җитмәгән булган. Ә Ягайло бу вакытта берни белмичә татарлар белән яуга бару өчен гаскәрен җыя гына башлаган булса кирәк. Епифанийның язуы шул хакта сөйли.

Тарихчылар күрсәтүенчә, кенәз Ягайло яуга 21 сентябрьдә генә кузгала. Бу нәрсә турында сөйли: димәк, 8 сентябрьдә ул Куликово сугышында катнашырга уйламаган да, гомумән, ул хакта соныннан гына белгән. Ә Мамай мирза исә Куликово сугышыннан соң тиз арада кабат гаскәр туплап өлгергән, урысларның яу кырында коточкыч күп кеше югалтуын аңлаган хәлдә, Мәскәүгә яңа яу белән барырга җыенган. Әлбәттә инде, аның кенәз Ягайлога кеше җибәреп: «Көчем җитәрлек, килешү үз көчендә кала, тиешле вакытка килеп җит!»—дип икенче тапкыр яуга җыенуын хәбәр итәргә генә акылы җиткәндер. Менә ни өчен кенәз Ягайло 21 сентябрьдә Мамай мирза белән очрашу өчен яуга кузгалган. Чыннан

да, аның Одоев каласына килеп житүе, анда урыслар кулыннан Куликово кыры трофейларын тартып алуы билгеле.

Ә менә Мамай мирза белән очрашырга аңа Ходай насыйп итми. Алар бергәләшеп Мәскәү өстенә килә алмый калалар. Нәкъ шушы көннәрдә Алтын Урданың сул канатында үз хакимиятен урнаштырган Туктамыш хан, Иделне кичеп, Мамай мирзага каршы чыга. (Куликово сугышы хәбәре моңа этәргеч биргәндер, күрәсең. Һөҗүм итәргә иң җайлы чак!) Шулай Мамай мирза өчен Мәскәү мәсьәләсе үзеннән-үзе икенче планга күчә, вакытлыча көн тәртибеннән төшеп кала. Гаярь мирза тупланган гаскәре белән Туктамыш ханга, асылда Алтын Урданың законлы ханына каршы кабат көрәш башлап җибәрергә мәҗбүр була. Ә Литва кенәзе Ягайло, үзара сугышкан ике татар арасына килеп кысылырга теләмичә, кире борыла. Кайтып барышлый урысларны талап үз биләмәләренә юнәлә.

Ул көннәрдә вакыйгалар чылбыры менә шундыйрак төс алган дип уйларга нигез бар.

## XIII

Әлбәттә, Куликово сугышы Алтын Урда тарихына караганда урыс тарихы өчен әһәмиятлерәк вакыйга. Бу бәрелешне татар дәүләтенең зур фаҗигасе дип уйларга һич тә ярамый. Ни өчен дигәндә, әлеге бәрелештә рәсми хөкүмәткә (Сарай хөкүмәте) карата оппозициядә торган бер як кына катнаша һәм уңышсызлыкларга дучар була. Бу очракта, урыс тарихчылары язганча, Куликово кыры вакыйгаларының «дөньякүләм тарихи әһәмияте» хакында сүз алып бару ким дигәндә дөреслеккә хилафлык китерү булыр иде. Шул ук вакытта Мамай мирзаның уңышсыз явы Алтын Урда дәүләтендә хәлләрнең кирегә тәгәри башлавын күрсәтүче хәтәр төсмер дә ул.

Бу хасталык симптомы нилектән барлыкка килгән соң? Ни өчен шулай татар мәмләкәтенең эшләре артка китә башлый? Нинди сәбәпләр аркасында вакыйгалар шундый юнәлеш ала?

Билгеле ки, дөньяда һәр нәрсә мәгълүм закончалык-кануннарга буйсынып яши. Ул туа, үсә, хәрәкәт итә, ныгый, картая һәм үлә. Бу кануннар бөтен җиһан өчен уртак, алардан кечкенә бер бөҗәк тә, адәм баласы да, җәмгыять тә, гомумән кешелек дөньясы да, күк җисемнәре дә азат була алмый. Бар нәрсә дә Галәмнең кырыс һәм гадел кануннарына буйсына. Шулай ук аерым дәүләт-мәмләкәтләр дә бу кануннардан азат түгелләр.

Бар нәрсәне дә үзенә колачлаган ул нинди канун икән соң? Эволюция, эволюция кануны ул! Җиһанда, дөньяда бары тик эволюция канунына каршы бармаган нәрсә генә яши, тереклек итә ала. Каршы килде исә — бетә, акрынлапмы, зур тизлек беләнме — һәлакәткә бара.

Әйткәнебезчә, Алтын Урда дәүләтенең иң бөек чагы Үзбәк хан белән аның улы Җанибәк ханнар заманына туры килә. Бу елларда аның шәһәрләре мәшһүр мәдәният һәм сәүдә үзәкләренә әверелә, кәрван юлларында гаҗәеп иминлек, сәүдә әһелләре Кытайдан Кара диңгезгә кадәр бернинди кыенлыклар, хәвеф-хәтәр кичермичә туктаусыз йөреп тора. Италия сәүдәгәрләреннән калган документларда Алтын Урда җирләрендә кәрван саклау өчен отрядның кирәк булмавы, юлда киптерелгән балыктан, тоздан башка, азык-төлекне бик арзан бәягә сатып алырга мөмкин икәне кисәтеп әйтелә. Тәхеткә Бирдебәк хан чыккач үтерешләр китә, тәртип бозыла. Аның үзен дә тиздән юк итәләр. Тәхет бүлергә керешәләр. Һәлакәт менә шуннан башлана. Дәүләттә көйгә салынган тормыш җимерелүгә йөз тота, сәүдә дә аксый, чөнки юл йөрүләре хәтәр бер нәрсәгә әверелә. Ә бит Алтын Урданың икътисади нигезен сәүдә тәшкил иткән. Тәхет даулары аркасында Үзәк хөкүмәтнең хәлсезләнә баруын күреп, дәүләтнең олыслары аерылып чыга башлый, мөстәкыйль яшәргә керешә. Бу да мәмләкәтнең куәтен ала.

Әлбәттә, бу хәлләр берсе дә үсешкә, эволюциягә ярдәм итмәгән, шуңа күрә мәмләкәтнең язмышы инкыйразга таба борылган.

Дәүләтләр тарихын, үткән юлын җәядән ук ату белән чагыштырып булыр иде сыман. Әйтик, киертелгән ук тартылганда җәянең киерелүен ыру-кабиләләрнең бер мәмләкәткә җыелуы-укмашуы дип күз алдына китерик. Шулай җәядә зур көч, киеренкелек барлыкка килә, — бу инде дәүләтнең оешып җитүе, андагы халыкларның үзара якынаюы аркасында уртак идеал-максатны аңлар дәрәҗәгә күтәрелүе. Бу этапта тупланган көч-куәт инде мәмләкәт кысаларына гына сыеша алмый

башлый, тышка омтыла (ук очып китә), чит җирләрне, халыкларны яулау-буйсындыру, яшәү мәйданын киңәйтү башлана.

1255 елда Алтын Урдада Бату хан вафат була. Бу вакытта дәүләттә яулар инде күптән тәмамланып, калыплашкан тыныч тормыш урнашып өлгерә. Шул сәбәпле Батудан соң тәхеткә чыккан ханнар заманында күп калалар калкып чыга, борыннан калганнары чәчәк ату чорын кичерә. Кабат ук-җәя белән чагыштыруга әйләнеп кайтсак, бу инде атылган укның инерция белән очкан чагы булыр иде. Әмма ук та мәңге оча алмый, күпмедер вакыт үткәч арый, талчыга башлый. Аңа үз авырлыгын, җирнең тарту көчен, һава каршылыгын җиңү торган саен кыенлаша бара. Шулай ук башын җиргә бора, көчен югалта.

Бату ханнан соң бер гасыр вакыт үткәч, 1357 елда Җанибәк хан да вафат була. Бу вакытта дәүләтнең күге әле аяз (ук әле барча каршылыкларны җиңеп алга оча), мәмләкәт канаты астында яшәүче бер кавем дә чыңгызыйлар урнаштырган тәртипләр кайчан да булса бетәр дип башына да китерә алмый. Тормыш мәңге шулай дәвам итәр төсле. Ләкин бу давыл алдыннан күзәтелә торган тынлык кына булган икән.

Тагын өч елдан (1360) аерма җир белән күк арасы кебек. Кая китте ул иминлек, көйле тормыш, тыныч кына сәүдә итүләр? Сарай шәһәре — кырмыска оясын хәтерләтә. Әллә ничә фирка үсеп чыга, һәркайсы үз кешесен тәхеткә чыгармакчы. Шул сәбәпле низаглар, мәкер, үтерешләр. Дәүләт язмышын кайгыртучы, аның киләчәген уйлаучы, абруен сакларга омтылучы адәмнәр кайда? Үз мәнфәгатьләреннән өстен торган ватанпәрвәр шәхес кайда? Дәүләтнең төп максатын билгеләүче, ил язмышын уйлап, акыл белән эш итүче олуг затлар кайда?

Ни кызганыч, 20 елга сузылган болганыш дәверендә без андый шәхесне күрмибез. Шушы елларда ачыла да инде Алтын Урданың нинди дәүләт икәнлеге! Үткән бер гасыр вакыт эчендә бу мәмләкәт олуг максатлар эзләп табып, аларны үз алдына куя белмәгән икән ләбаса. Бер гасыр эчендә Алтын Урдада сәяси фикер чарланып өлгермәгән, аның тирәнтен уйланган үз идеологиясе эшләнмәгән.

Әйе, мәмләкәт яңа җирдә, яңа шартларда барлыкка килә, аның канат астында күп төрле менталитетка ия халыклар яши. Империя көч ярдәмендә механик рәвештә төзелә, тик соңыннан аның нигезен ныгыту, халыкларны берләштерүче уртак идея эзләү турында уйланучы табылмый. Аның каруы ерак далалардан ияреп килгән патриархаль тәртипләр, борынгы дала йоласы чәчәк ата. Дәүләтнең бөтен гайрәте тәхеттә утырган ханнарның шәхси сыйфатлары, зирәклеге, каты куллы була белүенә бәйле икән бит. Тарих күрсәткәнчә, ханнар вагая башлау белән аларның кулыннан дилбегә китә һәм бөек максатлары, төпле идеологиясе булмаган мәмләкәт таркалуга таба борыла.

Ә күршедә (Сарай кул астында бит әле!) максатлары ап-ачык, дин әһелләре ярдәмендә үз идеологиясен булдырган, даими рәвештә аны халыкка сеңдереп торган Мәскәү күтәрелә. Ул үзенә ни кирәген бик әйбәт белә, башта астыртын, ә инде бераз көч туплый төшкәч, ачыктан-ачык Сарайга каршы эш алып бара. Ул һәр мөмкинлектән файдалана, кирәксә, ялагайлана, Сарай ханнарына-түрәләренә бүләкләр ташый, ара-тирә үз кенәзләрен дә саткалый, хәтта татар белән бергә аларга каршы яу чаба. Әмма ни генә булмасын, иң астыртын уен — татарны хәлсезләндерү, аның кул астыннан ирекkә чыгуны һәр очракта да үзенең төп максаты итеп күрә белә. Икенче төрле әйткәндә, урыс кенәзләре, руханилары шәхси мәнфәгатьләр белән генә чикләнмичә, гомуми максатны онытмыйлар. Аны өстен куя беләләр. Әлбәттә, бу омтылышның үзәгендә Мәскәү тора, барысын да ул рухландыра.

Ни әйтсәң дә, урысларның татар даласының эченә үк үтеп керәп, Куликово сугышында инициативаны үз кулларына алуы, ифрат зур югалтулар белән булса да, өстен чыгуы — шушы максатчан сәясәтнең бер мисалы. Ә татар бу вакыйгадан тиешле нәтиҗә чыгарганмы?

Тагын ике елдан (1382) Алтын Урдада хакимиятне үз кулына алган Туктамыш хан Мәскәүне камый, берничә көннән татарлар башкаланы басып ала. Шушы вакыйгадан соң Куликово сугышы «каһарманы» Дмитрий Иванович Донской нәкъ элеккечә Сарайга ясак түли башлый. Ә татарлар, шуңа канәгать булып, Мәскәүне кабат үз иркенә куя — бары ясак кына түләп торсын.

«Рухны кылыч белән буйсындырып булмый»,— дигән Наполеон, гарчә үзе шуның киресен эшләсә дә. Ә Алтын Урда ханнары фәкать тупас көч куллану ысулы белән генә эш итәләр. Кул астындагы халыкларны үзара якынайту өчен бүтән чаралар куллану башларына да килми. Табигый, Мәскәү буйсынган төс чыгарып кына яши, ә үзе татарга китереп сугарга җай чыкканны көтә.

Ә татар нишли соң? Ул беркатлы, кызу канлы, турыдан бәрә, үз көченә артык ышана, төптән уйлап эш итми, урыслар узына башласа гына, килеп куркытып китә дә тагын тынычлана. Хакимиятен ныгытмый. Ясак түлиләр ич — шул җитмәгәнмени?! Бер каптармалы һәм акылсыз сәясәт! Шул харап итә дә бөек татар мәмләкәтен.

Дөрес, Туктамыш хан тәхеткә чыккач, тарала башлаган дәүләтне бер йодрыкка тупларга ирешә. Тик озаккамы? Мамай мирзадан соң бушап калган тарихи мәйданга икенче сепаратист Идегәй мирза килеп чыга. Ул да нәкъ Мамай мирза ролендә, үзәк хакимияткә каршы көрәшә. Димәк, мәмләкәттә ватандашлар сугышы дәвам итә дигән сүз.

Татар: «Ике тәкә башы бер казанга сыймый»,— дип бик дөрес әйткән. Үзе турында әйткән. Туктамыш хан үзенең иң сәләтле гаскәр башы Идегәй мирза белән уртак тел таба алмый. Тегесе Сәмәркандка Аксак Тимер хозурына качып китәргә мәҗбүр була һәм... калган гомерен Туктамыш хан белән көрәшүгә багышлый. Бу көрәшкә ул Аксак Тимерне дә тарта, яуга үгетли. Идегәйне биздереп, Туктамыш хан үзе утырган ботакны кисә. Ботакны гына микән әле. Гомумән, Алтын Урда дәүләтен һәлакәткә этәрә. Шулай итеп, Аксак Тимер яулары дәүләтне бер җимерсә, ике татар — Туктамыш белән Идегәйнең үзара тынышa алмавы хәлне тагын да авырайта. Дәүләт хәлсезләнә, икътисады җимерелә, халкы туктаусыз сугышлардан туеп, таралып, әрәм-шәрәм булып бетә. Шулай мәмләкәтнең абруе һаман төшә бара.

## XIV

Алтын Урда дәүләте алай ук тиз сүнәргә тиешле мәмләкәт түгел иде. Һәр империя кебек, ул да үсеш, эволюция кануннарына каршы килде, үз бәхетенә аркылы ятты һәм шул сәбәпле тарих мәйданыннан төшеп калды. Һәр империя кебек, аны да нәфсе, амбицияләре харап итте. Ә бит чын мәгънәсендә бөек бу мәмләкәт, үзгәрә-үзгәрә, әле шактый дәверләр яши алган булыр иде. Әмма ул үзенә умыртка баганасыдай тотрыклы идея таба алмады. Дөресрәге, оеша башлаган идеянең әһәмиятен вакытында сизеп алып, аны үстерү, ныгыту юлына басмады.

Нинди идея соң ул?

Үзбәк хан заманында, дәүләтнең чәчәк аткан көннәрендә бу идея инде борын төртә, Идел буе халыкларында уртак үзәң оеша башлый. Алар үзләрен бөтен бер дәүләт организмының тулы хокуклы әгъзалары итеп тою баскычына күтәреләләр. Мондый үзәңнең барлыкка килүенә үзәкләштерелгән көчле дәүләт, бер үк тәртипләр, тотрыклы тормыш үзе ярдәм итә. Бу үзәңнең үзәген **Идел-Йорт идеясе** тәшкил иткән дисәк, дөрес булыр шикелле. Укучылар хәтерлиләр, «Идегәй» дастанының беренче юлларында ук Идел буе төркиләренең уртак ватаны Идел-Йорт белән горурлану хисе ярылып ята:

> Борын үткән заманда,
> Болгар белән Сарайда,
> Җаек белән Иделдә,
> Алтын Урда, Ак Урда —
> Данлы кыпчак җирендә,—

диелә. Ә шушы данлы йортның үзәген «Идел сырты Сары тау» тәшкил итә. Бу хис-тойгы, гомуми үзәң дастанның башка бүлекләрендә дә үзен сиздереп-сиздереп куя:

> Йортым Идел-йорт икән,
> Үзем кыпчак би икән.

Дастанның икенче бер җирендә «данлы кыпчак җиренең» географик кысалары тагын да киңрәк күрсәтелә:

> Идел, Җаек сулары,
> Иртеш белән Чулманны,
> Дүрт дәрьяле йортыңны...—

диелә. Ләкин шушы йорт-мәмләкәтнең умыртка баганасын Идел елгасы, аның тирәсенә сырышкан төрки кавемнәрнең уртак ватаны Идел-йорт тәшкил итә.

Читкәрәк китү булса да әйтеп үтик: XX йөз башында татарның иҗтимагый һәм сәяси фикерендә кабат «Идел-Урал штаты» дигән идеянең калкып чыгуы очраклы хәл түгел. Аның нигезе әле Алтын Урда дәверендә үк салына, әмма дәүләт таркалу аркасында ул ныгый алмый кала.

Әйе, Идел-йорт идеясен тормышка ашыру өчен Алтын Урда идарәчеләре киләчәк турында күбрәк уйланырга, бу кадәр зур территорияне киләчәктә саклап калып булмаячагын чамаларга тиешләр иде. Бу эшләнмәде. Алар үз-үзенне чикләү, нәфесеңне, амбицияләреңне тыю юлына басмадылар. (Әлбәттә, XX йөз азагында бу хакта фикер йөртүләре җиңел!) Моның өчен Идел тирәсендә яшәгән барлык төркиләр Идел буен туган бишекләре, Ана Ватаннары дип санап, шушы гүзәл җирдә үсеп чыккан көчле һәм мөстәкыйль мәмләкәт канаты астында берегергә, Идел-йорт өчен җан атып яшәүче халык булып бер йодрыкка тупланырга тиешләр иде.

Әлбәттә, Идел-йорт ныгып китсен өчен татар мәмләкәте идарәчеләре авыр канатларын ике тарафка җәйгән зур империяне җиңеләйтү, җыйнакландыру юлына басарга тиешләр иде (чөнки идарә итүе барыбер кыен, мәшәкате күп, ә файдасы юк дәрәҗәсендә). Моның өчен, беренче чиратта, сул канаттагы Күк Урданы кыеп төшерергә, шулай ук уң канаттагы Украина далаларын, Кырымны, хәтта Мәскәү кенәзлеге кебек олысларны да дәүләттән кисеп ташларга, ул җирләрдән, гомумән, баш тартырга тиешләр иде. Ул чакта көч җитмәслек йөзне хәтерләткән зур мәмләкәт җиңеләеп калган, яңа сулыш алган булыр иде. Әмма Алтын Урдада моны аңларлык затлар табылмый. Ә телгә алынган олыслар соңрак барыбер аерылып чыга, ләкин инде соң була. Бу мәмләкәтнең бетүенә китерә.

Тарихи спиральнең яңа боҗрасында, инде безнең күз алдында, соңгы империя булган Русиядә дә шул ук процесслар бара. Ләкин империя яклы көчләр тешетырнагы белән республикаларга, регионнарга ирек бирмәскә тырышалар. Тик бу да юкка көчәнү — Русия барыбер элекке хәлендә калмаячак, чөнки ирекле үсү, эволюция кануннарына каршы килгән һәр нәрсә бетүгә бара. Бу — катгый канун, галәм кануны. Эволюция галиҗәнаплары бер Русия өчен генә ташлама ясап тормаслар дип уйларга кирәк. «Бүленмәс һәм бердәм Русия» тарафдарлары моны тизрәк аңлаган саен азрак нәрсә югалтачаклар.

Бүгенге көндә Русия дәүләте, үз вакытындагы Алтын Урда кебек үк, Галәмнең икенче бөек канунына да каршы килә. Бу канун — Ихтыяр һәм Сайлау ирке кануны дип атала (Закон Свободы Воли и Выбора). Империяләр һәрвакыт халыкларның ихтыярын кысып яшәгәннәр, аларга үзләренчә тормыш корырга ирек бирмәгәннәр. Бу — Галәм (аны Аллаһы тәгалә дип тә атап була) каршында зур гөнаһ санала, иртәме-соңмы барыбер җәзасын ала. Тарихтан мисаллар китереп торуның кирәге юктыр, дип уйлыйм. Кешелек дөньясы моңарчы җимерелми-таркалмый калган бер генә империяне дә белми. Шуңа күрә Русия тиз арада акылга килмәсә, аны да Алтын Урда язмышы көтә. Галәм кануннары тәрәккыять юлына аркылы ятучыны һәрвакыт рисвай итә.

Әйе, Алтын Урда дәүләте тарих арбасыннан алай ук тиз төшеп калмаска тиеш иде. Бу мәмләкәтнең көче күп булса да, акылы сайрак булган. Бу сүзләрне мин, татар кешесе буларак, әрнү хисе белән әйтәм. Үз татарым өчен сер итеп кенә әйтәм. Без җитешсез якларыбызны белеп яшәргә тиешбез. Хаталарны кабатламас өчен! Татарга гомер бакый бердәмлек һәм төптән уйлап эш итү җитенкерәмәгән. Казан ханлыгы да шул ук хаталар аркасында егылган. Аның да, дәүләт буларак, төпле идеологиясе, киң карашлы идарәчеләре күп булмаган. Гомумән, бу төрки халыкларга, алар төзегән дәүләтләргә хас сыйфат түгелме икән? Алар гомер-гомергә, гайрәтле халык буларак, дәүләтләрен бик тиз төзегәннәр. Тик саклап кала алмаганнар. Тарихта моның мисаллары байтак.

Безнең бүгенге көнгә хәтле чал тарихыбыздан, шул исәптән Куликово сугышыннан, Казан ханлыгы егылганнан соң күп гасырлар буе дәүләтсез яшәвебездән, 1917 елдан соң да «автономияле» милләт кенә булып калуыбыздан тиешле нәтиҗәләр чыгара алганыбыз юк шикелле. Бүгенге көнгә хәтле татарның үз йөзен саклап калырлык милли идеологиясе юк. Ул мәктәп дәреслекләренә кермәгән. Димәк, милләтебез үз алдына ачык программа рәвешендә эшләнгән бөек максатлар куя алмаган дигән сүз. Ә алдавычлар күп һәм безгә аларны гел тәкъдим итеп торалар. Татар һаман саен алдана килә. Татарга һаман бердәмлек, акыл, зирәклек җитми, ул төптән уйлап эш итми, үзара талашып, башлаган уңай эшләрен үзе үк тарата тора.

Бөтен татар өчен уртак максатларыбыз — милли идеологиябезнең эшләнмәве соңгы еллардагы суверенитет өчен барган көрәштә үзен бик нык сиздерде. Үзенә туры юл сыза белмәгән, шуңа бару өчен көн дә эшләмәгән халык якты хыялына ирешә алырмы? Куликово кырының, гомумән, ифрат бай тарихыбызның иң мөһим сабакларын мин шунда күрәм.

*Июнь-октябрь, 1996 ел.*

# ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ...

Җитмешенче язьма чыгып барам. Олыгайган саен үткәннәрне иңлисе килә, кылган яхшы гамәлләрне уйлагач эч җылына, ялгыш-хаталарны искә төшергәч тагын бер тапкыр тәүбәгә килеп, Тәңрегә ялварасың: «Йа, раббем, кичер!»

Әдәбиятка үзем килгән еллар... Кемнәрдәндер җылы сүз көтеп тилмереп яшәгән мизгелләр... Җылы сүз өмет итеп минем катыма килгән яшьрәкләр: Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликовалар. Йа, хода, үзләре мәйдан тотарлык әдибәләр булып җитештеләр, хезмәтләре белән илгә танылдылар. Буяучы киемнәрен дә салырга өлгермичә минем катка йөгергән Нәбирә Гыйматдинова. Чандыр гына, музыкаль аһәңнәр белән сөйләшүче, чая Нәбирә Гыйматдинова! Синең калын бер дәфтәр җыентыгыңны укып чыккач катырак сүзләр әйтеп ташламадым микән? Юктыр, юктыр... Синең чәчрәп торган җөмләләрең, дөнья агышын аңларга омтылган чаялыгың сокландырган иде. Шул йомгак фикеремне көне-сәгате белән җиткерә алдыммы, юкмы? Драматургия кысаларын җимереп, дулап, Ионеско, Бекетларга охшарга тырышып үз сукмагын салырга, бары тик шул юлдан гына Парнас биеклекләренә ыргылган Юныс Сафиуллин... Синең сәхнә күрә алмаган ничәмәничә гүзәл пьесаларыңны укыган идем мин. «Буйдак ир һәм аның иптәшләре» пьесасы бүген дә күз алдымда. Сиңа лаеклы театр да, режиссер да табылмады ул чагында... Озак интектең син заман бөжрасына үтеп керә алмыйча... Хәер, бездәге, бездәге тәрбиядәге тамашачылар арасыннан абсурд театрын кабул итүчеләр табылыр иде микән? Шунысы куанычлы, качмадың, югалмадың, театрда калдың...

Иң нык хәтердә калганнарның берсе, мөгаен, Фәрит Гыйльми булгандыр. Ничәнче ел иде микән, /65—70 нче еллар тирәсе/ без ул чагында Воровский урамындагы кысан гына фатирыбызда яши идек. Килеп керде бу бер заман. Өс-башы да әллә кем булмагандыр, аларын хәтерләмим. Әмма Фәритнең алагаем дәү, ике якка җәелеп, изелеп төшкән бишек-ботинкалары исемдә. Ябымлы көн булгандыр инде, атлый Фәрит, идәндә дәү-дәү аяк эзләре кала. Мин егеткә, «Җилкәнсезләр»дәге Зәйнетдин кебек итеп: «Әй, парин, синең каталар протестка чыккан икән!» дип көлемсерәдем. Зарланмады егет, мин ыргыткан җимгә үрелмәде. Егетнең кысылган иреннәренә карап, мин аның нык бер карар белән ишегемне шакуын аңладым. Хикәяләр алып килгән икән! Зәңгәр тышлы дәфтәрен куеныннан чыгарды һәм миңа тапшырырга ашыкмады, кадерләп ике куллап кысып урындыкка утырды.

Сөйләшә башладык. Егет сүзгә саран вә сак иде, алай да мин аның Чыңгыз Айтматовны чиксез яратуын, минем әсәрләргә дә тартылуын аңлап алдым. «Без бер төсле язабыз!» — дип үк ычкындырмаса да, егетнең сак тавышында үзенә дә, язганнарына да ышануы сизелеп тора иде. Шул чакта гына зәңгәр дәфтәр минем кулга күчте. Мин дәфтәргә күз салдым да күрше бүлмәдәге язу өстәленә кертеп куйдым. Фәрит тә миңа ияреп, без бер-беребезгә каршы утырдык. Мин аның бераз моңсу, уйчан күзләренә карадым. Университетта укый икән егет, Мөслим ягыннан.

Кулына каләм алып язарга тәвәккәлләгән яшь язучыларны мең төрле бусагалар, йөзләрчә киртәләр каршылый. Үзеңне һәм иҗатыңны таныту шактый кыюлык, үткенлек сорый. Гадәттә яшь каләм ияләре сүзне зарланудан башлыйлар. Фәритнең сүзендә үтә тыйнаклыгы истә калды. Зарланмады егет, язмышын сүкмәде, тагын Чыңгызга әйләнеп кайтты. Хикәяләреннән мисаллар китерде. Ул арада әби, Нәкыяның әнкәсе, чәй әзерләп безне кухняга чакырды. Студентның карыны бер чакта да тук булмый, Фәритнең дә ул дәвердә тамагы тук булдымы икән? Гаҗәпләнүемә каршы, Фәрит безнең сыйдан баш тартты, кискен итеп: «Рәхмәт, мин тук», — диде. Кат-кат кыстасам да, мин аны җиңә алмадым һәм егетнең әйткән сүзендә нык торуы, бирешмәве ошады. «Бу егеттә характер бар икән», — дип уйладым.

Без бер чакта да артык якынаймадык, еш очрашмадык, әмма мин дөньяда Фәрит Гыйльметдинов барлыгын, аның сабыр күз карашын бер чакта да хәтеремнән чыгармадым. Егетнең тәүге әдәби адымнары авылны, крестьянның җанын тирәнтен аңлавы, телебезне камил белүе күңелемне җылытып килде. Күрешкән мәлләрдә мин аны дәртләндерергә тырыштым. Әкренлеген читкә куеп, ешрак, күбрәк язуын теләдем. Ул Әлмәттә яши башлады, шунда төпләнде, ныгыды. Мул һәм иркен яшәмәгәндер, ахрысы. Казанга килер иде, кайтырга еш кына акчасы калмас. Юк, акча туздырып, теләсә ничек исраф итеп йөргәндер дип уйламыйм, артык гади, юаш иде Фәрит. Әҗәтен дә өзеп-өзеп ваклап кайтаруларыннан чыгып мин аның тормышы, көн күреше җиңел булгандыр дип уйламыйм. Мәгәр ул бер чакта да авыз тутырып зарланмады. Тышындагысы эчендә иде егетнең. Мин һаман өметләндем, көттем. Егетнең күңел серләрен иңртеп сирәк булса да хикәяләре чыга торды. Сирәк дим, әмма моның сәбәбен әйтә алмыйм.



Фәрит күздән югалып торды һәм көз якынлашкан җәйләрнең берсендә Займищега, Равил Фәйзуллинның дачасына кайтып төште. Армия хезмәтендә булган икән! Өлкән лейтенант, иңбашлары калынайган, күкрәк киңәйгән, күз карашы кыюланган, әмма сүзсезлеге, яшерен уйчанлыгы һаман калган иде. Ул җәйдә Равил балык белән мавыккан иде. Равил берәр нәрсә белән чынлап торып мавыкса, бетте баш. Дөньясын да онытты, вак-төяк мәшәкатьләрен дә! Өчәүләшеп күрештек, мин Фәриткә: «Сиңа, мөгаен, солдат боткасы житешмәгән булгандыр, армия, ниһаять, синең чатыңны ачкандыр. Хикәя, повестьлар хәзер өзмәс языла торыр»,— дидем. Фәрит, гадәтенчә, күңелле генә көлемсерәде, әмма вәгъдә бирергә ашыкмады. Иртәгесен, таң белән, кирәк-яракларны төяп Иделгә кереп киттек, балык тотарга. Фәритнең кармак салганы да, көймәдә утырып балык тотканы да моңарчы юк икән. Күңелле чаклар! Аннан да, моннан да пыр-пыр очып кыр үрдәкләре күтәрелә, утрауларда ялга туктаган акчарлаклар ак буран булып очып китә. Фәритнең йөзе балкыган, ул нидер әйтмәк булып авызын ача, мотор тавышы белән мин берни ишетмим. Гомеренең һәр секундын эш белән үткәрә торган тынмас Равил кесәсеннән кәгазь, каләм чыгарып нидер, мөһим бер фикерен төртеп куя.

Балыклы тугайга барып якорь салдык, көн гаҗәеп матур. Иренеп кенә чыккан кояш Идел көзгесенә аллы-гөлле җәймәләр җәйде.

Минем моңарчы Идел балыгы белән очрашмаган бик күпләрне иңртеп кергәнем бар, күзәтүләрем җитәрлек, беләм, балык үтә сизгер, хәйләкәр җан иясе ул!

Сул якка, коерыкка Равилне утырттык. Ул инде остарып килә, балыкчы, кармакларны башта ук сайлап алды. Егет кайда да беренчелекне бирми! Үзем уртага утырдым да бер чакта да балык эләкми торган, калын җепле, кәкере сапллы җайсыз кармагымны Фәриткә тоттырдым. Аңа җим капчыгының да иң бәләкәе, сыегы эләкте. «Балыкка хирыслыгы юк, утырыр шунда кысыр сыер имчәген тарткалап!» — дип уйламадым микән?! Утырыштык. Идел ага, ага! Һәркем үз кармагына йотылган. Карасам, Фәритнең кармак җебе дер-дер селкенә. «Тарт, чиртә!» — дип кычкырып җибәрдем. Фәрит сискәнеп калкынды. Кәкере кармак сабын күккә чөеп, үзе көймә борты аркылы ук чыгып китте һәм чулт Идел суына! Мин, авыр аяк, исемә килгәнче җитез Равил килеп тә җитте, Фәритне күлмәк якасыннан сөйрәп тартып та чыгарды. Фәрит дустыбызга бәләк чаклы, куе сары корбан эләккән икән... Шуннан китте, китте, Фәрит балыкны чупыра гына, безгә дә ара-тирә килеп эләккәли...

Равил кыза, матур итеп көнләшә, ә Фәрит бер чиләк балык тоткач кына арып туктады, мактанмады. Шундый егет иде ул, артык тыйнак, сабыр холыклы иде. Иделдән кайткач корбаннарны шәплэп чистартып табада куырып алдык, мин беренче мәртәбә Фәрит белән хәмер эчтем. Бүтән чакта тота идеме, белмим,

кызыксынганым булмады. Табын янында мондыйрак сүзләр әйттем: «Фәрит дус, котлыйм. Адәм баласы бөтен җирдә дә сынала! Синең кулың җиңел, тырышлыгың әүкәтле икән! Тормышыңда бәрәкәтең качмасын! Син талантлы егет! Хәзер гомереңне бушка әрәм итмә, яз да яз!»

Мин аның кул астыннан чыккан гүзәл хикәяләрен укып куандым. Без күбебез авылны, авыл кешесен Сабан туйларында күреп кенә үтә тар рәвештә әдәбиятка кертеп җибәрәбез. «Су өстендә чәчәкләр», «Горур», «Кунак кызы» кебек хикәяләрендә Фәрит Гыйльми үзе яшәгән чор татарларының үзенчәлекле язмышына тирәнтен үтеп керде. Бу җәһәттән «Су өстендә чәчәкләр» хикәясен аерым күрсәтеп үтәсе килә. Үсмерләр психологиясе, колхоз балаларының хәсрәт-шатлыклары, үзара мөнәсәбәтләре үткен тел белән, тапкыр тасвирлау чаралары аша бәян ителә. Бу хикәяләрендә автор актив күзәтүче сыйфатындарак чыгыш ясаса, 1991 нче елда басылган «Зәйтүнәкәй, акчарлагым» хикәясендә автор заманның, коммунистик режимның саф күңелләргә ни чаклы мәсхәрәләү китерүен әрнеп, гуманистик югарылыккаирешеп яза. Саф күңелләр коммунист җитәкчеләрнең һәр каюсыннан таптала, сытыла, изелә. Гүзәл татар кызы, сылу Зәйтүнә кара реакция елларында әче язмышка дучар була да үз-үзенә кул сала. Бүтәнчә явыз власть вәкилләренә каршы торырлык көч юк аңарда! Кыска, төгәл язылган хикәя Олы тәэсирле көчкә ия буларак авторны бер баш югарылыкка күтәрде.

Фәрит Гыйльми тынмады, һаман иҗат итте, заман шаукымына тагылып, адашып заводларга, цехларга да кереп киткәләде.

«Урсай тау итәгендә», «Елганың борылган төшендә» повестьлары укучы күңелендә җылы урын тапты.

Мин һаман көттем, бер өзлексез өметләндем. Чиста күңелле каләмдәш дустым, алай әйтергә яраса, шәкертем, үз күкрәгендә салмак кына дөрләгән утны дөньяга чыгарыр дип уйладым.

Ни аяныч! Тыйнак дустыбыз бу дөньядан ашыгып китеп барды.

Яшьли дөнья куйган каләмдәшләрем хакында мин еш уйлыйм.

Әгәр бүген Газиз Мөхәммәтшин, Фаил Шәфигуллин, Хәсән Сәрьян, Фәрит Гыйльми, Газиз Кашапов кебек затлы прозаиклар исән булса... Хәер, алар эшләп киткәннең кадерен белик, иҗатларын онытмыйк. Изге җаннар иде алар!

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ,
21 февраль 1997

Фәрит

Гыйльми

# КУНАК КЫЗЫ

## I

Безнең урам малайлары авыл башындагы аланга каз бәбкәләре сакларга җыела. Саклау дигәч тә, көне буе алар янында утырып булмый инде. Елга буена төшеп китәбез дә вак балыклар куарга тотынабыз. Кайчак карга йә тилгән безнең бәбкәләрне чәлдереп киткәли. Нишлисең? Дөнья гел рәхәттән генә тормыйдыр шул. Урыны белән ачысын да татырга туры килә... Әй, аның каравы елга буйлап йөгерә-йөгерә хәлдән тайгач, бер су коенуы ни тора да, өйгә кайткач, балык күрсәтеп, мәчене әтәчләр белән сугыштыруы ни тора! Хайваннар мәгъ-

нәсез дә инде. Ашау өчен җаннарын да кызганмаслар. Ә без, малайлар, алай юк-барны бар дип тә белмибез. Балык өчен дә сугыш, имеш!.. Бик эре мәсьәләләр булса гына инде...

Ә бүген яңа уен — алмашлап әкият сөйләүне уйлап чыгардык. Тик кемнән башларга?

Менә сипкелле Хәмит сикереп торды.

— Чират кояш әйләнешеннән, егетләр. Хәзер Ирек сөйли.

— Юк, буйга карап, Рөстәм сөйләсен!

Күршене мин дә ялгыз итмәдем.

— Бүтәнгә бик беренче бит. Давай Ирек сөйләсен.

Башкалар да безне яклагач, Ирекнең каршы торырлыгы калмады. Ерак бабасыннан ишетеп калгандыр инде — Япон сугышы турында сөйләргә тотынды.

— Шулай яшь чак минем, җилле чак. Ике ат белән җир сөреп йөри идем, бервакыт халык сабанын ташлаган да авылга чаба. «Япуннар сугыш башлаган, давай шуларны кыйнарга!» — диләр болар. Мин дә киттем. Барсам, бер япун мылтыгын миңа төзәп тора. Пулясы маңгайга тигәч, алай да сыпырып төшереп исән калдым. Югыйсә, честный слово, беткәнием. Теге япунның эшен бетердем дә киттем Кавказга су эчәргә. Кайчандыр шуның суын тәмле дип ишеткән идем. Туктале, мин әйтәм, бер килгәч су да коенып кайтыйм, дим. Менеп киттем Памир түбәсенә. Сикерсәм, Кара диңгез каткан. Баш очлырак бит минем, тишеп кереп китте бу бозны...

— Кара диңгез катамыни, ахмак!

— Памир Кара диңгез буендамы соң инде. Их, чүбек баш!

Рөстәмнең бу сүзләреннән соң Ирек түзмәде, сикереп торды да үзе дә атакага күчте.

— Малайлар, Рөстәм үзе чүбек баш икән ул. Һәр көн иртән йокыдан торгач, аның әнисе Мөнҗия апа Рөстәм мендәреннән бер уч чүбек җыеп ала икән.

— Кайчан күрдең?!

— Борының үзеңнеке булса, җибәр диләр сиңа яканы!

Шулвакыт беребез дә уйламаган хәл булып алды.

— Кайсыгызныкы иде әнә тегендәге ала каз? Бәбкәсен тилгән алды бит! Их сез, калай әтәчләр, җитмәсә тавышыгыз Каф тавы артына ишетелеп тора.

Борылып карасак, безнең янда бер кыз белән Җиһан әби басып тора. Оялудан кып-кызыл булып, башларны аска идек. Ник оялганбыздыр инде?..

Мин бер урында басып торалмый башладым: теге кырыйдагы ала каз минеке бит...

— Бабушка, калыйм алар белән, ә?

— Алла диген. Алар ише малайлар белән уйнасаң, бөтен киемең пычранып бетәр.

Җиһан әби, кызны ияртеп, алма бакчасы буена китеп барды. Кыз борылып карагач, мин аны үзебезнең янга чакырып кул болгадым: «Әй, кызый!» Җиһан әби сүзенә тәки күнгән: телен күрсәтеп матур итеп елмайды да китеп барды. Матур дигәннән елмаюы гына түгел, үзе дә гаҗәп матур ул. Башындагы ал бантигы әллә каян күренеп тора. Ә өстендә кыска зәңгәрсу күлмәк. Нәкъ чәчәк өстенә кунган зәңгәр күбәләк инде...

Җиһан әби начар хәбәр белән кәефне төшереп җибәргән иде, кызы шуны янадан күтәреп китте. Нәрсә эшлисең? Әхмәт бабай әйтмешли, сугыш корбансыз булмый инде. Хәер, җәй буена бер бәбкә күпмени ул? Тик менә өйдә генә бу корбанга ничек карарлар?

Яңа уеннан борчак пешмәде безнең. Узыша-узыша яр буена йөгердек.

## II

Бәбкәләр шактый үсте. Хәзер инде аларны ни җитте тилгәннәр генә алып китә алмый башлады. Җиһан әби дә сүзендә торды. Кунак кызын безнең белән уйнарга бер тапкыр да җибәрмәде. Аның янына үзебез барсак, безне куып җибәрде. Кыш көне отряд белән барып утыннарын кисүне, су алып кайтып бирүне онытты әби.

Бөркөнне әбинең карты Әхмәт бабай мине чакырып алды:

— Улым, минем атны колхоз дворына илтеп тугарып кайт әле.

Карасам, арбада кунак кызы утыра. Җиһан әбинең өйдән чыгып килүен күрүгә, тиз генә арбага сикереп мендем дә дилбегәне кулга алдым. Бу юлы җиңелдең, әби. Кунак кызың безнең белән! Куркыныч беткәч, атны атлатып кына бара башладым. Ни дисәң дә, яңа кеше бит. Атка утырырга өйрәнмәгән.

— Безнең авылның трамвае була инде бу. Бар җиргә дә шуның белән генә йөрибез.

— А билет ничек саталар?

— Әй сез, шәһәр халкы, авылдан калышасыз. Күптән коммунизм бит бездә. Теләсәң, көне буе утырып йөр. Беркем бер сүз әйтми, билет та сорамый.

— А минем бабай сирәк ала мине үзе белән.

— Әхмәт бабай заправщик бит ул. Майлы мичкәләр төяп йөри. Менә мин дә озакламый әти белән эшкә йөри башлыйм. Бригадир абый риза булды. Утырып йөрисеңме миңа?

— Бабушка җибәрми шул.

— Ә син качып чык. Бик җиңел ул.

Кайтканда кунак кызын юри әйләнеч тыкрыклар буйлап алып киттем. Олы урамга чыксаң, малайлар урап ала. Болай рәхәт, беркем комачауламый. Кайта-кайта аның Казан шәһәрендә торганын да, чын исеме Марина икәнлеген дә белеп алдым. Җиһан әби генә аны Мәрьям дип йөртә икән. Миңа калса, бу исемнәрнең берсе дә ошамый. Күңелемнән генә мин аны зәңгәр күбәләк дип йөртәчәкмен.

Атлый торгач, үзебезнең яланга килеп җиткәнбез. Ә анда, безне сагалап торган кебек, Җиһан әби бәбкәләр җыеп азаплана. Биек читәннәргә ышыкланып, кирегә чигендек.

## III

Иртәгесен Рөстәм төрткәләүгә уянып киттем.

— Илдус, тор тизрәк. Әйдә урманга барабыз. Кичә типтәр урамы малайлары кузгалак, юа җыеп алып кайтканнар. Җиләк тә пешә башлаган ди.

Киенеп урамга чыксам, урамның бөтен малайлары диярлек безнең турыга җыелган. Минем күңел болар белән генә канәгатьләнми. Тагын кемдер юк сыман тоела. Ә-ә, менә кем икән.

— Малайлар, көтеп торыгыз. Хәзер чыгам.

Йөгереп Әхмәт бабайларга кереп киттем. Өйдә Җиһан әби белән Марина чәй эчеп утыралар.

— Әби, таба биреп тор әле. Әни коймак пешермәкче иде.

Җиһан әби таба эзләп мич каршында маташкан арада, Маринаны ымлап кына урамга чакырдым.

Бераздан, Марина белән икәүләп, малайларны куып җитәбез. Алар салмак кына атлап, дөнья хәлләрен сөйләшеп баралар. Ашыгып нигә алҗырга? Урман бит әле ул өч чакрым ераклыкта. Кайтасы да бар.

Урман авызына кергәч, бераз шпионлы уйнап алдык. Дөресен әйткәндә, башкалар өчен генә уен булды ул. Мин үртәлүдән ярылып үләрдәй булып йөрдем. Үземне тоттыру өчен һәрвакыт зәңгәр күбәләккә якынаям

/шпион булып качу миңа эләкте/, ә аның янында һәрвакыт берничә малай. Кая ул мине тоту турында уйлап карау! Мариналың авызына гына карап торалар. Болай буласын белсәм, мин ул кызны гел алып чыкмый идем.

Урман эченә үк кергәч, берсе, әллә юри, әллә чын, бөтен көченә кычкырып җибәрде: «Малайлар, куян!» Корыган ботакларны сындыра-сындыра, малайлар алга омтылдылар. Мин аларга ияргән Маринаның кулыннан тотып туктаттым да бер урында басып калдым.

— Нигә йөгермисең? Малайлардан калабыз бит.

— Ышан син аларга, Марина... Берсе юри генә кычкырды бит аны. Менә хәзер әйләнеп кайта алар. Әнә теге тирәдәрәк кырмыска шәһәре бар. Телисеңме, шуны карый торабыз?

Чынлыкта минем теләк малайлардан качып китү иде. Тик моны Марина гына сизмәсен. Йөрибез-йөрибез, бер кырмыска оясы да очрамый. Кирәкмәгән чакта адым саен очрый торган иде. Бара торгач, бер аланга да килеп чыктык. Ә безгә кирәкле булган машина юлы юк та юк. Урман авызына без гадәттә шул машина юлы белән чыга идек. Су да эчәсе килә башлады.

Хәзер кайтырга чын-чынлап вакыт җитте. Ипи дә бетте. Ике кешегә күпмегә бара ул. Малайлар авылдадыр инде хәзер. Ә без әле урман авызына да чыкмаган. Чынлап адашып китсәк, бүген генә чыга да алырбыз микән?

— Илдус, кайтыйк инде.

— Кайтабыз ич. Борчылма, Марина, бер бөртек тә борчылма! Хәзер кайтып җитәбез аны.

— Кире яккамы?

Мин икеләнеп калдым. Тирә-якта урман да урман. Кайсы якка китәргә соң? Тиз генә иң биек агачка менеп юлны карарга булдым.

Менә торган агачы да әллә нинди юан имән булып чыкты. Бөтен кул сыдырылып беткән.

— Берни дә күренми.

Әйттем дә үкенеп куйдым. Шәһәр кызы бит ул. Адашканны сизеп, елап җибәрсә? Менә гаҗәп. Бу сүзләргә кызыйның керфеге дә селкенмәде. Биек, карт имәнгә игътибар белән карап торды да алга атлады.

— Минем арттан!

— Кирегә таба барасың бит син. Алай адашабыз гына.

Ул минем белән бәхәсләшеп тормады. Нәрсә эшлисең? Аның ялгызын калдырып булмый. Адашсак бергә адашыйк. Әкрен генә урман эченнән барабыз. Тагын да ныграк адашуга таба. Ул алдан бара, мин — яннан. Марина берничә мәртәбә туктап, киселгән агач төбенә карап торган булды, мүккә игътибар итте. География дәресендә без дә мондый нәрсәләрне үткән идек бугай. Котылырсың хәзер алар белән генә. Урман эченә шактый кердек ахры, караңгылатып җибәрде кебек. Нәрсә генә эшләргә соң? Ник килдем, ник малайлардан калдым икән. Их! Төн үткәрү турында уйлый башларга кирәктер хәзер.

Кинәт яктырып киткәндәй кебек булды. Әллә урманның теге ягына ук чыктык инде. Булмас. Тукта, тукта! Алда безнең авыл ич! Юлдан бераз читтәрәк урыннан чыкканбыз икән. Әй, кызый, чын-чынлап бөтен урман юлын белүче зәңгәр күбәләк икәнсең ич син! Хәзер яшәргә була. Күпмени ул өч километр? Син зәңгәр күбәләк булып кайтсаң, мин кояш булып йөзәм!

## IV

Икенче көнне Җиһан әбиләргә күмер сорап кердем. Марина өйдә юк иде. Урамга чыккач, кулымдагы күмерне ачу белән кычыткан арасына томырдым да сызгыра-сызгыра яланга киттем. Малайлар, элеккечә, елга буена җыелганнар. Мине беренче булып Рөстәм күрде.

— Җиһан әбинең кунак кызын алып киткәннәр бит, малай.
— Кем алып киткән?
— Маринаның әтисе хәрби кеше икән бит. Чинын хәзергә белә алмадым әле. Аларны башка шәһәргә күчерәләр икән. Менә шуңа күрә Маринаның әнисе кичә кич кайткан да бүген иртән алып та киткән.

Миңа дөнья күңелсез, бик күңелсез булып калды. Әкрен генә атлап, аякларын яр кырыена салындырып утырган малайлар янына барып утырдым. Ирек, кычыткан тел, яңа әкият сөйләп ташлаган икән. Мине күргәч, яңадан башлады:

— Борын-борын заманда бер зәңгәр күлмәкле хан кызы булган. Әкәмәт чибәр кыз булган ул. Шуны бер көнне уникe башлы дию урлап алып китмәсенме. Кызны коткару өчен бик көчле егетләр җыелган. Ләкин арада күрше хан малае Илдустан да көчле егет юк икән.

Минем сикереп торганны күргәч, Ирек тынып калды. Әле генә хихылдашып утырган малайлар да телләрен тешләделәр дә кызык көтә башладылар. Сугышып тораммы соң мин шундый мәгънәсез әкият өчен. Ике йодрыгымны ике кесәмә тыктым да акрын гына яланның аргы башына китеп бардым.

...Биектә-биектә тилгән бөтерелә. Бәбкә алып китәргә чамалый.

Ә миңа һаман нәрсәдер югалган кебек.

Нәрсә икән ул?..



# УЯТМАКЧЫ БУЛСАҢ...

«...Ул вакытта Җәүдәт унбиш яшьлек малай гына иде әле. Менә алар юлга чыктылар. Өстенә ул чорның үзенә хас киемен — кара күн тужурка, башына күн фуражка киеп, кылыч белән наган таккан атасы, иярле атка менеп, ике йөкнең алдыннан бара. Алдагы йөктә, Җәүдәтнең кечкенә энесен көзге җилдән яшереп, арба уртасына әнисе утырган. Аның янында — Җәүдәт. Арттагы арбада әйберләр белән олаучы бабай үзе генә. Җәүдәтнең әтисе элек төньяк өязләрнең берсендә комиссар булып эшләгән иде. Менә хәзер ул икенче эшкә билгеләнгәнлектән, алар Казан ягына күчеп баралар.

Каенлы зур юлдан бер атлатып, бер юрттырып килә торгач, зур инеш буена утырган волость авылына керделәр.

Урам башыннан кереп кенә җиттеләр, кырыйдагы өйдән, кулын болгый-болгый, шинель кигән бер абый йөгереп чыкты.

— Иптәш! Тукта, кермә авылга! — дип кычкырды. — Күрше авылга аклар кергән, хәзер бездә дә кулаклар кузгалды. Кермәгез, кире китегез!»

Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов үзенең «Намус» романында партия райкомы секретаре Җәүдәт Мансуровның «Унбиш яшьлек малай» чагын әнә шулай сурәтли. «Зур инеш буена утырган волость авылы»нда сәнәкчеләр белән бәрелештән соң, комиссар гаиләсе һәлак була, үсмер улы гына, инеш аша чыгып, әрәмәлек эченә яшеренә. Тормыштагы малайның /ә андый малай чыннан да булган/ шуннан соңгы язмышы билгеле түгел, ә Җәүдәт Мансуров — язучы фантазиясе белән тудырылган дәвамы гына. Әмма Балтач кешеләре, бигрәк тә өлкән буын китап укучылар, бу фаҗигале күренештә телгә алынган һәр нәрсәне таныйлар. Әнә бит, әсәрдәге «каенлы зур юл» — чынбарлыктагы Себер тракты, «зур инеш» — районның көнбатышыннан көнчыгышына кадәр борылып-борылып аккан Шушма елгасы. Шушма аръягындагы әрәмәлек тә, әнә, Кече Лызи белән Карадуган авыллары арасындагы олы юл буеннан күренеп кенә тора. Берничә гектарлы мәйданны биләгән бу әрәмәлек элек «бай бакчасы» дип йөртелеп, анда бихисап күп шомырт һәм карлыган куаклары үсә иде. Соңгырак елларда бу бакчаның агачларын төпләп, Карадугандагы мебель фабрикасының талчыбык плантациясенә әверелдерделәр. Янәшәдә генә — Ишморат болыны. «Бай бакчасы»н төньяк җилләреннән ышыклап, тау буйлап Муса урманы сузылган. Без бу атамалар белән кабат очрашачакбыз әле.

Канлы вакыйгалардан соң берничә ел узгач, Гомәр Бәширов эш белән бу якларга килгән һәм комиссар кыйссасын язып алган, аннары «Намус» романында, Җәүдәт Мансуровның тормыш юлын тасвирлаганда, файдаланган. Ә Казан ягына күчеп барышлый сәнәкчеләр кулыннан һәлак булган комиссар гаиләсенең каберe, әнә ул, ярты гасырлап Балтач авылы уртасында чәчәкләргә күмелеп утырды да, шул тирәгә өч катлы партия райкомы бинасы төзелгәч, каршысына Ленин һәйкәле корган чакта, зиратка күчерелде.

«Каенлы зур юлдан бер атлатып, бер юрттырып килә торгач», Балтачны чыгып асфальттан көнбатышка таба ике чакрым узгач, Кече Лызи авылына җитәсең. Хәер, борынгы Себер юлы буенда «Әби патша каеннары» күптән юк инде. Тракт үзе дә район эчендә «иске юл» буларак кына сакланып калды, ә Казан — Пермь юлы, бераз турайтылып, көньяккарак күчерелде. Балтач, Кече Лызи, Карадуган авыллары бу юлдан читтә калдылар. Кече Лызи авылында булган «комиссар вакыйгасы» ике күрше халыкның ике зур язучысын бер ноктада бәйләүче вазифаны үти хәзер. Эш шунда — бу авылда удмурт әдәбияты классигы,

сталин режимы корбаны Григорий Медведев туган. Аның «Лозя кыры» («Лозя бесмен») исемле трилогиясендә утызынчы еллар авылында барган зур һәм катлаулы үзгәрешләр реаль һәм бөтен катлаулылыгы белән тасвирлана.

Менә Ладя авылына яшь укытучы килә. «Һәр жиргә житешә торган Александр Пылькин аны иске мәктәп янында очрата.

— Пляхов мин, бәлки ишеткәнең бардыр,— ди укытучы.


— Пляхов, Пляхов...— Саня күз карашын югары күтәреп, күк буйлап йөртте.— Таныш фамилия болай.

— Мин үсмер чакта бу авылда булган идем. Әтием — комиссар Пляхов белән бергә. Аны унсигезенче елда сезнең авылда үтерделәр.

— Ие,— дип, гаепле кеше кебек авыр елмайды Пылькин. Ул күптән түгел булган күңелсез вакыйганы исенә төшерде. Бервакыт Ладя авылы аша атларда кызыл комиссар Пляхов узып бара иде. Хатыны һәм ике баласы белән өязгә китеше иде аның. Ә авылның чуалган чагы. Пляхов, атыннан төшеп, халыкны тынычландырмакчы булган иде, кемдер атып жибәрде. Яраланган комиссар маузерын тартып чыгарды һәм, ава-түнә арбасы янына килеп, йөк өстенә утырды да атын куа башлады. Ярсыган кешеләр аның артыннан ташландылар.»

Трилогиядә әлеге вакыйга менә шулай сурәтләнә. Шушма ярына житкәч, качучыларның арбасы авып китә. Фетнәчеләр аңын жуйган комиссарны, аның хатынын һәм имчәк баласын һәлак итәләр. Ә үсмер уллары арышлар арасына кереп яшеренә. Һәм менә ул, Георгий Петрович Пляхов, укытучы булып, бирегә кайткан.

Гомәр Бәшировның Жәүдәт Мансуровы белән Григорий Медведевның Георгий Пляховы, шулай итеп, бер комиссар вакыйгасы, бер фажига аша Балтач жирендә очрашалар. Әдәбият прототипларының гына түгел, күрше мәдәниятләрнең, ике халык тормышының кисешү, үзара бәйләнешү урыны ул Балтач. Әрәмәлектәме, арышлар арасындамы качып, һәлакәттән исән калган үсмер малай, берни белән расланмаган өзек-көтек истәлекләргә караганда, урман тирәләрендә каңгырып йөри, кайсыдыр байның умарталыгын да эшләүче Таузар кешесе Шәхмәт бабай янына барып чыга. Якын-тирә авылларда бу риваятьнең дәвамын хәтерләүчеләр юк инде. Әлегесен, Карадуганда музей оештырып ачу хәстәре белән йөргәндә, таузарлы Бакый Шәймулла улы Зиатдинов ишетеп хәтеренә салган иде. Бу авылның «Себер юлы почта» музее 1995 елның октябрь аенда ачылды.



*Карадугандагы Муса Жәлил һәм «Себер юлы почта» музей»ларын оештырып ачкан, хәзер аларда директорлык итүче, Россия Федерациясенең атказанган укытучысы Бакый Шәймулла улы Зиатдинов.*

Музейга тупланган беренче экспонатлар арасында «Казан губернасы Гадәттән тыш комиссиясенең 1917—1922 еллардагы документлар һәм материаллар жыелмасы» дигән русча китап та бар. Анда «Знамя революции» газетасының 1918 елның 29 ноябрь санынннан бер хәбәр күчереп басылган. Балтач төбәгендә булган һәм ике әдип романнарына кергән канлы вакыйга тасвирлана анда. Хәбәрдә язылганча, 1918 елның 14 ноябрендә Лызи авылы янында 2 ир-ат, бер хатын һәм бер имчәк бала мәете табыла. Шуннан соң Балтач янындагы үр өстенә артиллерия китертеп, авыл ягына мәетләр санынча — дүрт тапкыр — аталар. 14 ноябрьдә, Гадәттән тыш комиссия карары белән, үтерүчеләр атыла. Фетнә өчен жәза сыйфатында, Балтач авылына 100 мең сум акча, 2000 пот солы, 2500 пот арыш, ә бөтен Балтач волостена 300 мең сум акча, 10 мең пот солы, 15 мең пот арыш контрибуциясе салына.

Фажигале үткәнебезнең тузан бөртегедәй бер кечкенә кисәкчәсен искә төшерүче бу китапчык дистә еллардан бирле авыл китапханәсендә яткан, тик аңа

игътибар итүче генә булмаган. Тарихыбызга карата битрәкләр дә битарафлар идек шул без. Шуңа күрә, мәдәниятле тормыш итүләре белән Ибн Фадлан кебек гыйлемле сәяхәтчеләрне таңга калдырган горур халык оныклары, бүгенгедәй рухи фәкыйрьлеккә калдык та. «Буыннан буын чабылса, ул чагында ни калыр?» — диелә «Идегәй» дастанында. Хәзер төзелә торган музейлар әнә шулай бер-берсеннән чабылган буыннарны азмы-күпме ялгап җибәрергә, үз-үзебезне тануда, хәтерләребезне яңартуда ярдәм итәргә тиешләрдер. Ай-һай авыр вазифа бу! Кытайлыларда: «Үз-үзен сукырайткан кешегә табиб та ярдәм итә алмый» — дигән мәкаль бар икән. Безнең арада да үз-үзен томаналандырган, уйсыз-фәһемсез яшәүне кулай күргән замандашлар никадәр! Байтак хакимнәр тарафыннан да нәкъ шушындый тормыш рәвеше хуплана. Өч кешеле хезмәт коллективы булса, еш кына хәлләрдә, арадан үтә «тар маңгайлысы», мәдәни чикләнгәне, үзе һәм югарырак түрәсе мәнфәгатьләре белән генә яши торганы башлык итеп куела, ә калган икесе шуңа сүзсез буйсынырга, алдын-артын карамыйча эшләргә, мәдәнилек «дәрәҗәсендә» башлыгы белән тигезләшергә мәҗбүр ителә. Халык менә шулай ваклана, йокылы-уялы хәлгә китерелә.


Карадуган авылында Нәҗип исемле бригадир бар иде, дип сөйлиләр. Утызынчы елларның берсендә сабан чәчүе бара икән. «Бодай чәчеп киткән» җирне бер малайдан тырмалаталар. Тырмачы атлы тырма артыннан карап-карап йөри дә, туфрак өстендә бодай бөртекләре күрмәгәч, аптырап сорый:

— Нәҗип абый, берни чәчелмәгән түгелме соң монда?

— Алдыңа-артыңа карама, тырмала да тырмала! — дип җавап бирә бригадир.

Ә бит соңыннан, тишелмәгән бодай өчен, орлыкны урлап калган бригадир яисә бүтән кешене түгел, шушы тырмачы малайны хөкем итәчәкләр, белә торып шулай эшләячәкләр.

Безгә исә алдыбызга-артыбызга гына түгел, ерак үткәнебезгә дә күз төшерер вакыт җитте. Үткәнен үз кулында тоткан халык кына киләчәгенә ия була, дигән гыйбрәтле сүз бар. Болай да моңа кадәр тарихыбызның күп өлешен читләр язган, ятлар үзләштергән. Авылларыбызның йөз ел элекке тормышы хакында да татарча язмалар бөтенләй диярлек юк, ә милләтебезнең зур өлеше нәкъ менә шул тарихсыз авылларда яши.



*«Себер юлы — почта музее»ның бер залына борынгы элемтә җиһазлары куелды.*

«Сезнең авылларыгызның төзеклегенә, аларның көнкүреш культурасына сокланмаган кеше юк»,— диде 1995 елның 12 октябрендә Татарстанның мәдәният министры урынбасары Мөҗип Таҗи улы Низамиев. Балтач районында узган «Музейлар көне»нә килгәч. Мондый бәйрәмнең Татарстан җирендә икенче генә үткәрелүе иде әле. Беренчесе «рус телле» музейлар шәһәре Алабугада булды. Бу көнне, районда дүртенче булып, Карадуган авылының «Себер юлы — почта» музее ачылды. Чепьядагы «Халыклар дуслыгы» музееның утыз еллыгы бәйрәм ителде. Шода авылының Мирхәйдәр Фәйзи һәм Карадуганның Муса Җәлил музейларына карата да җылы сүзләр әйтелде. Болар дүртесе дә — Татарстанның берләштерелгән Дәүләт музее филиаллары.

Шул көнне генә ачылса да, Карадугандагы музейның ике дистә ел элек башланган үзенә бертөрле тарихы бар иде инде.

Милләт горурлыгы Муса Җәлилнең тууына җитмеш ел тулуга әзерләнә башлаган җәй иде. Директор Бакый Шәймулла улы Зиатдинов булган Карадуган мәктәбе дә үзенең илле еллыгын үткәрергә җыена. Бу мәктәпнең пионерлар оешмасы Муса Җәлил исемен йөртә. Мәктәптә киңәшәләр дә, шушы ике юбилейны балалар өчен тагын да истәлеклерәк итү теләге белән, бер төркем укучыларны Каһарман-шагыйрь эзләре буйлап озын-озак сәяхәткә алып чыгарга килешәләр. Бу эшкә география укытучысы, хәзер Бөгелмәдә педагогия училищесына җитәкчелек итә торган Әнәс Ибраһимов, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әминә Мөхәммәтҗанова бик теләп алыналар. «Сәяхәт башы»на Әнәснең билгеләнүе төрле яктан отышлы була, чөнки ул географ кына түгел, рәссам һәм фоторәсемче дә, сәяхәттә арган балаларның ялын күңелле итәрлек баянчы да. Киң карашлы, җитмәсә, үзе дә сәяхәткә атлыгып тора. Әминә дә тотынган һәр эшендә балаларча ихласлыгы белән билгеле.

Сәяхәтчеләр, Чаллы, Түбән Кама кебек шәһәрләрне үтеп, беренче зуррак тукталышны Бөгелмәдә ясыйлар. Монда аларны Советлар Союзы Каһарманы Газинур Гафиятуллин турында истәлекләр, аңа салынган һәйкәл кызыксындыра. Бер уңайдан Ярослав Гашек музеена да керәләр. Бу мәктәп коллективының иң тирән хыялы — үзләрендә Муса Җәлил музее төзү омтылышы белән бәйле иде. Аңа кадәр Каһарман-шагыйрь батырлыгына багышлап мәктәптә бер почмак кордылар, альбом эшләделәр.

Җәлилнең туган авылы Мостафада булу, аннан җәяүләп Ырымбурга килгәч, шагыйрьнең сеңлесе Хәдичә һәм элекке дуслары белән очрашып сөйләшү балаларга бик бай истәлекләр һәм мәгълүматлар бирә. Сәяхәтчеләр шулкадәр зур тарихи байлык һәм тәэсирләр белән кайттылар ки, аларны нинди дер «почмак»ларга гына сыйдырып бетерү мөмкин түгел иде инде. Мәктәптә Каһарман-шагыйрьнең музеен оештыру нияте менә шул чакта реаль төс алды.

«Уйнап башланган эш», мәктәп директорының һәм Әнәс Ибраһимов белән Әминә Мөхәммәтҗанованың ихласлыгы аркасында, тиз арада чынга әверелде. Күп тә үтми районга килгән кунакларны Муса Җәлил музеена алып керә башладылар. Төрле елларда биредә Татарстанның халык язучылары һәм шагыйрьләре Мөхәммәт Мәһдиев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, атаклы рәссам Бакый Урманче, сәхнә осталарыбыз Рәшидә Җиһаншина, Ринат Таҗетдинов, Җәлилнең көрәштәше Рушад Хисаметдинов, туганнан туганы Таһир Корбанов, аның иҗатын һәм батырлыгын өйрәнеп китаплар чыгарган Исхак Зәбиров, шагыйрь тууның туксан һәм музей ачылуның егерме еллыгына Альберт Җәлилов булып киттеләр. Альберт Муса улы Җәлилов, Татарстанның «Хәтер» китабы редакторы урынбасары Михаил Черепанов һәм берләштерелгән Дәүләт музее хезмәткәрләре бу көнне Карадуганга «Моабит дәфтәрләре»нең төп нөсхәсен алып килеп, мәктәп балаларына һәм авыл халкына күрсәттеләр. Кызганыч ки, музей җитәкчесе Бакый Зиатдиновның бирегә Әминә Җәлилованы һәм аның кызы Чулпанны алып килү хыялы әлегә кадәр гамәлгә ашмады. Балалар алар белән Мәскәүдә генә очрашып сөйләштеләр. Мәктәптә дистә еллар буена музей эшенең төп авырлыгын тартып барган «Кызыл ромашка» штабы членнары төрле җирләрдә тагын Җәлилнең көрәштәшләре Михаил Иконников, Фәрит Солтанбәков белән очраштылар, Җәлил сугышып әсир төшкән «Үлем үзәне»нә, Одессадагы «Муса Җәлил» теплоходына, элек аның көрәштәше Гайнан Кормаш яшәгән Мари Республикасының Бәрәңге районына сәяхәт ясадылар. Тәрбия өлкәсендә уңышлы эшләгәне өчен 1990 елда музейга Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге бүләге бирелде. Ачылуыннан соң ике дистә ел узгач, Татарстанның мәдәният министры урынбасары Мөҗип әфәнде Низамиев аның хакында «Җәлилчеләр музее шактый озак еллар буена балаларга тәрбия бирүдә зур эшләр башкарды»,— дип сөйләде.

Әмма һәр музейның үз юнәлеше, эчтәлеген чикли торган кысалары да була бит әле. Авылларыбыз тарихы бөтенләй диярлек язылмаган һәм өйрәнелмәгән. Туган якның үткәненә кагылышлы документлар һәм ядкярләр тапсаң да, аларны Муса Җәлил музеена бәйләү бик читен — ясалма килеп чыга. Шәймулла улы Бакый шундый уйларны күңеленнән кат-кат кичерде, теләктәшләре белән дә берничә киңәште дә, авылда туган якны өйрәнә торган тагын бер музей оештырырга кирәк, дигән фикергә килде. Шода авылының Мирхәйдәр Фәйзи музеен ачу тантанасында очрашкач, шул фикерен Татарстанның берләштерелгән Дәүләт музее хезмәткәре Дания Борһановна Баһаветдиновага да белдерде, юлда кайткан чакта район җитәкчеләренә дә шундый уе барлыгын әйтте.

Дания ханым уңай җавапны тиз генә бирмәде, чөнки аңа да күпмедер уйланырга кирәк иде. Туган якны өйрәнәбез дип, күбесе очраклы табылган борынгы әйберләрне, фәнни эшкәртмичә генә, тезеп куйган үзешчән музейлар байтак инде. Яңасын корырга тотынсаң, аның бүтәннәрне кабатламаган фәнни үзенчәлеге булырга тиеш. Мондый эштә максатыңны иң элек ачыкламасаң, соңыннан гына кыенга да калә. Кайсы портка барып чыгасын белмәгән корабка бер җил дә юл уңае булмый, диләр бит. Илдә үзгәртеп кору белән дә менә шундый әкәмәт килеп чыкты: «ил көймәсе»нең барыр юлын әле дә ачык күз алдына китерүче юк, ничә ел инде җир тетрәү вакытындагы кебек мәхшәрдә бәргәләнәбез.

Уйлашып керешкәч, Карадуган музее белән андый буталыш килеп чыкмады. Бу авыл борынгы Себер тракты буена, өстәвенә, элекке Россиянең почта-телеграф төенендә утыра. Менә шушылар яңа музейның исемен дә, эчтәлеген дә билгеләделәр. Җиһазлау эшен бу хезмәттә зур тәҗрибәсе булган карт рәссам Борис Михайлович Салосин башкарып чыкты. Шәймулла улы Бакый белән аларның танышлыгы һәм иҗади хезмәттәшлеге Муса Җәлил музеен төзү көннәрендә үк башланган иде.

Музей урыны итеп «Республика Татарстан: памятники истории и культуры» исемле китапка /Казан, 1993/ кергән матур бинаның икенче каты сайланды. Аның беренче катында Муса Җәлил музее урнашкан. Әлек күп еллар мәктәп булган бу йорт Балтач бае Мортаза Мөлеков тарафыннан шушы гасыр башында кызыл кирпечтән салынган, ул вакытта аскы катында — кибет, өске катында — кунак өе булган.

Экспонатлар белән таныша башлыйбыз. Иң элек зурайтып эшләнгән рәсемнәргә игътибар итик. Әнә Россия императрицасы Екатерина II карап тора. Бу авыл аша Себер юлын шул «Әби патша» төзеткән. Фаҗигаләр белән тулы тарихи юл! Каһәрле язмышыбызның бер кара шәүләсе Карадуган йөзендә дә чагылган: монда Себер юлы буйлап сөргенгә куылучыларның туктап төн куна торган урыннары булган. 1859 елгы авыллар исемлегендә шундый мәгълүмат бар. Бу хәл, билгеле, авылга әйбәт дан китермәгән, киресенчә, Карадуган атамасының килеп чыгышы хакында ямьсез имеш-мимеш таралуга ярдәм иткән. Җитмәсә, 1919 еллар тирәсендә авылда ГПУ бүлеге дә эшләп ала.

Рәсемнәрнең икенчесе — русларның демократ-язучысы А. Н. Радищевныкы. Аның да 1790 елдагы сөрген юлы менә шушыннан узган. Шушы елда ул «Петербургтан Мәскәүгә кадәр» исемле төп хезмәтен яза һәм халыкның искиткеч авыр тормышын, караңгылыкта, җәбер-золым астында яшәвен кыю сурәтли, нәкъ шундый туры фикерләре өчен Петропавловск крепостена сөрелә. Себер юлыннан узганда да күргәннәрен язып бара. Ул «Себергә сәяхәт» исемле көндәлегенә түбәндәгеләрне яза:

«12 ноябрь, 1790 ел.

Арчага өйләдән соң сәгать өчтә килеп җиттем. Ул Казансу елгасы буенда биек тау башында утыра. Борынгы агач манаралар, бер агач чиркәү сакланып калган. Анда яшәүчеләр җир эшкәртү һәм йөк ташу белән шөгыльләнәләр. 26 чакрым ераклыкта Арбаш исемле татар авылы. Янгулга 19 чакрым. Бал сатып алдык — бер поты 6 сум, балсыз кәрәз 10 сум, саф балавыз 20 сум. Кечкенә елгалар буенда татар күп».

13 ноябрь көнне А. Н. Радищев Янгулда туктала һәм көндәлегенә, бу як авылларын сурәтләп, кыйммәтле мәгълүматлар яза. Музей диварына рус географы һәм сәяхәтчесе П. П. Семенов-Тянь-Шанский, татар халкының мәшһүр драматургы Мирхәйдәр Фәйзи, бөек галим Шиһабетдин Мәрҗани рәсемнәре дә куелган. Өчесенең дә бу яклар, борынгы Себер юлы белән азмы-күпме бәйләнеше бар. Беренчесе нәкъ шушы юлдан Себергә сәяхәт ясаган, юлда күргәннәрен «Россия. Ватаныбызның тулы географик тасвирламасы» исемле зур хезмәтендә

язып чыгарган. Сәяхәтче үзе күреп язган бу кадерле мәгълүматларны без бүтән беркайдан таба алмыйбыз. Менә ул хезмәттән бер өзек.

— Казаннан 70 чакрымдагы почта станциясе Мәтәскәне узгач, 95 нче чакрымда тракт Карадуган станциясенә килә,— дип яза ул.— Бу авылда XIX гасырның 60 елларында кытат һәм комач фабрикасы булган, хәзер Якуповның зур булмаган сумала кайнату заводы гына бар. Арырак тракт, К. Лызи авылын үтеп, 1885 елдан бирле Мөлековның киез итек заводы булган Әхмәт авылына (Балтач), Ишморатовның ситсы туку фабрикасы булган 3. Норма авылына китерә. Нормадан соң тракт Вятка губернасының Малмыж өязенә керә».

«Тасвирлама»да искә алынган Мөлековның Карадуган музейларына бина салып калдырган Мортаза бай булуын да өстәп әйтергә кирәктер. Шул ук авторның язуына караганда, Мортаза Мөлековның Балтачта басылган бизәкле киез итекләре Германия ярминкәләрендә дә әйбәт сатыла.

Карадуган музеенда, аның исеменә — үзенчәлегенә туры китереп, борынгы почта-телеграф җиһазлары, ат белән почта куу әйберләре күп куелган. Экспонатларның байтагын Татарстан элемтә министрлыгы һәм Казан шәһәренең телефон челтәре житәкчелеге бирде. Министр Ринат Җәләлов һәм телефон челтәре башлыгы, аннан башка да, райондашлар буларак, Карадуганның Себер юлы-почта музеен коруда акчалата бик зур булышлык иттеләр, әле дә ярдәмнәреннән ташламыйлар.

Шиһабетдин Мәрҗани шушы юллардан Түнтәрдә мәдрәсе тотучы Ишмөхәммәт хәзрәт Динмөхәммәтов (җәмәгатьчелеккә ул, башлыча, Ишми ишан исеме белән билгеле) янына килә торган була. Мәшһүр «Галиябану», «Асылъяр», «Ак калфак» кебек драмалар авторы Мирхәйдәр Фәйзинең дә бу төбәктәге һәм Себер юлындагы эзләре шушы Ишми ишан белән нык бәйле. Ул хактагы мәгълүматларны без Шода авылының Мирхәйдәр Фәйзи музееннан табабыз.



*Мәшһүр «Галиябану» авторы Мирхәйдәр Фәйзинең Шодадагы музей-йортына аның бу замандагы каләмдәшләре әледән-әле килеп торалар.*

Мирхәйдәр Фәйзинең музей-йорты 1991 елның көзендә — драматургның тууына 100 ел тулуга багышлап ачылды. Район үзәгендәге һәм Казандагы күп ишекләрне кат-кат шакып, бу эшне кузгатып йөрүче һәм үҗәтлек белән ахырына житкерүче кеше — ул чактагы авыл Советы рәисе Гыйльмулла Дәүләтшин булды. Драматург монда кунакка килеп йөри торган йортның бер өлеше исән иде әле. Элегрәк анда мәктәп ашханәсе иде. Мәктәптән бушагач әкрен генә таралып ята,

рәтле хуҗа табылмаса, истәлекле бина озакламый юкка чыгарга да мөмкин иде. Азмыни алар — уртак ваемсызлык аркасында халкыбызның эзсез югалган тарихи һәйкәлләре. Мәдәни мираска чагыштырмача әйбәт караш булган шушы районда да Татарстанның тарихи һәйкәлләр исемлегенә кергән Янгул тегермәне таралып ята. Тегермәнне бу гасыр башында Әюп бай салдырган, күп өлеше таштан. Шушы хәрәбә хәлендә дә ике районны буйлаган Шушма елгасына бердәнбер ул хәзер. «Музейлар көне»ндә авыл кешеләре аны торгызу мәсьәләсен Мөҗип әфәнде Низамиев алдында кузгатканнар иде дә, министр урынбасарыннан алда, ашыга-ашыга, җирле җитәкчеләрнең берсе кул селтәп «җавап бирде»: «Беткән инде ул, торгызырлык түгел». Читтән килгән кеше кебек, күрелми үткән заман фигыле белән сөйләшергә түгел: «Бетте ул, бетердек без аны» — дияргә кирәк булгандыр бәлки. Гөрләп эшләп торган чаклары да әллә кайчан түгел бит.

Бәхеткәдер, Шодадагы Сәетгәрәй хәзрәт Фәйзуллин йорты кемнеңдер «Беткән инде!» дип кул селтәвенә кадәр барып җитмәде: узганны кадерли, киләчәкне уйлый белүчеләр табылды. Гыйльмулла Дәүләтшиннан тыш, музейны коруга мондагы күмәк хуҗалык рәисе Хәмит Гәрәев нык булышты, агач эшләрен авыл остасы Әхмәт Җамалиев башкарып чыкты. Укытучы Фәһимә Зәкиева белән авыл кибетчесе Минсылу Җамалиеваның /Әхмәт останың хатыны/, бигрәк тә клуб мөдире Флера Хәбибуллинаның экспонатлар, драматург турында кадерле истәлекләр туплауда гаҗәп ихласлык һәм мавыгу белән эшләвенә сокланырлык иде. Берләштерелгән Дәүләт музее хезмәткәрләре дә күп көч куйдылар. Мәгълүм Мансур Хәсәнов Казаннан торып та, Шодага кат-кат килеп тә, Мирхәйдәр Фәйзи музеен төзү эшен рухландыручы булды.

Экспонат дигәннән, ихлас эзләсәң, үткәннәребезне хәтерләтерлек истәлекле әйберләрне азмы-күпме табарга була икән әле, тагын да соңга калмаска гына кирәк. Шодада бер апа Сәетгәрәй йортының кин агач эскәмиясен табып китергән. Карт урманчы Мансур Гыйлаҗетдинов исә хәзрәт йортының борынгы агач шкафын музейга бүләк иткән. Берзаман авыл мәктәбенең туган якны өйрәнү бүлмәсендә Мирхәйдәр Фәйзигә бәйле һәм аның чорын чагылдырган көнкүреш әйберләре байтак тупланган булган. Чепьяда «Халыклар дуслыгы» музее ачылгач, авылдан барып йөрүче югары сыйныф укучылары ядкәрләрнең күбесен шунда илткәннәр.

Мирхәйдәр Фәйзи Малмыж, Шода якларына 1901, 1906, 1916, 1923, 1924 елларда килә. Ә иң беренче сукмакны аның бертуган абыйсы Сәетгәрәй сала. Ерак Орск шәһәрендә яшәүче Мостафа белән Зәйнәп гаиләсе унбер баланың берсен /Мирхәйдәр — унберенчесе/ — Сәетгәрәй исемлесен — Түнтәр мәдрәсәсенә укырга җибәрә. Нилектән дини мәдрәсәгә, ни өчен нәкъ менә Түнтәргә — бу сорауларга аның туганнары да җавап бирә алмыйлар. Түнтәр мәдрәсәсенең әйбәт даны шул Ырымбур якларына да барып җиткәндер, күрәсең. Сәетгәрәй монда әйбәт укып кына калмый, мәдрәсә хуҗасының Фатыйма исемле кызына өйләнеп тә җибәрә. Сәетгәрәйнең көтмәгәндә бу якларга килеп чыгуының сере дә, бәлки, менә шундадыр — Мостафа белән Ишмөхәммәт кодалар булышырга алдан ук килешеп куйганнардыр. Укып бетергәч, Сәетгәрәйне Шода авылының яңа мәхәлләсенә мулла итеп билгеләгәннәр. Мирхәйдәр Фәйзи музее менә шушы Сәетгәрәй хәзрәт йортында инде.

Хәзрәт эшләгән мәчет бинасы да төзек әле, манарасы гына юк. Анда авылның башлангыч мәктәбе урнашкан. Музей белән бер үк ишек алдында алар. Әйтүләренчә, мәчетне Сәмәрканд сәүдәгәре, чыгышы белән Шоданыкы булган Зәйнетдин хаҗи акча җибәреп салдырган, ул 1902 елда өлгергән. Акчаны бик күп җибәргән кебек тоелгандыр инде, бер кайтып күргәч, «мин бу мәчетнең ишек тоткаларына кадәр алтыннандыр дип уйлаган идем, алай булмаган икән» — дигән, имеш. «Мәктәп кенә мәчет бинасын шушы көнгәчә исән-сау саклап калды»,— ди музей директоры Фәрхәт Рәшитов. Инде авылда балалар укытырга кирпечтән ике катлы мәһабәт мәктәп салып куйганнар. Җылыту чаралары күрелеп, укучылар анда күчсә, иске мәчет бушап калачак һәм яңартылып, Мирхәйдәр Фәйзинең музей-йорты комплексына кушылачак. Мәчет янәшәсендә генә драматург эзләрен саклаучы бакча, аны күргән карт әянкеләр. Мирхәйдәр сокланып карап йөргән «тезелеп үскән биш каен» рәте генә сирәкләнеп килә. Шуларның берсенә, пәке белән уеп, шәмәхә карандаш белән менә шундый шигъри юллар язган ул:

Тезелеп үскән биш каен,
Яфрак яра ел саен.
Искә алырмын даим-даим,—
Сезне сагынган саен.

Бу язу, билгеле, исән түгел инде: каен кәүсәсе пәке ярасыннан төзәлеп, истәлекле шигырьне үзенә яшергән.

Драматургка ул чакта әле беркайда булмаган музейның нәкъ менә Шодада ачылуында аны кунак иткән йортның исән булуы гына сәбәпче түгел. Мирхәйдәр бу авылны, аның кешеләрен, табигатен бик тә үз иткән. Көндәлекләре шулай сөйли: ул бирегә һәрвакыт нечкә хисләр белән, балаларча куанып килгән, җан сыкравы белән киткән. Шулай киткән — кешеләр газиз туфракларыннан гына мондый хис белән аерылырга мөмкиннәр. «Иртәгә китәргә булдым. Иген басуына чыгып йөрдем, Шода өстенә ерактан карап тордым. Шода белән хушлашып йөри башладым. Җыенда уен булган тугайга төшеп, сагынып-монаеп йөрдем»,— дип яза ул көндәлегенә 1923 елда. «Үзем китәм, күнелем кала... Хуш, Шода, хуш, туганнар!» — дип дәвам иттерә тагын бер елдан. Монысы аның Шодага соңгы килүе була, тагын дүрт елдан, рәхимсез авыру 37 яшендә аны якты дөньядан алып китә. Әмма, шул чакта бик дөрес язганча /Пәйгамбәрнең «Амин!» дигән мизгеленә туры килгән, күрәсен/ үзе китсә дә, күнеле, рухы Шодада мәңгегә калды. Бу авыл кешеләрен чиксез яратуы, аларга әсәрләрен багышлавы юкка булмаган, димәк.

Драматург үз гомерендә күп дистәләрчә дәфтәр тутырып көндәлекләр язып бара. Аларның Татарстанга караган өлеше нәкъ менә Шода сәяхәтләре белән нык бәйле. Көндәлекләрдә нечкә күңелле, шигъри җанлы драматургның эчке хисләре генә түгел, шул чактагы халык тормышы да киң чагыла. Аларның тулы килеш әлегәчә беркайда басылмавы гына кызганыч. Һәр әдипнең тормышын энәсеннән-җебенә кадәр өйрәнерләр, дигән Габдулла Тукай хыялларының гамәлгә ашар чоры һаман килеп җитми әле. Киресенчә, күп мисаллар андый хыялның ераклаша баруын күрсәтәләр.

Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләренең 1916 елга караганнары безнең өчен бигрәк тә кадерле һәм истәлекле, чөнки алар мәшһүр «Галиябану» драмасы язылган вакытларга туры киләләр. Күп истәлекләрдән, язма хәбәрләрдән ачыкланганча, «Галиябану» башта ук бер көй тарихы буларак языла. «1916 елда Орск өязенең Дүрткүл авылында яшьләрнең кымыз кичәсендә бер яңа көй ишеттек,— дип язган Сәеттәрәй хәзрәт улы журналист Сәгыйть Фәйзуллин.— «Сәгадәтбану» атлы бу көйне герман фронтыннан бер кулын өздереп кайткан гармунчы егет сыңар кулы белән дә бик матур уйнады, без барыбыз да кушылып җырладык. Мирхәйдәр абый аеруча бирелеп тыңлады».

Күңелендә шушы көй яңгырап торган Мирхәйдәр шул ук җәйдә Сәгыйтькә ияреп Шодага килә һәм юлда көндәлегенә язып куя: «Малмыж бакчасында «Сәгадәтбану» һәм «Җәмилә» көйләренә җырлап утырдым». Аннары, үз якларына кайткач, көйгә бәйле ниятләрен ачыграк белдерә: «Казан ягындагы авылларда йөреп кайттым. Бу яктагы авылларда күргән матур күренешләрдән файдаланып, «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды. Көннәрем шул хакта мәшгуль булып уза башлады».

«Бу яктагы матур күренешләрдән файдаланып...» — дигән сүзләргә игътибар итик. «Галиябану»ның иң элек «Сәгадәтбану» исеме белән язылуын беләбез инде. Драманың су буенда яшьләр уены күренеше Шода кебек авыллар тәэсирендә язылган булып чыга бит. Хәер, югарыдагы җөмләсе белән кистереп әйтеп куймаган булса да, аңлар, таныр идек без моны: бу якларның табигатенә соклануы, авыл тормышына, яшьләр уеннарына гыйшкы көндәлекләренең һәр юлыннан бөркелеп тора ич. Аларның әдәби әсәрләргә күчмәве һич мөмкин түгел. Менә 1916 елның җәйге истәлекләре:

«...Шодада көннәр бик күңелле уза... Бигрәк тә матур су буе манзарасы мине тәмам сихерләде. Кояшны көн дә су буенда озатам. Бу су юлын шул кадәр матур итеп җыештырып куйган Ходайга рәхмәт инде, дип уйлап куям кайчакта».

Драматургның табигать күренеш сурәтләүдән башланып киткән тәэсирләре әкренләп халыкның әдәбенә, тормыш-көнкүрешенә күчә. «Бу якларда, һәр авылда елга булу өстенә, суны чишмәдән алалар. Чишмә чыкмаган бер генә авыл да юк. Ул чишмә яны кызларның, егетләрнең иң кадерле урыннары була икән... Бу чишмәгә кызлы өйләрдән кызлар һәм яшь киленнәр килә икән. Кояш баеган вакытларда чишмә янында чиксез бер чуарлык. Шул нисбәттә бер күңеллелек хасил була. Егетләр йөргән кызларын күбесенчә шушында очратып сөйләшәләр.»

Шодага тагын җиде елдан соң — 1923 елның май-июнь айларында килгәч, драматург көндәлекләре бу якларны һәм шул чор тормышын бигрәк тә тәфсилле сурәтлиләр. «18 нче майда товарный вагонда Шәмәрдән станциясенә килеп төштем. 250 миллион сумга извозчик яллап, Шодага юнәлдем. Извозчик — Яңгыл егете... Юлда Әхмәди Мөхәммәтшин дигән Яңгыл егете очрады. Ул

ачлык елны читкә эш эзләп китеп, хәзер өенә кайтып бара. 19 яшьлек. Яңгылда Әхмәди өйләренә алып кереп, чәй эчереп җибәрде.

Кичке 5 ләрдә, меңнәрчә чакрым юл үтеп, барып житә алу хыял гына булып күренгән Шодага җиттем. Мине элек килгәннәрдә күңелемне сихерләгән кечкенә өйгә урнаштырдылар. Их, күңелле бу бүлмә! Шушындый матур бүлмәдә генә язып ятсаң икән!

Бу урында драматург көндәлекләрен һәм аның Шодадагы музее экспонатларын күздән кичерүдән туктап, бер уйланасы килә: Мирхәйдәр Фәйзи нигә соң «шушындый матур бүлмәдә генә» язып ятмаган? Шоданы шулкадәр үз итүенә, мондагы «саф һава, яхшы ашау, матур күренешләр, тәртипле тормыш, татарлар — һәммәсе»нең саулыгына яхшы тәэсир итүен кат-кат язуына, «мәңге торып калыр идем шушы илләрдә» дип җан авазы белән әйтүенә карамастан, драматург нилектән монда озаграк яшәмәгән, нигә торып калмаган икән? Туган туфрагы иясе әҗәле бу тынгысыз җанны һаман үзенә тартып торганмы, бүтән сәбәпләр булганмы? Мидхәт Миншинның бер шигырендә «таш өстендә гөлләр үстерерлек» дип макталган Балтач-Чепья халкы ни өчен хәзергә кадәр үз арасыннан бер татар язучысы да үстермәгән, Мирхәйдәр Фәйзине дә соңга калып кына үзенеке иткән һәм истәлеген мәңгеләштергән? Драматург үзе 1924 елда ук, «Татарстан җирендәге татар авылларын яратып, мәхәббәт игълан итеп «Мин-сезнеке» дип ышандырырга тырышкан бит, ник үзе дә шул чакта ук халыктан җылы җавап ишетмәгән? Халыктанмы бу, әллә күп очракта читтән китереп куелган һәм бүгенге белән генә яши торган вакытлы җитәкчеләрдәнме? Көндәлекләрендәге үзәк өзгеч сүзләрен чукрак-телсезләргә сөйләгән мәллә ул? Уйлана башласаң, сораулар күбәя шул, бу җәмгыятьтә уйсыз-ваемсызларга гына рәхәт.

Мирхәйдәр Фәйзинең Шодага үзгә бер мәхәббәт белән каравы «күрше Гыйльметдиннең матур кызы Гыйлембану»га да бәйледер. «Бергә уенга барырга вәгъдәсен алып куйдым. Уен вакыты житкәнче башка бер егет алып куймаса ярар иде, дип көенеп йөрдем» — дип яза драматург аның хакында. Гыйльметдиннең йорт урынында хәзер Сания Фәсхетдинова өе икән.

«Гыйлембану Шодадагы көннәремнең таҗы булды. Аның белән бер күрешеп сөйләшү мең рәхәттән рәхәтрәк тоела. Аның матур йөзләрендә нур уйнатып, матур күзләреннән уклар атып, органнарга хас тавыш белән ачык сөйләүләре хатирәмне аллар-гөлләр белән бизәде. Гыйлембану исеме исемә төшкәндә сөенеп, Ибрай исемә төшкәндә көенеп китәм...

Иртәгә китәргә булдым... Китү белән йомшаган күңел бу юлы Ибрайны дошман күрмәде. Ямьле егет бит, Гыйлембану белән икесе пар килгән бит, барыбер миңа бер файда да юк бит, дип уйладым».

Гашыйкларга хас сөенечле дә, көнләшүле дә бу хисләр шул 1923 елда ук Мирхәйдәр Фәйзинең «Сәрвиназ» хикәясенә нигез була. «Сәрвиназ» — просто күргән картина, күргәннәрдән җыеп яздым» — ди ул үзе. Мәхәббәт кыйссасы бер елдан соң да дәвам итә: «...Чишмә янында Гыйлембану белән очраштык. Алларым яктырып китте, куандым. Бик матур итеп исәнләште. Күңелемә нурлар тулды, телемнән гөлләр түгелде».

Гыйлембану белән Хәйдәр (авыл кешеләре арасында «Хәйдәр» генә булып киттем дип, аларның үз итүләренә куанып яза ул) шушы 1924 елдан соң бүтән күрешмиләр. Ә Гыйлембану исеме көндәлекләрне үтеп чыгып, аның әсәрләренә дә күчә:

> Тау астында кызлар су ала,
> Ал чиләген асып, вак-вак басып,
> Гыйлембану килгәч, бу бала
> Алларына бәхет баскан кебек,
> Күккә ашкан кебек куана.

Кыска гомерле авыру драматург һәм аны азга гына булса да бәхетле иткән, җанына җылы, иҗатына илһам биргән Шода кызы Гыйлембану! Милләтебезнең күп кенә кызлары һәм уллары кебек, әлләни бәхет күрмичә генә якты дөньяны кичкән бу ике җанны музей гына азмы-күпме очраштырды.

Авылның элекке укытучысы Кәримә апа Рәшитованың сөйләвенә караганда, Гыйлембану чыннан да бик сылу кыз була. Чем-кара кашлы, ак йөзле, зифа буйлы. Алар Гыйльметдин гаиләсендә җиде бала үсәләр, Гыйлембану икенчесе була. Сөйләүләренчә, бу якларның башка күп авылларындагы кебек, Шодада да элек борынгы мари халкы яшәгән. Алар хәзерге Мари иле якларына күчкәндә, берничә гаилә, ислам динен кабул итеп, Шодада калган. Без белгән Гыйльметдин абзый да шул марилар токымыннан, имеш, Гыйлембануның үзгә бер матурлыгы

бәлки шуннан да килгәндер. Алар Ибраһим белән дә бергә була алмаганнар: каты сүзле Гыйльметдин абзый кызын ирексездән якындагы Әтнә егетенә кияүгә биргән. Хәзер авылда беркеме калмады, диләр. Гыйлембануның Шәрәфетдин, Галимулла, Гарифулла атлы өч энесе дә Бөек Ватан сугышында һәлак була. Шушы авылдан сугышта өчәр кешесе ятып калган өч гаиләнең берсе бу.

Ибраһим да, нәкъ Мирхәйдәр Фәйзи сурәтләгәнчә, Гыйлембануга «икесе пар килгән бик ямьле егет» була. Бай гаиләдән, авылның югары тегермән хуҗасы Ногман улы, Гыйлембану китеп берничә ел узгач, Нөнәгәр кызына өйләнә. Аннары, байлар буларак, авылдан куылалар. Аларның да Шодада якыннары калмаган, истәлекләрен Мирхәйдәр Фәйзи генә менә шушы музейга «алып кайтты».

1913—1914 елның кышында, Фәйзуллиннарның утары булган Җүнәйдә, Мирхәйдәр, гадәтенчә, уеннарда яшьләрнең яңа-яңа җырларына игътибар итә. Хәсән Зәфәров аңа бигрәк тә ошый. «Җырлаучылар эчендә,— дип яза ул көндәлекләренә,— Дүрткүлнең Хәсән Зәфәров исемле унсигез яшьлек ямьле бер егетнең җырлары шундый үзгәмә үтте, шундый көчле тәэсир бирде ки, шундый саф, матур тавышлары бар халык та бәхетле булмаса...»

Әмма шушы сүзләрдән соң сигез дистә ел эчендә дә халыкка, Гыйлембану белән Ибрайларга бәхет килмәде, зар-моңнары гына артты. Татар халкы, үзенең күп меңнәрчә асыл егетләрен, аларга өстәп, сылу кызларын, Гыйлембануларныкы кебек, бер оядан өчәр, дүртәр, бишәр баласын шул бәхет өчен сугышка җибәреп корбан иткәч тә, ил-көндә үз кадерен арттыра алмады. Бөтенләй син күз алдына китермәгән мантыйк һәм кануннар белән яшәвебез, шулай яшәтүләренә юл куйганыбыз өчен кичер безне, якташ! Син безнеке бит, үзең шулай дидең. Ә син сокланган җыр-моңнар, шундый моң иясе булган Галиябану һәм Хәлилләр, каршысында син сәҗдә кылган авыллар татар халкының әлегәчә милләт буларак сакланып калуына бик күп ярдәм иттеләр. Кадерләрен генә беләсе бар!

Ибрайларның йорт урынында аның турында истәлекләр туплаган Кәримә апалар яши. Югарыда әйтелгәнчә, аның бер улы авыл музеена җитәкчелек итә, ә өлкәнрәге, Фәрит атлысы, күмәк хуҗалык үзәге булган Куныр урта мәктәбендә директор. Фәритнең хатыны Наилә ханым — Мирхәйдәр Фәйзи драмаларын бик яратып кат-кат сәхнәгә куйган режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе мәрхүмә Кәшифә Тумашева белән бер авылдан — Нөнәгәрнеке. Ул, язучы Шаһинур Мостафин, шагыйрь Рафаил Газизовлар белән бергә, мәшһүр әдәбият белгечләре Хатип Госманнан, Ибраһим Нуруллиннан, Мөхәммәт Мәһдиевтан сабак алган татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Мирхәйдәр Фәйзи табигатьтән генә түгел, кешеләрнең көйле эшләвеннән дә ниндидер матурлык таба, соклана белә. Шул ягы белән дә гади кешеләр күңеленә якын ул. «Һашимның җир сукалавын карарга бардым. Бик матур итеп эшләп йөри» — дип яза ул 1923 елда Сәетгәрәйнең икенче улы турында. Киткән чакта аның белән аерым хушлаша: «Хуш, Һашим энем, идеядәш энем, хуш, яшь крестьян. Саулыкта күрешик!»

«Кич. Кызларның киндер тукмаклаганын ерактан тыңлап тордым. Авыл өстендә музыка кебек чыңлап хөкем сөргән бу нәфис тавыш җанымны ямьләде» — дип яза шул ук елны. Карагызсана, халкыбызның үткән тормышыннан кайбер тавышларны да хәтерләрдә яңартып музейларда гына сакларлык икән бит. Барысы да үтә, үзгәрә, буыннар алмашынган саен, ядкярләр дә югала. Әмма югалган мирас белән тарихыбызны бай итү мөмкин түгел — һәммәсен бөртекләп җыярга, сакларга һәм өйрәнергә, яңа буыннарга күрсәтергә кирәк. Килик әле музейларга, халкыбызның еракта калган буын өзекләрен шул күперләр белән тоташтырып карыйк әле — үткәнебезне, өлкәннәрне, кем балалары булуыбызны яхшырак аңлый башларбыз, асылыбызга кайту юлын табарбыз, бәлки.

Чепьяның утыз елдан артык эшләп килгән «Халыклар дуслыгы» музее бер яктан бик бәхетле булды: шушы елларның бөтенесендә бу мәдәни мирас йортына Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, тынгысыз җан Гарифҗан Гали улы Галиев тәмам бирелеп җитәкчелек итә. Ә бит музей төзү эше анда да бик гадидән башланган иде. Чепья мәктәбе элек бөтен тирә-якка бердәнбер булганга, анда 42 авылдан килгән балалар укый иде. Тарих укытучысы Гарифҗан Гали улының үз дәресләрендә күрсәтмәлек итеп файдалану өчен туплаган борынгы акчалары һәм тагын ниндидер истәлекле әйберләре бар иде инде. Балалар аңдыйны мавыгып карыйлар, дәрес тә җанланып китә. Туган якны өйрәнү түгәрәге дә Гарифҗан абыйлары җитәкчелегендә эшли, үткән тормышның истәлекләре анда да кулланыла. Кыскасы, хәзер тугыз мең берәмлекне тәшкил иткән, авыл музейлары арасында иң байлардан саналган экспонатларның баш-

тагы унсигез данәсен Гарифҗан Гали улы үзе алып килде. Инде бу мәдәни мирасны 460 мең кеше карады. Алар арасында 47 өлкә һәм шәһәр, АКШ, Куба, Чехословакия, Польша, Алмания, Венгрия, Төркия, Кытай, Вьетнам, Корея, Монголия кунаклары бар. Әле дә ел саен 150—300 экспонат өстәлеп тора, елга 10—12 мең кеше килә. Кунакларның музей турында фикер-тәэсирләре генә дә инде 12 том булды. Алар дөнья халыкларының 23 телендә язылган.

Өч дистә ел элек иске мәктәпнең бер бүлмәсендә үз эшен башлап җибәргән музей бик тиз арада киңәеп, чикләренә сыймый башлады. Экспонатлар тиздән мәктәпнең спорт залын да биләп алдылар. Бу вакытта мирас йортының һәвәскәр директоры Гарифҗан Галиев кенә түгел, күп укучылар да музей белән шундый мавыктылар, бернинди каршы фикерләр һәм киртәләр белән дә аларны тыеп тору мөмкин түгел иде инде.

Галиевның эш тәҗрибәсе җитәкчеләргә дә музейлы районның нәрсә икәнен, бүтәннәрдән үзгәлеген тиз төшендерде. Кайдан, нинди кунаклар килсә дә, алып барып күрсәтерлек истәлекле урын булу начармыни? Беренче секретарь Рафик Фәесханов андый чакларда музейны бигрәк тә үз итте, мирас йортына махсус бина кирәклеген дә иң элек ул аңлады. Беренче нигез ташын 1978 елда салдылар, 1982 елның азагында ике катлы яңа музейны ачып керделәр. Аны төзүдә ничек эшләүләрен ул чактагы мәктәп балалары кызык һәм гыйбрәт итеп әле дә сөйлиләр. Бер ташы да үзеннән-үзе салынмады, ә акча мондый төзелешләргә ул елларда да бик аз бирелә иде. Иске урындагы экспонатларны Чепья уртасындагы яңа бинага, ярты авыл аша узып, бөтенесен берәм-берәм кулдан ташыдылар, шуңа күрә берсе дә ватылмады, сынмады, таушалмады һәм югалмады. Аларны зур-зур биш бүлмәгә урнаштырдылар. Һәр залда, темасына карап, биш-алты бүлек. Тик менә монысы инде тагын бер кыенлык. Гаҗәп хәл: унбиш еллар элек кенә бик иркен булып тоелган бина хәзер экспонатларны сыйдырмый башлады, әллә ничә бүлекне бер залга урнаштырырга туры килде, беразы иске складларда, тамашачылар күзеннән читтә ята. Шуңа күрә Гарифҗан Галиев 1996 елның көзендә район хакимияте башлыгы Марат Әхмәтов янына яңа үтенеч белән керде: музейга янкорма төзетеп, тагын дүрт зал арттырмыйча булмый.

— Иң элек чиркәүне түбә астына кертик инде, Гарифҗан Галиевич, шуннан соң уйлашырбыз,— диде хакимият башлыгы.

Чиркәүне музей янына, искесе янәшәсенә бик матур итеп салалар. Анысы да кирәк: районда мәчетләр күбәйде, халыкның уннан берен тәшкил итүче удмуртлар гыйбадәтханәсез иде әле. Һаман шул акчасызлык кулны тота.

Чепьяда музей оештыру Октябрь революциясенең 50 еллыгына әзерлек чараларына кергән иде. Һәм шәп эшне шундый тарихи көннәргә туры китерә торган чор иде ул. Әмма Гарифҗан Галиевның рәсми идеологиягә артык бирелми торган үзенчәлекле холкы ярдәм иттеме, әллә киләчәкне сиземләве көчле булдымы — мәктәп тарихчысы шул елларда да музейны «данлы партия казанышлары»н күрсәтү юлыннан алып китмәде һәм шуның белән бик күпне отты. Ел ярым элек Балтач музейлары экспонатларын соклану белән карап йөргәч, Татарстан җөмһүриятенең Аксакаллар Шурасы Рәисе, Кол Гали исемендәге халыкара бүләк иясе Рәфигулла Хәмидуллин да бу хәлгә игътибар итте:

— Миңа бигрәк тә тарихыбызның заманга, вакытлы идеологиягә яраклаштырылмыйча, нәкъ булганынча яктыртылуы ошады,— диде ул.

Башта бөтен табылдыкны бер витринага туплаганнар иде. Күбәя башлагач, аларны бүлекләргә аерып урнаштыру зарурлыгы алга килеп басты. Эш тәртибен Малмыж музеена барып өйрәнделәр. Үзем генә башкарып чыгасы эш түгел дип, Гарифҗан абыйлары анда зур бер төркем укучыларны да алып барды. Эзләнү экспедицияләренә дә бергәләп йөрделәр һәм күп вакытта гаҗәп табышлар белән кайттылар. Һәр табылдык — туган як тарихын өйрәнү-ачыклауда искиткеч кыйммәтле чыганак. Әнә, Чепьядан 25 чакрымдагы Гоньба урманыннан табылган снаряд. Аны корылган хәлендә тапканнар. Снарядны Вятка елгасының теге ягыннан атканнардыр, дип фараз ителә. Гражданнар сугышы, үзенең бөтен мәхшәре белән, менә кайларга кадәр килеп җиткән. Бу хәл бүтән истәлекләр белән дә раслана. Колчак армиясе шул якларга килеп җиткәч, ул чакта Малмыж өязенә кергән Яңгул волосте үзәгендә хәрби комиссариат төзелгән. Комиссар итеп шул авылдан Шәйхетдин Габдерәшитовны куйганнар. Ул, авылларда йөреп, акларга каршы сугышчылар туплап җибәрү белән шөгыльләнгән.

Музейның беренче экспонатлары арасындагы менә бу таш балта да үз вакытында зур кызыксыну һәм бәхәсләр тудырган иде. Балта 1967 елда Тагашур авылы янындагы елгадан табылган, музейга укучы Коля Раимов китергән. Башта аны чүкеч дип уйладылар. Казан дәүләт музееның археология бүлегеннән килгән

белгечләр, аның бик борынгы бабаларыбыз тарафыннан ясалган таш балта булуын әйткәннәр. Андый балталар моннан 3700—4200 еллар элек кулланылган, дип фараз ителә икән. Димәк, бу як җирләре таш дәвер кешеләре тарафыннан ук үзләштерелгән булган инде. Ә без шул озын тарихның күпмесен генә беләбез?

Музейда сугыш «һөнәре»нә, хәрби хезмәткә бәйле истәлек-ядкярләр җыелмасы бигрәк тә бай. Чөнки катлаулы үткәнебезнең зур өлеше сугышлар тарихыннан тора. Монда — богаулар һәм уннарча төрдәге ату кораллары, хәнҗәр һәм кылычлар, 1853 елда коелган төрек кылычы, 1855 елгы француз шпагасы. Андыйларны йөз ел буена саклаган хуҗаларыннан бернинди түләүсез гап-гади авыл музеена китерү өчен Гарифҗан Гали улы нинди ышандыру көченә ия булды икән, дип тә уйлап куясың. Иң мөһиме — музейның киләчәгенә, бәһа биргесез мирасыбызның менә шушында гына әйбәт сакланачагына үзе дә ихластан инангандыр, башкаларны да инандыра алгандыр ул. Югыйсә, ярдәм итәргә атлыгып торучылар шулкадәр күп булыр идеме?

Халкыбызның Бөек Ватан сугышына бәйле батырлык һәм фаҗига тарихын яктырту музей эшчәнлегендә бик мөһим урынны били. Аның төзелүенә ун ел тулган чорда илебез Бөек Җиңүнең утыз еллыгын бәйрәм итте, шуннан бирле монда ике юбилей бергә үрелеп бара.

Иң элек мәктәпкә укучылары йөри торган һәр авылның кульязма «Хәтер китабы»н эшләп чыктылар. Ә Чепьяның үзеннән китеп яу кырында калган алтмышлап кешенең фоторәсеме тупланды. Татарстанның әле басылып чыга торган «Хәтер» китабы иң элек Чепьядагы кебек музейларда, тынгысыз эзтабарлар төзегән альбомнарда, шул темага язучыларның куен дәфтәрләрендә туды. Сугышның үзен, андагы коточкыч авыр җиңүне хәзер, әллә нинди күзлекләр аша арап, төрлечә бәяләргә омтылучылар булса да, ул көннәр истәлекләренең бәһасе беркайчан югалмаячак. Әмма бу истәлекләр бүген яши торган һәм киләчәктә яшисе җирдәшләргә бер кисәтү дә бит әле. Хәрби бүлектә йөргәндә, авыр тәэсирләрдән сискәнеп, уйлап куясың: менә хәзер ниндидер могҗиза булыр да, монда тупланган ату һәм шартлау кораллары телгә килер, солдат котелокларыннан аш пары күтәрелә башлар, Каһарман-шәһәрләрнең изге туфраклары салынган янчыклардан кан саркып чыгар кебек. Сугыш кырларында ятып калган якташларыбыз рәсемнәренең җанлануы, фронттан язган хатларның сөйли башлавы күз алдына килә. Кайсыдыр спектакльдән, ирен сугышта югалткан тол хатын сүзләре күңелдә янара: «Безнең никадәр сагынуыбызны белсәгез, каберләрегездән торып кайтыр идегез!» Кайта калсалар, йә хатлары җанланса, нәрсә әйтерләр иде икән? Тормышыбызга күз салырлар да, сез бәхетле яшәсен өчен без яшьли бу гүзәл җирдән киттек, Аллага һәм язмышыбызга шөкер, корбаннар юкка булмаган икән, диярләрме, шулай әйтергә урын бармы? Бәлки җирнеңме, күкнеңме кайсыдыр читеннән ишетелгән билгесез гөрелтене тыңларлар да, мәгълүм җырдагыча, «әллә күкрәү, әллә үткән сугышлар кайтавазы» дип шомланырлар, «Кешелек, без бу Җирнең соңгы корбаннары түгелмени соң әле?» дип аваз салырлар? Әле кайсыдыр хөкүмәтләрдә һәм парламентларда элеккечә сугыш белән яныйлар, һич югында, читләргә шом салу өчен, үз кардәшләрен дөмбәсләләр, һаман кеше каны коела, гомерләр киселә. Кайчандыр бу илгә Җиңү китергән шәһитләр каберләренә дә тынгылык юк: җирләр зур хәвеф алдындагыдай дерелдәп тора.

«Дерелдәп тора!» Бу сүзләрне кайдан күчердем соң әле? Шода авылының Хәйретдин солдат хатыннан түгелме? «Кадерле хәләлем Нәгыймәгә безки Хәйретдиннән сагынычлы сәламнәремне сөйләп, исән-сау тазалык белән дошманнарны җиңеп, исәнлектә бергә кавышуны теләп калам. Шулай ук кызларым Мәүлия белән Зөлхиягә сагынып вә бик саргаеп сәламнәремне сөйләп калам. Үземнең хәл-әхвәл белергә теләсәгез, әлегә дошман белән Мәскәү ягында бик каты сугышабыз. Оренбургтан чыгып китеп, Мәскәү урамыннан полный корал белән җәяүләп үттек. Орудие тавышларыннан бөтен тирә-як дерелдәп тора. Без шулай сугышып Волоколамский дигән городны алдык. Мин үзем төнге разведкага йөрим.

Дошманны җиңеп исәнлектә кайтуны теләп калучы хәләлең Хәйретдин».

Төрле уйлар кузгата, күз алдына төрле күренешләр китерә торган мондый хатлар Чепья музеенда байтак.


Җиңүнең егерме еллыгы чорларында «Комсомолец Удмуртии» газетасында журналист В. Иванов имзасы белән кызыклы бер мәкалә басыла. Анда сөйләгәнчә, мәкалә авторы Алма-Ата язучысы Сергей Мартьяновның «Беренче залплар» исемле китабыннан Брестта фашистларның беренче һөҗүменә эләккән сугышчылар арасында бер удмурт та булганлыгын белә һәм аның кем булуы белән

кызыксына башлый. Чик буе гаскәрләренең Үзәк архивы аңа бу кешенең 1919 елда туган, 1939 елда Совет армиясенә алынган Александр Егорович Алешкин булуын хәбәр итә. Егет ул чактагы Чепья районының Иске Кәшкәт авылыннан булып чыга. Мәкаләдә райондашыбыз хезмәт иткән икенче погранзастава начальнигы Горбунов истәлекләре дә китерелә. Командирның сөйләвенә караганда, Саша бик тәртипле сугышчы, хәрби һәм политик әзерлек отличнигы була. Язмада шуны раслый торган эпизод та бар. Сугышның беренче иң авыр көне аның гомерен кисә. Музейдагы күп меңләгән истәлекнең һәрберсе хакында, әнә шулай, бик күпне сөйләргә булыр иде. Шушындый бай ядкярләр хәзинәсен туплаучы һәм аны бүгенге хәленә житкереп саклаучы, халык хәтерен уятучы Гарифжан Гали улы Галиевнын, аңа булышучыларның искиткеч зур һәм изге гамәленә киләчәк буыннар да сокланыр әле.

Районда иң өлкәне булган Чепья музее карадуганлылар өчен дә, шодалыларга да үзләрендә мәдәни мирас йорты төзүдә матур үрнәк булып хезмәт итте. Инде яңа дәвамчылары булырга тора: Нөнәгәрнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Дания Кәлимуллина үзләрендә яңа музей оештырып ачу хәстәренә керешге. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә Габдулла Тукай бүләген алган ике зур шәхеснең гомер башы шушы авылга килеп тоташа: Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер Равил Тумашевның әнисе һәм язучы Ибраһим Салаховның әтисе — Нөнәгәрнекеләр. Бу авыл, алардан башка да, күренекле шәхесләрне илгә күп биргән: колхозчы-ударникларның беренче Бөтенсоюз съезды делегаты, беренче чакырылыш СССР Верховный Советы Депутаты, районда беренче Хезмәт Кызыл байрагы ордены иясе, комсомолның ике съезд делегатлары, партия өлкә комитетының икенче секретаре... һәркайсының катлаулы тормыш юлы музей залларының зур стендларында яктыртуны сорап тора. Дания ханымга бу изге эшендә Алла һәм хакимнәр ярдәм итә күрсеннәр!

Быел, 1997 елның мартында, Ырынбур якларында «Галиябану»ның беренче тапкыр сәхнәгә куелуына йөз ел тулды. Исән булса, Нөнәгәр кызы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашевага 1997 ел азагында 100 яшь тулыр иде. Шушы истәлекле көннәргә туры китереп, 1997—1998 еллар кышында мәдәният бүлеге районда сәнгать фестивале үткәрергә ниятли. Бу чарага Мәдәният министрлыгы да якыннан катнашса, фестивальгә күрше-тирә районнардан да иң көчле драма коллективлары чакырылса, халык сәнгатен җанландыруда, мәдәни мирасны баетуда, якташларыбыз истәлеген яд итүдә матур эш булыр иде.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.



# МИРГАЗИЯН ЮНЫС

# ЮГАЛГАН КЫЙБЛАНЫ ТАБУ

Әйе, бәлки инде кабатлыйм да булса кирәк... Ләкин дөресе шул: бүгенге көн әдәбиятының иң көчле коралы булган очерк-эссе тиз арада гына үз позициясен башка жанрларга бирмәс әле. Чөнки хикәя, повесть, роман һәм шигърият әсәрләре — барысы да публицистика рухында яңгырый башлады. Сәбәбе аңлашыла. Болгавырлык, Рәсәй империясенең һәм империягә житмеш ел җан өреп торган социалистик системаның җимерелеп төшүе, ул хәрабә кисәкләренең адәм балалары язмышлары өстенә авып төшеп, аларны сыта, имгәтә һәм кыямәт куркынычлары тудыра башлавы шушы иң оператив, укучы белән кара-каршы торып сөйләшү мөмкинлеге биргән жанрны көчәйтте. Ләкин күпсанлы Язучылар берлеге әгъзаларыннан бер дистә, юк, биш-алты әдип кенә публицистика жанрын күтәрә аламы икән?

Ә инде хикәягә килсәк, хикәя язуы чиктән тыш авыр. Әйтик, синең кулыңа бер патрон тоттырып ауга җибәрделәр ди. Шул бер патрон белән син аю, янсә бүре алып кайта аласыңмы? Бик оста, тәҗрибәле аучы гына шундый катлаулы эшне башкарып чыга ала торгандыр! Нәкъ шуңа күрә дә соңгы елларда роман язучылар үрчеп китте бит. Романчының кулында патроннар күп, аның пушкасы, пулеметы, кирәк чагында танк һәм самолетлары да бар. Куллан гына! Ә хикәя язуы авыр. Публицистик мәкалә язуы исә — аннан да авыррак. Публицистика жанры белән эш иткәндә укучының күзенә төтен җибәрүе дә кыен. Беренчедән, телисеңме-юкмы, син үзеңнең карашыңны ак кәгазьгә чыгарып салып, укучыга күрсәтергә тиешсең. Икенчедән, бу жанрда эшләү өчен белем кирәк. Юк, диплом түгел, фәнни дәрәҗә дә түгел, чын мәгълүмат, эрудиция, акның нилектән ак, караның ни сәбәпле кара икәнлеген укучыга исбат итеп күрсәтә алу сәләте кирәк. Ниһаять, публицистика жанрында эшләүче кешегә кирәкле өченче сыйфатка килеп җиттек: мөстәкыйль фикер йөртә белү, философия өлкәсендә хәбәрдарлык һәм мантыйк сукмагыннан тайпылмыйча эш итү.

Бүгенге татар публицистикасының алгы сафында кемнәр әйдәп бара икән соң? Әйдәп баручыларның да иң алгы сафында инде менә шактый озак Айдар Хәлим атлый. Аның быел басылып чыккан ике китабын: «Гомеремнең ун көне»н һәм урыс телендә язылган «Бу җиңелмәс чәчән»не генә алыгыз. Ничек өлгерә?! Күпме көч түгәргә кирәк ул материалларны туплау, сайлап алу, анализ ясау өчен. «Гомеремнең ун көне» бүгенге көндәге иң катлаулы, иң кайнар проблемаларны күтәрә. Көндәлекләр, документлар, сәясәтчеләргә, хакимият дилбегәсен тотучыларга, аларның конкрет эшләренә, татар милләтенең язмышына кагылышлы вакыйгаларга бәя бирү... Бу китапның киләчәктә елъязма (летопись) вазифасын башкарачагы шиксез һәм мондый китап язган авторның беркайчан да башыннан сыйпамыйлар. Дөрес, соңгы елларда фаш итүләргә каршы матбугатта бәхәсләшү, инкяр итү мәкаләләре тулысынча диярлек юкка чыкты. Аның каравы үч алу, авторын карангыда саклап торып калак сөяге астына агулы без кадау гадәти гамәлгә кереп бара. Хәер, авторны физик яктан юкка чыгармыйлар. Сталин-Берия чорының бу алымы, Аллага шөкер, әлегә кулланылмый. Ләкин көрәшчедән «халык дошманы» ясау, аны куркыныч, әшәке әрәк итеп җәмгыятькә күрсәтү әле һаман сакланып килә. «Ул — экстремист», «ул мижнатсионалыный

кәнфликет ясап йөри»... Бу очракта безнең татар бик тә курка. Шуннан соң андый шәхеснең битенә дегет ягу берни тормый.

Совет чорында шәхси дуслыкны бергәләп урлашу ныгытса, илдәге «халыклар дуслыгын» да кырым татарларын «эшкәрткән» ысулда, хакимият түрәләренең олтаннарын ялату юлы белән ныгыта килделәр. Мескен татар халкы да, кызганычка каршы, карагруһларның терсәктән канга баткан кулларын ялауны әле һаман «мижнәтсиәнәльнәй кәнфликет»тән котылу дип аңлап йөри.

Менә шушындый шартларда Айдар Хәлим ишеләрне киң катлам җәмгыятькә: «Сез мондый кешедән сак булыгыз, андыйларның кылган гамәлләре, әйткән сүзләре халыкка бик тә зур, бик тә куркыныч фаҗигалар китерүе мөмкин»,— дип әйтеп, аларга карата дошманлык хисе тудыру гаҗәп җиңел. Кайвакыт куркып куясың: Айдар ишеләр ничек шушы көнгә кадәр иректә йөриләр? Соң бит андыйларның урыннары... Әйе, андыйларның тәкъдирләре совет чорында нидән гыйбарәт икәнлеген аңлатып торуның кирәге юктыр дип уйлыйм. Татарстанда да, әнә, колхозлар исән, урам исемнәре, ритуаллар, эш оештыру ысулы әлегә тулысынча элеккечә диярлек. Ә Айдар Хәлим шикелле — кара көчләргә турыдантуры каршы чыгучыларның — яралары йөрәкләрендә. Алардагы кан сауган җирләр тыштан күренми. Әнә, Рәшит Әхмәтҗанов... Чәчәннәргә аткан беренче пуля аның йөрәген тишеп чыкты!

Публицистика белән мавыгуның тагын бер куркыныч ягы бар. Бусы үз ирегең белән үзеңне кыйнатырга дошманнар әзерләүдән дә куркынычрак афәт — әкренләп әдәби әсәр язу сәләтеңне югалту. Чөнки публицист вакыйгаларны, яшәешне публицистика фикере белән үлчәп, анализ аша сурәтли. Әдәби әсәр язучы исә вакыйгаларны, анда катнашучы шәхесләрне укучыга сурәтле (художественный образ) тасвирлау аша күрсәтә. Әдәби публицистика белән мавыгу әдип күңелендәге шул сурәтле күрүне әкренләп вата һәм әдип әкренләп әдәби әсәр язу сәләтен югалтырга мөмкин.

Айдар Хәлимнең «Кыйбла» исемле хикәясе («Казан утлары», 8 сан, 1996 ел) мине иң беренче чиратта шул ягы белән куандырды: публицистика белән мавыгу татар халкының фидакяр улын әдип һәм шагыйрь буларак тагын да өскәрәк күтәреп җибәргән икән. «Кыйбла» хикәясе татар әдәбиятында лаеклы урын биләп торачак.

«Фатих абый Хөсни истәлегенә»,— дип багышлаган Айдар бу хикәясен. Шушы җөмләне укыгач, күңел йомшарып китте. Без бит бүген татар әдәбиятын «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» кебек әсәрләрдән тыш күз алдына да китерә алмыйбыз! Белмим, сез бәлки башкача уйлый торгансыздыр? Фатих Хөсни иҗаты, аның әсәрләрендәге туган телгә булган чын, кайнар мәхәббәттән тыш бүгенге көндә без Мөхәммәт Мәһдиевне дә, Марсель Галиевне дә, Батулланы, Гамил Афзалны, Рафаил Төхвәтуллинны һәм дистәгә якын туган телебезнең сафлыгын саклаучыларның барлыгын да белмәс идек. Хәтта Фәнзаман Баттал шикелле, һәр әдәбиятта гасырга бер тапкыр гына килеп китә торган, иҗаты өчен үзе исән чагында тукмалудан, тапталудан башка бернинди игелек күрмичә, газап «гонорары» өчен генә эшләүче әдипнең дә, остазы итеп Фатих Хөснине күрәм мин.

«Кыйбла» — кыска хикәя. Журналның 22 битенә сыйган да беткән. Укый башлап, аның эчтәлеге белән танышкач күрәсең: Айдар Хәлим шушы кыска әсәренә төрки (ул аларны «түрекләр» дип атый) халыкларының мең еллык язмышларын сыйдыра алган! Тын океан ярларыннан алып Урта диңгез ярларына кадәр, Чукоткадан Беринг бугазы аша Америка материгындагы Юкатан ярыматавына хәтле барып җиткән төркиләрнең агылышларын, берләшү-таркалуларын, Тәре походларын, яңа империяләр барлыкка килгәндә, шуларның аяусыз кырып ташлаулары аркасында юкка чыга килгән татар язмышын — барысын, барысын хикәя авторы шушы кечкенә генә күләмгә сыйдыра алган.

Айдар Хәлимнең бу хикәясе Нурихан Фәттахның узган елны (1995) басылып чыккан «Кичү» исемле китабына кергән «Кырык дүртнең май аенда» исемле повесте белән аваздаш, эчтәлеге ягыннан да шактый охшашлы. Нурихан Фәттах татар милләтенең фаҗигасын аерым бер шәхес язмышы аша ачып күрсәтсә, Айдар Хәлим милли фаҗиганы — төрле юллар, төрле алымнар белән күп гасырлар дәвамында чынга ашырылып килгән төркиләр геноцидын — бер тезмәгә беркетеп, ачып сала алган. Хикәянең эчке структурасы (умыртка сөяге) менә ничек оештырылган. Авторның үзенә сүз бирик:

«...Кайчандыр кешелек таңында Алты Ай һәм Урхан-Йәнәсәй киңлекләреннән һау-һаулап чыгып, бормаланып аккан Иртеш һәм Уралтаулар тезмәсе аша Европага ашкан, үзара ызгышта халыкларның бөек күченешен барлыкка китер-

гән һуннар, шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй кыяларында «Туган йирим — мәңгү бар!» дип ташны уеп, кешелеккә бөек ядкарь калдырган түрекләр, гасырлар аша шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй бишегеннән ур-ра-а-лап чыгып, ярты дөньяны уратып, биләп алып, тарихы яңа гына борынлап килгән мәҗүси милләтләр һәм шивәләргә иман һәм дәүләтчелек бүләк иткән түрек-мангуллар Идел дәрьясы һәм Хәзәр, Урта диңгез буйларындагы шәһәрләр, Атлантидалары Фәст дисбеләре белән су астына киткән түрекләр, Эгей ярларына, кыйтгаларның бөек чукындыручылары — Рум башкисәрләре каршына басып, «Әһә-һә-һәй!» кычкырып, мондый көчләү, асу-кисүләргә чик куйган, кайчандыр шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй тундыраларыннан Чукыт ярыматавы аша Америка лабылыкларына үтеп әстәк, әнкә һәм майя мәдәниятләрен тудырган Ату-Алын варислары түрек-татарлар, кайдадыр Океания утрауларында төтенләп утырган Кракатау янартауларында яңа дәүләтләр барлыкка китереп, үзләре дәүләтсез калса да, юкка чыкмаган түрек-татар кавеменең ике гөнаһсыз баласы, ике чакматаш йолдызы — Гарифулла карт һәм Өммегөлсем карчык, һәркайсы үз уен уйлап, Әкчин станцасына китеп бара...»

Татарчасын белмим, урысча мондый озын, чиктән тыш озын җөмлә «период» дип атала һәм аны гаҗәп катлаулы, мөһим фикерләрне укучыга җиткерер өчен кулланалар. Лев Гумилев, Грум Гржимайло, Әҗи Морат, Нурихан Фәттах, Мюллер һәм башка ориенталистларның фәнни эшләренең сөземтәсе итеп алынган шушы җөмләләрдән соң Айдар Хәлим бүлекне тәмамлый да, яңа бүлекне менә нинди җөмләләрдән башлап җибәрә:

«СССР да таркалды. Нибары өч кеше тарката алгач, димәк, аның үзен дә өч кенә кеше оештырган булмады микән?» Шушы ике кыска җөмлә күп гасырларга сузылган Евразия (галимнәр «евразиячелек» тәгълиматын мыскыл итәргә теләгән урыннарда «Евразия» урынына «Азиопа» сүзен дә кулланганыйлар) тарихын СССР дип аталган империягә тоташтырылды. Ә СССР чорында эшләнгән җинаятьләрне исә кечкенә хикәягә түгел, күп томлык романнарга да сыйдырып бетерерлек түгел. «Кыйбла»ның авторы укучыны Бәләбәй-Бөгелмә калкулыкларына алып килә дә, Шатман авылына туктата. Авылда яшәүчеләрнең тарихларына кагылсаң да ерып чыгуы ифрат авыр булыр иде. Автор безне Садретдин мәзиннең гаиләсенә җитәкләп алып килә.

Утызынчы еллар. Күмәкләшү чоры. Сыйнфый дошманнарны тар-мар иткән, мәчет манараларын кискән, динне һәм Аллаһы Тәгаләне юкка чыгарып, дин урынына коммунистик идеологияне куйган, Алла урынына Бөек Юлбашчыга табынуны маузер ярдәмендә халыкка керткән чор. «Кыйбла»да бу эшне Өтәләү Зариф һәм Ак Керфек Сөнгатуллалар башкара. Мәзин хатынының көмеш чулпыларын толымнары белән кисеп алып, үзен каравыл йортына ябып куялар. Садретдин мәзиннең караңгы төндә йорт-җирен, мал-туарын ташлап калдырып үз авылыннан качуы гаҗәп көчле, җаныңны тетрәндерерлек итеп бирелгән. «Әтисе мөгезле эре терлек, кәҗә малы һәм бәрәннәргә кагылмады. Дүрт баш сарыкның авызларын бисмилла тастымаллары белән уратып, мекердәтмичә генә тыннары каткан алмагачлар арасыннан мунча артына сөйрәттереп, берсе арты берсен чала, Гарифулла исә туный торды»...

«— Тамакларына кадалсын, бәдбәхетләрнең! — Садретдин мәзин хатынын утлы караш белән көйдереп алды.— Качып китсәң дә, чәчеп кит дигән борынгылар».

Бу гаилә Ырумбурга, аннан казакъ далаларына кача. Сугыш та юк бит әле, яу да килмәгән. Ләкин колхозлашу чорының куркыныч афәтеннән кача Садретдин мәзин гаиләсе! Казакъ далаларында гөбән чиренә (чума эпидемиясе) юлыгалар. Зур, тату бер гаиләдән мәзин малае Гарифулла белән килене Өммегөлсем генә исән кала. Алар һаман еракка — Урта Азиянең кайнар кочагына, афәт, ачлык килгән чакларда татарларның даими качып киту төбәкләренә — юл тоталар. Сугыш ир белән хатынны да аера. Яңа туган баласын күтәреп туган ягына кайтырга чыккан Өммегөлсем бер ялгызы гына туган җиренә кайтып җитә ала. Юлда үлгән баласы Тансыкны Әкчин исемле тимер юл станциясендә җирләп китәргә мәҗбүр була мескен хатын. Аның ире Гарифулла, икенче бөтендөнья сугышының барлык михнәтләрен, яралануларны, әсир төшүне, концлагерьларны, «смерш» тырнагына эләгүләрнең барысын да татып, туган җиренә әйләнеп кайта... Сугыштан соңгы еллар да сыйган кыска хикәягә. Сыйган, ләкин әсәрнең эчтәлеген сөйли башлау белән аның тылсымлы тәэсире, тойгыларга бәреп торган кайнарлыгы сүрелә, юкка чыга.

Айдар Хәлимнең «Кыйбла»сын укыганчы мин: «революция елларын, колхозлашу чорын татар әдәбияты инде шактый яктыртты, без хәзер ул заманның

фаҗигасын, милләткә һәм шәхесләргә китергән чиксез зур зыяннарын аңлыйбыз» дип ышана идем. Әмма шушы бер кечкенә хикәя безгә, татарларга һәм гомумән, барлык төрки халыкларга карата оештырылган тарихи геноцидларның тоташ бер ташкын булуын, аның күп гасырлар буена дәвам итүен ачыклады.

Әдәбиятта мәңгелек темалар бар. Мәхәббәт, бәхеткә омтылу, хакыйкать вә ялган, шәхес һәм җәмгыять — менә бу темаларга туктаусыз язып торырга була һәм һәр буын бу проблемаларны өр-яңадан, үзенчә, яшәешнең яңа туган шартлары фонында күрсәтергә омтыла. Егерменче гасырның утызынчы еллары турында — СССР дигән илдә социализм төзегәндә гасырлар буе камилләшеп, буыннан-буынга тапшырылып килгән гореф-гадәтләрне, яшәү ысулларын җимереп, социаль катламнарның күбесен тулысынча кырып бетерүләр турында да — һәр яңа буын үз сүзен әйтергә, аңа үз бәясен бирергә, аны үзенчә сурәтләп күрсәтергә тиеш дип уйлыйм мин. Әдәбиятта күп тапкырлар сурәтләнгән темага язылган андый әсәрләр татар язучыларына яңа бурычлар йөкли һәм яңа мөмкинлекләр ача бит.

Ә Айдар Хәлимне «Кыйбла»ның уңышлары белән котлыйсы килә. Бу хикәя татар әдәбиятында лаеклы урында калачак. Әдәбиятыбызда шушы хикәягә тиң әсәрләр туып торсын иде әле.

*Мәскәү.*
*1996 ел, декабрь.*

# Алдан хәбәр итәбез!

**Хөрмәтле укучылар!**

**Менә сез әле генә язучы Миргазиян Юнысның кульязмасы белән танышып чыктыгыз. Көндәлек матбугат битләрендә кайнар хисле, фәлсәфи-публицистик язмалары һәм әдәби әсәрләре белән еш күренә килгән бу әдип — безнең даими авторыбыз.**

**Аның тормышыннан кызыклы бер үзгәреш, мәгълүмат килеп иреште безгә: Миргазиян Юныс әле күптән түгел Әлмәт якларына әйләнеп кайткан икән. Торырга, яшәргә, иҗат итәргә. Ул бу юлы да буш кул белән кайтмаган, «Юлда уйланулар»ның өченче китабын — «Соңгы сулыш» исемле әсәрен юллаган. Анда безгә таныш татар егете — диңгезче Габдрахманның өлкәнрәк яшьтә дә диңгезгә кайнар омтылышы, еракеракларга кылган сәяхәтләр тәэсире, чит илләр мозаикасы бәян ителә.**

**Автор элекке СССР һәм бүгенге Россия тормышындагы империячел сәясәтне, милли проблемаларның берничек тә хәл ителмәве турында ачынып яза, үзенең күпьеллык күзәтүләрен уртаклаша.**

# НИ ӨЧЕН РОССИЯ АЛЯСКАДАН КОЛАК КАККАН?

«Казан утлары» журналының 1996 елгы 6 нчы санында Россия Дәүләт гуманитар университеты профессоры Әгъдәс ага Борһанов белән язучы Әхәт Мушинскийның кызыклы әңгәмәсе бирелгән иде. «Кая бара бу Россия?» дип атала иде ул әңгәмә. Әгъдәс ага Борһанов, тарихчы галим буларак, Россиянең һәм үткәнен, һәм бүгенгесен өйрәнеп-тикшереп, аның киләчәгенә дә күз сала. Бу илнең, алга таба да «бердәм һәм бүленмәс бөек Россия» шигаре белән барса, үлемгә йөз тотачагына ишарәли. Хәзерге идарәче даирәдәге түрәләрнең шуны аңлый алмаулары гына гаҗәп.

Шул уңайдан бер тарихи вакыйга искә төшә. 1867 елны урыс патшасы тота да Аляскаңы американнарга 7,2 млн долларга сатып җибәрә. Әй тиргиләр тегене, әй каргыйлар! Әле булса партсовноменклатурачы түрәләр дә, янәмәсе, авыллардагы хәерчелектә яшәүче иң томана карт-корылары да патшаның ул «гөнаһын» кичерә алмыйлар, имеш...

Кайчандыр Новгород-Псков сазлыкларында оешкан Русь дәүләте, ничәмәничә гасырлар дәвамында башка халыкларның җирләрен яулап алып, үзләрен буйсындырып, үләт чире шикелле һаман да киңәя-җәелә торгач, ниһаять, «дөньяның читенә» барып чыга — океан-диңгезләргә барып терәлә. Урыс баскынчылары Төньякның карлы-бозлы салкын суларында бик аяк җылытып утыра алмыйлар, җирле эскимослардан кайсысыдыр аларга «дөньяның чите» әле монда гына бетмәгәнен, диңгез бугазы аша 90 чакрымнар ераклыкта янә коры җир барлыгын, анда да эскимослар яшәгәнлеген әйткән булса кирәк, урыслар,— аларны урыс тарихы «яңа җирләр ачучы каһарманнар» дип атый, Америка кыйтгасындагы Аляска ярымутравына да барып чыгалар. Җирле эскимос халкының бирелмәгәннәрен үтереп-суеп, бирелгәннәренә ялтыравык тәтиләр өләшеп, аракы эчертеп-исертеп, Аляскаңы «бөек Русь җире» дип игълан итәләр, анда Россия дәүләте байрагын күтәрәләр. Шул рәвешле, «русский колос на глиняных ногах», ягъни «балчык аяклы алагаем урыс баһадиры» «җир читенең» аръягына да хуҗа булып ала. Алга таба Казагыстан, Урта Азия, Кавказ җирләрен буйсындырып, бөек Петр Беренче патша васыятьләрен үтәү йөзеннән, Һинд диңгезләренә кадәр барып чыгасы гына кала. Әмма һәр халыкта булган акыллы мәкаль-әйтемнең мәгънәсе бердер: сеңдерә алмаганны йотарга тырышма!

Россия империясе өчен дә Аляска әнә шундый «сеңдерә алмаслык» төбәк була. Бер очыннан икенче очына барып чыгарга атналар-айлар кирәк булган, озак еллар дәвамында яулап алынган галәмәт зур җирләрдә Россия империясенең нәтиҗәле идарә итә алмаслыгын, ниһаять, патша галиҗәнапләре дә аңлагандыр, күрәсең. Әле бит ул заманнарда самолетлары түгел, тимер юлы да юк чак! Россиянең «бүленмәс бердәм бөтенлеге» өчен бүгенге ялган коммуно-патриот шовинистлардан ким кайгыртмаган патша, шулай да, акыллы шәхес булган. Аляскаңың мәңге туң җирләрен саклап ятканчы, уңдырышлы туфраклы Идел-Дон буйларын югалтмыйм әле, дип уйлагандыр, мөгаен: Аляскаңы үзенчә бик һәйбәт бәягә — 7,2 млн долларга американнарга сатып та җибәргән.

Бу хәл-вакыйгалардан соң йөз егерме биш елдан артык вакыт үткәч кенә Россия Фәннәр Академиясе галимнәре галәмәт зур империя-дәүләтләрнең энергетик җегәре нинди мәйданнарда файдалы икәнлеген исәпләп чыгарганнар. Баксаң, андый җир-мәйданнарның зурлыгы 500 мең квадрат километрдан артмаска тиеш икән. Менә ни өчен Голландия, Дания, Швеция кебек кечкенә илләр тук-мул тормышта яшиләр булып чыга түгелме соң? Россиянең эчкечелеккә бирелеп,

эшләмәскә өйрәнгән халкы өчен бу империянең «сеңдерә алмаслык» байлыгы — патша заманында барыбер шул туймас тамак дәүләт түрәләре һәм, үз халкын да, башка халыкларны да куркытып-өркетеп, аларның җирләрен басып алырга һәрвакыт әзер торучы армия корсагына кереп барган түгелме? Бу очракта ике катлы кабыклы «акыллыбаш» ташбака турындагы бер хикәят искә төшә. Бу ташбаканың ике катлы кабыгына хәтта җәнлекләр патшасы арсланның да теше үтми, имеш, әмма ташбака, шул ике катлы кабыгын күтәреп йөртә алмыйча, үз авырлыгыннан сытылып җан тәслим кылган...

Никита Хрущев заманындагы «җепшетү» чоры да, түрәләр санын кимету һәм армияне кыскарту омтылышы булганы өчен, яңадан бозланып, торгынлык елларына әверелмәдемени? Михаил Горбачевның «үзгәртеп кору процессы»да, шул ук сәбәпләр аркасында тукталып калып, СССР дигән бөек державаның бер көн эчендә җимерелеп төшүенә китермәдемени? Аңлаганга аңларлык югыйсә. Идарәче түрәләр һәм армия-милиция бүгенге көндә ул — берничә башлы аждаһа кебек явыз нәрсә: бер башын киссәң, аның урынына икәү үсеп чыга тора.

Әгәр дә Россия әлеге империянең (өтек калган империянең!) һәр карыш җире өчен, үзе белән бер түбә астында яшәргә теләмәгән башка милләт халыкларын юк итә-итә, соңгы тамчы канына кадәр сугышырга тели икән, ул үз комсызлыгына үзе тончыгып һәлак булачак. Дәүләт Думасындагы шовинистик рухлы депутатлар Борис Ельцинны Чечнягә өстереп, хурлыклы сугыш башлатып, үзен йөрәк авыруына дучар иткән булсалар (ярый әле, коткарырга татар табибы Ренат Акчурин табылды!), илне исә күтәрәмгә калган хәерче хәленә төшерделәр. Хәзер инде аларга яңа «дошман» кирәк: «Севастополь — урыс диңгезчеләренең горурлыгы!» дигән сылтау белән Украинага каршы сугыш ачарга да җыеналар шикелле. Украина сиңа Чечня генә түгел, аны ялангач кул белән генә яулый алмаячаксың. Димәк, атом-төш коралы селтәп кенә куркытырга була, янәмәсе...

Бүгенге Россиянең исән-сау калырына бер генә мөмкинлек бар. Ул да булса, Кремль түрәләренә генә түгел, ә барлык урыс халкына күп гасырлар буе каннарына сеңгән империячел тәкәбберлектән котылу кирәк. Ил исән-сау калсын дигәндә, аның галәмәт зур җир биләмәләрен, Америка Кушма Штатлары үрнәгендә, аерым төбәкләргә бүлгәләү һәм аларга мөстәкыйльлек бирү хәҗәттер. Шул ук вакытта Кремль түрәләренә, янә дә Россияне коткарып калу хакына, шул түрәләрне һәм армия-милиция кебек көч структураларын туендырып торуга китә торган талау салымы сәясәтеннән дә арынырга кирәктер.

Әгәр дә Россия НАТО составына керсә, — ул шуңа омтылырга тиеш! — армияне кирәкле күләмдә генә калдырып кыскартырга да мөмкин. Шулай эшләгәндә Россия үзен басып торган күтәрә алмас авыр йөктән котылыр һәм кереп баткан төпсез сазлыктан калкып чыга алыр иде шикелле. НАТО — Россияне коткарып калырлык бердәнбер көч. Ә инде АКШның штатлары хокукын алган мөстәкыйль җирле төбәкләр, «артык кашык» түрәләрдән һәм кирәкмәс салым-чыгымнардан арынып, эшсезлеккә дә чик куяр һәм икътисади үсешкә — бай-мул тормышка да ирешер иде. Россия өчен шуннан да артыкны теләргә мөмкинме соң?

«Аляска... Куриль атаулары...» дип авыз суы корыту нигә кирәк, шовинист әфәнделәр? Их, сез...

**Локман ЗАКИР.**
Казан.

# Шагыйрь Рафаилга 50 яшь

«...Кайчан бездән Рафаэльләр чыгар?» — дип, сорау ташлаган иде гасыр башында Бабич, «шамаилләр генә чыккан» заманда, сәнгатебезнең киләчәге турында уйланып. Бу, әлбәттә, әдәбиятка да, шигырьгә дә карый иде: Шекспирлар, Пушкиннар биеклегенә омтылу, дөнья әдәбияты югарылыгына ирешү турында хыял... Әйе, халкыбыз бу чакыру-омтылышка колак салды булса кирәк: ул сынлы сәнгатебезгә Бакый Урманче кебек зур талантлы улларын бирә алды бу йөздә. Әдәбиятта да, төрле зур исемнәр белән бергә, Рафаэль исемлеләре дә пәйда булды: Рафаил Төхфәтуллин, Рафаэль Мостафин, Рафаэль Сибат. Рафил, Равил — шул ук бер Рафаэль исеменнән инде ул. Шулар янына соңгы елларда Рафаил (Газизов) дигән шагыйрь дә килеп кушылган иде. Менә аңа да 50 яшь тулган икән! Рафаил Шәкүр улы — Мамадыш районы егете: ул — гаҗәеп матур, үзенең йөзгә якын чишмәсе белән кешеләренә көч-гайрәт биргән Кече Кирмән авылыннан; шул ук авылда туып үскән әдип Ринат Мөхәммәдиевнең сабакташы; райондашы — шагыйрь Зиннур Мансуровның замандашы, ә шул җирлектән чыккан иң яшь әдип Марат Закирның өлкән агасы... Күп еллар укытучы, мәктәп директоры булып эшләгән Рафаил, әлбәттә, күпләр өчен ага-абый тиешле кеше. Әмма аның үзенең беренче иҗат тәҗрибәләрен күреп, аңа ярдәмгә килгән — аны авылына ук эзләп барган ил агасы бар, ул да — шул ук Мамадыштан юл башлаган Шәйхи ага Маннур... Әхмәт Гадел, Шаһинур Әхмәтсафа — дуслары.

Аннан — көндәлек матбугатта үсү, «Агымсу» әдәби берләшмәсендә кайнау, аралашу. Ул берләшмәгә шефлык итеп, үземә дә анда булу, утырышларда катнашу бәхете эләкте. Җитәкчеләре — бик уңган-тәвәккәл Чәчкә Туташ Хөснетдинова оештырган кичәләргә Зөлфәт белән дә, соңрак Рәшит Әхмәтҗан белән дә бардык, бик рухланып кайттык. Һәм Рафаил бу арада бик якын дус-каләмдәшкә әйләнгән иде инде. Аның беренче китабына кереш сүзне Зөлфәт язды («Җиләкле алан» исемле бу китап 1980 елда дөнья күрде. Аннан — «Бөре керфекләре» (1985), балалар өчен «Җиләкле алан» (1990), «Чөгендер хикмәтләре» (1990), «Хат» (1992) исемле лирика китаплары басылып чыкты).

1992 елдан алып ул — Язучылар берлеге әгъзасы. Менә шундый шагыйребез яши Кече Кирмәндә. Илдус Гыйләҗев, Гарифҗан Мөхәммәтшиннар кебек үк, әдәбиятка турыдан-туры җирдән, хезмәт һәм тормыштан килгән, шуңа да иҗатында тормышчан фәлсәфәле, табигатькә гашыйк һәм рәссам күзле, фикерле шагыйрь ул Рафаил. Хикәяләр дә яза ул, аларда да аның шагыйрьлеген, сүзләрдән ясалган оста сурәтен күреп була. Шулай, Рафаил яза, дәвам итә.

Ә Бабич язган, күрергә теләгән биеклек? Аңа ирешү — барыбызның да хыялы. Шунсыз иҗат буламыни? Әйе, чыгар әле ул бездән андый корифейлар — яңа Рафаэльләр дә, Рафаиллар да, Равилләр дә чыгар!

Милләт кенә исән-имин булсын, дусларым!

**Рәдиф ГАТАШ.**

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

# Гази Кашшаф

(ТУУЫНА 90 ЕЛ)

Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Гази Кашшаф 1907 елның 15 апрелендә элеккеге Уфа губернасы Бәләбәй өязе Яңа Арсланбәк авылында мулла гаиләсендә туа.

1920—1925 елларда ул Бәләбәй шәһәрендә укытучылар семинариясендә укый, аннары, Казанга килеп, Көнчыгыш педагогия институтына керә. Шуннан соң төрле урыннарда тел-әдәбият укыта.

1937 елда Г. Кашшаф китап нәшриятына эшкә күчә. 1942 елның октябрендә аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының баш редакторы итеп билгелиләр.

Г. Кашшаф бай әдәби-фәнни мирас калдырган әдип. Аның беренче тәнкыйть мәкаләләре 1928 елда, студент чагында ук басыла башлый. Утызынчы елларда инде ул аерым язучылар, аларның әсәрләре һәм театр постановкалары турында язган мәкалә-рецензияләре белән үзен әдәбият-сәнгать дөньясын нечкә аңлаган югары зәвыклы тәнкыйтьче итеп таныта. Бер үк вакытта ул прозада да үзенең көчен сынап карый — хикәяләр, повестьлар яза. 1940 елда аның берьюлы өч китабы — Ш. Камал турындагы монографиясе, «Каләм мастерлары» исемле тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы һәм чик сакчылары тормышыннан алып язылган «Чүл буенда» дигән повесте басылып чыга.

Илленче еллардан башлап, Г. Кашшаф үзенең калган бөтен гомерен, бай тәҗрибәсен һәм сәләтен татар халкының горурлыгы — герой-шагыйрь Муса Җәлилнең легендар тормышын һәм иҗатын тикшерүгә багышлый. Г. Кашшаф Муса Җәлилнең үз әсәрләрен халыкка җиткерү, популярлаштыру буенча да зур фидакарьлек күрсәтә. Ул «Моабит дәфтәре»нә иң беренче гыйльми комментарийлар яза, шагыйрьнең өч томлыгын (1955—1956), русча бер томлыгын (1962), фотоальбомын (1966) хәзерләп чыгара, М. Җәлил турында истәлекләрне җыеп, туплап бастыра (татарча басмасы — 1964; русча басмасы — 1966 елда). Әдипнең герой-шагыйрь турында язган мәкаләләре дистәләгән телләргә, шул җөмләдән чит ил телләренә дә тәрҗемә ителеп басыла. М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турындагы тикшеренүләре өчен 1976 елда (вафатыннан соң) Г. Кашшаф Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек була.

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — МИСЫРДА

23—26 февраль көннәрендә Президент М. Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Мисыр Гарәп Республикасында булды. Җөмһүриятебез Илбашы Мисыр Гарәп Республикасы Президенты Хөсни Мөбарәк һәм башка рәсми кешеләр белән очрашты. Ике ил арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне тагын да ныгыту-үстерү мәсьәләләре турында эшлекле сөйләшүләр булды.

## ПОЛЯК ДУСЛАР КАЗАНДА

11 мартта Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Казан Кремлендә Польша Хөкүмәте делегациясен кабул итте. Польша Премьер-министры урынбасары, Эчке эшләр һәм хакимият министры Лешек Миллер җитәкчелегендәге әлеге делегация Казанга «Польша хезмәттәшлеккә чакыра — Татарстан, 97» күргәзмәсен ачу тантанасына килгән иде.

## ХАЛЫКАРА КҮРГӘЗМӘДӘ

16 мартта Әбү-Дабида (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) «Айдекс — 97» халыкара күргәзмәсе ачылды. Шул уңайдан бирегә Татарстан Республикасы Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге делегация дә килгән иде. Җөмһүриятебез мондый күргәзмәдә беренче тапкыр мөстәкыйль рәвештә катнаша. Безнең экспозиция күпләгән чит ил җитәкчеләре игътибарын үзенә җәлеп итте. Килгән кунаклар һәм тамашачылар армия өчен дип чыгарылган «КамАЗ» машиналарына аеруча сокланууларын белдерделәр.

## ҮЗБӘКСТАНДА — ТАТАРСТАН ВӘКИЛЛЕГЕ

Билгеле булганча, Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев «Үзбәкстан Республикасында Татарстан Республикасының Даими вәкиллеген төзү турында» Указ чыгарган иде. 1997 елның 1 мартыннан Җөмһүриятебезнең Үзбәкстандагы Даими вәкиле итеп Өмидә Латыйп кызы Сабирова билгеләнде.

## КАЛӘМДӘШЛӘР ШОТЛАНДИЯГӘ ЖЫЕНА

Быел 5—11 август көннәрендә Шотландиянең Эдинбург шәһәрендә Халыкара ПЕН-клубта әгъза булып торучы язучыларның Бөтендөнья конгрессы үткәреләчәк. Аның эшендә катнашырга чакырып, Татарстан язучыларының ПЕН-үзәгенә дә рәсми чакыру килгән. Конгресска Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники һәм «Казан утлары» журналының баш мөхәррире — танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Равил Фәйзуллин барачак.

## МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ МӘНФӘГАТЕН КАЙГЫРТЫП

Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты бюросы үзенең күчмә утырышларын милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдә уздыруны матур бер гадәткә кертә бара. Ул быелның 28—29 август көннәрендә Казанда үтәчәк II Бөтендөнья Татар конгрессына хәзерлек максатыннан оештырыла. 1 мартта чираттагы утырыш Самара өлкәсенең Камышлы районында үткәрелде.

Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе — академик И. Таһиров җитәкләгән делегацияне Самара өлкәсе губернаторы урынбасары А. Жабин бик җылы каршылады. Аннары һәр ике делегация вәкилләре татар халкының тел, мәдәният һәм милли традицияләрен торгызу, киләчәктә милләтебез үсешен югарырак баскычларга күтәрү юллары турында иркенләп сөйләштеләр, конкрет эш планнарын килешүләр белән беркеттеләр. Соңыннан Татарстан сәнгать осталары Камышлы районы мәдәният сараенда, җирле артистлар белән берлектә, халыкка зур концерт күрсәттеләр.

## МӨХӘММӘДЪЯРГА БАГЫШЛАП

ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Фольклор үзәге (директоры — К. Хөснуллин) 13 мартта Кукмара районы үзәгендәге мәдәният йортында Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның 500 еллыгына багышланган семинар-конференция үткәрде. Аның эшендә районның мәдәният хезмәткәрләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәрләре Д. Рамазанова, Ф. Баязитова, С. Гыйләҗетдинов һәм Н. Исмәгыйл-Нәккаш тыңлаучыларны Мөхәммәдьярның тормышы һәм иҗаты белән таныштырдылар, күпсанлы сорауларга җаваплар бирделәр. Соңыннан фольклор коллективларының чыгышлары булды — арадан иң яхшылары, Мөхәммәдьярга багышлап, быел октябрь аенда Казанда узачак республика фольклор фестивале өчен сайлап алынды.

## МӘШҺҮР МӘГЪРИФӘТЧЕНЕ ОЛЫЛАУ

1 мартта Җөмһүриятебезнең Яшел Үзән (Зеленодол) районында зур тантана булып үтте. Күренекле галим-мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган авылы Кече Шырданда әлеге бөек шәхескә бронза бюст куелды. Ә Олы Ачасыр авылында Татарстан берләштерелгән Дәүләт музееның филиалы — К. Насыйри исемендәге архитектура һәм этнография музее ачылды. Әлеге чараларны оештыруда һәм үткәрүдә катнашкан район һәм шәһәр хакимияте башлыгы С. Коготин, Татарстан Президенты аппаратыннан бүлек мөдире И. Терентьева, ТР Мәдәният министры М. Таишев, Татарстан халык депутатлары Ф. Сафиуллин, Р. Вәлиев, филология фәннәре докторы Г. Саттаров, Яшел Үзән шәһәре мәчете имам-хатыйбы Габделхәмит хәзрәт, К. Насыйриның туганы Бәрра ханым һ. б. бөтен Шәрык дөньясына яхшы таныш булган олуг мәгърифәтченең кылган изге гамәлләрен һәрьяклап киң яктырттылар.

## БАКЫЙ УЛ — МӘҢГЕЛЕК ДИГӘН СҮЗ

Татарстан халкының бөек рәссамы һәм сынчысы Бакый ага Урманченың тууына 100 ел тулу уңаеннан, Татарстан Республикасында күп кенә мөһим чаралар тормышка ашырылды. Казанда ул яшәгән йортта мемориаль такта куелды, Г. Тукай музеенда шәхси күргәзмәсе ачылды. 27 февральдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Б. Урманче һәм милли мәдәният» дигән темага фәнни-гамәли конференция булып узды. 28 февральдә исә Татарстан Рәссамнәр берлеге урнашкан бина каршындагы бакчада — Зур Кызыл урамында — мәшһүр остага һәйкәл ачу тантанасы булды (аны Үзбәкстанда яшәүче шәкерте Мәхмүт Гасыймов иҗат иткән). Шул ук көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Б. Урманчены искә алу кичәсе үткәрелде.

* * *

Түбән Кама шәһәре музеенда исә Б. Урманче әсәрләреннән торган күргәзмә ачылды. Шул ук көнне халык иҗаты йортында, Бакый агага багышлап, «Җидегән чишмә» кичәсе үткәрелде. Анда мәшһүр останың хатыны Ф. Әхмәтова, Башкортостанның һәм Татарстанның халык җырчысы Ф. Кудашева, ТР халык язучысы Ә. Еники, рәссамнәрдән Х. Нәфыйков, З. Басыйров, артистлардан Ш. Монасыйпов, К. Хәйретдинова, Л. Маслова һ. б. катнашты һәм чыгыш ясады.

Б. Урманченың якты истәлеген, кылган изге эшләрен мәңгеләштерү йөзеннән, Түбән Каманың 2 нче татар гимназиясенә аның исеме бирелде. Шәһәрдә атаклы рәссам-сынчы исемен йөртүче урамга быел Бакый аганың һәйкәле дә куелачак. Бу гамәлләрне тормышка ашыруда шәһәр һәм район хакимияте башлыгы Ә. Галиәхмәтов, Түбән Камадагы Татар иҗтимагый үзәге рәисе А. Зыятдинов нәтиҗәле эшчәнлек күрсәттеләр.

*ТАТАРСТАН*
*ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ*

## ЯШЬ ТАЛАНТЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

5 мартта Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында яшь һәм башлап язучыларның республика конференциясе булды. Анда Җөмһүриятебезнең төрле районнарыннан һәм Казандагы югары уку йортларыннан килгән иҗаты укучы һәм студент катнашты.

Конференцияне ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачты һәм алып барды. Яшь талантларны күренекле шагыйрьләрдән — Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов, Дәүләт Советының милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе рәисе Р. Миңнуллин котладылар, иҗат уңышлары теләделәр. Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты — шагыйрь һәм драматург Р. Мингалимов, танылган шагыйрә, күп кенә популяр җырлар авторы Р. Вәлиева, чирек гасыр гомерен «Ялкын» журналына багышлаган язучы-мөхәррир Р. Хафизова, аның дәвамчысы Э. Закирова, «Салават күпере», «Идел» журналларының баш мөхәррирләре З. Хөснияр, Ф. Зөлкарнәй һ. б. яшь каләмнәргә файдалы киңәшләрен ирештерделәр.

Аннары яшь иҗатчылар Татарстанның халык язучылары Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, А. Алиш исемендәге бүләк лауреаты Л. Ихсанова, Татарстанның халык шагыйрьләре Ш. Галиев, И. Юзеев, күренекле шагыйрь, прозаик һәм драматург Ә. Баянов, танылган балалар шагыйре Х. Халиков, яшьрәк буын шагыйрьләрдән Р. Гаташ, Л. Шагыйрьҗан, Р. Рахман һ. б. житәкләгән секцияләрдә эшләделәр. Биредә аларның язмалары җентекләп тикшерелде, иң яхшылары матбугатка һәм күмәк җыентыкка тәкъдим ителде.

Кичен Тукай клубында яшь иҗатчылар катнашында әдәби кичә булды.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Фаил Зыязовның «Кояшлы иртә» картинасыннан фотокүчермә.

# БАРЧАГЫЗ ДА — «КАЗАН УТЛАРЫ» ЯКТЫСЫНА!

Мөхтәрәм милләттәшләр, журналыбызның якын дуслары!

Билгеле булганча, ошбу елның 1 апреленнән 1997 елның икенче яртысы (июль, август, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь айлары) өчен газета-журналларга язылу башланды. Бу чара Татарстанда — 15 июньгәчә, Җөмһүриятебездән читтә 1 июньгәчә дәвам итәчәк.

Халкыбызның 75 еллык бай тарихлы журналы — «Казан утлары» — Сезне яңадан үз яктысына чакыра. Күпьеллык эчкерсез дуслыгыбыз элеккечә матур дәвам итсен — киләчәктә дә бергә булыйк!

**Журналыбызга язылу бәясе,** башка кайбер басмалар белән чагыштырганда шактый арзан — **ярты елга нибары 15 мең сум**. Элемтә бүлекләрендә әбүнә тартмалары (абоняшиклары) булган укучыларыбыз өчен безнең басманы алдыру хакы тагын да арзанрак булачак.

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
"Союзпечать"

**АБОНЕМЕНТ на** газету / журнал — 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания) — Количество комплектов:

на 1997 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

на газету / журнал — 73210 (индекс издания)

(наименование издания) „Казан утлары"

| Стоимость | подписки | ______ руб. ___ коп. | Кол-во комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб. ___ коп. | |

на 1997 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

# БҮЛӘККӘ — ЖУРНАЛ!

Алдагы еллар тәҗрибәсен һәм күпсанлы укучыларыбызның теләкләрен искә алып, журналыбызга язылуны җиңеләйтү максатыннан, бу санда 1997 елның икенче яртысы өчен хәзерләнгән әбүнә кәгазе (абонемент үрнәген) тәкъдим итәбез. «Казан утлары»н июль-декабрь айларында алдырырга теләгән һәр кешенең, шушы квитанциягә үзенең тулы адресын, исем-фамилиясен, язылырга теләгән айларын күрсәтеп (билге ясап), аны үзе яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшыруы сорала. **Онытмагыз: индексыбыз — 73210.**

Мөмкинлектән файдаланып, урыннардагы хакимият башлыкларына, предприятие-учреждение хуҗаларына, авыл хуҗалыгы, мәгариф, мәдәният һ. б. өлкәләрдә эшләүче җитәкчеләргә мөрәҗәгать итәбез: «Казан утлары» журналы — алдынгыларны хөрмәтләү өчен иң яхшы бүләк ул!

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

---

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки "ПВ-МЕСТО" производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Татарское отделение "Росбланкиздат", 1/24/112/, 02.95 г. т. 350000

Асбест. тип. 3. 641.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Әхмәт РӘШИТОВ. **Таң илчесе.** *Шигырьләр, җырлар, поэмалар.*— Казан: Тат. кит. нәшр., 1996.— 288 бит.




Укучыларыбызга яхшы таныш булган шагыйрь Әхмәт Рәшитнең 60 яшь уңаеннан чыгарылган бу сайланма китабы аның элекке нәшер ителгән җыентыкларыннан үзенең күләме белән дә, тема-эчтәлек ягыннан да уңай бәяләнергә лаек. «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан бу китапка авторның иң яхшы лирик-фәлсәфи шигырьләре, популяр җырлары, мәгълүм поэмалары тупланган. Ун бүлектән торган шигырь цикллары шагыйрьнең диапазонын һәм үсеш эволюциясен анык күз алдына китерә. Китапның ахырында поэтик аккорд рәвешендә Әхмәт Рәшитнең киң катлам укучыларга билгеле булган «Сөембикә», «Колшәриф» исемле тарихи поэмалары урын алган. Китап шагыйрьнең «Шигырьләремнән танырсыз...» дигән кереш сүз белән ачыла. Үзенчә бер ихласлыгы булган шагыйрьнең ул башламда мондый сүзләре бар: «Гомумән, бөтен үткән гомерем шигырьләремдә чагылыш тапкан бугай. Шагыйрь өчен шигырь дөнья белән, кешеләр белән, заман белән бердәнбер аңлашу чарасы бит ул. Ә шигырьдә алдашып булмый.

Бай тормыш тәҗрибәм, төрле-төрле чыганаклардан бөртекләп җыйнаган белемем, гел үзгәреп торган дөньядагы вәзгыятьне тарих бизмәне, намус бизмәне белән үлчи алу һәм бәя бирү сәләте миңа бүгенге әзерлекле һәм таләпчән укучы белән рияланмыйча ачыктан-ачык сөйләшү хокукы бирә.»

Китапта, шулай ук, шагыйрь иҗаты турында тәфсилле библиография дә бирелгән.

Индекс 73210



Шагыйрь Рафаил Газизов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЫ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)